# Казан утлары



3

МАРТ

1967

Журналыбызның бу саны татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовка багышлана.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**3**

МАРТ
1967


## Бу санда:

### Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ


Г. Ибраһимов турында галимнәр һәм әдипләр . . 3
М. Хәсәнов. Г. Ибраһимов һәм татар әдәбиятында социалистик реализм формалашуының кайбер мәсьәләләре . . . . . . . . . . 6
О. Кадыйров. Романтизмнан реализмга . . . 15
Ә. Баянов. Яшьлегемне эзлим. Лирик повесть . 18
Г. Хуҗиев. Шигырьләр . . . . . . . . . 54
Р. Фәизов. Гафур. Хикәя . . . . . . . . . 60


### 8 МАРТ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ


Л. Ихсанова. Мин әле бу. Хикәя . . . . . . 62
С. Сөләйманова. Көз; Серләремне сиңа сөйлим. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 67
М. Фәйзуллина. Тапшырылмаган хатлар. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Г. Зәйнашева. Үз илемдә; Ник чәчәгең сары; Тәрәз төбемдә. Шигырь . . . . . . . . . 69
С. Гәрәева. Әй, бер заман; Юлларга чыгам; Ул көнче; Карлы юллар; Кайтып килэм; Син еракта. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 70


### Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ


Безнең анкета . . . . . . . . . . . . . . 72
Г. Бәширов. Әдәбиятыбызның аксакалы . . . 72
М. Әмир. Гүзәл тойгылар уятучы әдип . . . . 75
Ф. Хөсни. Баскычлы юл юк . . . . . . . . 77
Г. Минский. Бай мәктәп . . . . . . . . . 79
А. Расих. Килер буыннарга да остаз ул . . . 81
С. Рафиков. Беренче йолдызлар . . . . . . 82
Н. Фәттах. Мондый кешеләр сирәк туа . . . 84



КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Ж. Молдагалиев. Татарстан турында шигырьләр . . . 85
Х. Бекхожин. Жырчыга . . . 88

И. Салахов. Шигырьләр . . . 89

ВЬЕТНАМ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Чанг Хыу Тхунг. Бишек жыры . . . 91
Нгуен Дин Тхи. Дөге . . . 92
То Хыу. Кешелек язы . . . 93
Мин Ле. Үлем килсә әгәр . . . 93

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

К. Фасеев. Бөек Октябрь һәм интернациональ культура . . . 94
Г. Әдһәмова. Киң дала — чал тарихның шаһите . . . 103

И. Юзеев. Кайбер уйланулар . . . 106

КОНКУРСКА КИЛГӘН МАТЕРИАЛЛАР

С. Шәкуров. Ана. Драма . . . 110

Г. Сафиуллин. Днепрны кичү . . . 120

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г. Шәрипова. Көндәлек битләреннән . . . 129
З. Кәримова. Ул безнең якын дустыбыз иде . 132
Әдипнең телеграммалары, яңа хатлары . . . 142

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Р. Гәрәй. Жырлап үтик еллар аркылы . . . 146

Г. Бакиров. Жимерелгән бастион . . . 148

ШАГЫЙРЬНЕҢ КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

Ә. Ерикәй. Шигырьләр . . . 150
Ш. Галиев. Шигъри рецензияләр . . . 152

Журналга язылу уңышлы үтте . . . 153

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . 156

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянен адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: жаваплы редактор — 2-68-21, жаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары»*

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА ГАЛИМНӘР ҺӘМ ӘДИПЛӘР

Галимҗан Ибраһимов 1907 елда әдәбият мәйданына чыкты. 1927 елдан соңгы ун елга якын иҗат гомерендә, каты авыру сәбәпле, күп эшли алмады. Татар әдәбиятының алтын фондын тәшкил иткән олы сәнгать әсәрләре, нигездә, 1907—1927 еллар арасында язылган.

Талантлы язучы булу белән бергә, ул күренекле тарихчы да, философ та, тел һәм әдәбият галиме, сәнгать белгече дә, ялкынлы публицист, җәмәгать эшлеклесе, оста оештыручы да иде.

Әдипнең матур әдәбият һәм тарих буенча язган хезмәтләре 1920 елларның башыннан ук рус теленә, ә әдәби әсәрләре СССР халыклары телләренә киң рәвештә тәрҗемә ителә башлый.

30 еллар башында, аерым басмалар булып, роман, хикәяләре әзербәйҗан, үзбәк, казакъ, төркмән, уйгур телләрендә чыкты. Соңгы елларда әдипнең әдәби әсәрләре яңадан казакъ, үзбәк телләрендә, ә 1966 елда «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» романнары, аерым җыентык булып, кыргыз телендә, 1962 елда «Хикәяләр» җыентыгы башкорт телендә басылды.

Илебезнең төрки халыкларына әдипнең иҗаты оригинал аша да билгеле. Шунсы кызык, гарәп алфавиты нигезендә язган вакытта, әдипнең әсәрләре төрки халыклар теленә тәрҗемә ителмәделәр. Казакъ, үзбәк, әзербәйҗан, башкорт, төркмән, кара-калпак, кыргыз укучылары аның әсәрләрен оригинал буенча укып килделәр.

Күп кенә казакъ, төркмән, башкорт, әзербәйҗан язучылары Галимҗан Ибраһимовны үзләренең остазы итеп саныйлар, әдипнең әсәрләренең үз халыклары укучылары тарафыннан яратып укылуын, хәтта үз әдибе булып хисаплануын күрсәтеп үтәләр.

Әдипнең әсәрләре, үзе исән вакытта ук инде, чит ил укучыларына да юл таптан. 1928 елда «Адәмнәр», «Карт ялчы» хикәяләре, «Безнең көннәр» романы, һәрберсе аерым басма булып, төрек телендә чыккан.

Уйгур, таҗик, әзербәйҗан телләрендәге басмалары аркылы Ибраһимов әсәрләре Һиндстанга, Пакистанга, Иранга да барып җиткән. Рус телендәге тәрҗемәләр аша, әдипнең әсәрләре башка ил халыкларына да таныш.

Әдипнең бай иҗаты, тормышы һәм эшчәнлеге замандашларын сокландырган. Әдипнең хезмәтләренә рус галимнәре, илебезнең күренекле каләм осталары үзе исән вакытта ук зур бәя биргәннәр, әдипне хәзер дә зур ихтирам, хөрмәт белән искә алалар.

Биредә без аларның истәлекләреннән, әдип турында язган мәкаләләреннән өзекләр китерәбез. Материалларны Ә. Кәримуллин әзерләде.

* * *

Моннан егерме ел элек мин Кави Нәҗминең шушы гасыр башы классик шагыйре — царизм золымы астында иҗат иткән Габдулла Тукай турында сөйләгәнен тыңладым. Ул шагыйрь үзенең бер шигырендә әйтә:

Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары;
Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.
...Ул — түгел күңелем эшеннән, тик ялан кулның эше;
Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылып чүпләрем.

Әнә шундый кырыс башлангыч, Тукай һәм Мәҗит Гафури поэзиясе, Галимҗан Ибраһимовның типографиядә конфисковать ителгән романнары Татарстан республикасы совет язучыларына юл әзерләде. Күренә ки, Горький аларга ташламалар ясамаган, һәм бу очракта өлкән туган киңәшләре, күпне күргән һәм иҗат өчен авыр шартларны — Тукай һәм Ибраһимов кичергән шартларны үзе татыган һәм үзе ул шартларга каршы көрәшкән рус язучысының киңәшләре, милли әдәбият үсешенә никадәр зур этәргеч була.

Луи АРАГОН.

...Галимҗан Ибраһимовка бик күп төрле эшләр башкарырга, төрле мәшәкатьләр чигәргә туры килде; һәм ул барысына да өлгерә иде, һәрвакыт шат, актив, ихтыярлы, дәртле була иде һәм башкаларны да рухландыра да, дәртләндерә дә белә иде. Патриот-революционер туган республикасының уңышлары өчен чын күңелдән шатлана иде.

Академик Үзәк председателе буларак, Г. Ибраһимов үзенең гаҗәп тырышлыгы белән шаккатыра иде. Әллә никадәр учреждение[ләр] аның инициативасы белән булдырылды, әллә никадәр басмалар аның катнашы белән чыгарылды.

И. Н. БОРОЗДИН, профессор.

Галимҗан Ибраһимов иҗатының җәлеб итү көче — аның күпкырлы булуында. Ул — әһәмияте үз иле чикләреннән еракка китә торган художникларның берсе. Дөньядагы иң яхшы шагыйрьләр рәтенә горур атлап басарлык кеше ул... Ул күпкырлы иҗатының төрле яклары белән безне үзенә тарта. Аның әсәрләре безнең күңелне, барыннан да элек, үзләренең гадилеге һәм реаль булуы белән әсир итә. Ул яхшы мәгънәсендә тормыш-көнкүреш язучысы. Халыкның үзенчәлекле тормышын, көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен ул көнчыгыш буяуларының барлык чуарлыгы белән балкып торырлык дәрәҗәдә киң полотнолы итеп сурәтләп бирә белә... Ибраһимовның кыйммәте аның зур масштаблы художник булуында гына түгел. Татар җәмәгатьчелегенең горурлыгы булган, тормышның яңа формалары өчен көрәшкән данлыклы көрәшчеләрнең дә берсе ул. Ул безгә шуның өчен якын, чөнки ул, рус интеллигенциясенең иң әйбәт вәкилләре кебек үк, күкрәк киереп реакциягә, искелеккә, көчләүгә һәм дини хорафатларга каршы торган. Ул Радищевтан алып Чернышевскийга һәм Горькийга кадәр чорда әдәбиятыбызда бик күп булган мәгърифәтчеләр, яктылык һәм ирек рыцарьлары тибына керә...

П. КОГАН, профессор.

Ибраһимов Галимҗан... В. И. Ленин әсәрләрен татарча тәрҗемә итүне оештыручы, революцион хәрәкәт тарихы, атеизм, әдәбият һәм сәнгать теориясе буенча хезмәтләр авторы. Октябрь революциясенә кадәрге әсәрләрендә Ибраһимов сәнгатьнең бурычы социаль прогресс һәм халык иреге өчен хезмәт итү дип санады, дини томаналыкка каршы чыкты, фән үсешен, рус культурасын үзләштерүне яклады, милләтчелекне, пантюркизмны һәм панисламизмны хөкем итте. Октябрь революциясеннән соңгы хезмәтләрендә Ибраһимов диалектик һәм тарихи материализмның төп положенияләрен пропагандалады, дини ышануларны юкка чыгару өчен көрәште. Ул, социалистик культураның үзенчәлеге итеп, политиканың, хәрәкәтнең, философиянең, бөтен пролетариат идеологиясенең нигез ташлары булган көрәш динамикасын, сыйнфыйлыкны, коллективизмны, хезмәтне һәм интернационализмны санады (Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960 ел, 177 бит). Ибраһимов татар культурасында интернациональлек белән миллилекнең гармоник кушылуын алга сөрде, сәнгать эшлеклеләрен «буржуаз һәм вак буржуаз чүп-чардан арынырга... пролетариат идеологиясенә үтеп керергә, эшче-крестьян массалары арасына ташланырга һәм шул диңгездән әдәби энҗеләрне җыярга» чакырды.

Философик энциклопедия. II нче том.
Мәскәү. 1962 ел. 193 бит.

Г. Ибраһимов иҗаты татар әдәбиятында да, тугандаш халыклар — әйтик, башкорт, казакъ һәм төркмән — әдәбиятларында да реалистик прозаның алга китүенә уңай йогынты ясады... Әле хәзер дә, иҗат ителүенә ярты гасыр диярлек вакыт узганнан соң да, бу зур һәм катлаулы әсәр («Безнең көннәр») бик җиңел һәм кызыксынып укыла. Г. Ибраһимовның художестволы сурәтләү көче шундый — ул бер-ике абзацта да укучылар күз алдында кабатланмас төгәл образ иҗат итә яисә үз героеның мөһим һәм катлаулы психологик сызыгын ачып бирә ала.

Л. КЛИМОВИЧ, профессор.

Турыдан-турымы яисә читләтепме, Галимҗан Ибраһимов 20 ел буена эшчәнлегенең һәр тармагында, нигездә, татар халкына хезмәт итте; аның бу күпкырлы эшчәнлеге һәм Татарстанны, һәм татар халкын төрле яктан үсәнүгә бик нык ярдәм итте. Шулай итеп, бүген безнең юбилярны татар көнкүрешен, татар культурасын, татар әдәбиятын, татар телен бик яхшы белүче буларак... котларга тулы хакыбыз бар.

А. САМОЙЛОВИЧ, профессор.

Зур язучы үз халкының гына түгел, бәлки башка милләт кешеләренең дә йөрәкләрен буйсындыра. Менә шуңа күрә Галимҗан Ибраһимовны казакълар үз язучылары, казакъ язучысы, итеп исәплиләр... Безнең халык тормышын шулай яратып язганы өчен, казакълар Ибраһимовка һәрвакыт хөрмәт белән карарлар (Сүз «Казакъ кызы» романы турында бара)... Гаҗәеп әйбәт кеше һәм язучы Галимҗан Ибраһимов исеме безнең күп милләтле социалистик культурабыз тарихына мәңгелеккә керде.

Сабит МУКАНОВ,
казакъ язучысы, академик.

Сулар ага, ә кыялар какшамас булып торалар. Аларга вакытның да көче җитми. Үз эшләренең көче һәм рухы белән мәгърур кыялардай күтәрелгән кешеләр дә шулай. Аларның исемнәрен вакыт та, очраклы хәлләр дә кешеләрнең ихтирамлы хәтереннән тартып ала алмый. Татар әдәбияты классигы, әдәбиятның зур һәм катлаулы юлында минем беренче остазым Галимҗан Ибраһимов та әнә шундыйларның берсе...

Аның әсәрләрендә барлык социалистик милли әдәбиятлар нигезләнгән принципиаль яңалык бар иде һәм бу яңалык минем өчен, башка язучыларга караганда, аңлаешлырак һәм көчлерәк яңгырады. Һәм мин Ибраһимовның бер генә әсәрен дә укымыйча калмадым. Аның һәр сәхифәсе минем өчен ачыштай була иде.

Берди КЕРБАБАЕВ,
төркмән язучысы.

Зур татар прозаигы, романист Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре 1925—30 елларда аеруча еш (әзербайҗан теленә — Ә. К.) тәрҗемә ителә иде. Аның хикәяләре, повестьлары һәм романнары республикабыздагы киң катлау укучылар арасында зур уңыш казанды. Күпләр хәтта аны әзербайҗан язучысы дип санадылар.

Яшьлек елларымда, беренче хикәяләремне яза башлаган вакытта, мин соклану белән Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен кат-кат укый идем. Безнең буынның башка вәкилләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Бу зур язучының фаҗигале үлеме безнең йөрәкләрне тетрәтте. Ниһаять, ул арабызга кире кайтты, һәм без аның гүзәл әсәрләрен яңадан популярлаштыра алабыз.

Мәһди ХӨСӘЕНОВ,
әзербайҗан язучысы.

*Мансур Хәсәнов*

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА СОЦИАЛИСТИК РЕАЛИЗМ ФОРМАЛАШУЫНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Совет әдәбиятында социалистик реализмның формалашуын һәм үсүен тикшерүдә әдәбият фәне соңгы елларда зур уңышларга иреште. Бу өлкәдә милли әдәбиятлар туплаган бай тәҗрибә дә шулай ук кызу өйрәнелә, фәнни гомумиләштерелә башлады. Алда Бөек Октябрьның 50 еллыгы. Әдәбият галимнәре Совет властеның ярты гасырлык юбилеен зур гыйльми хезмәтләр белән, СССР халыкларының Октябрь кояшы астында үткән әдәби үсеш юлын фәнни-теоретик гомумиләштерү, В. И. Ленин идеяләренең һәм коммунистлар партиясенең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге политикасының тантанасын мөмкин кадәр тулырак күрсәтү белән каршылыйлар. Бу табигый дә, чөнки Октябрьның сүз сәнгате үсеше өлкәсендәге иң зур җимешләреннән берсе — милли әдәбиятларның социалистик реализм әдәбияты булып үсеп җитүләре, күп милләтле әдәби хәрәкәтнең аерылгысыз өлешенә әверелүләре. Шуның белән бергә СССР халыклары әдәбиятларының ярты гасыр эчендә туплаган бай әдәби-эстетик тәҗрибәсен өйрәнү әдәбият теориясе һәм эстетика өлкәсендәге төрле буржуаз бозуларга һәм уйдырмаларга, совет язучыларының иҗат методын декрет белән кертелгән, әдәбият һәм сәнгатькә көчләп тагылган догма, дигән һәртөрле яла ягуларга лаеклы отпор булачак, социалистик реализмның һәр милли әдәбиятның совет чорындагы эчке үсеше нәтиҗәсендә ирешелгән югары этабы, социалистик милләтләрнең әдәби-эстетик казанышы икәнлеген раслаячак.

Татар совет әдәбиятының ярты гасырлык бай тарихын фәнни өйрәнү өлкәсендә әдәбият белгечләре зур эш башкардылар. Соңгы елларда гына да укучылар кулына «Татар совет әдәбияты тарихы»ның татарча һәм русча басмалары, әдәбият үсешенең аерым этапларын тикшергән бай хезмәтләр, күренекле язучыларның иҗатларына багышланган җитди монографияләр бирелде. Аларда милли әдәбиятның, аның аерым жанрларының һәм күренекле вәкилләренең, сүз сәнгате алдына Бөек Октябрь куйган зур бурычларны уңышлы хәл итә барып, совет әдәбияты булып формалашу процессы тулы күрсәтелә. Ләкин шулай да татар совет әдәбиятының илле ел эчендә туплаган бай иҗат практикасы тулысынча өйрәнелде, эстетик яктан анализланды, тиешле фәнни нәтиҗәләр ясалды, дию иртә булыр иде. Безнең карашка, әдәби хәрәкәтне социалистик реализм иҗат принцибының формалашуын ачып бирү ноктасыннан тикшерү, бигрәк тә татар әдәбиятының күренекле вәкилләренең үз иҗатларында социалистик реализмга үсеп җитү юлын күрсәтү әле һаман да актуаль бурычларның берсе булып кала.

Татар әдәбиятында социалистик реализмны үстерү өчен гаять күп көч куйган, бу өлкәдә, үзенең әдәби әсәрләре белән генә түгел, теоретик хезмәтләре һәм оештыру эшчәнлеге белән дә аеруча роль уйнаган язучы, әлбәттә, Г. Ибраһимов булды. Шуңа күрә әдәбият белгечләре соңгы елларда аның иҗатын өйрәнүгә, бигрәк тә әдипнең совет чорындагы идея-эстетик эволюциясен тикшерүгә зур игътибар бирделәр. Бу эшкә галимнәрдән аеруча Г. Халит, Р. Бикмөхәмматов кыйммәтле өлеш керттеләр.

Г. Ибраһимов иҗатына багышланган фәнни тикшеренүләр шуны күрсәтә: Октябрь революциясе рухи дөньяны, әдәбият һәм сәнгатьнең үзенчәлекле сыйфатларын кинәт, бер селтәнү белән үзгәртмәгән шикелле, табигый, әдипнең социалистик реализмга үсеп җитүе дә кинәт кенә булмады. Чөнки язучының дөньяга карашларында революцион борылыш нәтиҗәсендә барлыкка килгән зур идея-политик үзгәрешләрнең иҗат принциплары, чынбарлыкка художниклык карашы аркылы чагылуы, гәүдәләнүе зарурый иде.

Рус, украин, әрмән, әзербәйҗан, грузин әдәбиятлары шикелле үк, татар әдәбияты да үзенең үсешендә Октябрьга кадәр критик реализм стадиясен үтеп өлгергән иде. Монда, әлбәттә, алдынгы рус әдәбиятының йогынтысы, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Камал һәм М. Фәйзи әсәрләре белән бергә, Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге иҗат практикасы, әдәби-тәнкыйть эшчәнлеге зур роль уйнады. Ул инде революция алды елларында ук критик реализмның күренекле вәкиле булып житешкән, татар прозасын идея-тематик яктан баетуга, аның әдәби-эстетик куәтен арттыруга зур өлеш керткән әдип иде. Ә 1914—16 еллардагы әдәби-тәнкыйть эшчәнлеге белән Г. Ибраһимов татар тәнкыйтен һәм эстетикасын революциягә кадәрге иң югары дәрәҗәсенә — революцион-демократлык этабына күтәрде. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов 1917 елга инде үзенең әдәби иҗат үсеше белән пролетариат әдәбияты алдына килеп җиткән, аның идея-эстетик эволюциясе киләчәктә бары тик социалистик реализмга таба гына мөмкин иде. Кыскасы, Г. Ибраһимовны революциягә иҗтимагый-политик карашлары үсеше генә түгел, әдәби-иҗат практикасы да китереп җиткерде. Февраль революциясе булгач та, аның, һичбер икеләнүсез, язучылык каләмен бер якка куеп торып, тулысынча революцион көрәш эченә чумуы да нәкъ әнә шуның белән аңлатыла.

Бөек Октябрь социалистик революциясе Г. Ибраһимовның идея-политик үсешендә генә түгел, художник буларак чынбарлыкка мөнәсәбәтендә, әдәби-эстетик принципларында да зур үзгәрешләр тудырды. Аның «Мин үземнең әдәби иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алулары тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына мөмкин булды дип табам», дигән сүзләреннән нәкъ әнә шуны аңларга кирәк тә. Монда хәлиткеч рольне Г. Ибраһимовның революционер булуы, зур идея-политик үсеш мәктәбе үтүе уйнады.

Күренекле рус совет язучысы А. Фадеев: «Мин язучы булганчы башта революционер булып житештем. Кулыма каләм алганда мин инанган большевик идем инде. Әнә шуңа күрә дә минем иҗатым революцион рух белән сугарылган», — дип язган иде. Бу сүзләрне тулысы белән Г. Ибраһимовка карата да әйтергә мөмкин.

Октябрьдан соң иҗат эшенә керешкәнче үк әле Ибраһимов революциянең асылын һәм китерәчәк нәтиҗәләрен, социалистик төзелеш өлкәсендә сәнгать работниклары алдында торган бурычларны, яңа тормыш төзүдә әдәбиятның ролен тирән аңлаган иде. Революциядән соң әдәбиятның характеры, роле үзгәрүе турында 1920 елда ул болай дип яза:

«...элекке икътисади мөнәсәбәтләр әдәбиятны, сәнаигы нәфисәне милек, милли, дини, ватани дошманлык рухында сугаралар, шуңа хезмәт кыйлдыралар иде; капитализм гыйлемдә, фәлсәфәдә, сәнаигы нәфисәдә үзен аклый, үзенә юл ача торган идеология эшли иде. Тарихның хәзерге бөек кузгалышлар дәвере исә, үзенең кызыл каһарманнары, сугышчан егетләре белән бергә, икътисади азатлык әмәлләрен җырлаучы шагыйрьләр, җир йөзен яңа, якты, ирекле тормышка чакыручы әдипләр, философлар, гыйлемне, фәнне яңа әмәлләргә тәтбикъ кыйлучы галимнәр, техниклар тудырды» [1].

Революция нәтиҗәсендә тукталып торган иҗат эшен яңадан башлап җибәргәндә, Г. Ибраһимов җәмгыять үсешенең фәнни теориясе — марксизм-ленинизм белән нык коралланган иде. Бу аның иҗат эволюциясенә киң юл ачты, әдәбият үсешенең тагын да югарырак этабы — социалистик реализмга күчешен шактый җиңеләйтте. Фәнни социализм теориясен өйрәнү эшенә Г. Ибраһимов алга таба да зур игътибар бирде, үзенең бай революцион көрәш тәҗрибәсен марксизм-ленинизмның якты нуры белән баетты. Татар әдәбиятында социалистик реализмның нигез ташларын салган әсәрләрен — «Кызыл чәчәкләр хикәясе»н (1922), «Казакъ кызы» (1924) һәм «Тирән тамырлар» (1926) романнарын иҗат иткән елларда әдипнең татар коммунистлар университетында, Өлкә партия мәктәбендә партия тарихын, әдәбият теориясен укытуы беренче карашта аның хезмәт биографиясен билгели торган гади фактлар гына кебек. Ләкин, асылда, алар язучының иҗат үсеше өчен принципиаль әһәмияткә ия иделәр. Г. Ибраһимовның әдәби үсеше өчен шулай ук аның 1922 елга кадәр РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Төрки халыклар үзәк бюросының матбугат бүлеге редакция коллегиясе җитәкчесе, партиянең Татарстан Өлкә Комитеты каршында төзелгән В. И. Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү комиссиясе председателе булып эшләвенең зур әһәмияте булуын күрсәтеп үтәргә кирәк. Аның марксизм-ленинизм өлкәсендәге эрудициясе турында ул вакытта партиянең Татарстан Өлкә Комитетының матбугат бүлеге мөдире булып эшләгән, хәзер персональ пенсионер Л. Гомәр менә нәрсә яза:

«Бу комиссиядә Г. Ибраһимов бик зур дәрт белән эшләде. Монда уңышлы рәвештә эшләү өчен Ленин әсәрләренең эчтәлеген яхшы белергә кирәк иде. Галимҗан ага аларны үз вакытында басылып чыккан берен укып барган булса кирәк, аларны яхшы белә, Ленинның кайсы әсәрләрендә нинди мәсьәләләр турында нинди фикер әйтелгәнен дә хәтерли иде. Менә шуңа күрә ул комиссиянең лаекле председателе булды» [2].

Г. Ибраһимов иҗатында социалистик реализмның формалашуы һәм үсүе ничек барды соң? Бу сорауга төпле җавап бирү әдипнең идея-эстетик эволюциясен билгеләү өчен генә түгел, татар совет әдәбиятының формалашуын өйрәнү өчен дә әһәмиятле. Чөнки Г. Ибраһимовның социалистик реализмга үсүе — асылда, татар совет прозасының формалашуы дигән сүз.

---

[1] «Эшче» газетасы, 1920 ел, 7 ноябрь.
[2] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Казан, 1966. 189 бит.

Г. Ибраһимов иҗатын тикшерүчеләрнең бердәм фикеренчә, әдипнең бу өлкәдәге беренче әһәмиятле адымы — «Яңа кешеләр» драмасы белән «Кызыл чәчәкләр хикәясе» иде. Язучының критик реализмнан социалистик реализмга таба ныклы борылыш ясавы, барыннан да бигрәк, аның чынбарлыкка художниклык карашы үзгәрүендә, бу әсәрләрнең тематикасында һәм проблематикасында, аларда сурәтләнгән тормыш материалының яңалыгында чагылды.

Г. Ибраһимовның тормышка мөнәсәбәте нинди юнәлештә үзгәрүе социалистик реализм иҗат методының үзәк мәсьәләсе булган уңай герой проблемасының гәүдәләнешендә күренде. Бу әсәрләр татар әдәбиятына бөтенләй яңа тема (пролетариат революциясе өчен көрәш темасы) алып килеп кенә калмадылар, ул көрәшне конкрет гәүдәләндергән яңа геройлар — кызыл командир, комиссар — образларын да күрсәттеләр. Дөрес, алар татар совет әдәбияты тарихына классик әсәрләр булып керә алмадылар. Аларның әдәби эшләнешләре ягыннан кимчелекләре дә бар иде. (Бигрәк тә «Яңа кешеләр» драмасының). Ләкин бу кимчелекләр Г. Ибраһимовның дөньяга карашыннан, идея-эстетик принципларыннан бигрәк, яңа жанрны, аның үзенчәлекләрен үзләштерү өлкәсендә килеп туган авырлыклар һәм ашыгып иҗат итү белән аңлатыла иде. Һәм, бик табигый, үз чорында әсәрнең житешсезлекләренә караганда аның татар әдәбиятына алып килгән яңалыгына, революцион пафосына, идеологик куәтенә игътибар ителде. Аны пролетариат әдәбиятының классик бер мисалы итеп карау (тәнкыйтьче Г. Ходаяровның әсәргә язган кереш сүзенә игътибар итегез) нәкъ әнә шуның белән аңлатыла иде.

Татар совет әдәбиятының формалашуы, үсүе тарихын тикшерүгә багышланган хезмәтләрнең бер ишенә тарихилык җитеп бетми. Шуның нәтиҗәсе буларак, егерменче еллардагы кайбер әсәрләр сүз сәнгатенең бүгенге үсеше, әдәбият фәненең хәзерге югарылыгыннан торып тәнкыйть ителәләр. Ләкин социалистик реализмның формалашуын критик реализм эволюциясеннән аерып, һәр чорның әдәби җимешен, аларның әдәби-эстетик кыйммәтен әдәбиятның шул чактагы үсеш биеклегеннән, халыкның эстетик зәвыгы дәрәҗәсеннән аерып карарга ярамый. Шулай эшләгәндә, Г. Ибраһимовның бу әсәрләренең заманы өчен зур вакыйга, татар әдәбиятының идея-эстетик казанышы булуын күрү кыен түгел.

Социалистик реализмның «Яңа кешеләр» драмасында һәм «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндә ачык күренгән нигез сыйфатлары (революцион көрәш темасы, яңа кеше образлары, язучының чынбарлыкка мөнәсәбәте үзгәрүе, революциянең тормышчанлыгын раслау) Г. Ибраһимовның аннан соңгы әсәрләрендә тагын да үстерелделәр һәм баетылдылар.

1924 елда Мәскәүдә «Казакъ кызы» романы басылып чыга. Анда беренче карашта идея-тематик алга китеш юк төсле. Романда турыдан-туры революцион көрәш темасы да куелмаган, кызыл командир, большевик образлары да бирелмәгән. Ләкин, асылда, нәкъ шушы роман татар әдәбиятында яңа идея-эстетик принципларның җиңүенә зур өлеш керткән әсәр, чынбарлыкны социалистик реалист буларак сурәтләүнең гүзәл җимеше булды. Күренекле төркмән язучысы Берди Кербабаев Г. Ибраһимов турында:

«Совет власте урнаштырылган беренче елларда, Урта Азия халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда, татар әдәбияты аеруча алга киткән иде. Анда Галимҗан Ибраһимов күренекле урын алып торды. Аның әсәрләрендә барлык социалистик милли әдәбиятлар нигезләнгән принципиаль яңалык бар иде. Һәм бу яңалык минем өчен, башка язучылардагыга караганда, көчлерәк, аңлаешлырак һәм гүзәлрәк яңгырады. Һәм мин Ибраһимовның бер генә әсәрен дә укымый калмадым. Аның һәр сәхифәсе минем өчен бер ачыштай була иде (астына мин сыздым — М. Х.)»[1], — дип яза.

«Барлык социалистик милли әдәбиятлар нигезләнгән бу принципиаль яңалык» нәрсәдән гыйбарәт иде соң?

Ул Г. Ибраһимовның чынбарлыкка художникларча карашының үзгәрүе, дала халкы тормышын сурәтләүгә яңача, совет язучысы идея-эстетик принципларыннан чыгып килүе. «Казакъ кызы» романына карата Б. Кербабаев бу сорауга түбәндәгечә җавап бирә:

«Минем беренче әсәрләрем төркмән хатын-кызларын изелүдән азат итү темасына багышландылар. Икърар итә алам һәм моны шатланып эшлим — минем әсәрләрем Галимҗанның зур йогынтысы белән иҗат ителделәр. Ул, совет язучыларыннан беренче булып, семья һәм җәмгыять изүенә каршы баш күтәргән мөселман хатын-кыз образларын иҗат итте»[2].

Кайберәүләр өчен сәер тоелуы ихтимал. «Семья һәм җәмгыять изүенә каршы баш күтәргән мөселман хатын-кыз образларын» иҗат итү өчен социалистик реалист, совет язучысы булуның ни хаҗәте бар, диярләр. Үзләренең үсешендә критик реализм этабын табигый дәвамлылыгында, бөтен тулылыгы белән, җиренә җиткереп үткән әдәбиятлар өчен бу, бәлки, шулайдыр да. Ләкин критик реализм чорын тизләтелгән рәвештә үткән әдәбиятларга мондый караш, безнеңчә, бер яклы. Ул — әдәби-эстетик төшенчәләрне кулланганда милли әдәбиятларның иҗат практикасын искә алып җиткермәүнең нәти-

---

[1] «Правда» газетасы, 1962, 13 март.
[2] Шунда ук.

җәсе. Ә төрки халыклар милли әдәбиятларының Октябрьга кадәр үткән юлына күз салсаң, Б. Кербабаев дөрес әйткәнчә, мондый образларны аларның бары тик совет чорында гына иҗат итүләрен күрәсең. Һәм монда алдан юл күрсәтеп баручы, һичшиксез, Г. Ибраһимов булды. «Казакъ кызы» романы белән ул бер татарлар өчен генә түгел, башка төрки халыкларны да гасырлар буе борчып килгән, мәнге чишелмәс кебек тоелган проблеманы хәл итү юлын — хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен социаль азатлык проблемасы белән бәйләнештә карау кирәклеген раслады. Аның яңа тип, совет художнигы булуының асылы әнә шуннан гыйбарәт иде.

Язучы иҗатында социалистик реализм иҗат принципларының формалашуын әдипнең идея эволюциясенә генә кайтарып калдырырга ярамый, әлбәттә. Г. Ибраһимовның чынбарлыкка идея-эстетик мөнәсәбәте үзгәрүе әсәрнең, идея-тематикасы белән бергә, сюжет-композициясендә, образлар системасында, сурәтләү чараларында, кыскасы, әдәби әсәрне җанлы һәм канлы иткән барлык әдәби-эстетик компонентларның җыелмасында чагылышы итеп каралырга тиеш [1]. Әсәрне менә шулай тикшергәндә, «Казакъ кызы»-ның татар прозасына алып килгән зур идея һәм художество яңалыгы, совет әдәбияты үсешенә керткән өлеше ачык күренер.

Г. Ибраһимов ирешкән идея-эстетик эволюциясенең югарылыгын «Тирән тамырлар» романы белән «Безнең көннәр»нең яңадан эшләнгән варианты ачык күрсәтте. Бу әсәрләрендә ул татар халкының XX йөз башы иҗтимагый тормышын, беренче рус революциясе тәэсирендә революцион аңы уянуын һәм азатлык өчен көрәшкә күтәрелүен тасвирлады, Октябрь нәтиҗәсендә халык тормышында барлыкка килгән тирән социаль һәм рухи үзгәрешләрне, авылда һәм шәһәрдә җәелгән социалистик төзелеш, сыйнфый көрәш эчендә яңа, совет кешесе, социалистик характер формалашуын сурәтләде. Бу ике роман үрнәгендә татар совет прозасы идея-художество ягыннан житлегүен, чынбарлыкка мөнәсәбәттә диалектик материализмга, марксизм-ленинизмга нигезләнүен, әдәбиятның тормышка мөнәсәбәте тамырдан үзгәрүен раслады. Г. Ибраһимовның новаторлыгы әнә шунда иде. «Безнең көннәр» романының яңа вариантында барыннан да бигрәк баш геройларның характеры, идея-эстетик йөкләмәсе үзгәрә. Большевик образлар буларак, Булатов, Коля, Солтан, эшче-революционер Абдулла һәм башкаларның идея-политик юнәлеше ачыклана. Әсәрнең беренче вариантында алгы планга куеп сурәтләнгән Д. Урманов, Х. Мансуровларның революцион көрәштәге роле тарихи дөресләнә. Революциянең ачык дошманнары һәм аларның ярдәмчеләре — анархистлар, эсерлар, буржуаз милләтчеләрнең чын йөзләре ачып бирелә.

«Безнең көннәр» романының татар әдәбиятына алып килгән тагын бер яңалыгы шунда ки, ул әдәби геройларны тарихи шәхесләргә нигезләнеп иҗат итүне башлап җибәрде. Ә бу — язучының реализм юлыннан үсешен характерлый торган әһәмиятле фактор. Г. Ибраһимовка монда 1905 ел революциясенә караган архив материалларын ныклап өйрәнү һәм, ниһаять, беренче рус революциясе турында «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле хезмәт (1925) язуы да ярдәм итте.

«Безнең көннәр»дә сурәтләнгән уңай геройларның прототиплары — Татарстанда һәм Башкортстанда 1905—1907 еллардагы революцион вакыйгаларда зур роль уйнаган тарихи шәхесләр, партия эшлеклеләре, большевиклар. Алгы планда, әлбәттә, большевик Булатов исеме белән бирелгән беренче татар революционеры — большевик Хөсәен Ямашев образы тора. Г. Ибраһимов бу образны аеруча зур хөрмәт һәм мәхәббәт белән сурәтли, аның 1905—07 еллар революциясендә тарихи эшчәнлеген күрсәтә. Әсәрдә шулай ук большевиклар партиясенең актив эшлеклеләреннән берсе, 1906 елның көзендә В. И. Ленин заданиесе белән Казанга килгән И. А. Саммер, 1901 елдан КПСС члены, Уралда һәм Башкортстанда 1905—1907 еллардан бирле революцион вакыйгаларда актив катнашкан Э. С. Кадомцев сурәтләнә. Архив материалларыннан Гәрәй Солтан кавказлы образының прототибы РСДРП(б)ның Баку оешмасыннан Казан большевикларының сугышчан группасын ныгыту өчен җибәрелгән Әгълиулла Билалетдинов булуы билгеле. Ул 1908 елны төрмәдә җәзалап үтерелгәч, патша властьларының ерткычлыгына каршы протест йөзеннән, Казан университеты студентлары һәм күп кенә предприятиеләрнең эшчеләре баш күтәрәләр. Ул хакта 1908 елда большевистик «Пролетарий» газетасында да хәбәр ителә. Бу фактлар Г. Ибраһимов-художникның 1905 ел революциясенә мөнәсәбәтенең социалистик реализм нигезендә үзгәрүен характерлыйлар.

Язучының совет чоры әсәрләрен тикшерү Г. Ибраһимов иҗатында социалистик реализмның нигездә Октябрьның 10 еллыгына, ул каты авырып Ялтага күчеп киткәнче формалашып өлгерүен күрсәтә.

Ә алай булгач, «Безнең көннәр» читтә калмыймы соң, дигән сорау туарга мөмкин. Әдипнең совет чоры эволюциясен ачык күрсәткән бу романының икенче варианты 1934 елда басылып чыга бит.

Бердән, «Безнең көннәр»нең яңа варианты аның басылып чыгуыннан берничә ел элек тәмамланган булуын әйтергә кирәк. Моның өстендә эшләвенең утызынчы елларга кадәр сузылуы авторның идея-эстетик үсешенә түгел, бәлки, каты авыру белән бәйләнгән. Мәсьәлә монда вакыт факторында гына. Романга кертелгән идея-эстетик үзгәреш-

---

[1] Бу яктан Г. Халитның Г. Ибраһимовның иҗат методына һәм әдәби осталыгына багышланган мәкаләсе («Совет әдәбияты» журналы, 1963 ел, 8 сан.) аеруча әһәмиятле.

ләрне башкарырга Г. Ибраһимов әле егерменче елларның уртасында ук өлгергән була. Ә әсәрнең беренче басмасына авторның үзенең мөнәсәбәтенә килгәндә исә, ул Г. Ибраһимовны әле басылып чыккач ук канәгатьләндерми. Аның 1934 елгы басмасына язган сүз ахырында әдип болай дигән иде:

«...1914 елда басыла башлап та, тукталган әсәр бары тик революциядән соң гына дөньяга чыга алды (1919—1920, Казан, Өмит типографиясе). Бу беренче басма шул 1914 елгы кульязма тексты буенча эшләнде. Кульязманы икенче тапкыр типографиягә биргәндә мин аны яңадан төзәтеп чыгу түгел, хәтта бер тапкыр карап, күз йөртеп үтәргә дә вакыт таба алмадым... Шулай китап чыкты. Матбугатта мактап каршы алуларга карамастан, мин китап чыгу белән үземдә тирән канәгатьсезлек сиздем. Шул вакытта ук, әгәр гомерем булса, вакыт җиткерә алсам, бу әсәргә яңадан бер кайтырмын дип, үз күңелемдә кистереп куйдым» (астына мин сыздым — М. Х.).

Г. Ибраһимовның Октябрьдан соңгы тарихи карашларын тикшерү, аның егерменче елларның беренче яртысында язган гыйльми хезмәтләре, бигрәк тә 1925 елда татар һәм рус телләрендә басылып чыккан һәм «Правда», «Известия» газеталары битләрендә югары бәя алган «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле зур китабы алда куелган тезисны тулысынча раслый.

Язучының социалистик реализмга үсеше туры сызык буенча бармады, билгеле. Аның иҗат эше, чынбарлыкны совет художнигы буларак үзләштерүе кайвакыт аерым уңышсызлыкларга да очрады. Моның ачык мисалы 1923 елда язылган «Адәмнәр» хикәясе. Туп-туры әйтергә кирәк, бу әсәр Г. Ибраһимов иҗатында алга китеш түгел, совет язучысы буларак, художникның чынбарлыкка мөнәсәбәтендәге кимчелеге. Ул үз чорында әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан нәкъ шулай каралды да. Мондый караш белән автор үзе дә килешә булса кирәк. Чөнки үзе килешмәгән фикерләргә каршы матбугатта бик тиз язып чыгучан Г. Ибраһимов бу юлы дәшмәде. Аннан соң ул бу әсәрне утызынчы еллар башында чыгарылган сайланма әсәрләр җыентыгына да кертмәде.

Ләкин иҗат уңышсызлыклары, чынбарлыкны үзләштерү юлында идея-эстетик кимчелекләр социалистик реализм язучыларында булмый дип кем әйткән?! Социалистик реализм методы ул һәртөрле хәвеф-хәтәрдән саклый торган калкан, барча авыруларга дәва түгел бит. Ул иҗат уңышын үзеннән-үзе тәэмин итми.

«Адәмнәр» хикәясендә Г. Ибраһимовның төп кимчелеге натурализм тышауларына эләгүендә булды. Әсәрдә ул ачлык дәһшәтен, аның нәтиҗәләрен йөрәк тетрәткеч картиналарда сурәтләде. Ләкин нәрсә өчен?

Сәнгатьнең максаты — гуманизм. Ул һәр дәвердә кешенең һәм кешелекнең кара көчләрне җиңеп чыгуын раславы белән, аның киләчәккә, яңалыкка омтылышын күрсәтүе, шуңа өндәве белән көчле булды. Дөнья әдәбиятының классик әсәрләре шуның белән үлемсезләр. Социалистик реализм әдәбияты, сәнгате бигрәк тә. Ә «Адәмнәр» повестенда Идел буендагы ачлыкның дәһшәте авторның идеалын да каплап китә. Г. Ибраһимовның төп кимчелеге шул. Ул аның социалистик реализм методын үзләштерү юлындагы иҗат уңышсызлыгы итеп каралырга тиеш.

Ә «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның 1928 елгы төзәтелгән басмасы?

1965 елның җәендә СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында «Татар совет әдәбияты тарихы»ның Мәскәүдә чыккан русча басмасын тикшергәндә кайбер әдәбият белгечләре бу әсәр критик реализм җимеше итеп каралырга тиеш дип чыктылар. Мондый караш берничә ел элегрәк шул ук әдәбият тарихының татарча басмасы чыккач та әйтелгән иде. Бу иптәшләр үзләренең тезисларын нәрсә белән дәлилиләр соң? Аларның дәлиле бер: әсәрнең төп героинясы Гөлбануның һәлакәте, татар хатынының ул хәлдән чыгу юлы күрсәтелмәве, әсәрнең пессимистик тәмамлануы. Беренче карашка, бу дөрес тә кебек. Әсәрнең беренче варианты (1909) оптимистик рухта тәмамланган, анда Гөлбануның «азатлыкка» ирешүе сурәтләнгән иде. Ә совет чорында иҗат ителгән яңа варианты пессимистик, трагик бетем ала. Беренче караштa, Г. Ибраһимов үсми, бәлки артка китә кебек. Ләкин бу өстән караганда гына шулай. Әсәрне тирәнрәк тикшерү «критик реализм» тарафдарларының дәлилләре җитди түгеллеген, бәлки әдәби әсәргә схематик, язучының иҗат үсеше үзенчәлеген искә алмыйча карауның нәтиҗәсе булуын күрсәтә.

Ә бит мәсьәләнең асылы — Г. Ибраһимовның уңай идеалы критик реализм язучысы идеалыннан принципиаль аерылуында. Әсәрнең беренче вариантында Гөлбану һәлак булмый, үзенә татар тормышы тарафыннан әзерләп куелган каһәрле язмыштан котыла. Ләкин нинди юл белән котылуына игътибар итәргә кирәк. Бу бит әдәби-эстетик гомумиләштерү тапкан, реаль һәм типик юл түгел. Әсәрнең яңа вариантын автор Гөлбануның һәлакәтен күрсәтү белән тәмамлый. Һәм, әйтергә кирәк, ул бик дөрес эшли. Әдип моның белән ул тормыш рамкаларында татар хатынын коткару мөмкин түгеллеген раслый, аның өчен иҗтимагый тормышны нигездән үзгәртү кирәклеген күрсәтә, укучы күңеленә шул фикерне җиткерә һәм читләтелгән рәвештә татар дөньясын төбе-тамырыннан үзгәрткән Октябрьның көчен, бөеклеген, зарурый булуын исбатлый. Моны, әлбәттә, марксизм-ленинизм белән коралланган совет язучысы гына эшли алды. Социа-

листик реализм язучысының уңай идеалы белән критик реализм уңай идеалы арасындагы аерманы без нәкъ шунда күрәбез.

20 нче елларда бу темага багышланган әсәрләр бер татар әдәбиятында гына язылмады. Казакъ язучысы М. Ауэзовның «Энлик кебек» исемле пьесасында шулай ук Октябрьга кадәрге казакъ хатын-кызының трагик язмышы сурәтләнә. Үзбәк язучысы Хәмзә, ингуш А. Гойгов, кыргыз язучылары А. Токомбаев һәм К. Баялинов, мари М. Шкетан әсәрләрендә дә хатын-кызларның фаҗигале образлары бирелә.

Ниһаять, «Татар хатыны ниләр күрми?» повестеның яңа варианты турында сөйләгәндә, тагын бер моментны истән чыгарырга ярамый. Бит Г. Ибраһимов 1928 елда татар хатыны, аның язмышы турында яңа әсәр иҗат итмәде, бәлки 20 ел элек язылган һәм басылып чыккан хикәясен төзәтте. Автор татар халкының Октябрь революциясенә кадәрге мәгълүм бер чор тормышына караган фактик материал, билгеле бер сюжет һәм композиция белән бәйләнгән иде. Һәм ул шушы әдәби материал рамкаларында торып эш итте. «Яңа кешеләр» дә революция өчен актив көрәшче Камәр, «Тирән тамырлар»да Гайшә, Нәгыймә кебек активисткалар образларын иҗат иткән Г. Ибраһимов, әгәр теләсә, татар хатынының язмышына багышланган әсәрдә дә актив көрәшче, хәтта революционерка образын тудыра алган булыр иде. Ләкин ул вакытта инде бөтенләй яңа әсәр язылган булыр иде. Озын сүзнең кыскасы шул, «критик реализм» тарафдарлары бу очракта язучының иҗат лабораториясен искә алып җиткермиләр, аның әдәби эволюциясенә догматик караштa торалар. «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның яңа варианты егерменче еллар татар совет прозасының әһәмиятле бер факты, Г. Ибраһимовның үсешен күрсәткән социалистик реализм әсәре. Әдәбият фәне аны шулай карарга тиеш тә.

Егерменче еллар ахырына Г. Ибраһимовның социалистик реализмга үсеп җитүе совет әдәбияты иҗат методының нәкъ шул чорда гомумән татар прозасында формалашуын тәэмин итте. Табигый, татар әдәбияты алдында торган бу тарихи миссияне үтәүдә Г. Ибраһимов ялгыз булмады. Бу өлкәдә аның иҗаты белән бергә, Ш. Камал, М. Гафури, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи, К. Нәҗми, А. Шамов әсәрләре зур роль уйнадылар. Бу язучыларның уртак тырышлыгы белән татар прозасы утызынчы елларга кергәндә үзенең идея-художество потенциаль мөмкинлекләре ягыннан татар халкының бүгенгесен һәм үткәнен тематик һәм проблематик яктан тиешле киңлектә һәм тирәнлектә сурәтли алырлык, киләчәккә разведка ясарлык, социализм төзүче халыкның рухи таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәгә үсеп җиткән иде. Егерменче еллар татар прозасында революцион хәрәкәт, гражданнар сугышы, авылда һәм шәһәрдә сыйнфый көрәш, иҗтимагый тормышта хатын-кыз роле темалары үзәк тема булып тордылар, проза әсәрләрендә революцион көрәштә, гражданнар сугышы фронтларында формалашкан яңа кеше образы сурәтләнде, социалистик моральнең җиңүе күрсәтелде. Һәм, әйтергә кирәк, бер прозада гына түгел, поэзиядә, драматургиядә дә нигездә шул ук хәл иде. Г. Ибраһимов 1930 елда язган «Ерактан сәлам» исемле мәкаләсендә, татар совет әдәбиятының 10 еллык үсешенә йомгак ясап, болай ди:

«Әгәр дә татар әдәбияты тарихының үткән бер баскычы, үткән бер заманы белән чагыштырып карасак, мондый аз бер заманда бу чаклы көчләрнең бер мәйданга чыкканлыкларын очратырга мөмкин түгел. Мондый аз заман эчендә мондый бер хәрәкәтне тик пролетариат революциясенең бөек масса кузгалышы гына тудыра алды, Татарстан җөмһүрияте әдәби иҗаты да тик менә шул гомуми пролетариат революциясенең масса хәрәкәте һәм коммунистлар партиясенең тугры юлбашчылык тәэсире генә мондый зур иҗади кайнашны күрергә насыйп итте»[1].

Татар әдәбиятында социалистик реализмның формалашуын татар халкының рухи үсешендәге табигый югары этабы, әдәби процессның тарихи нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Монда, әлбәттә, татар әдәбиятының бай традицияләре, Октябрьга кадәрге үсеш дәрәҗәсенең югары булуы да зур роль уйнады. XX йөз башы татар әдәбиятында революцион азатлык идеяләре гаять көчле, М. Горький традицияләре шактый нык тамыр җәйгән иде. Анда социалистик реализм элементларын әле 1905—07 елгы революция чорында ук күрергә мөмкин. Г. Коләхметовның «Ике фикер» һәм «Яшь гомер» драмалары татар әдәбиятының М. Горький күрсәткән юлдан үсешендә зур роль уйнадылар. Ул әсәрләрнең Октябрьга кадәрге чорда татарларда пролетар әдәбиятның башлангыч үрнәкләре булуын Г. Ибраһимов әле 1926 елда ук күрсәтеп үткән иде. Ул Г. Коләхметовны «беренче марксист әдип»[2] дип атады.

Татар әдәбиятының социалистик реализм юлыннан уңышлы үсүен тәэмин иткән әһәмиятле факторларның берсе — революциягә кадәрге төп әдәби кадрларның пролетариат ягында булулары, революция вакыйгаларында актив катнашулары, сыйнфый көрәш һәм гражданнар сугышы фронтларында политик чыныгу алулары. Г. Ибраһимов белән бергә, М. Гафури, Ш. Камал, Ш. Әхмәдиев, Ф. Сәйфи, Ф. Бурнаш Октябрь революциясен кабул итеп кенә калмадылар, аны тормышка ашырышуда актив катнаштылар, үзләренең каләм көче һәм практик эшчәнлекләре белән аның казанышларын

---

[1] Уя ел эчендә татар матур әдәбияты. Казан, 1930, 99 бит.
[2] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1926 ел, 12 январь.

саклаштылар, күбесе 1919—20 елларда Коммунистлар партиясе сафына керделәр. Әдәбиятның язмышы өчен бу тарихи фактның әһәмияте зур булды.

Шул ук вакытта Октябрьдан соң татар әдәбиятына турыдан-туры революцион көрәш һәм гражданнар сугышы фронтларыннан яшь әдәби көчләрнең күп килүен, аларның әдәби процессны революцион пафос, сыйнфый көрәш рухы белән сугаруын, аңа иҗат ялкыны һәм энергия өстәвен әйтергә кирәк. Ш. Усманов, М. Җәлил, К. Нәҗми, А. Шамов, М. Максуд әнә шундый әдипләрнең иң күренеклеләре иделәр. Бу әдәби буын алып килгән романтик пафос, өлкән буын язучыларының иҗат тәҗрибәсе белән кушылып, татар әдәбиятын идея-тематик яктан баетты, аны революция һәм яңа тормыш таләпләренә якынайтты.

Совет әдәбиятының формалашуы турында сүз алып барганда, Октябрь нәтиҗәсендә рус әдәбиятының милли әдәбиятларга йогынтысы аеруча көчәюен әйтергә кирәк. Милли әдәбиятларның социалистик реализм юлыннан үсүе өчен иң әһәмиятлесе шул иде ки, илдә гомуми әдәби хәрәкәт барлыкка килде. Татар әдәбиятына килгәндә исә, бу чорда аңа рус классик әдәбиятының тәэсире көчле булды. Шуңа күрә булса кирәк, татар язучылары ул чорда шактый киң җәелгән пролеткультның һәм төрле формалистик агымнарның тәэсирен кимрәк тойдылар. Татар әдәбиятының төп кадрларының демократик әдәбиятның бай традицияләре, егерменче еллардагы төрле формалистик тәҗрибәләргә караганда, рус классик әдәбияты белән ныграк бәйләнештә булуы һәртөрле формалистик мавыгуларга дәва ролен үтәде. Г. Ибраһимов 1923 елның әдәби йомгагы турындагы хисап мәкаләсендә әдәбиятның төп кадрларының реализм юлыннан үсүләрен, символизм, футуризм, имажинизм кебек формалистик агымнар, кайбер язучыларның иҗатында чагылса да, әдәби хәрәкәттә киң тарала алмавын күрсәтеп үтә. Аның:

«Бу агым бездә үле тудымы яки башка икълимнан ясалма рәвештә күчертеп утыртылганга, татар әдәби бакчасындагы һаваны күтәрә алмый шиндеме?» — дигән сүзләрендә зур хакыйкать бар иде. Аннан соң Г. Ибраһимовның үзенең дә төрле формалистик агымнарны татар әдәбиятына кертмәү өлкәсендә күп хезмәт куюын әйтергә кирәк. Моны раслау өчен әдипнең һ. Такташ, Г. Кутуй, К. Нәҗми иҗатларына мөнәсәбәтен, аларның формалистик мавыгуларын кискен тәнкыйть итүен әйтү генә дә җитә. Ә яшь көчләр тәҗрибәле өлкән язучының киңәшләренә колак салдылар, үзләренең иҗатларында формалистик чирдән тиз арындылар, алар иҗатының үсеше нәкъ Г. Ибраһимов алдан әйткәнчә булды.

Егерменче еллар татар әдәбиятында яна сыйфатлар формалашуда тәнкыйтьнең ролен, әдәбият теориясенең һәм марксистик эстетиканың төп мәсьәләләренең кызу эшләнүенең, әдәби иҗат практикасының үз вакытында тиешле идея-эстетик гомумиләштерелә барылуының зур әһәмияте булуын әйтергә кирәк. Бу өлкәдә беренче скрипка шулай ук Г. Ибраһимов булды. Ул, каты авырып, Казаннан Ялтага киткәнгә кадәр, республикада тәнкыйтьчеләр отрядының алгы сафында барды, гомеренең соңгы ун елында, җанлы әдәби процесстан аерылгач та, тәнкыйть каләмен ташламады, аерым мәкаләләрендә, каләмдәшләренә һәм дусларына җибәргән хатларында әдәбият үсешенең мөһим мәсьәләләрен күтәрде, совет әдәбият фәне һәм тәнкыйтенең алгы рәтләрендә кала бирде. Әдәбият белгечләре бик хаклы рәвештә татар әдәбиятында марксистик тәнкыйтьнең формалашуын беренче чиратта Г. Ибраһимов исеме белән бәйләп карыйлар.

Г. Ибраһимов үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә һәм хезмәтләрендә марксистик эстетиканың нигез проблемаларын эшләде. Совет властеның беренче елларында ул әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый ролен, аларның сыйнфыйлыгын ачуга аеруча игътибар бирде. Ә әдәбият кадрларының бу мәсьәләне дөрес аңлавының татар халкының художество культурасы үсеше өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын, әдәбиятчылар арасында сәнгатьнең иҗтимагый тормыштагы урынын аңлауда әле бердәм марксистик караш булмавын 1922 елда «Татарстан» газетасы битләрендә булып узган бәхәс ачык күрсәтте. Беренче караштә бу ике әдәбиятчы (Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди) арасында гына килеп чыккан аңлашылмаучылык һәм әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләсенә генә караган кебек тоелса да, асылда ул сәнгатьнең иҗтимагый ролен, әдәбиятның үсеш юлларын аңлауда капма-каршы ике линиянең бәрелеше иде. Г. Ибраһимовның марксистик позициясе яшь әдәби кадрларны үстерүдә генә түгел, өлкән буын язучыларга йогынты ясауда да зур роль уйнады.

Егерменче еллар башы әдәби иҗат практикасы өчен Г. Ибраһимов тарафыннан язучының дөньяга карашы, иҗтимагый позициясе мәсьәләләренең теоретик эшләнүе һәм пропагандалануы зур әһәмияткә ия булды. Әдип талантлы шагыйрь Ш. Бабичка багышланган «Вакытсыз һәлак булды» исемле мәкаләсендә, М. Гафуриның «Эшче» поэмасына язган сүз башында һәм башка хезмәтләрендә иҗат эшендә, талантның үсешендә дөньяга карашның, революцион теориянең хәлиткеч ролен күрсәтте, әдәби осталык мәсьәләләрен шагыйрьнең политик йөзе, идея үсеше белән органик берлектә тикшерүнең матур үрнәкләрен бирде. Әдип бу проблемаларны фәнни эшләвен «Пролетариат әдәбияты турында» (1924) дигән хезмәтендә уңышлы дәвам иттерде. Анда совет язучысының әдәби-эстетик позициясе, чынбарлыкка мөнәсәбәте мәсьәләсе бөтен калкулыгы белән куела.

«...бер шарт бардыр ки, — дип яза Г. Ибраһимов, — ул да язучының марксизм аркылы күрүе, андагы сыйнфый каршылыкларны ачуы, андагы надстройка, идеология

тармакларының иҗтимагый-икътисади тамырларын күрүе, шуны күрсәтүе!! Әгәр бу күзлек булса, без завод-фабриктан, шахтадан, приискадан, пролетариатның восстаниеләреннән үтеп, буржуаның, алпавытның, вак буржуаның, безгә союзник крестьяннарны, кулакларын, урталарын, ярлыларын тасвирда гына тукталу түгел, тарихның «милли», «дини» каһарманнарынача барып җитәрбез»[1].

Г. Ибраһимов шул ук вакытта пролетариат әдәбиятының уңышлы үсеше өчен әдәби осталыкның, сәнгать чаралары камиллегенең әһәмияте юк дигән вульгаризаторлык карашларына кискен каршы чыкты. Ул яшь әдәби көчләрне, сәнгатьнең үзенчәлеген анламыйча, әсәрләрен коры идеяләр схемасына, политик тезислар иллюстрациясенә кайтарып калдырудан сакланырга чакырды. Әдип үзенең хезмәтләрендә пролетар әдәбиятының формасы, художество осталыгы, иҗат методы мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Ул «иске савытта яңа эчемлекләрнен» саклана алмавын, сәнгатьтә революцион эчтәлек, зур тарихи мәгънәләр үзләренә лаеклы яңа формалар тудырырга тиешлеген әйтү белән бергә, моның яңа әдәбият, социалистик культура төзүдә иң кыены, иң күп көч таләп итә торган эш булуын да кисәтте. Ибраһимов үзенең мәкаләләрендә, әдәби хәрәкәтне анализлап килгән еллык хисапларында рухы һәм иҗтимагый юнәлеше белән революциягә кадәрге әдәбияттан бик нык алга киткән пролетариат әдәбиятының сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе ягыннан әле шактый аксавын күрсәтеп килде. Ләкин әдип бу өлкәдә һичкайчан һичбер схемалар тәкъдим итмәде. «Марксизм алдан әзерләнгән формалар бирми», дип күрсәтте ул һәм яңа форма кемнәрнеңдер уйлап чыгаруыннан түгел, әдәбиятның табигый үсешеннән, дөнья сәнгатендә һәм әдәбиятында гасырлар буена тупланып килгән тәҗрибәгә таянган һәм аннан иҗади файдаланган хәлдә, революция, яңа тормыш тудырган бөек мәгънәләрне киң халык массаларына җиткерерлек итеп художестволы уйлау аркылы әйтеп бирергә омтылыштан туачагын әйтте. Һәм чынлыкта ул нәкъ шулай булды да. Совет язучылары иҗат методының, буржуаз әдәбиятчылар язуынча, кемдер тарафыннан уйлап чыгарылган һәм иҗат практикасына декрет белән кертелгән догма түгел, бәлки җанлы әдәби процессның бөтен барышы белән барлыкка китерелгән гомуми әдәби-эстетик казаныш булуын Г. Ибраһимовның бу өлкәдәге эзләнүләре тулысы белән раслыйлар.

Октябрьга кадәрге чорда татар тәнкыйте һәм эстетик фикере СССР халыклары тәнкыйте арасында шактый нык үскән, алга киткәннәрдән саналса да, бездә әдәбият белеме, фән буларак, совет чорында гына формалашты. Ул тулысынча Октябрь җимеше итеп каралырга тиеш. Аны нигезләүче Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Гали булдылар. Бу өлкәдә Г. Ибраһимовның «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» (1922), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Имла, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» (1924) исемле зур фәнни хезмәтләренең аеруча роль уйнавын әйтергә кирәк.

Әдәбиятның үткән юлын өйрәнми торып, аның хәзерге хәлен һәм киләчәген билгеләү мөмкин түгел иде. Татар әдәбиятының күп гасырлык бай тарихын системалы рәвештә фәнни тикшерү шулай ук Октябрьдан соң башланды. Һәм бу совет әдәбиятының уңышлы үсеше, аның халыкның рухи культурасындагы бай традицияләр белән азыклануы өчен бик кирәк, бик әһәмиятле булган факторларның берсе иде. Марксизм-ленинизм нигезендә бу эшкә башлап керешүче шулай ук Г. Ибраһимов булды. Ул әдәбият тарихына идеалистик карашларны җимерде, алар урынына материалистик принциплар урнаштырды. Әдәбият тарихын, аның дәверләрен ул, буржуаз галимнәр шикелле, аерым шәхесләр, әдәби талантлар тирәсенә кормыйча, әдәби күренешләргә ныклы нигез итеп халык тормышындагы социаль-экономик үзгәрешләрне алды. «Әдәбиятлар, — дип язды ул, — фәлсәфәләр, гыйльми ысуллар, диннәр, әхлаклар — кыскасы, бөтен идеология хезмәтләренең һичбере күктән яумаган кебек, нинди дә булса бер даһиның тик үз башыннан уйлап чыгаруы белән дөньяга килмиләр. Боларның фикерләре, рухлары, мөндәриҗәләре — һәммәсе тарихның мәгълүм дәверендәге мәгълүм бер матди, иҗтимагый катлаулар туфрагында үсеп чыга торган чәчәкләре генәдер»[2].

Г. Ибраһимов әдәбият тарихында тикшерү объекты итеп татар халкының үз туфрагында, үзе тарафыннан тудырылган әдәби җимешләрне алу тиешлеген куйды. Әнә шул принциптан чыгып, ул татар әдәбияты тарихының эчтәлеген билгеләде, аның иң борынгы чорыннан алып Октябрьга кадәрге үткән дәверләрен тикшерде.

Егерменче елларда әдәбият тарихын өйрәнү өлкәсендә зур эш башкарылды. Г. Ибраһимов сызган юл белән барып, әдәби истәлекләр социаль-экономик җирлеккә куелып, халык тормышына, илдәге социаль-политик вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә тикшерелә башладылар. Һәм бу өлкәдә күп фактик материал тупланды, әһәмиятле фәнни нәтиҗәләр ясалды.

Әдәбият тарихын тикшерү дә җиңел генә бармады, әлбәттә. Бу өлкәдә марксистик-ленинчыл принципларның урнашуына вульгар социологизм карашлары комачауладылар. Ул елларда совет әдәбияты белеменә хас булган бу гомуми чир, табигый, Г. Ибраһимовка да йокмый калмый. Ул үз чорының әдәбият фәне үсеше дәрәҗәсеннән аша сикерә алмый. Ләкин шулай да киң эрудицияле галим, фикер иясе һәм сәнгатьнең

---

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960, 172 бит.
[2] «Безнең юл», 1922, № 1, 31 бит.

асылын тирән аңлаган тәҗрибәле язучының карашлары еш кына вульгар социологизм кысаларын җимереп чыктылар.

Ниһаять, егерменче елларда татар совет әдәбиятының формалашуы турында сөйләп тә, Г. Ибраһимовның бу өлкәдәге тагын бер хезмәтен — әдәби хәрәкәтне оештыру, иҗат көчләрен партия куйган зур бурычлар тирәсенә туплау эшчәнлеген билгеләп үтми мөмкин түгел. Совет властеның беренче ун елы эчендә әдәби-иҗат эшенә билгеле бер оешканлык һәм система кертүдә аның роле аз булмады. Ул Татарстан совет язучылары оешмасын нигезләүчеләрнең берсе. Әле 1927 елның башында ук Г. Ибраһимов партия Өлкә Комитетына татар әдәбияты җәмгыяте төзү турында махсус тәкъдим белән керә һәм Өлкә Комитетының матбугат бүлегендә бу мәсьәлә буенча үткәрелгән махсус киңәшмәдә «Татар язучыларының ассоциациясе турында» доклад ясый. Һәм шушы киңәшмәдән соң республикада бу юнәлештә практик эш башлана [1].

Татарстан совет язучылары оешмасын төзү идеясе партия Үзәк Комитетының совет язучыларының бердәм союзын төзү турындагы 1932 ел 23 апрель карарыннан соң тормышка ашты. Бу вакытта инде Г. Ибраһимов Ялтада булып, ул эшкә турыдан-туры катнаша алмаса да, аның планнарын каләмдәш дуслары һәм иптәшләре дәвам иттеләр.

Г. Ибраһимовның егерменче еллардагы әдәби-иҗат практикасы, тәнкыйть һәм теоретик хезмәтләре, оештыру эшчәнлеге татар әдәбиятының киләчәктә социалистик реализмның магистраль юлыннан үсешенә ныклы нигез булдылар. Татар совет әдәбиятының илле ел эчендә ирешкән казанышлары Г. Ибраһимов исеме һәм традицияләре белән аерылгысыз бәйләнгән.

—●●—

[1] Бу турыда Л. Гомәрнең «Әдип һәм көрәшче» исемле мәкаләсен карагыз (Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Казан, 1966, 194—195 битләр).

*Октябр Кадыйров*

# РОМАНТИЗМНАН РЕАЛИЗМГА

*(Әдипнең революциягә кадәрге эстетик карашлары)*

Галимҗан Ибраһимов яшәгән чордан ераклашкан саен, аның халык күңелендәге сурәте тулылана, ачыклана бара, татар культурасын үстерү юлындагы хезмәтләре исә зуррак, тагын да әһәмиятлерәк һәм нәтиҗәлерәк булып күренә. Әмма, халкыбызның бу данлы улы, аның бай мирасы үзенә лаеклы бәяне алды инде, дип расларга иртәрәк әле. Дөрес, соңгы елларда Галимҗан Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлына багышланган күп кенә хезмәтләр чыкты. Шуңа да карамастан, ул калдырган бай мирас хәзергә гомуми сызыкларда гына бәяләнгән, аның әдәби-эстетик карашларының үсеш эволюциясе, закончалыклары, тарихи шартларга бәйле булуы ныклап тикшерелмәгән.

Галимҗан Ибраһимовның әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә караган тәүге фикерләре матбугат битләрендә моннан 60 еллар элек басылган. Аннан бирле күп гомер үткән, күп сулар аккан. Ярты гасырдан артыграк бу вакыт — әдәби-эстетик карашлар үсешендә барган зур үзгәрешләр белән характерлы. Иҗтимагый аңның үзенчәлекле бер формасы булган сәнгать, аның асылы, бурычлары турындагы фәнни карашлар да бик нык үзгәрде, үсте, камилләште. Заманында Г. Ибраһимов алга сөргән фикерләрнең кайберләре шактый искерде инде. Бу — аңлашыла торган әйбер, бу — табигый хәл. Шуның белән бергә, Г. Ибраһимов яклаган әдәби-эстетик карашларның байтагы бүген дә искермәгән, бүген дә актуаль яңгырый.

Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов безгә әле дидактизм, үгет-нәсихәтчелек принциплары өстенлек иткән бер чорда әдәбият мәйданына килде. Ул елларда әдәбият, күбрәк, әхлак, гадәт төзәтү чарасы дип кенә карала, аның чынбарлыкны сәнгатьчә танып-белү юлындагы роленә тиешле игътибар бирелми иде.

Дидактизм вәкилләре тарафыннан Гоголь хәтле Гоголь «сүз белән вәгазь сөйләүчеләр» төркеменә кертелде. «Хикәя вә романнар фәкать... әхлак өчен язылырга тиешләр»[1], диде Г. Сәгъди. Ваграк кешеләр турында сөйләргән дә юк, Г. Сәгъди фикеренчә, хәтта Г. Тукай, Ф. Әмирхан кебек чын сәнгать осталары да «әсәрләрен әхлак карасына манып» яздылар. Кыскасы, егерменче йөз башы татар әдәбиятында мәгърифәтчелек тенденцияләре гаять көчле иде, һәм ул әдәбият кешене белемле, культуралы булырга өндәде, бозыклык кылмаска, ярлы һәм ачларны кимсетмәскә, хатын-кызны җәберләмәскә өндәде[2]. Дидактизм тарафдарлары җанлы тормыштан үзләренең нәсихәтчелек карашларына туры килердәй якларны гына алдылар, күп очракта, өч тиенлек мораль бәрабәренә, чынбарлык күренешләрен бозып сурәтләделәр. Әдәби образ аларга, тере, җанлы характер, чынбарлыкны танып-белү, ачыш ясау чарасы булудан бигрәк, әзер тезисларын иллюстрацияләү өчен кирәк иде. Алар сәнгатьнең, художестволы образның асылын берьяклы, бозып аңлаттылар.

Галимҗан Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары, барыннан да элек һәм беренче чиратта, әнә шул үгет-нәсихәтчелек әдәбиятына каршы көрәштә формалашты, дияргә мөмкин. Дөрес, дидактизмга каршы көрәштә ул ялгыз түгел иде. Егерменче йөз башы татар әдәбиятында, бигрәк тә 1905 елгы революциядән соң, реалистик сәнгать өчен көрәш актив төс алды. Шулай да, арада аеруча әзлекле, ныклы көрәшүчеләрнең берсе Галимҗан Ибраһимов булды. Матбугатка чыккан беренче мәкалә һәм рецензияләрендә үк ул дидактизм әдәбиятына кискен отпор бирде, тормышчан сәнгатьнең күп кенә нигез принципларын билгеләде.

Ф. Әмирханның «Хәят» әсәренә карата язылган бер рецензиясендә Г. Ибраһимов болай ди: «Безнең бик күп мөхәррирләребез авыр вә үтерең язалар... Аларда буяу аз, аларда действие булмый... Ә «Хәят»та алай түгел. Монда мөхәррир үзе фәлән вакыйга булганын сөйләп кенә килми, бәлки каһарманнары үзләре сөйлиләр, кунакка йөриләр, театрга баралар, кешеләр илә танышалар, уйныйлар, көләләр, тәннәр була, сандугачлар сайрый»[3].

Галимҗан Ибраһимов татар халкында әдәбият-сәнгать әсәрләре турында дөрес караш булдыру өчен тырышты. Әдәбиятны ул рухи культураның мөстәкыйль бер тармагы, тормышның көндәлек вак-төяк мәшәкатьләреннән өстен торган үзенчәлекле бер төре,

---

[1] Г. Сәгъди. Әдәбият ысуллары. Оренбург. 1912 ел. 9 бит.

[2] И. Нуруллин. Егерменче йөз башы татар әдәбияты. Лекцияләр курсы. Казан. 1962 ел.

[3] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960 ел. 61 бит.

дип бәяләде. Шул фикерләрен дәлилләү өчен, бөек рус әдәбияты туплаган бай тәҗрибәгә таянды.

Алдынгы рус сәнгатендә ул шул чордагы татар әдәбиятына бик тә җитми торган күп уңай сыйфатлар күрде. Бередә ул гаҗәеп бай сәнгатьчә сурәтләү чаралары, образлар дөньясы белән очрашты. Галимҗан Ибраһимов 19 гасырдагы рус әдәбияты әсәрләрен сәнгатьчә камиллекнең гүзәл үрнәкләре дип карады. Мәкаләләренең берсендә ул болай язды: «...халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәве, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятына бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булучылыгы белән рус әдәбиятының бөтен дөньяда мөмтаз вә мөстәсни урын тотканлыгы мәйдандадыр».

Әле 1910 елда ук, В. Г. Белинскийның туууына 100 ел тулу уңае белән, Г. Ибраһимов «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикатчы В. Г. Белинский җәнаплары хакында» дигән махсус мәкалә язды һәм, татар матбугатында беренче буларак, бөек рус тәнкыйтьчесенең әдәби-эстетик карашлары белән коралланырга чакырып чыкты:

«Тарих аны рус әдәбияты дөньясында чын мәгънәсе белән булган иң беренче мөнтәкыйть саный.

Ул иң беренче буларак, әдәбият, сәнгате нәфисә, художество хакында рус дөньясында туры юл күрсәтте...

Һәр нә безнең интикатчыларыбызга ул бөек рәһбәр була алыр. Бездә тәбган әҗүәф әдәбият бабында тәхсилән «җәяүле бәндәләр» оялмый мөнтәкыйть сыйфатын таккалыйлар. Ул әфәнделәр Белинскийны укый төшсәләр яхшы булыр иде»[1].

Акылдан бигрәк, кешенең хисләренә, хыялына, әхлак дөньясына көчле эмоциональ йогынты ясаучы чын художниклар итеп Г. Ибраһимов Пушкинны, Лермонтовны саный. Бизәкләр байлыгы белән күзләрнең явын алырдай проза әсәрләре дә, аныңча, чын сәнгать була ала. Нәкъ шул нәрсә Ибраһимовка Тургенев, Гончаров, Гогольләрне чын художниклар рәтенә кертергә мөмкинлек бирде. Фикерләрен тагын да ныклырак дәлилләр белән раслау өчен, ул бөтен дөнья әдәбияты җәүһәрләренә мөрәҗәгать итә: «Сукыр Гомерга (Юнан кадим шагыйре) мәңгелек нам вә әбәди хәят биргән, Шекспир, Шиллер, Байрон, Гете, Гюго, Эмиль Золя вә саир әдип вә шагыйрьләргә бөтен дөнья тарихында үлмәс вә сүнмәс кадер вә шәраф биргән, русларның Тургенев, Гогольләренә шулкадәр ихтирам казандырган... нәрсә — фәлсәфә сату, ул кирәк-бу кирәк дип язу булмыйча, хакыйкый мәгънәсе илә язылган роман, хикәя, драм, шигырьләр идеге дә мәгълүм бит»[2].

Г. Ибраһимов замандашларын кешелек җәмгыяте ирешкән культура казанышлары белән коралланырга чакырган киң, энциклопедик белемгә ия тикшеренүче һәм галим иде. 19 гасыр алдынгы рус әдәбияты белән якын танышлык, бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский хезмәтләрен җентекләп өйрәнү аңа әдәбиятның асылы турында шактый тулы һәм төзек фәнни караш булдырырга ярдәм итте. Г. Ибраһимов тарафыннан эшләнгән бу концепция бүгенгә кадәр үзенең әһәмиятен, фәннилеген югалтмаган.

Әдәбиятның асылын, төп үзенчәлеген һәм хасиятен үгет-нәсихәттә, акыл сатуда күргән мәгърифәтчелек реализмына капма-каршы буларак, Г. Ибраһимов: «Шигырьдә исә бер нәрсәне исбат тәкълим, мантыйкый бер дәгъва касд кыйлынмый, ул кешенең хиссиятенә, куәи хыялиясенә кагылу вә шул як илә үзенең идеясенә алып баруны юл тотадыр. Анда укучының рухын дулкынлата, йоклаган хиссиятен кузгата торган, фәгалияте фикериясен хәрәкәткә китерү вә теләгән якка юнәлдерү хасиятләре булырга тиеш... Аңардан киңәш, рәһбәрлек көтелми, бәлки абызыннан хәсән, җәмал коелуы теләнәдер»[3],— дип язды.

Шуның белән бергә, Г. Ибраһимов тарафыннан эшләнгән художестволылык теориясенең шактый чикләнгән, берьяклырак булуын да онытырга ярамый. Шагыйрь һәм әдипләрдән, алар каләме белән язылган сәнгать әсәрләреннән ул гүзәллек һәм матурлык таләп итте, ә гүзәллекнең чыганагын дөрес аңлатмады. «...Олуг шагыйрьләрнең хакыйкый шигырьләрендә,— дип язды Ибраһимов,— табигатьнең моң, мөәссир вә матур манзаралары, үзенең хиссияте шәхсиясе, әүлахы руханиясе мөһим урын тоталар»[4]. Ул гүзәллекнең чыганагын шагыйрьнең эчке рухи дөньясында, матур табигать күренешләрен тасвирлауда күрде, үз чиратында, бу — аны романтизмга китерде. «Татар шагыйрьләре» исемле мәгълүм китабында Г. Ибраһимов үзенең бу карашларын тагын да күпертеп җибәрде, чынбарлыкның гүзәл күренешләрен генә поэзиянең тасвирлау предметы итеп санады.

Татар әдәбиятында романтизмның көчәеп китүен, гадәттә, реакция елларының тәэсире, я булмаса татарлар арасында милли аң уяну белән аңлаталар. Татар әдәбиятын романтизм юлына этәргән сәбәпләрне эзләгәндә, югарыда әйтелгәннәр генә җитми кебек. Монда, бәлки, әдәбият һәм сәнгатьнең эчке ихтыяҗларын, үсеш закончалыкларын да исәпкә алырга кирәктер. Безгә калса, романтизмның ул чордагы татар әдәбиятында киң таралган һәм бик туйдырган үгет-нәсихәтчелеккә, дидактизмга каршы реакция рәвешендә туусын да инкарь итәргә ярамыйдыр. Хәтта шулай дияргә дә мөмкин: әдәбиятны, үгет-нәсихәтчелектән, риторикадан коткарып, чын сәнгать югарылыгына күтәрү өчен, аерым бер үзенчәлекле тарихи шартларда, бәлки, нәкъ менә романтизмның тууы кирәк булгандыр. Романтизм фантазиягә, әдәби хыялга киң җирлек тудырды, художник хезмәтенә мөстәкыйльлек бирде.

Ләкин, мәгърифәтчелек әдәбиятыннан килә торган үгет-нәсихәтчелекне, коры акыл сату һәм үгетләүне кире кагу белән бергә, романтизм әдәби иҗатны акылга буйсынмаган, акыл катнашыннан тыш бара торган

[1] Шунда ук, 56—57 битләр.
[2] Шунда ук, 35 бит.
[3] Шунда ук, 44—45 битләр.
[4] Шунда ук, 45 бит.

бер процесс итеп күрергә теләде. Рационализм әдәбиятына хас схематизмнан баш тартып, романтизм әдипнең иҗат хөрлеген яклады. Ләкин бу хөрлекнең мөмкинлекләрен арттырып, күпертеп күрсәтте.

Әдәби иҗат процессын романтизм принциплары буенча аңлату ягыннан карагында, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» китабы аерым игътибарга лаек. «Татар шагыйрьләре»нә бәя бирергә керешкәнче, бернәрсәне басым ясап әйтеп китәргә кирәк: бу китапта хәтта бик дөрес, фәнни фикерләр дә еш кына буталчык, идеалистик терминология ярдәмендә аңлатыла. Бу исә әлеге хезмәтнең кыйммәтен тагын да кимәтә төшкән.

Мәгълүм булганча, үзенең әдәби-эстетик хезмәтләрендә Белинский әдипнең табигый талантына, аның сәләтенә күп урын һәм зур әһәмият бирде. Ул поэтик фикернең, коры акыл хезмәте генә булмыйча, художникның пафосына, фантазиясенә, хисләренә дә бәйле икәнен аңлатты. Бөек рус тәнкыйтьчесенең бу карашларын Галимҗан Ибраһимов та уртаклашты. «Чын мәгънәсе белән шагыйрь булу өчен анаңнан шагыйрь булып туарга кирәк. Кеше үзе теләп шагыйрь була алмый, аны табигать ясый»[1],— дип язды ул «Татар шагыйрьләре»ндә. Аның фикеренчә, шагыйрь вәгазь сөйләүче, резонер түгел, ә рәссамчы, иҗатчы. Башкаларга ул үзенең таланты, шигъри сүзе белән тәэсир ясый.

Ул әдәби әсәрнең идеясе укучыга автор тарафыннан чәйнәп каптырылмаска тиеш, ә бәлки «сурәтнең тәмамы, торышы теге идеяне аңлатсын, сөйләп торсын», диде. Икенче бер урында болай дип тә өсти: «Тормыш агымы бөтенесеннән көчле, шуның өчен әдип, шагыйрь җанлы тасвирларда реаль тормышның күп төрле картиналарын сурәтләргә тиеш... Идея һәм фикер әсәрнең бөтен яңгырашыннан, тәэсиреннән аңлашылырга тиеш...» Бу — Г. Ибраһимов яклаган эстетик карашларның никадәр алдынгы булуы һәм бүген дә искермәве турында сөйли. Бу мәсьәләдә Ибраһимов марксизм-ленинизм классикларының сәнгать турындагы карашларына якынлаша...

Югарыда Г. Ибраһимовның эстетик карашлары шактый каршылыклы булуын әйтеп киткән идек инде. Чыннан да, аның эстетик карашларындагы йомшак якларга күз йому, аларны күрмәмешкә салышу — дөрес булмас иде.

Бер урында Г. Ибраһимов әдәбиятның бурычын «сәнгатькәрнең йөрәгеннән халык йөрәгенә турыдан-туры юл салу»да күрә һәм мәсьәләгә фәнни дөрес якын килә. Ләкин шунда ук, сәнгатьнең нинди дә булса бурычы, максаты турында сөйләшү «төпсез, мәгънәсез мәсьәлә» дип, үз фикерләренә үзе үк каршы да чыга.

Ләкин моңа карап кына Г. Ибраһимовны «саф сәнгать» тарафдарлары рәтенә бастырырга да ярамый. Аннан соң, әдәбиятның асылы, максатлары һәм бурычлары турындагы кайбер ялгыш карашларын ул, әле революциягә кадәр үк, төзәтә алды, фәнни нигезгә салды.

Бүген, Галимҗан Ибраһимов фәлән мәсьәләдә хата җибәрде, ул фәлән мәсьәләне дөрес аңлатмады дип, аның бай иҗат мирасына «печать» сугып утыру, билгеле, җиңел эш. Тик бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк: Г. Ибраһимов моннан күп еллар элек иҗат итте. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьнең үсеш дәрәҗәсе шактый түбән бер чорда, ул, төрле каршылыклар аша, ялгыша-ялгыша һәм хаталар ясый-ясый, берләнбер дөрес карашка килде. Моны ул бөтен иҗаты, үзенең бөтен гомере белән раслады.

[1] **Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Оренбург. 1913 ел. 12 бит.**

МӘХМҮТ ГАЛИЕВ

## КАЙБЕР ИСЕМНӘРНЕҢ МӘГЪНӘЛӘРЕ

Кибеткә чыгып азык-төлек алганда, аларның исеме русчамы, татарчамы яки французчамы икәнлеге турында уйланып тормастан, без аның сыйфаты турында фикер йөртәбез. Уйлап карасаң, ул исемнәрнең байтагы теге яки бу азыкның беренче мәртәбә кайда әзерләнүе, безнең халыкка кайчан һәм ничек килеп җитүе турында сөйли икән ич!

Сүзне **умачтан** башлыйк. Элек бу исемнең ике сүздән: **он** һәм **аш** сүзләреннән кушылып **он ашы** формасында йөртелгәне беренче караштa ук күренеп тора. Ә менә **колбаса** дигән исемне бездә әле дә **казылык** яки **казыдан** килеп чыккан дип уйлаучылар бар. Хәтта **казы** сүзен сәүдә эшчеләре ат казылыгы мәгънәсендә дә куллана башладылар һәм, белемнәре җитешмәгәннәре, аны **козы** дип ялгыш язалар.

Мәсьәләгә кайтыйк. Колбасаны руслар, поляклар — **колбаса**, украиннар — **ковбаса**, серблар — **ковбасина**, венгрлар — **колбас** һәм **малами** дип атыйлар. **Колбас** сүзе безгә таныш булса да, икенче сүз—**малами** итальянча **салами** сүзеннән алынган. Румын, чех һәм болгарлар да **салам** дип йөриләр. **Колбаса** сүзе славян сүзе булган булса, шуңа якын булыр иде. Чынлыкта исә, **колбаса** сүзе татарча сүз булып **кул** һәм **баса** дигән сүзләрдән үзгәртелгән, һәм руслардан үзебезгә кире кайткан. **Әртил** сүзе дә татар сүзе булса да, соңга таба бераз үзгәртелеп **артель** формасына кереп, үз телебезгә кире кайткан.




*Әхсән Баянов*

*Лирик повесть*[1]

Ул сүзсез генә тынлады. Соңыннан, аның йөзенә карагач, сөйләп нинди хата иткәнлекне абайладым: ул чырайдан язган иде, дөнья белән бернинди кызыксынуы калмаган төсле салкынайган иде. Мин куркып киттем: аның күңеле мондый салкынлыкка түзәрлекме икән?

— Фәһимә, кичер син мине, булдыра алсаң, кичер Фәһимә!

Кичерергә дә, кичермим дияргә дә әзер түгел иде әле ул. Мин моны сиздем һәм ашыктырмадым.

— Мине Уфада филармониягә чакырганнар иде. Эшкә. Мин кермәдем.

— Беләм.

— Синең яныңа кайттым.

— Әйе шул.

Кичке урам буйлап йөрдек. Базы күпере өстеннән суга карап тордык.

— Бу сулар Агыйделгә тоташа! — дим эчке мәгънә белән.

Фәһимә эндәшми. Соңрак салмак җыр белән җавап бирә:

> **Караңгы төн, болытлы көн,**
> **Без аерылган көн бит ул...**

— Агыйделдә без булган җирләрдә беркем дә юктыр инде, караңгы, тын...

— Әйе. Тып-тын. Син юкта, шушындый тын вакытларда, минем шунда китәсем килә иде. Син шунда кебек. Син Уфада түгел кебек.

Бу сүзләрне ул әйтте. Ул мине уйлаган. Ул мине сагынган! Кемне! Мин бит аның янында болай торырга да лаеклы түгел! Ә ул! Шушындый да мәхәббәт була икән! Һәм ул, нәкъ элеккечә, һичнәрсә таләп итми. Мондый яратуны минем ишеткәнем, укыганым юк, белмим.

---

[1] Ахыры. Башы 1—2 саннарда.

— Синең Агыйдел буена тагын барасың киләме? — дип сорадым мин һәм колакларыма ышанмаслык сүзләр ишеттем:

— Әйе, Агыйделне тыңларга, болыннарны тыңларга, былтыргы сүзләрне, былтыргы баян тавышын.

— Әйдә соң, барабыз.

— Кайчан?..

— Син кайчан барсаң, шунда.

— О! Хәзер бүре күп диләр анда, мин куркам...

— Ә минем мылтык бар, мин аны алып барырмын. Килешәбезме шулай?

— Карарбыз әле.

Мин аның кулларын тоттым. Куллар салкын, боз кебек. Мин аларны жылытмакчы булам, аңардан бигрәк, аларның жылысын тоймакчы булам. Ул минем кулны үзе дә чак кына кысса, куллары белән генә булса да сагынуыма жавап бирсә, бу минем өчен бәйрәм булыр иде. Юк, куллар жавапсыз, алар күрешкәндә дә, хәзер дә бер сүз әйтмиләр.

Ярты төн житкәндә, йокларга без аның квартирасына кайттык. Болын гадәтен яңартып, урынны өялды идәненә жәйдек. Тышкы ишектән кергәч каршы якта, бездән ярты метр гына алдарак, фанер бүлмә. Бүлмәсе кадаклап түгел, ничектер утыртып кына куелган бугай. Теге якка кәжә япканнар, шул ышкылган саен, фанера калтырап китә.

Түбәгә карап ятабыз. Түбә ярыкларыннан безгә йолдызлар жемелдәп карый, төнге сыек яктылык күзләрне иркәли, Фәһимә дәшми, нәрсә хакындадыр уйланып ята.

Кәжәнең бүлмәгә ышкынуы мине бераз сагаерга мәжбүр итә.

— Бу кәжә теге бүлмәне безнең өскә аудармас микән? — дим мин.

— Ауса, фанер гына ул...

Тып-тын. Йолдызлар жемелдиләр, менә черкиләр дә безелдәп куйды, борынга каяндыр яшь печән исе бәрелеп китте бугай. Бу минутларга ни житә, янда иң яраткан кешең булган минутларга! Менә шушы кызның үзем өчен шушы кадәр дә якын икәнен моңарчы нишләп аңламадым икән? Ул бит минем өчен бердәнбер, аны яраткан кебек итеп мин беркемне дә яратмыйм икән бит!

Әрнүемне басар өчен, аны кочаклыйм, ул мине читкә дә этәрми, тик үзе чак кына да, һичнинди дә хис белдерми, әйтерсең — жансыз. Мин аңарда күкрәкләремә яратып суккалый торган, кочакларыма сарыла торган Фәһимәне эзлим, ә ул юк. Ул — жавапсыз.

Ул һаман уйлануында, бөтен дөньяны онытып, шашынып яратсаң да, халык әйткәнчә, кыйнасаң да бер сүз әйтмәс шикелле ята да ята.

— Һавадагы иң якты йолдыз... Хәтереңдәме?

— Син миңа ул чакта әйткән идең: син бер нәрсәнең дә кадерен белмисең, дигән идең. Иң изге нәрсәңне югалтырсың дип курка идең. Хәтеремдә.

— Мин сиңа алай әйтмәдем.

— Минем шулай хәтердә калган.

— Дөрес калган. Барыбер дөрес ул.

Хыялланып, сөйләнеп озак яттык. Аны да, мине дә йокы алмый. Хәзер ул минем хәлләрне сорашмый, үзенең эше турында, авылдагы хәлләр турында сөйли. Ә кәжә, үч иткәндәй, һаман кыштырдый. Дөпдөп тырмаша, мөгезләре белән бәрелә... Бер мәлне, бөтен гәүдәсе белән ышкына башлаган иде... Мин нәрсә булганын аңлап житкергәнче, нәрсәдер дөп итеп идәнгә төште, тагын, тагын... Һәм без кул астында, йөзәр хәлдә калдык.

— Әләй, кәжә суны түкте! Тизрәк тор, су баса! — дип кычкырды Фәһимә. Һәм көлеп жибәрде.

Бу мизгелдә бу көлүнең миңа никадәр сөенечле икәнен сез аңлыйсыздыр инде. Бәлки, шушы хәлдән соң ачылып китәр ул.

Сикереп тордым да авып төшкән чиләкләрне янадан эскәмиягә куйдым. Өйдә Фәһимәнең иптәш кызы уянган, ул да көлә. Ярый әле кәжә булды, бер секундта икебезнең дә күңелләр күтәрелеп китте менә. Без инде яңадан ятмадык, чөнки яктыра башлаган иде. Июнь төне шулай була бит.

Фәһимә мине күпергә хәтле озата төште. Юл буе кәжә, я тегеләй, я болай, безнең телгә керә дә күңелне күтәреп җибәрә иде. Соңыннан, әлеге беркатлы җиңеллеген саклаган хәлдә, сүз уңаенда гына әйтеп куйды Фәһимә:

— Кәҗә акыллы ул. Сине юарга кирәген белә, Ленадан соң...

— Хуш, Фәһимә, вакыт юар әле... Менә күрерсең, без күзләребезгә туп-туры карый алырбыз.

— Белмим шул.

— Мин сине икенче елга Агыйделдә көтәм.

— Икебезне дә бүреләр ашамаса...

— Хуш!

...Ул бүредән курка. Ләкин болында куак арасында безне бүредән дә хәтәррәк бәла көткәнен ул башына да китерә алмаган икән шул. Мин үзем дә.

* * *

Аның күзләренә туры карар өчен, тормышны яңача корырга, «намус» дигән, күренми торган сызыкның бу ягында, сафлык, гаделлек ягында торырга кирәк. Менә мин хәзер шул якка чыктым.

Авыл тирәләрен карыйм, басуларда йөрим. Июль ае житкән инде, ә печәннәр чабыла гына башлаган... Арыш өлгергән... Басуда — ике-өч кеше... Комбайн — биш-алты колхозга бер әү. Кайчан җыеп бетерерләр, алла белә.

Җир! Элек колхоз кешесе җирдән доход ала иде. Эшләсә, белеп тора: аңа моның өчен күпмедер тиеш. Хәзер аңа эшләсә дә юк, эшләмәсә дә юк. Шуңа күрә эшләмәү — яхшырак, көч аз китә. Эштән бизә. Җир — игенченең намусы ул! Игенче җирдән аерылгач, намусыннан да аерыла. Мәхәббәтсез, музыкасыз яшәгән кебек.

Шомлы җәйге кич. Кояш баеп, энгер-менгер чак җиткән. Куак арасыннан кичке басу киңлекләренә карап уйланам.

Күрәм, олы юл басуыннан мин торган якка, түбән таба, казлар кебек тезелеп, хатыннар килә, уракчы хатыннар. Башларына каралып төсе киткән яулыклар бәйләгән, озын күлмәкле, киң күлмәкле билсез хатыннар. Сүзләре бетәсе түгел, басу яңгырап тора. Әллә кычкырышалар, әллә сөйләшүләре шул. Икесе дә алар өчен бик табигый. Юллары минем яннан уза, миңа каршы якта тагын куаклык. Хәзер мин боларны карап калырга тиеш. Авылдаш апалар, гайбәтче, явыз, юаш, акыллы, булдыклы хатыннар. Бу заманда аларның бер генә сыйфатлары җуелган — иркәлек... Авыл хатыннары... Авыл өйләрендә учакларда ут яна икән, моржалардан сирәгрәк булса да төтен чыга икән, болар тик сезнең аркада гына бит. Авыл хатыннары!

Менә алар минем турыга якынлаштылар. Ишетәм: кайсыдыр улын көтә, сугыш беткәнгә байтак узды, кайтам дип хат язган...

Кайберсенә иренең үлүе хакында хат килгән, шулай да ул көтә. Үз күзе белән күрмәгәч, ышана алмый. Кайсылары кемнәрнеңдер ирләрен кызгана: кайткач килешә алырлармы, янсә гафу итәрләрме?

Кайчак гөнаһ та ят түгел аларга, шулай, нишлисең бит...

Алданрак килгән хатын ана каз кебек нидер кычкырып куйды, аңардан соң башкалары кангылдашты... Бүре күргәндәге кебек... Бүреме? Юк, каршыларына ап-ак костюмлы берәү килеп чыккан икән. Хатыннар төрлесе төрле якка таркалдылар. Ак костюмлы кеше, теге дөньядан

кайткан эрвах төсле, аларны куркыта, артларыннан чаба. Күпмедер җир киткәч берсен эләктереп тә алды. Тегесе ычкынып китте, монысы тагын куып җитте. Ир кеше бит, бу юлы көче җитте, ычкындырмады. Хатын чыелдап кычкыра, көтүеннән аерылган кош шикелле. Ир кеше дә усал кычкыра.

— Туктал яхшылык белән, күрсәт, нәрсә бар анда...

— И-и, Сафуан, Сафуан, нишләп оят түгел сина хатыннар итәген тикшереп йөрергә. Оялмасаң, күрсәтәм, мә, кара...

Сафуан абзый! Син шушыңа да сәләтлемени? Шушы хәтле вакланырсың дип башыма китермәгән идем!

— Итәк астың кирәкми миңа. Болай да беләм, билеңә урап арыш тутыргансың, чыгар, сал хәзер...

Тарткалаша торгач, тәки чыгартты арышны:

— Син аларны урак урырлар дип җибәрәсең, алар анда башак урып яталар.

— Нишлик соң, ашарыбызга тамчы да калмады бит. Ышанмасаң, өйгә кереп кара, шалтырап тора.

— Миңа анысы караңгы.

— Нигә караңгы булсын, кер дә кара ышанмагач, балалар ач утыра, ике көн инде җылы аш күргәннәре юк. Арыш киптереп өйрә пешермәкче ием. Сафуанкаем дим, елатма балаларны, каргышлары төшәр...

Сафуан абзый хатынның ай-һаена исе китмәде.

— Миңа түгел, милициягә сөйләрсең, — дип, бер төенчек арышны тәки калдырырга мәҗбүр итте.

Башка колхозларда, минем ишеткәнем бар, ике йөз грамм өчен алып киталәр икән. Бу хәл хәзер бөтен халыкка билгеле. Ләкин безнең бу хатыннарны алмадылар. Ничек алай, төшенмим. Тик Сафуан абзыйның болай йөрүе дә сагайта.

Берничә көннән тагын шул хәл кабатланды. Хатыннар гына түгел, малайлар, егетләр дә башак кыркый иде. Шулай, хәзер көлке, ләкин бернишли алмыйсың... тамак тәмугка кертә. Менә ул ничек эшләнә: капчык авызына җеп бәйләп муенга эләсең дә уң кулга урак, сул кулга арыш башакларын тотып кистерәсең. Икенче көнне игеннең сабаклары гына тырпаеп утыра. Җәл иген дә, кешеләр дә кызганыч. Башак кыркырга бер көнне мине дә ияртте..р, тик шул көнне үк чәнти бармагымның шактый итен кисеп ташладым. Кан ургылып ага. Каяндыр чүпрәк табып бәйләдем дә, үземә һәм кешеләргә карап, тын калдым. Айлы июль төне нинди матур, ә без нинди эшләр белән йөрибез. Акылга сыярлык түгел.

Минем кулда урак. Безнең дәүләт гербының бер элементы. Хезмәт ярату символы. Аның хуҗасы булу өчен безнең әтиләр кан түккән! Ә минем кан аңа мәгънәле эш өчен буялмады. Урак тотып ант итәм: ул мәгънәне мин табарга тиеш, хәзер үзем чыгарган бу бәяне, кан бәясен акларга тиеш. Кан һәм мәгънә... Кан һәм мәгънә... Бүген соңгысы болай йөрүнең.

Йөз метрлап ераклыкта куак кыштырдады һәм аннан тагы ак костюмлы кеше килеп чыкты. Аны күрүгә хатыннар тагы бөтенесе бергә чәрелдәп җибәрделәр. Малайлар, яшьрәкләр, пошилар шикелле, шабырдау, дөпелдәү тавышлары чыгарып, күз ачып йомганчы юк булдылар. Хатыннар исә, капчыклар белән булыша-булыша, беркая китә алмадылар. Сафуан абзый беркөнге хатынны — Хәтирә апаны күргәч, кычкырып ук җибәрде:

— Ә! Син тагын килдеңмени? Урлашырга ярамаганны төшенмәденмени әле. Алайса, яхшылыкның кадерен белмәдең. Иртәгүк под конвой китәсен. Бетте.

— Без генә түгел бит, бөтен тирә-якта шулай, без ачтан үликмени? — дип шаулашкан бүтән хатыннарга Сафуан абзый:

— Капчыкларыгызны шушында бушатыгыз. Барыгыз да. Берегез амбарга илтсен. Бушатмаганнар яхшылык күрмәсен.

Шул минутта мин үземнең дә җинаять эшләгәнемне һәм Сафуан абзыйдан куркып куак артына яшеренгәнемне, яфрак арасында торган килеш һаман тегеләрдән күз ала алмавымны абайладым. Үзем гаепле булгач, бүтәннәрне дә яклый алмыйм.

Алар һаман бәхәсләшәләр. Хәтирә апа аңлашылмаслык, бәйләнешсез сүзләр кычкыра:

— Тимә, Сафуан, ирем кайтыр вакыт житеп беткәндә харап итмә. Көлкегә калдырма. Юк, юк, мин риза түгел, язмаганны. Әни үпкәләр... Балалар көтә... ачуланмасыннар.

Аңа карап торуның никадәр кызганыч икәнен белсәгез иде! Һәм мин түзә алмадым. Сафуан абзый янына атылдым да каршысына бастым:

— Бир хәзер үк, нәрсә алдың?..

Сафуан абзый, үз колагына үзе ышанмыйча бугай, гаҗәпләнеп карады.

— Син нәрсә?

— Нигә кыраннатасың бу хатыннарны?

Сафуан абзый йомшак тавыш белән әйтте:

— Син катнашма монда, кирәкми.

— Катнашам. Белеп тор, икенче тапкыр хатыннар куып йөрүеңне күрсәм...

— Кара, ничек сөйләшә!

— Мин чынлап.

— Чынлап булса, шул сиңа: колхоз тормышына катнашу өчен анда эшләргә кирәк. Ә синең хакың юк. Без үзебез карарбыз.

— Мин колхозда эшләмәгән кешеме?

— Хәзер.

— Хәзер дә эшләрмен.

Без кычкырышкан арада баягы хатын көләргә тотынды. Әллә акылдан яза инде, басу яңгыратып көлә. Аның көлүе Сафуан абзыйның дөрес сүзләре белән берләшеп йөрәккә кадала. Бәлки, чынлап та хакым юктыр. Монда эшләмәгәнгә елга якын вакыт үтте, хәзер бу кырлар, бу игеннәр минеке түгел микәнни инде? Сафуан абзый ничек кырыс сөйләшә хәзер! Ничек үзгәреп китте ул! Моннан бер ел элек кенә бөтенләй башка иде. Митинглар, чыгышлар... Әллә ораторлык осталыгын да югалттымы? Сәбәп нәрсәдә? Җылы сүз әйтүдән бигрәк, куркытып эшләтә, сугыш вакытында болай түгел иде. Әллә, куркыныч еллар узгач, күнеле тупасландымы? Менә бу хатын — Хәтирә апа... Аны ник рәнҗетергә?

Хәтирә апа!

Бәлки, ул да тиздән кайтыр дип ирен көткәндер, мең төрле планнар коргандыр...

Хатыннар, күлмәк асларына кыстырып, граммлап алып кайталар. Ә кайберәүләр ат йөге белән ташый. Ә Сафуан абзый аларны күрмиме? Юриме, ялгышамы, куркамы? Ничек кенә булса да, аңа моны исбат итәргә кирәк. Кемнәрнең ничек урлаганын мин сизенәм.

...Базы елгасы басуында комбайн бодай ура. Кичкырын Хәмит ат җигеп шул таба китте. Озак та үтмәстән, мин Хәмитләрнең ындыр юлы тирәсендәрәк агачлыкка ышыкландым. Аның әйләнеп кайтуын көтәм.

Бер сәгатьләп торам — юк. Ике сәгатьләп торам — күренми. Әллә урам капкадан кайттымы? Алай дисәң, капка шыгырдаганы ишетелмәде. Аннары, урам буйлата ук кайтырга йөрәге җитмәс.

Төн уртасы якынлашканда, ындыр артында ат пошкырганы ишетелде. Менә ат бирегә таба килә... Шул булырга тиеш. Безнең ындыр буеннан ук йөри икән! Сикереп торып каршына бастым.

Ат тукталды. Хәмит арбадан сикереп төште, тавыш-тын чыгу юк.

Хәмиткә үзебезнең бакчада мине күрү бер дә гаҗәп түгел, нәрсә уйлап монда килүемне, нишләргә җыенуымны да башына китермәгән иде, билгеле.

— Капканы ачып та куймагансың! — диде ул шаяртып.

Бер секундта аңа ярдәм итәргә, әрәтәләрне алышырга кузгала да яздым. Әмма шундук күз алдыма Хәтирә апаның монсу күзләре килеп басты. Алар миңа текәлделәр: «Гаделлекме бу?» дип сорау бирделәр һәм җавап таләп иттеләр. «Гаделлекме бу? Тигезлекме? Кемнендер өенә ашлык йөкләр белән керсен, ә кемнендер... Монда безнең өлеш, әнә теге кыр казлары төсле тезелеп йөргән хатыннар өлеше түгелмени? Кеше хакын ашап яшәргә син дә юл куйгач, кем генә безне яклар?» — йөрәк әчетеп, сулкылдап китте һәм мин шул минут дустымны рәнҗетергә мәҗбүр булдым:

— Әйдә, Хәмит, кире бор атны!

— Я, котырма, иртәгә үзеңә алып кайтырбыз. Шаяртма.

— Шаяртмыйм. Минем өйдә бура тулы ашлык. Миңа кирәкми.—дим.

— Былтыр җитәрлек җыйгансыңдыр шул. Сөйләгәннәр иде аны.

— Ничек? Мине син үзегез дип беләсеңме?

— Былтыр весовщик булып эшләгәндә өч йөз центнер ашлыгың җитмәгән.

Көтелмәгән мондый гаеп ташлавыннан ачуым купты. Ниндидер каты сүз әйтергә тырыштым, тик андый сүз табылмады. Ачулансаң, һәрвакыт шулай була бит.

— Өч йөз центнер! Алдашма! — дидем мин, күкрәктә авырту тоеп.

— Килмит абыең гына йомды. Югыйсә, башың...

Ул, әлбәттә, хәзер миңа ачу итә. Мондый вакытта кеше ни әйтмәс. Шулай да минем эчкә шом керде: нинди өч йөз центнер ул? Үз башыннан уйлап чыгара алдымы икән? Юк, юк, мин мөмкин кадәр дөрес, гадел исәпләргә тырыштым ашлыкны, ялгышсам да шул кадәргә ялгышу мөмкин түгел... Ачыкларга, болай калдыра торган эш түгел бу...

— Исеңә төштеме? Я, быел гына акыллыланган булма, бүлешик.

Аны тыңларга, йөкне бүлешергә минем бөтен нигез бар, ашлык һава кебек кирәк, аннары... Тагын Хәтирә апаларны хәтерләп, үз сүземдә тордым.

— Сөйләштек, җитте. Киттек.

Ачуланып та карады, үпкәләп тә, куркытып та — барып чыкмады. Соңыннан ялынган тон белән:

— Мине утыртып синә нәрсә була инде? Я? Тамагың туямы?

— Тегендә ике йөз грамм өчен хатыннарны бишәр елга утыртканда, син йөк белән урлый торып, тыныч яшәмәкче булдыңмы? Ярый, мин син уйлаганча ук явыз түгел, бер юлга калдырам...

— Әйдә, монысын сезгә кертәбез, — диде Хәмит, тиз генә әләктереп, — миңа — иртәгә.

— Кызык син. Амбар алдына илтәбез.

— Үзе бер юлга калдырам, ди... Ничек була инде...

— Син бригадир кеше ич, басуда калган ашлыкны кайтарырга миңа куштың. Үзең, контрольлек итеп, каршы алдың. Яхшы бригадир ич син. Җитмәсә, дуслар без.

— Э-э... әйе шул, дошманмы әллә!

Атны тавышсыз-тынсыз гына борды. Бераз баргач, дилбегәне үз кулыма алдым:

— Миңа хезмәт көне язарга туры килә инде... — дидем мин, елмаерга тырышып.

Ул көлмәде. Аяк астына карап, сүзсез генә атлый бирде. Үз турларын узгач, әзгәләнеп:

— Җүләр син! — дип куйды.

Бәлки, дөрестән дә җүләрлегемдер. Ләкин мин үземә, нинди хәлдә калсам да, теге куркыныч сызыкның аръягына атламаска, намуска хыянәт итмәскә сүз бирдем ич. Ул якка минем өчен юл юк хәзер. Беркайчан да!

Амбар алдына килеп җиттек. Каравылчы Фазлый бабай, таягына таянган килеш, сөйләшә-сөйләшә каршылады безне.

— Төн убырлары! Сез икәнсез әле. Нишләп болай бик соңлап? Нишләп йөрисез?

— Тегендә арба тәгәрмәче чыгып йөдәтте, — дидем мин, аклanып, — ярый әле Хәмит эзли килгән, үзем генә таң атканчы азапланыр идем.

Шул арада, җир астыннан үсеп чыккан кебек, Сафуан абзый килеп чыкты. Ул шушы тирәдә, ул-бу булмасмы дип, бу юлы да сагалап яткан, ахрысы.

— Молодцы, тегеләй-болай борылмагансыз, — диде ул.

— Болар ышанычлы, — дип мактады безне Фазлый бабай. Килмит бүген ак киемнән түгел, ә яшел кительдән, озын кара чалбар һәм туфлидән иде. Башындагы хәрби фуражкасын кулына тотты да рәхәтләнеп бер сулыш алды.

— Яз да әйбәт килде, егетләр, җәй дә. Уңышы гына юк. Бөртекләп җыймасаң, беребезгә дә калмый. Колхозчыга да, дәүләткә дә.

Ул көшелгә утырды, аннары чалкан ятты. Арыган, күрәсең, күпмедер вакытка тынып калды. Бу көннәрдә ул басудан басуга чаба, һәр җирдә көн саен аны нинди дә булса күңелсезлек каршы ала: я берсенең аты буразнада егылып үлгән, я күрше авылда бер ферма сарыкны бүре буып чыккан, кайдадыр сушилка җимерелгән, кемдер ачтан шешенгән, кемдер кар астында калган ашлык ашаудан кан эчендә ята... Барысы өчен дә ул җаваплы, барысына өлгерергә, чарасын күрергә тиеш. Ачу килүләрне читкә ташлап чынын гына әйткәндә, ул кайтып ике-өч ай эшләгәч үк, авылда хәлләр сизелерлек яхшырган. Моны бөтен авыл күрә. Ләкин бит әйтү генә ансат: ничек, нинди бәрелешләргә дучар була ул моның өчен!

Аның хәлен аңлап, кызганып, сүзсез калдык: әз генә булса да ял итсен.

Ләкин берничә минут үткә, Сафуан абзый башын күтәрде. Фазлый бабай белән безнең уйлар бергә туры килде, ахрысы. Ул нәкъ мин әйтергә теләгән, тик әйтмәячәк сүзләрне җиткерде:

— Син, Сафуан энем, кайчан гына йоклыйсың соң? Көндез басуда, төнлә тагын монда.

— Йокылар качты инде, Фазтин абзый. Урлаша бит халык. Бөтен ашлыкны тарката. Кышын ач утырачагын уйлый белми. Бөртекләп җыя алсак, ашлыгы булса, мин аларны ачлыктан саклый алыр идем. Юлын табар идем. Ә болай? Ятсаң кузгә йокы керми. Менә әле — сез сөйләшми торган арада бераз оеп алдым. Юлда тарантаста шулай кайтасың. Урак өсте, диләр моны. Урак өсте!

— Һәм печән өсте! — дип ялгадым мин аның сүзләренә.

— Әйе. Каһәр суккан. Печәне дә чабылып бетмәгән. Чабылганы кибәндә түгел, күбесе күбәдә чери.

— Мине шул эшкә җибәрегез әле, Сафуан абзый. — Ул чак кына сәерсенеп калган арада дәвам иттем, — минем дә кеше арасында сүзгә катнашасым килә.

Ул әле бер-ике көн генә элек миңа әйткән кинаяле сүзләрен исенә төшерде, мөгаен.

— Ярый, бар. Иртәгә үк кит. Синең кебек көчлерәк кешеләр монда ашлык тирәсендә кайнарга тырышалар...

«Кышлык азык җыеп калырга», дигән мәгънәсен әйтми калдырды ул.

— Миңа хезмәт көненә бирелгәне дә җитәр.

Шушы урында Фазлый бабай рәхәтләнеп көлде. Бер читтәрәк ат тугарып маташкан Хәмит тә атын тышаулап җибәрде дә безнең янга килде. Ул безнең сүзне тыңлап торган икән.

— Былтыр дүрт йөз грамм булдек, — диде ул.

— Нишләп?

Фазлый бабай тагын көлде дә аңлатырга керәште:

— Соң синең киткәнеңә бер генә ел лабаса. Онытырга да өлгергәнсең. Каян аласын ашлык, җитмәгәч.

— Былтыр ашлык бар иде, — дим мин, — димәк, каядыр таралган. Өчәр йөз центнерлап.

Бу сүзне ишетүгә Хәмит сикереп торды:

— Ни сөйлисең син?

— Үзең әйттең ич, былтыр мин үлчәгән...

— Анысы синең хата.

— Ялган!

— Сине быел ул эшкә куймаулары ни өчен дисең, алайса?

Аның мине күрәләтә кимсетергә маташуы чыгырымнан чыгарса да, тыелып калдым. Зурлар алдында тавыш куптарырга ничектер кыюлык җитмәде. «Синең белән сөйләшергә дә теләмим мин», дигәнне аңлатып, Сафуан абзыйга эндәштем. Сүз корырак чыкты бугай, чөнки ишеткән җавабым буенча шуны чамаларга мөмкин иде.

— Бригадир булдым дигәч тә аңа теләсә ни сөйләргә ярыймы? Кешедән көләргә дә рөхсәт ителәме? Мин үлчәгән ашлык ялгыш чыккан, ди. Син генә яклап калган, ди. Миңа кем ярдәме кирәк?!

— Ташла син пүчтәк сүзне.

Гарьләнүдән шактый кыза төшкәнгәме, мин туктала алмадым, Сафуан абзыйның алдына ук күчеп утырдым:

— Әгәр чыннан да ашлык җитмәгән булса, бу — минем гаеп түгел. Бу — сезнең гаеп.

— Кемнеке? — Бу сорауны Хәмит бирде.

— Минннән соң ашлыкка кем хуҗа?

— Персидәтел.

— Хуҗалар гаепле монда. Каядыр куйганнар.

— Җиттеме сезгә, юкмы в конце концов?

Бер секундта баштан шундый көйдергеч фикер узды: «Сафуан абзый сөйләтергә теләми, алай булгач...»

— Алай булгач, монда председатель гаепле, — дидем мин кабат.

Болай ук әйтергә уйламаган идем, сүз үзеннән-үзе ычкынды. Сүз чыпчык түгел, бер очса аны тота алмыйсың һәм мин үземне куркудан калтырангандай тоя башладым.

— Уз абыеңа үзең пычрак атасың, — диде Фазлый бабай, офтанулы тавыш белән.

— Ә миңа пычрак ташларга ярыймы? Белеп торыгыз, мин моның азагына чыкмасаммы!

Сафуан абзыйның да ачуы кабарган иде булса кирәк, озак кына сүзсез торды. Аннары, үзе дә уңайсызлангандай тотлыгып, онытылмый торган тупас һәм мәгънәсез сүз әйтте:

— Азагына чыкмакчы! Чыкмыйни син! Таз!

Теләсә нинди сүзен күтәрә алам, ләкин кимсетүне мин бервакытта да кичергәнем юк...

Ул караңгыга кереп югалды. Мин сүзсез генә өйгә таба борылдым. Хәмит тә минем арттан иярде, тик ул өйләренә кереп калганчы безнең арада бер сүз дә булмады.

Икенче көнне кич белән Килмитнең өенә кереп, телдән әйтә алмаган сүзләрне хатка күчереп калдырдым:

«...Син миңа беркемнән ишетмәгән сүзләр әйттең. Ә мин әйтә алмадым. Синең кебек үк кыргый түгелмен, ахры. Ярый, шулай булсын. Ләкин син хәзер белеп тор: мин аңладым — өч йөз центнерны син йоткансың. Җавабын да бирәчәксең. Таз энең хәзер синең өчен ут-ялкынга әвереләчәк!»

Монда бер искәрмә кирәк. «ут-ялкын» сүзен мин күчермә мәгънәдә язган идем. Ә Сафуан абзый аны туры мәгънәсендә аңлаган. Шул харап итте эшне...

Хатны язганга үкенәм дия алмыйм, ләкин гарьләнәм, кыюсызлыгымнан гарьләнәм. Ул сүзләрне мин аңа ни өчендер күзенә карап әйтә алмадым. Ачу килсә дә, туган кеше бит; мин аны күрәлмыйм һәм яратам...

* * *

Ул көнне мине колхоз эшенә — эскерткә көлтә ташырга җибәрделәр. Көн буе басуда йөреп арылса да, бүген күңел күтәренке — безнең сүзгә катнашма дип беркем әйтә алмый хәзер. Менә бит эшнең нинди мәгънәсе бар икән: ул сиңа хокук бирә. Үземнән канәгать хәлдә, шулай, көтү кайтыр алдыннан, югары очтан үзебезнең очка кайтып барганда, кинәт үзем дә сизмәстән тукталдым. Хәтирә апалар өе икән, аның хәлен беләсем килде: теге көнне әллә ничек тоелган иде миңа, акылдан язган төсле. Хәер, юктыр, авыл өйләре бер-берсенә чыбыксыз телефон аша бәйләнгән, андый-мондый нәрсә сәгате-минуты белән урап чыга. Шулай да, керим әле...

Капканы ачасы юк, ул ярым җимерек хәлдә җирдә ята, бер башы гына утырып тора. Капкадан күптәннән ат-арба узмаганын тар гына җәяүле сукмак күрсәтеп тора. Бөтен ихатаны яшел үлән баскан. Күтәрмәгә баскан идем, чак кына егылып төшмәдем: кадаклары купкан икән, яңадан беркетергә кешесе дә, вакыты да кирәктер инде.

Шәһәрчәрәк итеп ишек шакыдым, җавап бирмәделәр. Ишекне ачып кердем:

— Өйдә берәрсе бармы?

Җавап бирмәделәр. Түргә уздым, җан иясе юк. Өйнең һәр почмагын тикшереп йөри торгач, кайдадыр кеше тавышы ишетелгәндәй булды. Карасам, кровать астында Хәтирә апа!

Бу вакытта миндә нинди хисләр туганын беләсегез! Иң башта күз алды караңгылангандай, кемдер каты итеп суккан һәм кыйнавын дәвам иттергәндәй тоелды. Курку, аптырау, белергә тырышу башта берьюлы бутала башлады.

— Хәтирә апа! Син ни бу!

Ул эндәшмәде.

— Я инде, эндәш инде! Син бит бу! Ник кердең анда? Бу мин — Әнис булам. Миннән курыктыңмыни! Әйт әле, миннәнме?

— Юк! — диде ул, куркынган хәлдә бөрешеп. Шундый көчсез иде аның тавышы. Шулкадәр кызганыч.

— Нәрсәдән курыктың син? Нидән?

— Кайгыдан... Хәсрәт күп, артык күбәйде. Шулардан куркам, шулардан качам!

— Хәтирә апа! Җүләр син! Кайгыдан шулай кровать астында котылып буламыни! Чык тизрәк, чык әйдә, кеше көлдермә, исәрләнгән диярләр.

— Юк, юк!

Мин аны кулыннан тотып чыгармакчы булган идем, ул чырылдап кычкырып җибәрде:

— Кит! Кит!.. Чыгып кит!

Ниш;ләргә инде мондый хәлдә? Чыктым. Амбар алдына — Фазлый бабай янына килдем. Ул юк, каядыр киткән. Шул тирәдә генә дустым Әзһәрләр өе — аңа кереп киңәшим...

Аларның да өйләренә тәрәҗләр салынган. Ярым җимерек.

Кердем. Өйдәләр икән, тик Әзһәр урында ята... Әнисе аны кроватена утырып саклый.

— Ни булды?

— Авырый. Кичә кичтән бирле.

— Нәрсәдән?

— Колхоздан алган оннан боламык пешереп биргән идем. Он дигәч тә, ямь-яшел нәмә. Шуны ашагач егылды, — диде әнисе, еламсырап.

Минем тавышны таныгандыр, ахрысы, Әзһәр башын күтәрде.

— Таныйсыңмы, кем килгән? — диде әнисе, улын торгызырга теләп.

Әзһәр чыннан да бик тиз генә торып утырды. Ике кулы белән дә битен сөрткәндәй итте дә мина карады. Ай, ул күзләр! Алар бөтенләй башка дөньяга карыйлар! Мин моны беләм, эшләр болайга ук киткән икән инде.

— Танымыйча! — диде Әзһәр, бернигә исе китмичә.— Әнис ич!

Мин якынрак утырдым, сөйләшмәкче, соңгы кабат сөйләшеп калмакчы, эчтә җыелганны аз гына булса да бушатмакчы идем. Ә ул кузгалды да чыкты да китте. Авыртуга чыдый алмый, мөгаен. Аның, чынлыкта, ярым җуйган ич инде ул! Миңа моннан соң нәрсә кала? Мин нишләргә тиеш? Кем белән сөйләшим? Кайсы өйгә керим? Анда мине кем, нинди хәлдә каршылар? Кинәт шул минутта миңа бөтен авыл сугыш җәрәхәтеннән җәфа чигеп, үлем түшәгендә ятадыр төсле тоелды.

Тирә-якны безгә инде күптән таныш булган куркыныч тынлык урап алгач, тагын да кыенрак булып китте. Төн буе, йокы аралаш, авылны— шул олы хәстәне урыныннан торгызырга, терелтергә тырышып, бастырылып чыктым. Ярый әле кояш чыга. Көндез җиңелрәк төсле. Тагы басуга менеп киттем. Анда инде атлы машина белән ашлык сугалар: барабан гүләве, ат куган тавышлар, барабанчының:

— Әйдә, куала! — дип кычкыруы ишетелә.

Әһә, тормыш бар икән әле. Авыл әле бирелмәгән, ул яралы, ләкин егылмаган, ул көрәшә. Тегендә туплар тавышы инде тынса да, монда андагыдан да ким булмаган каты сугыш бара. Бу сугышның да үз геройлары бар, үз полководецлары.

Менә Сафуан абзый хакында уйла син. Авыруы, бөере начар булу аркасында фронтка җибәрмәсәләр дә, монда ул андагыдан ким файда китермәде: колхоз ел саен күпме ашлык җибәрә иде... Тик менә соңгы вакытта... Әйе, ул — командир, батыр җитәкче, ләкин аңа орден бирмиләр...

Тагын бер көн үтте. Кояш батып килә. Ишкарга барырга уйлыйм. Бүген бүтәннәр дә шунда барачаклар икән, колхозда эшләгән һәр кешене клубка чакырганнар — медаль бирәләр, ди. Соңгы көннәрдә мин уйлап йөргән орденнар булмаса да, бөтен илгә таралган җиңү медале монда да килеп җиткән.

Клуб.

Әле бер-ике ел гына элек шаулый торган кичке дәрт хәзер бөтенләй сизелмәс хәлгә килгән. Кешеләр йөзендә елмаю, бер-берсенә әйтелә торган шаян сүзләр юк, гармоньнар кайдадыр хәрәкәтсез ята, җыр, әйтерсең, канатларын салган, тынган.

Халык ярты төн дигәндә генә җыелды. Ә эскәмияләрдә урын барыбер бетмәде. Әлегрәк, урын беткәч, басып торучылары да хәтсез була иде.

Сәхнәдә — өстәл кырында ике лампа яна. Берсе асылмалы, куыклы лампа. Куыгы корымланып беткәнлектән, уты сары нокта булып

кына күренә. Икенчесе — сукыр лампа. Ишектән кеше кергән саен леп итеп сүнә, аның саен кемдер шырпы сызып филтәгә ут кабыза.

Президиум өстәлендә Килмит һәм миңа таныш булмаган өч-дүрт кеше. Алар районнандыр инде. Сафуан абзый трибунага килде. Башта халыкның зур тантана уңае белән җыелганын хәтергә төшерде. Аннары фашистларның җиңелүе, совет халкының сугыштагы һәм тылдагы батырлыклары хакында сөйләде. Бүтән чакларда ул, мондый тантана булмаса да, һәрвакыт көр күңелле, якты йөзле була һәм шул күтәренкелекне тыңлаучыларга күчерә иде. Ә бүген, киресенчә, аның чырае гадәттәгедән караңгы, сукыр лампа сөреме аның йөзенә төшеп, чыраен тагын да күңелсезләндерә, ак йөзен каралтып күрсәтә.

Менә ул колхоздагы хәлләргә күчте. Авылның яхшы кешеләрен, эшчәннәрне мактады, кыенлыкларны да читләтеп узмады.

— Сездән яшерергә теләмим, хәл авыр. Келәт буралары шылтырап тора, колхоз амбарларында да шул хәл. Ләкин без кулдан килгән бөтен нәрсәне эшлибез. Кичәге көннән алып, колхоз эшенә чыккан һәр кешегә көндезлеккә аш — итле аш! — оештырдык. Тора-бара хезмәт көненә дә бүлә башларбыз. Ләкин шунысын тагын бер кат колагыгызга киртеп куям: басудан бер грамм ашлыкны да урлау булмаска тиеш. Күрше колхозларны ишетә торгансыздыр, аларда урлашу дигән нәрсә таралган. Кичә генә район үзәгендә зур бер җыелышта да шул турыда сүз булды. Иптәшләр, турысын әйтәм, позор бу! Бәхетебезгә каршы безнең колхозда мин мондый хәлне күргәнем юк. Моны киләчәктә булдырмас өчен, нык сөйләшеп, килешеп куйыйк. Ач каласыгыз килмәсә, урлашуны башыгызга да китермәгез.

...Ничек, урлашу юк, дидеме ул? Үзе күпме кешене тотты, ә шулай да кемгә дә әйтмәгән! Ник алай? Нинди кеше син, Сафуан абзый?

— Шуңа күрә,— дип дәвам итте ул,— әгәр мин сезне андый кара эшләрдән тыям икән, тик сезнең үзегезне кызганудан, үзегезне сакларга теләүдән бу. Әмма моны ялгыш аңлаучылар бар. Шул почвада минем иң якын кешеләрем дә ачу йөртә башлады. Берсе минем хатынга язу калдырып чыккан, минем өйне ут төртеп яндыру белән куркытмакчы була. Ә мин бу иптәшкә әйтәм: ут белән килүчеләр безнең илдә җәзаларын алдылар. Ут белән шаяру модада түгел хәзер. Юк белән маташмагыз.

Шушы урында гөр килеп кул чаптылар. Алар, әлбәттә, бу сүзләрнең миңа карата да әйтелгәнен белмиләр, алар бу сүзләрне фашизмга карата әйтелә торган зур сүз итеп кабул иттеләр.

Сафуан абзый шулай сөйли ала торган сирәк кешеләрнең берсе инде ул, бер үк сүзләргә ике төрле мәгънә сала белә, бер атуда ике куянга тидерә.

Менә ул медаль биреләсе кешеләрнең исем-фамилияләрен атый башлады.

Шунысын да әйтим, бүтән авылларда бу медальләрне таратканда колхоз председательләре бөтенләй катнашмады диярлек. Аларны берниндн тантанасыз бирделәр дә киттеләр. Ә Килмит бу очракны да халыкта үзе теләгән хисләр кузгату өчен файдаланды — житәкчелек итә белү аңа табигатьтән бирелгәндер, ул һәрнәрсәгә сизгер, бер генә очракны да файдасыз уздырмаска тырыша. Мин моны күреп торам. Менә ул Тимербикә апа фамилиясен әйтеп, аны сәхнәгә чакырды. Тегесе ояла-ояла менеп басты да Сафуан абзый авызына карап сүзсез калды. Председательнең олы гына җөйле, кырыс кына авызы нәрсә белән дер буйсындыра, гипнозлый ахрысы — шундый мәхәббәт белән карап тора аңа Тимербикә апа. Ул да тыңлый, без дә — бөтен клуб.

— Син үзең кулга корал тотып сугышта йөрмәдең. Шулай да иреңнән, туганнарыңнан һич тә ким батырлык күрсәтмәдең син. Син — алар

кебек үк герой. Сезнең ирләрегезгә ашлык, ит, май озатучы колхозларны менә шушы куллар күтәреп торды бит. Әле игътибар житмәсә дә, сезгә багышлап җырлар җырланачак, һәйкәлләр куелачак әле...

Вакыты белән бу сүз бик төче, ясалма, кабарынкы яңгырарга мөмкин, ә бүген ул шундый дөрес һәм табигый ишетелә ки, сүзнең урынын, вакытын белеп куллану осталыгының нәрсә икәнен тагын бер кат төшенергә мөмкин иде анда. Әйе, бу — иң дөрес сүзләр, аларның эчтәлеге авыр хезмәт, йокысыз төннәр, борчылулар, кайгылар белән беркетелгән.

Тимербикә апа сәхнә уртасында кулъяулыгын чыгарып яшьләрен сөртте дә, сүз әйтергә теләгәндәй, тукталып калды. Медаль балкыган күкрәген горур тотып, авылдашларына карады. Баягы кыюсызлык, тартынуның бу минутта төсмере дә калмаган иде инде.

— Иптәшләр! Рәхмәт сезгә. Иптәш персидәтел, рәхмәт сиңа. Безнең колхоз дәүләткә ел саен планнан тыш ашлык биреп килде. Башка колхозлар өчен дә түләп килдек. Монда иң беренче мактау персидәтелгә. Ул оештырмаса, булмый иде ул. Быел язны гына карагыз, чәчү ансыз үтте. Чәчү начар чәчелде. Игеннәр начар булды. Кемнән бу? Персидәтелдән. Рәхмәт, Килмит энем, мең яшә!..

Колхозчылар таралышканда таң әтәчләре кычкыра иде инде. Арыган, эштән һәм ачлыктан йончыган күзләрдә ышаныч кабына, аларның гәүдәләре үк турая, тавышлары көрәя... Дөреслек көче, сүз көче аларны киләчәк бәлаләрне ничек каршыларга өйрәтә. Әйе, сугыш әле монда бетмәгән, ул яңа батырлыклар, яңа газаплар, яңа җиңүләр вәгъдә итә...

Миңа медаль юк. Малай дип карадылармы, әллә кышны укуда уздыру комачауладымы? Ә бүтән елларны шуның аркасында сызып ташладылармы? Медаль юк. Хәер, миңа ул кирәк тә түгел, вөждан тыныч минем. Вөждан тынычлыгыннан да зуррак бүләк бармыни дөньяда! Тик менә теге өч йөз центнер... Сафуан абзый! Бер яктан дәүләт кешесе булсаң, икенче яктан — җинаять. Сиңа ул җинаятьне халык алдында бүгенге кебек аңлатырга туры килсә? Ни өчен эшләдең син ул эшне? Мине карак яки булдыксызга чыгару, исемемне, кешелек дәрәҗәмне таптау өчен генә түгелдер ич! Миндә синең ни үчең бар иде?!

Мин синең өстән жалобалар күтәреп йөри алмыйм, андый эш табигатемә чит, дошман. Сине, ни дисәң дә кеше төсле кешене, әләкләп йөрү — үзем өчен җәзага әйләнер иде. Юк, мин моны эшли алмыйм, ләкин безгә исәпне өзәргә туры киләчәк. Икәүдән икәү.

* * *

— Фәһимә! Я, оныт күңелсезлекләрне, болытсыз иртә төсле балкып, элеккечә елмай әле бер.

Ул елмая, тик бу елмаю елаудан да яманрак.

Эштән тукталган араларда, икәүләп әрәмәдә Фәһимәгә карлыган, шомырт җыйдык. Агыйделдә икәүдән икәү су коендык. Мин аны судан курыкмаска, көзән җыерса, ничек йөзәргә икәнен өйрәттем. Эчкәрәк алып кердем. Аның саф тәненә бәрелеп уйнаган дулкыннарга карап сокландым. Аннары икәүләп каршы яктагы Кирәмәт тавына карап тордык. Агыйдел, ул турыда текә борылып, ниндидер кара-кучкыл төскә керә. Тауга менсәң, кешене шул шомлы чоңгыл суырып алыр сымак тоела.

— Үч итеп, әллә меңнәбезме шунда? — дидем шаяртып мин.

Фәһимә баягы елмаюы белән елмая:

— Башың икеме әллә...

— Синеке белән — икәү...

— Булмый, анда бүреләр улый... кичә дә тыңлап яттым. — Ул яр буенда комлыкта аунап яткан берданкага карап куйды. — Барыбер... Ерак ул, иртәгә менәрбез.

— Иртәгә? Мин риза. Менәбез.

Мылтыкны кулбашка асып, чиләкләрнең берсен ул, берсен мин тотып, әрәмә сукмагыннан атлыйбыз. Ул алдан бара, мин арттан. Бервакыт Фәһимә сукмак буендагы озын гына талның очыннан тотып алга узды да мин килеп җиткәндә юри ычкындырды:

— Чыж-ж-т!..

Пеше тал күкрәгемә бәрелде, ботаклары биткә сыпырып шактый авырттырды.

— Әләктеме? Шул кирәк сиңа. Мин синең әниең булсам, арканны нечкәрәк тал чыбыгы белән сыптырыр ием әле.

— Минем шул хәтле гаебем бармы?

— Бар, бар, бар!

Сукмак ачыграк, биегрәк җиргә алып чыкты. Хәзер без шушы утрау сыман биеклектән атлыйбыз. Аста — вак-вак күлләр... Әнә кыр үрдәкләре...

— Әллә атыйкмы?

— Юк, тимә, бала үрдәкләр...

Тагын атлыйбыз. Күрәм. Уң якта, куак төбендә, бер олы кош, тырнаклары белән каптырган да кечерәк бер кошның күкрәген чукый...

— Олы кош бала үрдәкне ашый... ат!

— Куркытма, — дим мин пышылдап.

— Явызлык ярсынуы белән ишетми ул хәзер, ат, тизрәк...

Мин кабаланып чиләкне җиргә куйган идем, чылтырап китте... Шулай да кара кош курыкмады. Куркуын да оныткан хәшәрәт! Куак арасыннан мылтыкны шул кошның нәкъ канат төбенә төзим. Бер секунд һәм ул бала үрдәк каршында үзе аунап ятачак. Секунд... Курокны тартам, чакма саңгырау тавыш чыгарып капсульгә бәрелә... Ә шартлау юк! Нәрсә бу? Кара кош, куркуның ни икәнен дә белмичә, чукый бирә. Төкерәм мин синең мылтыгыңа, ди бугай. Затворны кире кайтарам, курокны әләктерәм... Төзим... Юк, шартлау тагын юк. Тагын, тагын. Мылтык, димәк, ватык... Ачулануның, гарьләнүнең соң дәрәҗәсенә җитеп, Фәһимәдән күзләремне яшерәм. Башны иеп, сукмак буенча атлап китәм. Фәһимә кара кошка кычкыра:

— Көш, бәдбәхет, көши!

Кош очып китте, корбаны кузгалмады, без аны коткара алмадык. Тегесе, эшләгән ерткычлыгы, җинаяте өчен җәза тиеш икәнлеген сизмичә, күздән югалды. Ярый әле бүре түгел иде. Бүре каршында шундый хәлгә калсаң, гафу итми ул...

— Ярар, Әнис, кайгырма... Төзәтербез әле.

— Тутыккан ул. Чистартырга оныткан мын.

— Мондый нәрсәне онытырга ярамый,— диде ул шаяртып һәм үз чиләге белән минем чиләккә суккалады.— Мылтык ул үзең теләгән мишеньгә теләсәң кайчан атарлык булсын.

— Боерыгыгыз үтәлер.

Куыш янына җиткәч, чиләкне Фәһимәнең үзенә бирдем дә, уңайлы гына җиргә утырып, затворны сүтә башладым. Частьларын куяр өчен иске чүпрәк сорап алдым. Ел буе өй почмагында, чөйдә эленеп торавторгач, тутыккан шул мылтык. Аш пешереп йөрүче Тимербикә ападан керосин сорап алдым да берданканың затворын, магазинный коробкасын да сүтеп, чистартырга керештем.

— Әнис, бу юлы баяныңны ник алкилмәдең? — дип сорады учак янындагы Тимербикә апа.

Мин бу сүзне Фәһимәдән көткән идем, әлбәттә. Ә аның өчен гүя барыбер, кызыксынып та карамый.

— Җәяү килдем бит,— дим мин.

— Аның каравы ул быел мылтык алып килде, — диде Фәһимә, уртәгәндәй дәвам итеп. Һәм, чирәмгә җәймә җәйде дә, берәмтекләп карлыган бөрчергә тотынды. Мин мылтык частьлары чистартам, ул карлыган бөрчи.

— Бөтенләйгә кайттыңмы? — ди Тимербикә апа.

— Юк, быел көз тагын китәм. Консерваториягә. Былтыр имтихан биргән идем. Шул килеш тагын алырлар әле. Хат яздым инде, җавап көтәм.

Бу сүзләрне мин, Тимербикә апага дигән булып, Фәһимәгә сөйлим, билгеле. Югыйсә, үзе берни сораштырмый, хәзер нишләвемне, киләчәктә нишләячәгемне дә белергә теләми. Ә минем белдерәсем килә.

— Консерваторияне бетергәч, беләсеңме, ничек бәхетле булырбыз?! — дим мин аңа ясалмарак күтәренкелек белән.

— Башкаларга сөйләрсең инде.

— Мин синең хакта уйлап уйнармын, сиңа атап җырлар язармын, романслар.

— Минем кебекләр бетмәс әле.

— Син миңа ышанмыйсыңмы?

Ул башын иде:

— Син — барыбер минеке түгел. Булмаячаксың да.

Мин аңа киләчәк матурлыгы турында сөйлим, ул матурлыкның уртак булачагы турында сөйлим. Ә ул:

— Миңа киләчәк кирәкми,— ди.

— Ни сөйлисең син, Фәһимә?!

Мин аның күзләрендә яшь мөлдерәвен күреп тынып калдым. Шулкадәр кызганыч иде ул бу минутта. Әгәр сораса, мин аңа йөрәгемне ярып бирергә әзер, тик аңа берни кирәкми, аңа берничек тә ярдәм итә алмыйм. Мин көчсез. Көчсезлектән дә авыр нәрсә бармы?!

Минутлар үтәләр, сүзсез үтәләр.

— Белсәң иде, минем ничек яратканны! — дим мин.

— Кемне?

— Сине!

— Былтыр әйткән идең шул.

Тынлык.

— Нәрсә генә кирәк соң сиңа? Мин нишләргә тиеш?

Тагын тынлык. Бераздан гына мин баягыча ук сүренке сүзләр ишеттем:

— Мин синнән бернәрсә дә сорамыйм, Әнис.

Сорамыйсың шул. Син бернәрсә дә, беркайчан да сорамадың. Сорасаң иде шул!

— Телисеңме, мин хәзер алдыңда тезләнеп гафу үтенәм. Елый-елый гафу үтенәм. Ант итәм. Синең өчен үләргә ант итәм.

— Җүләр син, Әнис!

Сүзне тагын ничек дәвам итәргә? Хәзер нәрсә әйтергә? Тимербикә апа да берни әйтми, ичмасам. Әллә хәзер ул безне бөтенләй ишетми, үз кайгысын уйлый, аш пешереп йөри. Ул да шаян түгел бу юлы.

Килешә алмау кыенлыгыннандыр ахрысы, мылтыкны чистартыпҗыеп бетергәнемне дә сизми калганмын. Мылтыкны куйдым да җиргә чалкан яттым. Күккә карадым.

Күктә ап-ак болытлар, кисәкле болытлар талгын гына каядыр йөзәләр. Мондый чакта ирексездән уйга каласың, күз алдына әллә нинди бүтән күренешләр килеп баса. Теге болыт, әнә, оча торган тылсымлы палас шикелле. Шуңа утырсаң иде дә җирдәге бөтен нәрсәдән югарырак күтәрелеп, шул болыт белән мәңге-мәңге сәяхәт итсәң иде... Икенче болыт... Анда биек яр... аста төбе күренми торган, ахы-

рына төшеп житү мөмкин булмаслык упкын... Упкын кырыенда гына кеше басып тора... Упкынга сикерү өчен махсус килгән инде әллә? Әнә ул уйлана, чишү мөмкин булмаган катлаулы нәрсәне чишәргә, хәл итәргә, бөтен игътибарын, хисен, акылын туплап җавап табарга тырыша. Ул кеше... таныш төсле. Хатын-кыз. Әллә Фәһимә инде. Шул, аңа охшаган! Ул упкын алдында басып тора! Күзләремне йомам... Берничә минуттан тагы күккә карыйм — анда инде баягы кыз юк, упкынга ташланган бугай...

Үз уйларымнан үзем куркып, сикереп тордым да бер дә юктан йомыш чыгарып, күрше колхозлар җиренә киттем. Бүтән печәнчеләр көндезге ялга, кайсы кая таралышкан иде. Фәһимә, мылтык, Тимербикә апа шул килеш үзләре генә калдылар.

Чокырлар, куаклар аша ун-унбиш минут та китмәгәнмендер, арттан гөрселдәп тавыш — мылтык тавышы ишетелде. Келт итеп башка иң куркыныч уй килде: минем мылтык, Фәһимә... Бүтән нәрсә уйлый да алмыйча, килгән юлымнан бөтен көчкә кире йөгерергә тотындым. «Әгәр ул булса?» Тыннарым кысылды, йөрәк тибүдән туктар шикелле сикерде. Килеп житкәнче хәлдән тайган идем инде. Менә ул! Ул ята, баягы урынында, бөрчегән карлыганнары белән рәттән, мылтык янында... Тимербикә апа аның күкрәгенә иелгән, тыңлыймы, үксиме? Мин ишетмим, күзем күрми, күрергә теләми.

— Нәрсә булды, Тимербикә апа!

Әллә ул җавап бирми, әллә мин ишетмим. Кузгала алмыйча, аңны җуйгандай торам, үксеп җибәрермен төсле. Фәһимәне барып торгызмакчы булам, кузгала алмыйм, сүз әйтмәкче булам, тавыш чыгара алмыйм. Тимербикә апа сүзләре ишетелә башлады. Юк, юк, ышанмыйм, саташу гына бу, акылдан язам мин, бары шул гына. Юк, мылтык атылмады, Фәһимәгә тимәде, ул исән, бу бары коточкыч төш — буталчык, авыр бастырылу. Ул исән, ул яшәргә тиеш! Ләкин төшкә дә охшамаган, югыйсә, бу кадәр авыр төш шушы хәтле озакка сузылмас иде. Мин кулларымны Фәһимәгә таба сузам... Кулларым аңа житмиләр. Тимербикә апа шул вакыт:

— Бәйлә инде, ичмасам,— диде бугай.

Ишетәм дә, ишетмим дә.

Эчке ак күлмәгемне салып Тимербикә апага бирәм... Җиргә ургылган канны күреп, башым тагын томалана:

— Кем үтерде аны? Кем?

— Харап булды балам, балакаем...

Ниндидер көч мине урынымнан кузгатты. Фәһимәне кочаклап баягыча утыртырга тырыштым. Баягыча миңа каравын, былтыргыча сөйләшүен, көлүен, елмаюын, шаяртуын, үртәвен күрергә һәм ишетергә телим. Ул мине, баягыча ук, бар дип тә белми... Тимербикә апа тагын коточкыч сүз әйтте, ахрысы:

— Үлде... үлде бит!..

Тимербикә апа аның күзләрен сыйпап йомдырды. Мин аңларга тырышам. Нишләп үлде? Мондый хәл булырга мөмкинмени? Мылтыкка ул кагылдымы? Ялгышмы? Әллә үзе аңлы рәвештәме? Ничек?.. Ничек булса да барыбер түгелме хәзер? Моны белүдән генә аны терелтергә мөмкинме?

Фәһимә минем кулда... Элеккечә гүзәл, элеккечә сабыр... Ул һәрвакыт миңа хәзергечә сабыр иде... Аңына килеп, могжиза булып, аңа үз сүзен әйтергә кушсалар, ул барыбер мине тиргәмәс, кычкырмас иде...

— Гафу ит, Фәһимә, гафу ит!..

Ул эндәшми... Эндәшә алса, шаяртып әйтер иде:

— Нинди мылтык инде ул, ерткыч кошны үтерә алмады, ә мәхәббәтеңне үтерде, — дияр иде.

* * *

Бу коточкыч фаҗига килеп чыкканга үземне ышандыра алмыйча, берничә атна буе өйдән чыкмый яттым. Кемнәрдер минем янга килеп:

— Син аны гына түгел, үзеңне дә харап иттең. Сине... Төрмә көтә... Җәза... — диләр.

Нинди җәза турында сөйлиләр алар? Шушыннан да катырак җәза буламыни? Бусы иң авыры, иң коточкычы түгелме? Хәзер инде калганы барыбер түгелмени?

Мин үземне чыннан да гаепле кебек күрәм. Менә ничә ел инде шул сорауга җавап таба алганым юк: ничек килеп чыкты? Фәһимә? Аңлы рәвештә булдымы бу эш, әллә мылтык үзлегеннән атылдымы? Ничек? Фәһимә инде безнең мәхәббәткә, безнең уртак бәхеткә ышанмый, шунсыз яшәргә дә теләми иде түгелме соң?

Свердловскидан хат килде. Консерваториягә кабул итү тәртибе үзгәрде, укучылар җиде еллык белем белән алынмый, музыка училищесы бетергән кешеләр кабул ителә, диганнәр. Миңа хәзер унбер ел вакыт кирәк була: музыка мәктәбенә җиде ел, училищега дүрт ел. Унбер яшькә яшәреп бөтенесен яңадан башларга. Мин шуңа да риза булыр идем — унҗиде яшемдә җиде яшьлек балалар белән укыр идем, алмыйлар. Аңлыйм, яшьлектә шундый чаклар була: бер еллык вакыт бөтен гомерне, язмышны хәл итә. Әле генә узган бер елымны югалтмаган булсам, бу фаҗига, ихтимал, килеп чыкмаган булыр иде. Шул бер ел аркасында мин куып җитәргә мөмкин булган унбер ел гомеремне кабат югалттым түгелме соң? Дөньядагы иң олы хыялымны, яшәвемнең мәгънәсен югалттым түгелме? Мин ул хыялымны аңсыз рәвештә, үзем атып үтердем бугай. Юк, әллә ул да, хыял да үзен-үзе... Фәһимә кебек...

Фәһимә! Кара, мин аны берничә минутка истән чыгарып тора алганмын бит. Кечкенәрәк нәрсәләр турында уйлый алганмын. Иң зурысы шул бит: мин аны — мәхәббәтемне югалттым. Аның белән чагыштырганда бөтенесе кечкенә булып кала. Хыял! Нәрсә ул Фәһимә каршында! Нәрсә ул! Нәрсә!

Үземнән һәм башка кешеләрдән, бигрәк тә Тимербикә ападан сорашып озак кына тикшергәннән соң, миңа гаепсез икәнлегемне әйттеләр. Ничектер, бу хәбәр дә мине сөендермәде... Фәһимә үз үлемендә үзе генә гаепле икән... Ничек булса да ул инде юк.

Иге-чиге күренмәгән сызлану инде куркыта башлады. Күз алдында Фәһимә елмаеп тора, мин аңа эндәшәм, ул җавап бирми, мылтык тавышы яңгырый һәм ул үлән өстенә егыла... Мин аны кулларымда күтәрәм, тик аны, карак кулыннан урлаган әйберсен тартып алган шикелле, миннән тартып алалар да каядыр күтәреп китәләр.

* * *

Инде сентябрь башы җитте, игеннең исә яртысы да урылмаган әле. Сугу турында уйлыйсы да юк. Килмит ары чаба, бире чаба, кешеләрне басуга, эшкә кудыра һәм үзе дә куыша; халыкның көч-куәте булганнары эшләсә дә, күпчелек я басуда чүмәлә артында ята, яисә ярты юлдан борыла да үз ихатасына кайта. Кайткан солдатлар атна-ун көн йөри дә каядыр китә, эшче көчләр артмый, киресенчә, кими генә бара.

Ә мин тагы басуда эшлим. Берничә колхозга бердәнбер булып калган комбайн, астматик төсле ютәлли-ютәлли, башлары кайгылы иелгән арыш басуын әйләнеп йөри. Шул бердәнбер комбайн безнең җирне ташлап китмәкче — Сафуан абзый икенче тәүлек инде өенә кайтмыйча карап эшләтә. Мин бункердан чыккач ашлыкны әрҗәле арба белән авылга ташыйм. Хәзер авылдан килүем.

Басулар аркылы узам. Колхозның ярты җире — ташландык басуга әйләнгән. Җир — крестьянның аерылган хатыны төсле, аңа синең нинди хокукың да бар кебек, ләкин ул инде синеке дә түгел. Син аңа кагыла алмыйсың, эч серләренне сөйли алмыйсың, ышана алмыйсың. Чөнки аның уңышы синеке түгел, ул үзе дә һичнәрсә вәгъдә итми. Күрәм, ташланган хатынның кәефе шәптән түгел, ул саргайган. Элекке чип-чиста бодай-арыш чәчләре күптән инде рәтләп таралмаган, чәбәләнеп беткән, чүп-чар белән күмелгән: кагылсаң, очарга торган билчән мамыклары, песи койрыгы, сарут, эт эчәгесе... Аерылган хатын рәтле мендәр дә күрми, мөгаен... Ул юынмый да, чистарынмый да, ахрысы, татлы бодай исеннән бигрәк, әрем, алабута исе аңкый үзеннән. Болай барса, ул яңадан кавышу, туй ясау хакында хыялланырга тиеш түгел.

Боек тол хатынны күз алдына китереп барганда, чыннан да, ялгыз бер хатынны очраттым. Бу кадәр дә вакытында тап булыр икән! Басу юлы белән миңа каршы килә. Менә ул бөтенләй якынлашты. Нидер сөйләнә, аңлап булмый. Хәтирә апа! Шул бит! Бер сүз әйтә дә, көрсенеп, нәрсәгәдер үкенгән кебек, авыр сулый һәм телен чәпелдәтә.

— Әй, алла, соңга калганмындыр инде. Кызымны бозау ашап чыккандыр. Бер генә сәгать алдан кайтып җитсәм дә бу хәл булмас иде. Әй, аллам... нишләрмен икән инде? Сәхипгәрәй бәгырем кайтканнан бирле күзгә күренми, качып йөри. Әллә бизде... әллә башкалар белән чуала инде. Әй, алла... Персидәтелгә әйт әле, Сәхипгәрәй җаным, бер телем икмәккә тилмертмәсен. Әй, алла...

Ул кайтмаган ирен кайткан дип уйлый. Ә күзләрендәге сагыш?! Бу кадәр сагыш! Әгәр бу күзләргә шушы минутта кеше түгел, ерткыч караса, ерткычның да кызганудан йөрәге сулкылдап эрнер иде... Бу күзләр! Искә төшкәч тә бөтен тән калтырап китә, йөрәкне курку катыш кызгану, теге дөнья кешесен очраткан шикелле җан өшүе биләп ала, әйтеп аңлатырлык түгел. Бу күзләр... ике йөз грамм яшел арыш хакына акылдан язган күзләр... Моның өчен кем дә булса үкенәдер, үзе дә дөньяда яшәмәс хәлдә газапланадыр, әлбәттә, шулайдыр.

Хәтирә апа яныннан, гаепле кеше сыман, башымны иеп уздым.

Тол хатын — ташландык җир, колхоз җире... Ул бер кеше рәвешендә язмышны тирги, зарланып һаман көрсенә:

— Әй, аллам, персидәтелгә әйтегез...

Кайсы, нинди председательгә әйтергә кирәктер инде...

Әнә сап-сары билчәнле кыр, шул «игенне» комбайн ура. Үзебезнең председательнең, Килмитнең, бөтен тормышы шул комбайнга килеп бәйләнгән. Аның үзенә ярдәм итәргә кирәк. Әгәр соң булмаса.

Атны читтәрәк туктаттым да Сафуан абзый янына килдем. Нәрсәдер әйтергә теләп, күзләренә карыйм. Әллә ул да...

Юк, юк, нәрсә уйлыйм мин, миңа шулай тоелды гына. Әйе, тоелды гына. Син аның күз кабаклары, няк асты шешенке, кабарынкы булуга карама... Аның бөерләре авырта ич, су күбрәк эчсә дә шулай шешеп чыга.

Комбайн шаулап бирге почмакка килеп җитте. Килмитнең бөтен игътибары шунда: шул машинадан башка бернәрсә дә, бер кешене дә күрми. Иреннәре соң дәрәҗәдә кысылган. Читтән аз гына булса да кагылсаң, бөтен гәүдәсе дөрт итеп кабынып китәр төсле.

— Соңгы тапкыр уравым, — диде комбайнер көчкә тын алып.

Астма бугай, гыжлавы машинасыныкы төсле үк, биш метрдан ишетелә. Мин аны арыгандыр, ял итәсе киләдер дип уйласам, алай түгел икән. Килмит аңа ике төрле уйлауның мөмкин дә түгел икәнлеген сиздерә торган кискен тон белән:

— Башыңа да китермә! — дип куйды. Усаллыктан иреннәре тагын да катырак кысылды.

— Булмый, Килмит, мин нишләй алам, миңа әйттеләр — бетте. Ник миңа әйтәсең аны, начальство белән сөйләш, директор МТС белән.

— Сөйләшербез, сөйләшмәс дисеңме әллә! Әгәр хәзер шушы килеш калса, бөтенләй кала ул. Кул белән урырга кем бар? Ачтан үләчәкләр ич алар!

— Миңа нәрсә әйтсәләр — шул. Яңадан килермен.

Килмит пошкырырга җыенган ат кыяфәтенә керде, борын тишекләре киң ачылды, аннары тагын кысылды, күзләре усал очкынланды.

— Шушы басуны урып бетермичә, беркая атламыйсың.

— Син кем, директормы, безнең бригадирмы?

— Икесе берьюлы. Бар, тизрәк, юкка вакыт әрәм итмә.

— Соңгы тапкыр бер урыйм да...

Трактор, комбайнын өстерәп, үкерә-үкерә тагын горизонтка кереп югалды. Килмит белән икәү тып-тын басып торабыз. Күптән түгел әйтергә җыенган сүзләрнең берсен дә әйтергә вакыт юк. Мондый чакта ничек итеп сүз башламак кирәк... Ул үзе ярсынган, нәрсә әйтсәң дә барыбер ишетми. Чабыштан соң ат тиз генә тынычлана алмаган сымак, ашыга-ашыга басу буйлап йөренә, чыдый алмый. Җитмәсә, көзге көнгә хас булмаганча, кояш кыздырган була. Әллә шуннан, әллә эчке әрнүдән, иреннәре кара янып көйгән. Бәхетсезлегенә каршы, моннан ике-өч метрлап ары, сазлыкта чишмә бар икән. Шунда китте, мин дә аңа иярдем. Салкын, саз чишмәсе. Килмит түмгәккә тезләнде... Чалбары аша су үтте булса кирәк, ул тагы торып басты һәм, чиләк-фәлән юкмы дигәндәй каранып, бернәрсә дә күзенә чалынмагач, яңадан тезләнде, комсызланып салкын су чүмерә башлады. Салкынлыктан тешләре чатнады бугай, бераз тукталып, куллары белән авызын каплап торды.

— Сафуан абзый, җитәр, — дидем мин куркып.

Ә ул, ишетергә дә теләмичә, тагы иелеп, тагын комсызланып эчәргә тотынды. Тагын тешләрен җылытып, тагын чүмерде... Ярты сәгать эчкәндер. Комбайн тавышы якынлашкач кына башын күтәрде... Күзләре шундый кызганыч карыйлар... Элекке усаллык кая киткән! Тәнендә температура булырга тиеш, битләре күмердәй кара-кучкылланып яна:

— Җитәр, эчмә, сиңа ярамый! — дидем мин, кабатлап.

Ә ул миңа тагын колак та салмады, борылып та карамады. Аның өчен, әйтерсең, мин бөтенләй юк.

Комбайн, бездән алдарак өлгереп, урыласы җирен калдырып, басу почмагына юнәлде. Килмит йөгерә-атлап каршыга чыкты.

— Туктат! Борыл! — дип акырды ул, хәлсез тавышы белән.

Тегеләр, аны ишетмәгәндәй, баруларында булдылар. Килмитнең авыру кыяфәте кинәт юкка чыкты, ул ярсып трактор каршына ыргылды:

— Чыгыгыз, минем гәүдәм аша!

Ә трактор һаман килә, туп-туры килә, аның өстенә.

— Сауфан абзый! — Аның тапталуыннан куркып, җан әчесе белән кычкырган төсле кычкырып җибәрдем. Ә ул мине тагын ишетмәде. Аның өстенә килеп менәр чиккә җиткәч кенә, шып тукталды трактор.

— Нишлисең син, иптәш председатель? — дип кычкырды комбайнер һәм ютәлләргә тотынды.

— Мин сезгә әйттем. Бүтән колхозларга юлыгыз минем гәүдә аша уза. Башыгыз ике булса, таптагыз!

Килмит йодрыкларын төйнәп җикеренде, тегеләрнең бик гади нәрсәне аңламауларыннан һаман ярсый барды. Иреннәре соң чиккә тартылып бөрештеләр:

— Сез урмый киткәч, боларны кем урыр дисез? Хәзер яңгырлар киткәч, ул шул килеш калса, сөрлегеп, коелып, череп бетәчәк. Башыгыз бармы, юкмы? Күпме ашлык харап була?

— Бүтән колхоз... — Комбайнер, йөткерүдән куркып ахрысы, тыелып калды да бераздан соң тагын дәвам итте, — бүтән колхозларда да шул ук... Аларныкы череде ни, сезнеке ни...

— Шулай булгач, юлга вакыт әрәм итмәгез, барыбер дәүләт ашлыгы, җыегыз!

— Югарыдан боердылар ич! Ничәмә кабат...

— Алар аңламыйлар!

Шул вакыт тракторга янадан ход бирделәр.

Килмит янә трактор каршына аркылы ятты. Бәхәсләшергә бүтәнчә хәле калмаганга, ахрысы. Йөзе күм-күк булып көйгән, тагын да кызганычрак төскә кергән иде.

— Чыгыгыз минем аша... Сезгә шул кирәк ич!

Тракторны кирегә чигереп, аның гәүдәсен урап узарга теләделәр. Мәче тизлеге белән ыргылып, Килмит тагын трактор тәгәрмәче астына ташланды, тагын, тагын... Менә ул тәгәрмәч астында ук калды бугай, юк, ...трактор шатырдап тукталды һәм комбайн, чак кына авып китмичә, калтыраныр шалтырап куйды. Күзләремне Килмиттән алмыйм: тир, балчык, аның битен каплап, ул әллә нинди куркыныч төскә кергән, буялган. Күзләре усал, ләкин хәлсез... Алар тагын чак кына арадан соң гөлт итәр дә сүнәр төсле.

Кайчандыр дөнья җимертеп, бөтен авылны ихтирам иттерә алган горур председатель, Сафуан Килмитов! Синме бу? Бүген ул юк. Бу — бөтенләй башка кеше... Дөнья, нинди арысланнарны да бөгәсең син! Менә ул дошман тырнаклары астына эләккән яралы арыслан шикелле ухылдап, тыны бетеп, капланып ята:

— Минем аша... Минем гәүдәм аша гына... чыга аласыз.

Комбайнер аның янына килеп карап торды торды да яшьләнгән күзләрен сөртеп куйды. Аннары йомшак тавыш белән тракторчыга эндәште:

— Әйдә, теләсә нишләтсеннәр, күп булса, комбайннан төшерерләр... Әйдә, урып бетерәбез...

Һәм китеп тә бардылар. Ә Килмит кузгалмады, ятып калды. Мин аңа якын ук килдем:

— Ура башладылар, әйдә, Сафуан абзый, авылга, ял ит бераз... — Һәм, кинәт телсез калдым, — ул башын күтәрергә итә, күтәрә алмый... ыңгырашуын кеше ишетмәсен дигәндәй тыеп, күкрәге эченнән генә ыңгыраша... Менә ул аз гына үрмәләде дә биегрәк бураЗнага башын салды...

— Атны... — диде ул һәм бүтән сүз әйтә алмады. Кайдадыр аның аты булырга тиеш. Мин шуны эзли киттем.

Ат ярты чакрым чамасы ераклыкта тукталган. Сусыз үр буенда... Чыга алмаган, күрәсең. Тыным беткәнче йөгердем. Килеп тарантаска утыруга үзем дә котырган кеше сыман атны кыйный башладым. «Ә» дигәнче Сафуан абзый янында идем инде. Ә ул һаман бер килеш — башын бураЗнага салган да ята... Яралы солдат кебек...

Күпмедер мизгелгә аның баш очында тынып калдым. Менә ул... Әллә авыру, әллә яралы... Ничек булса да ул — чынлап та солдат. Кадровыйда хезмәт итеп кайткан өчен генә түгел. Эше буенча. Сугыш башланганнан алып, ул дәүләткә ничәмә мең пот ашлык тапшырды, күпме кеше ул азык белән үзенең җанын саклап, күпме фронтовик күпме фашистның башына җиткәндер. «Һәр бөртек — бер пуля!» Ул вакытта девиз шундый иде. Колхоз ул житәкләгәндә моңарчы бирешмәде дияргә ярый, чөнки ул үзенең төп бурычын — ашлык тапшыруын һич тә киметмәде. Ә менә хәзер, сугыш беткәч... Ул ята, бураЗнага башын салып ята... «Дошман җиңелде, мин үземнең бөтен сәләтемне, оештыру талантымны, азмы-күпме белемемне, бөтен көчемне, тормы-

шымны җәлләмәдем, расходка чыгарып бетердем, инде көч калмады... һәм мин гаепле түгел... инде миңа уларга дә ярый, хәзер үзегез карагыз», ди кебек. Чын мәгънәсендә батыр ирләргә, геройларга хас иде аның тормышы...

Тарантаска салам түшәгәч, мин, тиз генә аның култыгына кердем дә, сул кулым белән биленнән кочаклап, тарантаска сөяллердем. Ул бер сүз дә әйтә алмады. Юл буе, ыңгырашуын бар көченә басып, үлем белән көрәшеп кайтты.

Капка төбендә халык җыелды. Без аны өенә кертеп, түшәккә яткырдык.

Басуда калган, үзем җиккән ат янына ашыктым. Комбайн төнгә чаклы урды. Соңгы йөкне кайтарып бушаткач, Сафуан абзый яшәгән күрше авылга яңадан киттем. Кровате янында күпме утырганмындыр, ул миңа берничә сүз әйтте һәм аның һәр сүзе мәңге онытылмас булып хәтергә сеңеп калды.

— Я, — диде ул элеккечә кырыс, ләкин хәлсез тавыш белән. — Син ни өчен ачуланып йөрисең миңа?

— Нинди ачу, бернинди ачу юк, — дидем мин, аның нәрсә хакында сүз башлавын төшенеп. Мондый авыр вакытта бу турыда сөйләшү мөмкинмени.

— Әйт турысын. Син белеп калырга тиеш.

— Нәрсәне?

— Ялгышыңны.

«Ялгышыңны!» Әйтерсең, минем аңа элегрәк булган үпкәләвем ялгыш. Әйтерсең, аның Уфада хәлемне аңламавы, читләшүебез — минем гаеп. Әйтерсең, мин теге ашлыкны чыннан да дөрес исәпли алмаганмын, әйтерсең, мин аны каядыр куйганмын... Чынында аңа әйтеләсе сүзләр бар да бит, хәзер ничек әйтәсең аларны.

— Синең гаепсез икәнне аңладым, — дидем мин, үзе кебек үк тын тавыш белән. — Теге ашлыкны әйтәм. Аны кемдер бүтән берәү яшерде. Без бөртекләп җыйган ашлыкны. Мине чыгырдан шул чыгара, гаделсезлек... Миңа бернәрсә кирәкми, дөреслек кирәк. Урлашучының чын йөзе ачылырга тиеш.

— Дөреслек төрлечә булырга мөмкин.

Аңламаганга күрә, мин аның бу сүзен җавапсыз калдырдым һәм шунда тукталырга да җыенган идем. Сафуан абзый үзе дәвам итте:

— Ашлыкны басудагы килеш урласалар — аның яртысы әрәм була. Яшел килеш, түгелеп-чәчелеп... тагын ничек. Шуңа күрә аңа юл куймаска кирәк.

— Мин дә шуның өчен...

— Мин дә. Юкка гына күпме кешене куркытмадык...

— Ләкин син аларны судка бирмәдең, башка колхозларда...

— Анысы икенче нәрсә. Факт бит шунысы — кеше урлашмаска тиеш, гадел юл белән яшәргә.

— Әйе.

— Бу — дөреслек. Монысы синең дөреслек.

Мин аңа гаҗәпсенеп карадым:

— Синеке дә.

— Азрак минеке дә. Ләкин принцип түгел. Ә синең бит ул принципка әйләнгән. Тик шулай гына яшәргә тиешләр синеңчә. Ә тормыш катлаулырак. Анда дөреслек ике яклы... Мин үзем бер яктан урлашуны тыйдым, ә икенче яктан үзем дә шуны оештырдым.

Әллә колагым ялгыш ишеттеме, әллә Сафуан абзый авыруы аркасында буталамы дип, аңа текәлдем. Ә ул сөйли бирде:

— Шулай, шулай. Бу да дөреслек. Синең өч йөз центнерың кая китте диген. Безне бит шул ачуланыштырды? Шулай бит?

— Әйе, соңгы вакытта, — дидем мин дә ризалашып.

Ул, сөйләрлек хәле калмагандыр ахрысы, башын артка җибәреп, берничә минут сүзсез ятты. Әгәр шушы хәлендә үлеп китсә? Мин үз уемнан үзем куркып нервалана башладым — ул чакта бит, ул минем караштa кечкенә бер кеше, начар кеше, гадәти бер карак булып калачак! Монда тагын нәрсәдер бар, мин аны ишетергә тиеш! Көч-хәл белән биш минутлап түзгәннән соң, мин үзем сорарга мәҗбүр булдым:

— Сафуан абзый, син нәрсәнедер әйтеп бетермәдең.

— Әйе, — диде ул, сүз юнәлешен ычкындырмыйча. — Син шуны хәтеренә төшер. Ул вакытта көз көне һәр өйгә юеш ашлык керттердек.

— Әйе, киптерү өчен. Аннан соң аны яңадан тапшырдылар, колхозга, дәүләткә.

— Тапшырдылар. Ә бер өлешен үзләренә калдырдылар.

— Менә ничек!

— Яз көне кайбер колхозларда өчәр йөз кеше үлгәндә, бездә үлүчеләр бөтенләй диярлек булмады. Ни өчен дисең? Шул ашлык калу аркасында.

— Син минем турыда, минем исемем турында гына уйларга онытkансың икән.

— Мең кеше хакында уйлаганда, бер кеше... Үзен корбан да итә ала.

Менә ул миңа нинди роль тапшырган икән. Ә үзенә? Оешкан рәвештә урлау дигән сүзне ишеткәнем бар иде минем. Колхозчылар өчен тырышкан председательләрне конвой белән алып китүләрен ишеткәнем бар иде. Сафуан абзый! Син бит мондый мөмкинлекне белеп, күреп тордың! Ә шулай да җинаятькә бардың! Ни өчен? Йөзләгән тормышны саклап калу өчен, икенче елны шул ук икмәкне үстерергә кешеләр калсын өчен. Бу да — дөреслек. Тик ике генә яклы түгел, күп яклы дөреслек бу. Ул чынлыкта һәркем өчен файдалы — халык өчен дә, дәүләт өчен дә, шул ук вакытта үзе — җинаять... Кемдер үз язмышын корбан итәргә мөмкин. Дөреслек, менә нинди катлаулы нәрсә икән ул! Ә мин — аның бер генә ягын беләм.

Сафуан абзый бераз күтәрелебрәк ятты. Мин аның мендәрен кабартыбрак, өскәрәк күтәреп куйдым.

— Син, — диде ул, — мылтык тотып көрәшергә соңга калдың хәзер. Син баяннан аерылма, музыкадан...

— Аерылдым бит инде...

— Гафу ит, — диде Сафуан абзый ишетелер-ишетелмәс.

Бу турыда ул бүтән сүз кузгатмады. Ләкин мин аның ни өчен гафу үтенүен аңладым: кирәк чакта киңәшче, ярдәмче була алмадым, дигән сүзе иде бу аның. Нишлик соң, төзәтеп булмас бит хәзер. Миңа тиешле сүзләрнең әйтелеп беткәнлеген сизеп, саубуллаштым да чыгып киттем. Икенче көнне кич белән тагын килгән идем, инде күрә алмадым. Аны самолет белән шәһәргә озатканнар. Һәм мин аның терелмәсен эчке бер сизенү белән сизенеп, нәрсә уйларга да белмичә, таркау күңел, бәйләнешсез һәм җавапсыз сораулар, уйлар белән кире өйгә кайтып киттем. Бу югалту моңарчы таныш булмаган иң буталчык һәм иң авыр кичерешләр тудырды. Сафуан абзый дөньядан китте, хәзер аның язмышы минекеннән яхшырак төсле тоелды. Бүген мин аның урынында самолетта соңгы кабат очкан булсам, бәлки, үземне бәхетлерәк хис итәр идем.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Шулай. Калдым бер үзем: яратусыз, максатсыз, ышанычсыз. Шул көнне аңладым: югалырга мөмкин булганның берсе дә калмады миндә. Иң авыры — киләчәкнең кирәге калмады. Нишләргә? Хәзер кемгә киңәш сорап барырга? Әнигә мин шушы ел ярым эчендә баштан кичкәннәрне сөйли алмыйм, ул миңа берни әйтә алмый. Мине хәзер бер нәрсә кызыксындырмый. Шуңа күрә элеккеге мең сорауны конкрет бер сорау алыштырды. Бердәнбер сорау: башны кая куярга?

Мин кайбер җанварларның ничек үлүен беләм. Йорт хайваннарыннан мәче һәм этләр үлүен күзәткәнем бар. Үләр вакыт житүен сизсәләр, алар югалалар, өйдән ерак китәләр, үзләренең газаплануларын күрсәтмәс өчен каядыр чит җиргә китеп олагалар. Кеше өчен дә матур үрнәк түгелме соң бу? Хайваннар иленнән дә әйбәт үрнәкләр килә бит, ахрысы... Әйе, карар әзер... Кая да булса китәргә һәм бәлки... һәм мине инде пароход алып та китә. Аннан соң товар ташучы поездга утырам. Кая? Кавказга?

Әйе, Лермонтов геройлары янына. Кырыс чынбарлыктан хыял иленә. Бүтән барыр җир, бүтән максат күрмим... Бәлки чынбарлыктан шул юл белән котылырга, бөтенләй башка җиргә, материаль кысанлыктан идеаль киңлеккә чыгарга, Демон төсле, күктә, тау түбәләре буйлап сәяхәт итәргә мөмкиндер.

...Кавказ таулары буйлап чабам... Тик сихерле канатларда түгел, әлеге чын поезд түбәсендә... Шагыйрь гомере чикләнгән Машук тавын күзәтәм, Лермонтов исеме бирелгән капканы карыйм. Шуннан узаргамы, узмаскамы — уйланып торам. Узсам, тегендә, арырак... анда мине дә үлем сагалап ятадыр... Әйе, миңа да шунда барырга кирәк.

һәйкәл — обелиск... Бөтен уйны, ирекне кысып, әйләндереп алган тупас чылбырлар... Аларны шагыйрь үзе дә күреп, белеп торган. Минем дә хәл аныкыннан яхшы түгел... Бәлки начаррак тадыр, чөнки мин үземнең күзгә күренми торган чылбырлар белән уратып алынганымны сизәм, кычкырасым килә, кемгә, кайчан, нәрсә дип кычкырырга белмим... Тирә-якта сагыш кошлары... Алар үлем ярасыннан газапланып, яңгыр астында коенып яткан Мишельне күреп торалар, аңа нәрсәдер әйтәләр, ә миңа бер сүз дә эндәшмиләр... Мин аларның телен белмим... Миңа тагын да кыенрак...

Шагыйрь баскан ташларны чамалап, Пятигорск буйлап йөрим, Подкумок шавын тыңлыйм, нәрсәдер ишетәм дә бугай, тик аңламыйм... Йөрәк авыртып кысыла, юк, барыбер аңламыйм, үзем ишетергә теләгән киңәшне ишетә алмыйм.

Елга буенда гына базар икән. Ул минем өзелеп ашыйсым килгәнне искә төшерә, үзем күрә алмаган чынбарлыкка кайтара. Димәк, мин эзләгән дөньяның капкасы монда да бикле, бу тормышны мәңгелек белән куша торган юллар юк, аларны кемнәр генә таба, кемнәргә генә ачыла икән ул дөнья, белмим.

Поездга — электричкага утырам — Минеральные воды ягына. Дерматин белән тышланган йомшак креслолар — мондыйны гомеремдә дә күргәнем юк. Бу, ахрысы, мин эзләгән күренеш... Тирә-ягымда матур-матур киенгән кызлар. Аларның кайсы Мэри икән дә, кайсысы Вера икән? Мин аларны танырга телим — күзләренә карыйм. Алар да кайдадыр күргән кешеләрен төсмерләгәндәй миңа карыйлар. Тик бу бәхет тә озак дәвам итми, контролер билет тикшереп мине дөньяга тагы кайтара: минем билетым юк... Тагын нидер әйтә, ә мин ишетмим, урынымнан кузгаласым, бердәнбер ләззәтемнән, менә бу күзләрдән, хыялдан аерыласым килми. Шулай утыра бирәм. Инде хыял белән яшәргә

дэ ирек юк... Контролер миннэн ни өчен билет алмыйсың дип сорады булса кирэк. Э мин туп-турысын әйтэм: «Акчам юк». Кызлардан шикләнепме, ул бик йомшак сөйлэшэ: «Ичмаса, бу вагонда утырма, әйдэ башка вагонга». — дип пышылдый. Мондый әйбәтләп әйткән сүзне куптән ишетмәгәнгә күрә, буйсынырга, аның артыннан атларга мәҗбүр булам. Э күзләр һаман карыйлар. Сизэм, алар минем арттан гажэпләнеп һәм кызганып карап калдылар... Алар белән сөйлэшергә, шаярырга миңа нэрсэ комачауладыСоң? Мине бу дөньядан нэрсэ аерып тора? Башкалардан кимме мин? Ни гаебем бар минем?

«Минеральные воды». Озак та үтми, поезд мине «Прохладный»га китереп ташлый. Кая барырга тиешмендер, белмим, мине монда бер нэрсэ генэ борчый: ничек тамак туйдырырга? Базарга килэм, бернинди өмет юк, ичмасам, күз белән булса да ашап торам. Пирожоклар, ипи, пешкән бэрэңге, тавык ите... Ашказанны көзэн җыера, авыртуга чыдый алмыйча, читкэрэк китеп, бер киоск кебек нэрсэгэ сөялэм. Күпме торганмындыр, бер мәлне күрэм, минем янда гына прилавка алдына басып, юан гына бер хатын аш сатып тора. Чынаяк хэтле генэ балчык чүлмәккә салып аш бирэ, ашагач кына түлилэр. Эллэ фасоль, эллэ борчак ашы — исе борынга ук килеп бэрелэ дэ йөрэкне чеметэ. Кесәдэ бер тиен акча юклыгын белсэм дэ, чиратка басам. Миңа бер чүлмэк белэн миңа да аш бирэлэр. Читкэрэк китеп ике кабуда чүлмэкне ялт иттерэм. Эллэ фасоль, эллэ борчак ашы, төшенмим. Хэзер нишлэргэ? Тагын берэрне салдырып алыргамы, эллэ качаргамы? Качсаң була булуын, мине бөтенлэй онытгылар. Хуҗа хатын башкалар белән мэшгуль. Тик ташлап китсэң, кешенең чүлмэге җэл... Әйдэ, эрэм булмасын, прилавкасына илтеп куйыйм. Шулай эшлим дэ. Мине сатучы хатын исенэ төшерде дэ нечкэ тупас тавыш белэн чинап кычкырды:

— Э акчасын кем түлэр?!

— Хэзер, хэзер, — дип, кесэ актарган булып бер-ике минут вакыт уздырсам да, ник икэнен үзем дэ абайлап бетермэстэн, торып йөгерэм — вокзал ягына.

— Тотыгыз, тот! — Хатын чучка кебек чыелдый. Ирлэре читтэ тэмэке тартып аларны саклап утыра икэн, унлап ир кеше мине куа килэ. Гажэп, киң базар мэйданы буйлап мин чабам, алар чаба, мин чабам, алар чаба. Нэрсэдер акыралар. Күрэм, вокзал ягыннан бер милиционер минем каршыга йөгерэ:

— Тукта, курыкма! Ишетэсеңме, курыкма? Кил минем янга!

Вокзал янына житэрэк мин аның янында тукталдым. Тегелэр дэ килеп житте. Хэер, мин бу бэндэлэргэ караганда тизрэк йөгерэм икэн, алар мине тотачакларыюк иде. Э туктагач, йодрыкларын уйната-уйната минем өскэ эт өере сыман ташландылар, бер-икесе жопып та алды, җавап кайтарып өлгермэдем. Тик милиционер тегелэргэ каршы сугыша башлагач, өркеп чигенделэр, йомылышып, кайсы кай якка таралдылар. Милиционер минем белэн вокзал залына чаклы няреп килде. Монда минем юлда танышкан иптэш малаем калган иде. Төенчеккә охшаган бер нэрсэмне аның янында калдырган идем.

— Менэ мин шушында, — дидем милиционерга, эле һаман тынычлана алмыйча көчкэ тын алып.

— Э бу кем? — диде ул һэм егет каршына килде.

— Бүген генэ таныштык, юлда.

Йөгерүдэн ярсыган милиционер шул ук тиз хэрэкэт белэн егетне якалап торгызды да яңаклый ук башлады. «Тегесе ни өчен кыйныйсын?» — дип кычкыра. Э милиционер:

— Күземэ чалынма, курсэтермен мин сиңа! — дип тегене тукмап озатып та жибэрде. Эллэ кузгалган ачуын шулай егетне суккалап басты инде, эллэ гадэт буенча? Алай дисэң, ник минем үземне бэргэлэмэде? Мин сэбэбен белэм, гаебем бар, риза булып торыр идем. Э ул һич

гөнаһсыз кешене рәнҗетте. Ник? Мин моның сәбәбен аңлый алмыйча шушы көнгә чаклы баш ватам. Егет китүгә милиционер елмаеп та җибәрде:

— Тегеләр сине изеп ташлыйлар иде бит. Ә син, шундук минем янга киләсе урынга, миннән дә качасың. Ник курыктың син миннән?

— Милиционер бит...

— Әһә! Син начар милиционерларга туры килгән... Аңлыйм. Җәл.

Мин җавап бирмәгәч, тагы үзе сүз башлады:

— Ә син ничек, туйдыңмы?

— Юк.

— Ничәне ашадың?

— Берне.

— Күбрәк ашыйлар аны, ашагач-ашагач.

Милиционер иң якын дус кебек, минем хәлемне, каян, кем икәнлегемне сорашты. Соныннан гаҗәпләнеп карады:

— Тормыш авыр дип, бу якка килеп чыктыңмы?

— Әйе.

— Дурак син!

Мин эндәшмәдем, ләкин дусларча әйтелгән сүзгә ачуым да кузгалмады, ул миңа иркәләү сүзе булып ишетелде. Йөзендә борчылу! Сизеп торам, минем язмыш өчен кайгыра...

— Хәзер нишләргә уйлыйсың инде? — диде ул шул кайгыртулы кыяфәт белән.

— Белмим.

— Мин синең урында булсам, хәзер туган өемә кайтып китәр идем.

— Анда миңа берни юк.

— Иң мөһиме, хәзер ачтан үлмәскә кирәк. Аңладыңмы? Туган җир ул — ни әйтсәң дә үз анаң. Мондый чакта аннан да якын иткәнен таба алмассың.

— Ә мин укырга, кешечә яшәргә телим.

— Алайса бигрәк тә... Монда сине кем укытсын? Син кемгә кирәк? Стипендия — ул нигә җитә? Аны ала башлаганчы ничек яшәмәкче буласың?

— Эшкә керергә мөмкин.

— Син үзең кайсы якныкы?

— Идел ягыннан.

Милиционер кулын ук селтәде:

— Шулай булгач! Соң бит... Бу якларны бит фашист таптады, талады, хәзер җимереклек, хәерчелек. Үзебез сезнең ярдәм белән аякка басабыз.

Балачак әкияте искә төште. Куркаклыгыннан тәмам туеп, йөдәп, күл буена суга батарга килгән куян үзеннән куркып суга сикергән бакаларны күргәч, миннән дә куркаграклар бар икән ич әле, болай булгач, миңа шөкер итәргә дә мөмкин дип, үлмәскә була. Мин дә шундыйрак хәлгә калдым бугай. Без сездән дә кыенрак яшибез, диләр миңа...

Милиционерның күзләренә туп-туры карап, гаҗәпләнүемне сиздердем. Аптырашта калуымны төшенгән акыллы зәңгәр күзләр мине тынычландырырга тырыштылар. Башны игән хәлдә юатулы сүзләр ишеттем:

— Син ул хәтле боегып та китмә, иптәш, бу — вакытлы хәл. Әйтәм ич, менә туган җиреңә кайтып, бераз ис ал, ныгы. Аннары укырсың, кеше булырсың... Көтү — тактик алым ул, сугышта да, тормышта да кирәк була.

— Өйгә кайтырга... Хәзер акчам юк минем.

— Беләм. Ничә көнлек юл?

— Алты көндә кайтып җитәргә була.

— Менә алайса,— диде милиционер һәм, кайгысы беткәндәй жинел сулап, кесәсенә тыгылды, — алтмыш сум акча сиңа. Көнөнә бер тапкыр ашасаң, житкерерсең. Килештекме?

Миңа хәзер нәрсә әйтергә кала? Күзгә карап дөреслекне әйткән бу кеше — хаклы. Ул минем костюм кесәсенә акчасын үзе үк тыкты да кабатлап әйтте:

— Я, килештекме?

— Килештек.

Әңгәмә шуның белән тәгәлләнде. Ул минем аркамнан какты һәм китеп тә барды:

— Хәерле юл, браток.

Ярты сәгатьтән поезд мине яңадан төньякка таба очырта иде инде.

* * *

Чит жирләр хәтердә, ничектер, биеклек рәвешендә калган. Ихтимал, таулы урыннарда йөрү шулай тәэсир иткәндер. Ә биектә — куркыныч: егылып төшсәң, сөякләреңне дә жыярлык түгел. Ә мин туган жиргә кайтып егылдым һәм исән калдым. Аннан да ышанычлырак урын юклыгына ышандым. Туган жир! Ничә кабат кайтып егылдым сиңа мин үз гомеремдә, ничә кабат! Ничә кайтсам да кабул итәсең. Шуңадыр, күңел үзен монда тынычрак хис итә.

Кайткач та беренче ишеткән хәбәр шул булды: Сафуан абзыйны жирләгәннәр. Әлбәттә, минем өчен яңалык түгел бу, шулай булачагын сизеп киткән идем ич.

...Снарядлар яумый, ләкин кешеләр үлә.

...Сугыш дәвам итә... Геройларсыз, романтикасыз...

Икенче хәбәр — анысы менә минем кулда: Ленадан хат. Көтеп яткан.

Хатны ачарга ашыкмадым. Өстәл артында якын киләчәк турында баш ватып утырдым. Ихатага чыктым, бакчага кердем.

«Жәмгыятькә нәрсә дә булса бирмисең икән, синең аңардан үзеңнең дә таләп итәргә хакың юк». Дөрес сүз, килешәм. Дөресрәге: килешәм һәм килешмим. Ни өчен? Жавап әзер түгел.

Бакчада орлыктан тишелеп чыккан алмагач үсентеләре бар, күптән аларны күчереп утыртырга вакыт, әмма кемнең дә кулы тимәгән. Алар рәтләп үссеннәр өчен бераү кайгыртырга тиеш. Ни өчен шул бераү — мин түгел? Димәк, үсентеләргә урын сайларга кирәк. Бу урында элекке бакчаны бетереп бәрәңге утырта башлаганбыз. Бәрәңгесез — көн юк. Әнә тегендә, өй алдында, күпме жир буш ята, шунда киртә корып, ник бакча ясамаска?

Иске-москы агачлардан көн озын киртә тоттым. Икенче көнне алмагачларга урыннар казый башладым. Көзге кояш үзенә күрә жылыткан була. Тирләп маңгайларны сөртеп куям. Үзем эшлим, үзем уйланам.

Бу агачларны күчереп утыртмасам, су сипмәсәм, терлек ашамасын өчен хәстәрен күрмәсәм, койма тотмасам, алардан нинди уңыш көтәргә мөмкин? Жимеш бирми дип аларны тиргәргә кемнең хакы бар? Бакча гына түгел, басу да шулай. Хәзерге кырны кара инде син, кайчандыр күкрәп иген үскән жирдә — бүген сарут белән билчән котыра. Ашламагач, карап үстермәгәч, уңыш юк. Ә миннән уңыш көтәрләр...

Өй янында тәрәзәләргә каршы бакча барлыкка килде. Алмагачлар үсәр, шомыртлар. Алардан рәтле жимеш көт инде син: ялганмаган алмагачлар, вакытында кул житмәгән. Хәзер соң инде. Шулай да үссеннәр, әче булса да, жимеш бирсеннәр — безнең кичерешләр әчелеге аларда калсын. Кемнәрдер аны татып караячак бит әле! Татып караячаклар һәм, ихтимал безне дә аңлаячаклар...

Кесәдә хат һаман иәри — Лена хаты, таушалып беткән инде, ә ми-

нем ачканым юк. Нәрсә язуы мөмкин икән? Укыйм һәм «романтик» рух белән язылган төче сүзләр ишетәм:

«Әнис бәгырем!

Син минем белән серләреңне бөтенләй уртаклашмый башладың. Мин моның сәбәбен аңлыйм, әлбәттә. Ләкин чарасын таба алмыйм. Мин сине һаман үз янымда гына тотар идем, иң ышанычлы киңәшчең булыр идем. Тик син моны теләмәдең һәм теләмисең. Синең күңелең башкада иде һәм хәзер дә тынычлана алганың юк. Шулай да мин сиңа ачуланмыйм. Теләсә ничек кенә булса да, әллә нинди авыр хәлләрдә калсам да — барыбер мин сине яратачакмын. Сине миннән беркем дә тартып ала алмас.

Сине килмәсме дип көтеп арыгач, үзеңне эзләп авылыгызга килгән идем. Син инде киткәнсең икән. Кая, ни өчен? Синең миңа бу хакта әйтерлек тә якынлыгың калмагандыр шул инде. Яратуыңны таләп итмим, гади дус, таныш буларак, үзең хакында белдерүне дә хәзер артык күрәсеңмени?

Син бу хатны укый алырсыңмы, белмим. Минем өчен барыбер. Миңа эчтә җыйналган ярсынуымны тышка чыгарырга кирәк. Бары шуның өчен генә язам, чөнки язмыйча булдыра алмыйм, түзә алмыйм.

Авылыгызга килгәндә, урмандагы, үзебез генә белгән, кайчандыр янында үзебез кичләр уздырган каенга синең исемеңне уеп яздым. Каенның яралары төзәлгәч тә, ул исем барыбер танырлык булып калачак. Ул исем минем күңелдә дә үзенең эзен җуймаячак. Аерылсак та, бөтенләй очрашмас булсак та.

Хуш, минем бәхетсез мәхәббәтем!

Лена».

Хат, бер карасаң, йөрәк каны белән язылган, анда үлеп баручы мәхәббәтнең соңгы әче зары ишетелгән сыман тәэсир итә. Икенче минутта, әллә ничек, ышанмау, шик туа — бу сүзләр аның үз йөрәгеннән чыккан сүзләр түгел, ә күпләргә таныш, гомуми сүзләр, ятланган фразалар төсле тоела. Ләкин бер нәрсәгә ышанам, ул инде өметен өзгән һәм башкалар белән чуала башлаган. Бу җылы сүзләр мине рәнҗетмәскә, хәлемне җиңеләйтергә тырышудан гына язылганнар. Кирәкмәгән төчелекнең шулай максаты була, моны гына аңларлык хәлдә бит әле мин. Шушы кырыс нәтиҗәне раслар өченме, шикләнү тойгысын басарга теләпме, үзебез генә белгән теге каен янына ашыктым. Шигем монда тулысынча өстенлек алды — анда минем исем язылмаган, каен тузы чип-чиста. Ленаның кулы бөтенләй кагылмагандыр да, бәлки. Эх, Лена, Лена! Мәхәббәт турында, үлемсез мәхәббәт хакында сөйлисең бит син. Исемемнең синең күңелдә күпме сакланачагын инде ахырынача төшенгәнмен ич. Я, хуш инде. Мин сиңа ачуланмыйм. Минем сиңа бернинди дәгъвам юк, аерылсак та, бөтенләй очрашмас булсак та. Минем белән бернәрсә дә чыкмасына ышангач, үз тормышың хакында уйларга тиеш ич син, ниһаять!

Шулай да безгә тагын очрашырга туры килде. Кино килгән иде. Безнең авылда сирәк була торган вакыйга бу, бармый ничек каласың.

Караңгы күптән төшкән. Халык клубка шулай һаман соң җыела. Мин барып кергәндә, алдагы урыннарның да күбесе буш иде әле. Ни өчендер, арттагы урыннарның берсенә утырдым да тагын бер кешелек урын калдырдым. Әллә Лена өчен... Гаҗәп... Лена!

Озакламый керерсең, гадәтеңчә якты итеп бер елмаерсың, нечкә, җиз калай тавышың белән көләрсең... бәлки, бераз күңел дә күтәрелеп китәр әле. Белмәссең. Кергән бер кешегә күтәрелеп карыйм, уңайсызланып, караганымны сиздермәскә тырышам. Шулай азакка хәтле диярлек көткәч, күңел сине күрергә теләп ашкына башлады. Теләк — ярсынуга күчте. Без һәрвакыт шулай, үзебезне үзебез нәрсәгә дә бул-

са ышандыра алабыз, алдый алабыз һәм кичерә башлыйбыз. Кино башланырга санаулы минутлар гына калды. Урамда мотор гөрелди башлады, пленка тәгәрмәчләрен аппаратка якын китерделәр, берсе әнә куелды да. Ут сүнәр һәм... Шул минутта ишектән син күренден... Йөрәк шатлыгыннан сикереп, дөпелдәп куйды. Син күрсен өчен, мин урыным-нан торып бастым. Мена күрерсең дә таныш елмаюың белән... Син ел-маймадың... башыңны түбән идең һәм алга таба атлый бирдең. Синең арттан тагын бер кеше — ир кеше килә иде. Нишләп мин аны күрмә-гәнмен әле? Мена ул сине култыклап алды, нинди чибәр хатынны эләктердем бит дигән сыман, горур гына басып, алдагы рәтләрнең бер-сендә сиңа урын тәкъдим итте һәм... ут сүнде. Экранда ниндидер сурәт-ләр барлыкка килә, кемнәрдер нәрсә хакындадыр сөйләшәләр, бәхәс-ләшәләр, тиргәшәләр, сугышалар... Ә мин аңламыйм. Нәрсә соң бу? Лена, кем белән син? Аңладым, якында гына берәү күршесенең кола-гына иелеп пышылдады:

— Лена кияүгә чыккан.

Әйе, ул кияүгә чыккан. Табигый. Минем аңа бернинди дәгъвам юк, вәгъдәм юк, ул шулай булырга да тиеш. Ниһаять, бервакыт хәл үзгәрергә, тәгәлләнергә тиеш ич! Бары шул гына, бик примитив дә-рәҗәдәге табигый хәл. Ә ник син шушы хәтле югалып калдың? Сиңа нәрсә?

Кино бетте, кешеләр кузгала, мин дә ниндидер инстинкт белән куз-галып киттем. Төнге караңгы урамнан ялгызым гына барам. Япа-ялгыз... Менә шушы минутта инде мин чынлап та ялгыз... Кап-ка-раңгы...

Мине үзебезнең авыл кешеләре утыртып кайттылар. Нәрсәдер әй-тәләр, ишетмим. Эндәшеп-эндәшеп җавап ишетмәгәч, кул селтәделәр бугай, бөтенләй сүз кушмас булдылар. Үзара юл буе гәпләшеп, бәхәс-ләшеп, көлешеп, тиргәшеп кайттылар. Сүзләре колакка кермәде. Үз хәлемне соңыннан тикшереп карагач, мин тагын бер ачыш ясадым: күңелең белән аерылышырга һәр минут әзер торсаң да, яратмасаң да, һичнәрсә дәгъва итмәсәң дә, үзең белән бәйләнештәге кешеңнән ае-рылу — барыбер фаҗига, син аны барыбер көнлисең... Үзеңә кирәк тү-гел, ә читләргә бирәсең килми. Кеше күңеле бөтен дөньяны кочарга омтыла. Һәрвакыт шулай, һәркем шундый. Сынап карагыз, әгәр ышан-масагыз. Уйлап карагыз. Кешегә бервакытта да җитеп туктамый...

* * *

Тора-бара үзем өчен бер нәрсәне ачыкладым: әйтерсең, мин озак кына вакыт авырып яткан һәм хәзер терелеп урамга чыкканмын. Югалтулар ачысыннан һәм... ихтыярымны бәйләп торган, ярыйсы ук азгын мәхәббәттән терелеп чыгуым иде бу. Авылны, үз хәлемне шунда үз төсендә күрә алдым.

Сугыш дәвам итә... Сафуан абзыйлар гомерләрен дә кызганмый, ә син? Дезертирмы? Хакың юк бу көрәштән качып калырга. Сафуан абзый юк, бер кеше кимеде. Буш урынны кем алырга тиеш? Үз ха-кында гына кайгыртырга хакың юк. Сафуан абзыең, Килмитов, үзе өчен үлмәде. Хакың юк.

Йөгән тоттым да иртән иртүк атлар утарына кердем. Миңа «Гани аты» дигән кара-туры атны бирделәр. Тояклары чабата кебек җәелгән, яндырганнар. Яхшы ат иде шул син, дус, начар ат янмый ул. Әйдә, яңадан яши башлыйбыз, безгә үзебезнең нәрсәгәдер сәләтле икәнебез-не күрсәтергә кирәк хәзер.

Атым уйчан, акыллы күзләре белән карады да, мин риза дигәндәй, башын иде.

Камыт кидерә башлагач, атның муенында, күкрәк янынларак чәйнек

капкачы хәтле суелган урын, җәрәхәт күренде. Камыт тигән иде атка, кемгәдер, җансыз кешегә туры килгән. Шактый вакыт азапланып, камыт бөяте аркылысына, җәрәхәттән өскәрәк туры китереп, сәнәк сабы юанлыгында тегелгән чүпрәк бәйләдем. Хәзер яра төзәлергә тиеш.

Шулай, мажар җиктем дә «Сәлем тавы» ягы басуына көлтә ташырга киттем. Көлтә дип искерәк гадәт буенча әйтәм, ул чакта ашлыкны көлтәләп торырга вакыт җитмәгәч, чабып кына өяләр иде. Кара-туры дустым белән кара көзгә чаклы ул басуларның аркылысын, буен күп кичәргә туры килде безгә.

Бер көнне райкомолга чакырып алдылар. Әшмән авылы «Ишкар» колхозыннан аерылган иде ул чакта, башлангыч комсомол оешмасын да аердылар. Безнең оешмага секретарь итеп мине куйдылар. Авылда биш-алты комсомолец, аларның да яртышар еллык взнослары түләнмәгән, барысы белән дә сөйләштем һәм бөтенесе взносларын түләде. «Чынлап та комсомолец булсаң иде ул!» дип куйды кайберләре.

— Быелдан башлап, барыбыз да чын булырбыз, — дидем мин үземә дә, аларга да.

Җыелыш игълан иттем, комсомолның ачык җыелышы. Тыңларлармы сүземне, килерләрме җыелышка?

Кич. Комсомолецлар гына түгел, коммунистлар да, колхоз житәкчеләре, пожарниклар — бөтен авыл диярлек җыелды, мине тыңлыйлар.

Колхозның хәлен беләм, шуны сөйлим. Егетләрнең канатлары салынкы икәнен беләм, шуны сөйлим. Газетага язып чыгарлык эшләр үти алуыбызны, газетага үзем үк язачагымны әйтәм. Алар моңа ышаналар — минем фамилия белән басылган әйберләрне укыганнары бар. Шуннан соң үтенеч: күрше колхозларда урылмыйча гектар-гектар иген кала. Ярдәм сорыйлар. Нишлибез? Барырга тәкъдим итәм. Икенче көнне, кайчандыр болынга төшкән кебек, атларга төялеп күрше авылларга китәбез.

Үз сүземнең шулай күпме кешеләрне туплавын, аларның, нечектер, минем белән элеккечә түгел, җылырак исәнләшүләрен һәм сөйләшүләрен күреп гаҗәпләнәм дә, шатланам да.

Колхоз председателе белән сөйләшеп, соңрак үзем газетага язганча: һәр житди участокка — терлекчелек һәм ашлык җыюны тәгәлләү буенча, комсомол постлары булдырдык. Үзешчән сәнгать түгәрәге оештырдык. Күрше авыллар безнең спектакльләр һәм концертларны көтеп алалар. Театрлар юк иде бит әле.

Кырда кар ята инде. Ләкин ашлык һаман сугылып бетмәгән. Бозланып каткан чүмәләләрне көч-хәл белән куптарып төйибез.

Алда иң авыр 46 нчы ел...

Тик хәзер, теләсә нәрсә булса да, мине куркытмый инде: физик авырлыкны җиңә беләм мин, күп кичердем.

Хәзер үземчә яшим, байрагым — Кешелеклелек.

## БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

Шулай берничә елдан соң...

Төн. Узганнарны баштан кичереп, бакчада ятам. Капкадан кемдер керде бугай.

— Әнис абый! Әнис абый!

Мине кемдер уята. Мин йоклыйммыни әле? Әллә болар, истәлекләр түгел, авыр төш кенә булып чыктымы? Юк, артык мавыгып китүдән генә үз янымa килүчене сизми калганмындыр. Ул минем янда ук тора икән.

— Кем син?

— Мин Юрик.

Таныдым. Ул — ун-унбер яшьлек бала — Сафуан абзыйның иң өлкән улы. Ачык яңгырашлы нәзек тавышын тыя төшеп, миңа эндәшә. Тавышы, сөйләшүе әтисенекенә охшар, ахрысы.

— Нишләп йөрисең төнлә, Юрик?

— Мин түгел... анда бер кеше килде, — диде Юрик, акланырга тырышкан төсле.

— Кайда? Нинди кеше?

— Бездә. Сине күрәсем килә, ди.

— Кем соң ул?

— Белмим. Беренче күрүем. Әйдә, тор инде, Әнис абый.

— Мин аңа ник кирәк булдым икән?

— Түлисе бурычым бар, ди.

— Кем булыр икән ул?

— Баргач, үзегез сөйләшерсез инде.

Нишләмәк кирәк, йокларга язмагандыр инде бу төнне, кузгалырга туры килә. Һәм мин торып киенә башладым.

— Син минем кызыклы төшемне бүлдердең, Юрик,— димен, уенычыны белән.

— Әй, төш тагы керә ул.

Аларның өйләре — авылның теге очында. Барышлый, килүче кешенең тышкы кыяфәтен сораштырып, кем икәнен хәтерләргә, үземә бурычлы кешене искә төшерергә тырышып карыйм. Юк, хәтерли алмыйм. Миңа бурычлы кеше кем? Моннан берничә ел элек булса: «Аерым кеше түгел, миңа бөтен дөнья бурычлы, аның белән күзгә-күз карап сөйләшергә кирәк», дияр идем. Ә хәзер әйтә алмыйм. Кызык.

— Абый, синең укуың кайчан бетә инде?

— Өч елдан. Озакка киттеме?

— Юк, кешеләр сөйләшә, зурайгач укыды, диләр.

— Ә син үзең укыйсыңмы?

— Укыйм.

— Укып чыккач, үскәч, кем буласың инде?

— Минме? Әти кебек.

— Ә... аның кебек булырга ярый.

— Ә син кем буласың?

— Синең әтиең кебек.

— Минем әти укымаган.

— Хәзер укымыйча аның кебек булып булмый. Заман үзгәрде.

Килеп тә җиттек. Өйгә уздык. Эчке бүлмәдән тоныкут яктысы төшә.

— Әйдә, — дип елмаеп ишек ачты Юрик. Мин аның йөзендә хәйләкәрлек сиздем. Түр бүлмә ишеген ачтым... Һәм шул килеш тынып калдым. Анда, өстәл артында, чыжлап кайнап торган сары самовар янында Юрикның әнисе белән бер хатын-кыз утыра. Таратып җибәргән каштан чәчләр, саргылт ут яктысы белән кушылып, бөтен өй эчен тутырып торалар... Мине күрүгә, ул, каушап, күтәргән чәшкәсен төшереп җибәрә язды. Лена!

— Нишләп йөрисең монда? — дидем мин, исәнләшергә онытып.

Шактый тупас эндәшелде. Чит кеше белән болай сөйләшергә ярамый, билгеле.

— Ник? Килергә ярамыймыни? — дип сорады ул, гаебен аңлаган кыяфәттә.

Таныш, җиз тавыш... Елмаюы башка бугай, анда нәрсәдәндер курку сизелә кебек.

— Ярый, мине чакыртмаган хәлдә.

Лена кузгалды.

— Минем сиңа әйтәсе сүзләрем бар. Соңгы кабат.

Мондый вакытта мин нишләргә тиеш булдым икән? Ихтимал, мин

дөрес эшләмәгәнмендер. Хәзерге акыл белән шулай тоела. Ләкин Юрик алдында, аның әнисе алдында Ленаны рәнҗетеп, сөйләшүдән баш тартып чыгып китсәм, мине аңламаслар, алар мине гөрбиян, әдәпсез, тәрбиясез кеше кыяфәтендә күрерләр иде. Аннан соң хәзер Лена белән сөйләшүдән нәрсә югалтам әле мин? Бернәрсә дә. Өйләнмәгән, ирекле икәнемне искә алсак, бигрәк тә. Шуларны уйлап, Ленага каты бәрелергә тиеш тапмадым һәм, аның белән чыгарга риза икәнемне хәрәкәт белән сиздерсп, салмак адымнар белән тышка юнәлдем.

Шактый ара сүзсез килендә. Саз суын бүлеп ясалган буа өстеннән атлыйбыз. Су тып-тыныч. Тирә-якта куаклар. Кошлар тавышы сирәк ишетелә. Төн уртасы инде, табигать ял итә. Бакалар да анда бер, монда бер генә аваз бирә. Алар үзләренең чиста тавышлары белән я теге якта, я бу төштә ямансу бер ямь сирпиләр.

— Без күрешмәгәнгә ничә ел инде? — диде Лена, уйларымны бүлдереп. — Мин тиз генә җавап бирмәгәч, өстәп куйды, — үзең хакында сөйләр идең.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның.

— Ә?! Теләмәсәң сөйләмә, мин барыбер беләм.

— Син нәрсә беләсең?

— Миннән аерылгач, биш-алты ел авылда эшләдең. Эшләп укыдың, урта мәктәп бетердең. Хәзер университетта студент.

— Сиңа кем әйтте боларны?

— Мин синең һәр хәрәкәтеңне белеп торам, яшерсәң дә.

— Нәрсәсен яшерим... бөтенесе...

Җавап эзләп тотлыккан арада, Лена сүзне икенчегә борды:

— Син музыкадан аерылдыңмыни инде? Нишләп әле син консерваториядә түгел?

— Алмыйлар. Хәзер укучыларга кытлык бетте. Консерваториягә керү өчен башта музыка мәктәбе, аннан училище бетерергә кирәк. Минә егерме дүрт яшь. Беренче класстан башласаң, «алладан» икенче бер гомер сорарга туры килер иде.

— Ә болай кем булып чыгасың инде?

— Белмим.

Бер ара сүзсез торганнан соң, Лена мине култыклады.

— Китикме? Монда әллә ни матурлык күрмим мин.

— Аны күрә белергә кирәк.

Бака дуслар белән аерылышасы килмәсә дә, кузгалырга туры килде. Каршыда — сазлыктан соң еш очрый торган урманлы тау. Сукмакларның берсе тау итәге буйлап, сазлыктан биш-алты метр чамасы арадан уза. Бераз килгәч тә, Лена, яшь агачка сөялеп, башын игән хәлдә, тынып калды. Мин сукмакның икенче ягындагы агачка тотынып, аны күзәттем. Ленаның кыяфәте ямансу, кайгылы иде. Мин аның мондый кичерешле вакытын беренче тапкыр күрәм. Тормыш өйрәтә, димәк... Менә ул башын күтәрде. Мин аның күзләреннән атылырга торган яшь бөртекләрен күргән кебек булдым. Аның иреннәре нәрсәдер әйтергә талпындылар. Әмма мин берни ишетмәдем. Соңыннан ул ишетелерлегрәк итеп әйтте:

— Нинди шәфкатьсез бу тормыш.

Әлбәттә, бу сүздә минем өчен яңалык юк. Үземнең чирек гасырлык кына гомеремдә кайберәүләр бер гасырда күрә алмаганны күргәнмендер, бәлки. Мин аңлыйм. Ә Лена бу ачышны ничек ясады икән?

Әле берничә ел элек кенә без үз кешеләрчә ни теләсәк, шуны әйтә, сөйләшә ала идек. Теләсә кай җирдә бергә күренә ала идек һәм безне беркем моның өчен әрли алмый иде. Ә хәзер... Карап торсаң, бер үк кешеләр, арада күренер-күренмәс кенә сукмак, ләкин атлап чыгарга кыюлык җитми. Безнең дуслык әллә кайда, еракта калды. Мөгаен, Лена шул хакта уйлап әйткәндер. Бәлки, сәбәп ул гына да түгелдер.

Минем дөреслекне беләсем килде һәм шул хакта сорамыйча тыела алмадым:

— Син ник алай дисең?

— Барып чыкмады минем тормыш, Энис.

Гадәтенчә, хәзер елый башлар дип көтсәм дә, ул бу юлы үзен мин күрергә күнеккәнчә тотмады. Үксемәде, әмма үз-үзен тотышында мин аның тирән яшерелгән, беркемгә дә әйтелмәгән фаҗигасен сизеп калдым. Чын кичереш һәр вакыт шулай тын була, аның тирәнлеге, табигыйлеге дә шунда. Мин аңа якынрак килгәнемне сизми дә калганмын.

— Сез... Ирең белән? Аерылдыгыз?

— Юк. — Сүзнең ул юнәлештә бармаганын тоны белән ишарәләде.

— Соң?

— Аерылышу нәрсә ул. Эт тормышы белән торгач.

— Эчә, сугыша?

— Юаш адәм ул...

— Аңламыйм.

— Эчми дә, сугышмый да. Тынгылык та бирми, өзлексез чәйнәшә, тиргәшә... Синең исемне көненә йөз тапкыр кабатлап, мине иң түбән сүзләр белән хурлый.

— Өйләнгәндә, белеп өйләнгәндер ич! Әйткәнсендер!

Кылт итеп, клубта аларның минем алдан узып китүләре искә төште. Ул чакта нинди горур кыяфәтле иде ул ир!

— Белмичә. Бөтен авыл шаулаганда...

— Шулай булгач.

— Хәзер башкача сөйли. Кичерә алмыйм, ди. Шулкадәр туйдым, беләсең, шулкадәр...

Яшь аралаш йөрәк ярсынуы белән өзгәләнеп әйтелгән бу сүзне ишеткәч, аны чынлап кызганудан үземнең дә йөрәгем сулкылдады. Ярдәм итәргә иде. Ничек? Көчсезлектән җан әрнеде.

— Аерыл син аннан,— дидем, бүтән сүз тапмыйча аптырагач.

— Ә син? Алырсыңмы соң мине?

Әлбәттә, мин монысын ук ишетермен дип көтмәгән идем. Үзен-үзе кызгана белми бит кеше, хәзер турысын әйтсәң, үпкәли инде ул. Мөмкин кадәр читләтебрәк әйтергә кирәк. Ләкин теләгәнемчә килеп чыкмады, аны алдарга ярамавы башка килде дә:

— Мин алмасам, кеше беткәнмени, — дидем.

— Ә миңа бүтән кеше кирәкме? Аннан юньлесе булыр дисеңме? Юк... Шушыннан начары да, шуннан рәтлесе дә юк хәзер минем өчен. Син булмагач, миңа барыбер, кем белән торсам да.

— Соң, алай булгач, ник кияүгә чыктың?.. Бергә булмаган хәлдә дә мәхәббәт хакына бөтен гомерләрен багышлаган кешеләр бар.

— Мин шуны төшендем... соңрак төшендем: синең яхшылыгың үзеңнән аерылгач әйбәтрәк сизелә икән. Әгәр мин моны алдан белгән булсам...

Сүз таба алмыйча, кузгалып киттем. Лена култыклап алып, миңа иярде. Хәзер аны рәнҗетүдән куркып, кулын алмадым. Шактый тынлыктан соң тагын ул үзе башлады:

— Әйт әле дөресен генә, син ни өчен миңа өйләнергә теләмәдең? Теге вакытта...

Чын сәбәбен аңлата башласаң, озакка китәр иде. Бу минем яшәүнең бөтен эчтәлеге, принцибы белән, үзеңне-үзең һәрвакыт ихтирам итә алырлык хәлдә булырга тырышу белән бәйләнгән. Бу аның өчен кечкенә нәрсә төсле тоелуы бар, һәм... гомумән, аңлармы әле. Мин аңа болай да авыр атмосфераны беразгына җиңеләйтү нияте белән көлеп, шаяртып җавап бирдем. Ләкин максатка ирешмәгәнемне шул минутта ук аңладым.

— Ни өченме? Өйләнгәч, син, минә хәзерге кебек, минем янга килгән кебек, кемнәр янынадыр йөрер идең ич. Шуннан курыктым.

Бу сүзләрдә шаяруның шәүләсе дә юк, ул чынлыкка туры килә. Дөрес, теге чакта мин моны уйламаганмын. Әмма уйларга мөмкинлек булган. Сүземнең ничек тәэсир итүен Ленаның миннән кулын ычкындыруыннан сизеп алдым.

— Чынлап әйтәсеңме? — диде ул тукталып. Мин җавап бирми торгач өстәп куйды. — Рәхмәт...

Үпкәләвен бераз җиңеләйтү өчен, мин аның кулыннан тоттым. Очрашканнан башлап беренче тапкыр. Лена ниндидер ымлык белән тиз генә гафу итмәячәген белдерде.

Шулай да кулларының ут кебек кайнарлыгы һәм бөтен көченә җәһәт кысылуы миңа нәрсәдер сөйли иде.

Сукмактан читкәрәк, ялангарак чыктык. Инде бераз яктыра да төшкән. Әнгер-меңгердә бераз читтәнрәк торып карагач, тагын бер ачыш ясадым: ах, никадәр чибәр, кызыктыргыч икән син, Лена! Шундук башка бер мәзәк фикер килеп төште: Фәһимәгә мин, ничектер, һич тә мондый күзләр белән караганым юк иде бит... Ник шулай икән?

— Кил әле, утыр әле, — диде Лена ышыграк җиргә, куак артына җиткәч.

Утыргач ук күзләренә карадым. Ул, еларга житешкәндәй, үпкәле караш белән карап торды да кинәт минем муеннан кочаклап алды: нәрсә өчендер ялыну, якын итү билгеләре мине бөтереп алгандай тоелды. Ул куллары белән җилкәләргә сарылды, баштан сыйпады, күкрәккә башын куйды, аннары ирениәргә кытыклау төслерәк рәхәтлек бирде. Шул минутларда ул тагы миндә үзенә ниндидер җылы хис тудырды.

— Бүген мин синең ихтыярда. Аңлыйсыңмы син?..

* * *

...Инде кайтыр якка кузгалдык.

Бая килгән сукмак буйлап ул алдан атлый, мин читтәнрәк. Гаепле кешеләр сыман, башлар иеле. Барышлый Лена тез биеклегендә үскән сары чәчәкләрне өзгәләп, ургалгандәй атып бәрә дә, тагын өзә, тагын ыргыта. Әллә сары чәчәкнең халыкта таралган билгесенә ышана инде.

— Сорарга онтылган, гафу ит. Укулар ничек бара соң синең?

— Әйбәт. Рәхмәт.

— Ярдәм итүче бармы?

— Мин аңа мохтаҗ түгел.

— Шулай да, җиңел түгелдер...

— Анысы инде...

— Мин сиңа ай саен акча җибәрә алам.

— Рәхмәт. Беркемгә дә бурычлы буласым килми.

— Ә син беркемгә дә бурычлы түгелме?

— Әйе. Бурычлы. Алар күп — минә шушы тормышны безгә калдырган кешеләр.

Буа янына житәрәк Лена туктап калды. Моннан бераз гына элек булган борчулы төсе үзгәреп, яктырып китте. Әйтерсең, күптән түгел булган чәнечкеле сөйләшү аңа тәэсир итмәгән иде. Шулай тиз үзгәрә торган җиңел холыклы кеше инде ул, язгы һава кебек: яңгыры-кояшы, яшене-бозы — барысы бергә.

— Укуың беткәч, — диде ул һәм чын елмаюы белән елмайды. — син зур кеше булгач, приемга килсәм, берәр үтенечем булса, ярдәм итәрсеңме миңа?

Лена! Миңа карата мондый иллюзияләрең һаман калдымыни әле? Син минем кемлегемне тәки белә алмадың бит.

Минем гомеремнең яртысы — шушы көнгә хәтле инде — үземнең кешелек дәрәҗәмне югалта язганда саклап калу, теләсә нинди кыен шартларда да төшермәү, үземнең «мин»емне һәртөрле ялганнан, түбәнлекләрдән азат хәлдә тоту, горур шәхесемне раслау өчен көрәшеп узды. «Зур» дигән төшенчәне дан белән дә, югары постлар белән дә бәйләмим. Дәүләт күләмендә исеме булган күп кенә вакчыл, куркак кешеләрне беләм мин: аларның иң зур осталыклары — принципсызлык, демагогия. Бүген бер сүз сөйләсә, иртәгә ул аннан күз дә йоммыйча баш тарта, хәтта үз сүзләрен кабатлаган кешеләрне сыгылмалык җитмәүдә, политикасызлыкта гаепли. Болар — иң кечкенә җаннар. Кеше өчен шундый ахмаклар алдында — гәрчә язмыш шаяртуы аркасында бу үтмәс пычаклар зур йогынтыга ирешкән хәлдә булсалар да — алар каршында аңлы рәвештә юхаланудан, ярарга тырышудан да зуррак мыскыллану бармыни!

Мондый карашта торганда, билгеле, үзеңә зыянны шактый еш эшләргә туры килә. Әгәр мин һич югында бер генә тапкыр шушы принципымнан чигенсәм икән, ихтимал, кешеләр арасында зуррак йогынтыга ирешкән, күбрәк эш башкарырга өлгергән булыр идем. Ләкин миңа андый уңышлар кирәкми. Үз алларында бил бөгүемне, туры гәүдә белән тормавымны көткән кызганыч бәндәләр ялгыштылар — мин, кайбер яшь ялагайлардан аермалы буларак, үземнең бүгенге көнемә һичнинди яраклашусыз килдем. Бу яктан мин максатыма ирештем, бу — җиңү, намуслы җиңү. Намус һәм бәхет сүзләре барлык телләрдә дә ничектер бертөрле, охшаш яңгырыйлар төсле. Дөньяда иң зур фаҗига үзеңне ихтирам итү өчен хакың булмау...

Ә Лена олылыкны үзенчә аңлый һәм тормышның мәгънәсен ансыз да күрә ала, башкаларның бүтәнчә уйлавын уена да китерми. Шуңа күрә мин аңа үзенчә, гадирәк җавап бирергә тырыштым:

— Мин беркайчан да зур кеше булмаячакмын.

— Менә күрерсең әле. Мин әйтте диярсең, син барыбер... күрерсең... Нәрсәдер бар синдә, әйтә генә алмыйм, минем абый төсле син... Нәрсә, кабул да итмәссеңмени?

— Җүләр син. Кабул да итәр идем, кулдан килә торган булса, ярдәм дә итәр идем. Тик синең миңа карата өметләрең акланмаячак, син аларны оныт.

— Анысы — минем эш,— диде дә ул, читкәрәк тайпылды һәм өстәде,— кара, ничек үзгәргәнсең син... Төсең бөтенләй икенче... ямьсезләнгән димме?.. Кызлар түгел, хатыннар ярата торган...

— Рәхмәт... яхшы сүзеңә,— дидем шаяртып.

Ни өчендер хәтер калмады.

Ул минем кулларны кысып тотты, күзгә туп-туры карап, башы белән артка, буа өстенә тартылды. Әгәр мин ычкындырсам, суга аркасы белән төшәчәк иде.

— Хәзер син минем кулда,— дидем мин ирексездән көлеп.

— Шуңа күрә курыкмыйм да!

Ул янадан тураеп, миңа атылды:

— Я, хуш, мин әйткәнне онытма. Мин сине барыбер яратачакмын. Мин бүгенге кебек үк гомер буе синең ихтыярда.

Тирес күпер буйлап ул үзе генә атлады. Минем күз карашын сизгәндер, әлбәттә, берничә тапкыр артына борылды. Җиз тавыш белән көлә-көлә җиңел адымнар белән су буендагы таллар арасына кереп югалды. Шул мизгелдә баштан уй узды: «Лена — бәхетсез, аның кебек яшәп калган булсам, мин дә аның төсле булыр идем».

Кара көннәремнең матур һәм бәйләнчек юлдашы! Я, хуш, вакытлыча түгел, мәңгелеккә.

* * *

Һәр аерылышу күңелне аз гына булса да ямансу итә. Кайвакыт яратып кигән киемең тузгач та кыенлык белән ташлыйсың бит. Ә монда катлаулырак, гомернең бер өлеше белән саубуллашырга кирәк... Ул чакта мин шундый хәлдә идем, җәй дә акрын узгандай тоелды. Ниһаять, мине тагын юл көтә. Тагын аерылу. Тагын ямансу.

Китәр көн.

Чемоданны капка төбеннән читтәрәк үскән карт имән янына, чирәмгә куйдым да туган өй белән хушлашырга тын калдым. Таныш хисләр, таныш кичерешләр — каршыдагы һәр каен, һәр тал: «китмә, кал безнең белән» ди төсле. «Мәчет саклавы»ндагы теге карт нарат — миңа әтием туфрагын онытмаска, ташламаска куша.

Саубуллашырга әни чыкты. Кулында — баян, көчкә күтәреп килә.

— Ник алып чыгасың аны? — дидем мин, аның каршысына барабара.

— Алып китәсеңдер ич!

— Юк. Миңа кирәкми инде ул.

— Нишләп алай дисең, балакаем, гомергә яраткан нәмәң ләбаса!

— Яратсам да...

Мин чынлап, чын мәгънәсендә уйнарга теләгән идем. Укырга. Туры килмәде ич. Ә үзешчәннәр дәрәҗәсе миңа канәгатьлек хисе бирми.

Шул вакыт әнинең сәерсенүле карашын күреп алдым.— Нәрсә, аңлашылмыймы әллә? Баян ул — минем яшьлегем, ул кала инде шушында.

— Ә мин аның белән нишлим?

— Теләсәң нишлә. Теләсәң сатарсың...

...Авыл калды. Инде басу юлы белән атлыйм. Күпмедер җир узылгач, уртасында үзем басып торган гаҗәеп киңлеккә хәйран булып уйга калдым. Кара инде бу иркен дөньяны! Нинди генә төсләр юк анда — алтынсу иген, ямь-яшел люцерна, чем кара сөрүле җир. Бу бит инде теге билчән һәм сарут белән күмелгән, җил иссә мамык бураны күтәрелә торган басу түгел. Мин укырга киткәндә шушы хәлгә килгән иде ул. Бу матурлыкта минем дә өлешем бар. Мин киткәндә «сугыш» дигәнем беткән иде инде, сугыштагы төсле үлүләр беткән иде. Хәзер дә авырлыклар бар, киләчәктә дә булыр. Кыенлыклар да, хаталар да. Ләкин бу инде сугыш булмас, көрәш булыр.

Юл читендә, чирәмдә, кара-туры ат чемченеп йөри. Мин аны танырга итәм. Син бит, минем туры дустым! — Ул башын күтәрде, таныгандай, исәнләшкәндәй пошкырып куйды. Атымны кысып муеныннан сөйдем. Ә күкрәгендә теге җәрәхәт төзәлгән, аның урынына ап-ак йон үскән. Медаль! Теге вакыттагы эшләр өчен бүләк ул аңа. Минем дә бар шундый медалем, тик күренми генә.

Я, хуш!

Якында гына кечкенә бер тракторда ниндидер бер кыз басу әйләнә — үләнә җыйдыра. Аңа таба атлыйм. Иртәнге яктылыкны тагын да көчәйтә төшеп, кыз елмая. Косынкасы арткы яктан бәйләнгән, җилкәсенә бәрелә-сугыла җилферди. Кем ул? Аны да танырга тырышам. Бер авылда айдан артык торып, мин аны күрмәгәнмен. Бәлки күреп тә игътибар итмәгәнмендер.

— Туктагыз әле, мин сезне таныйм ич!

— Мин дә сезне таныйм, сез Әнис абый! — диде кыз елмаеп һәм тракторны минем турыда ук туктатты.

— Ә менә мин сезнең исемегезне хәтерләмим. Ләкин кемгәдер бик охшатам. Сез гафу итегез... мин... Мин сезне Хәтирә апага охшатам.

Кызның баягы көләчлеге, кул белән салдырып алынган матур япма шикелле, күз ачып йомганчы юкка чыкты.

— Сез минем әнине әйтәсез...
— Шулай шул. Ничек, ул терелдеме?
Кызның чырае тагын да караңгылана төште. Тракторның нәрсәсендер борып, чатырдатып җибәрде, гүләү кабат акрынайгач, тирән сулап, уфтанып куйды. Үкенечле тавыш белән әйтте:
— Күпме врачка күрсәтеп карадык — файдасы тимәде.
— Ул исәнме әле?
— Юк, үлде...
Трактор кузгалып китте. Мин кызның җилфердәп торган кызыл яулыгына, чәчләренә, тулы, сәламәт гәүдәсенә карап калдым. Читтән генә күзәтеп торсаң, бу гүзәл кыз күңелендә шатлыктан, куанычтан башка берни дә юктыр сыман тоелса да, якынрак килсәң... Менә ул күкрәп уңыш бирергә әзер торган, күмер төсле чем-кара туфракны эшкәртеп йөри... Бүгенге басуның хаклы хуҗасы, матурлыгы... Әнисен алыштырган...
Агыйдел.
Пароход Агыйдел буйлап бара, озакламый ул Камага, аннан соң зур Иделгә алып чыгачак. Тәрәзә каршында, бөтен шартлары китереп бизәлгән каютада кичке киңлекләргә карап баруы никадәр рәхәт! Авыл кырлары буйлап йөргәндә туган моңнар һаман колакта чыңлый, көчәя. Туган җир-кырлар, болыннар, урманнар, чиксез киңлек. Бу — минем яшьлегем, үзе бер ил... Бу — халык җырының бер өзеге... Әнә ул һаман үсә, төенләнә, һаман ныграк тарткалаша, көчлерәк ургыла, башка тормыш белән яши башлый — моң булып, йөрәкнең иң кадерле ашкынуларыннан туган рапсодия булып формалаша.
Үзем аны тыңлыйм, үзем гаҗәпләнәм: бер кеше башында күпме тавышлар туа һәм сыя ала икән! Бәхетемә каршы минем күңелдә еллар буе яшәгән Бетховен янадан кайтты бугай! Ләкин мин аның кебек симфонияләр, соната-лар түгел, бу юлы туган җирем, халкым тормышыннан бер кыйтга — рапсодия язарга телим. Рапсодия!
Тавышлар туктаусыз агыла, ә күз алдында... Әнә Агыйдел өстеннән үрдәк җилпенеп уза... Ул үзенең яраткан күленә, камышлар арасына барып төшә. Тик аны явызлык сагалап торган икән ерткыч кара кош... Кара кош үрдәккә ташлана, кәкре тырнаклары белән әләктерә, таптый, канлы борыны белән гөнаһсыз кошның күкрәген чукый... Күлдәге суларга алсу һәм саф кан тамчылары кушыла. Кинәт шартлау—мылтык тавышы... Каракош үрдәк өстеннән авып төшә: канатлары салынган, әшәке борыны үрдәкнең канлы күкрәге өстендә ята. Күл өстендә үрдәк каны чайкала, әкренләп бергә укмаша, менә ул яль-яшь бәбкә кыяфәтенә керә. Нәрсә хакындадыр башка үрдәкләргә сөйли... Нәни канатларына каурыйлар үсеп чыга... Менә ул җилпенеп куя һәм канатлар җилпенгәндә каурыйлардан йөрәк җилкеткеч нәфис көй чыга... Ул минем колак төбендә, — тынгысыз көч, нәрсәдер тели, каядыр омтыла, нәрсәнедер узып чыгарга тырыша: «Явызлык, мәкер, хәйлә — кешеләр арасындагы боз таулары. Ләкин алар ни чаклы зур булып өелсәләр дә, никадәр салкын, өшеткеч булсалар да — вакытлы гына яши алалар. Матурлык һәм яхшылык аларны барыбер эретеп агыза. Гомереңмәңгелеккә кушылсын дисәң, яктылык булып яшә син, матур яшә. Тормышны яктылык бар иткән!»
Бу тавыш мин утырган каютада, тәрәзәдә... Юк, түгел, монда тәрәзәдән чыгарга омтылып, адашкан бал корты өзгәләнә икән.
Бал корты әле аска төшә, әле өскә атыла... Шап итеп пыялага бәрелә. Аптырагач, ишек ягына китеп эзләнә. Анда яктылык юк, кабат тәрәзәгә таба безелдәп оча башлый. Тәрәзә ял-якты, ул пыяла барын күрми булса кирәк, килгән юлы чыгып китәргә, табигать кочагына атылырга омтыла, бөтен көченә тәрәзәгә бәрелә. Шулай була ул, дөнья — ял-якты, карыйсың, бөтен киңлекләр күз алдында, синс чакы-

рып, дәртләндереп торалар. Чыга башлыйсың, шап итеп килеп бәреләсең. Күзгә күренми торган ниндидер серле киртә... Бал корты, мин синең хәлне аңлыйм, шушындый камалышта үзем дә аз бәргәләнмәдем. Менә хәзер мин тәрәзә ачам: сине иркенлеккә чыгару өчен!

Ярый, хәерле юл сиңа, канатларың көчсезләнеп өлгермәсә, юлыңны югалтмасаң, үз көчеңә барып кушыл. Ә чәчәкләр күп быел, сине көтәләр.

Пароход бара да бара. Агыйдел безне үзенең изге күкрәгендә бәллүдәге шикелле тирбәтә. Анда, зәңгәр кыңлекләр артында, мине нәрсәләр көтә кебек, йөрәк тыныч түгел, ул һаман эзләнә, әлеге бал корты кебек һаман тиберчена. Нәрсә кирәк, нәрсә җитми миңа?

Җир өстендәге, кешеләр тәнендәге яралар төзәлде. Әмма күренми торган бомбалар һәм пулялар ясаган җәрәхәтләр калды... Аларны рентген нурлары яктылыгында әле дә күрергә мөмкин.

Кешенең бөтен гомере өчен иң җаваплы чорына аның акылы азрак чагы — яшьлеге бирелгән. Әгәр минем иң кирәкле, иң авыр чагымда шул җаваплылык житкән булса, күңелдәге һәм тәндәге яралар тизрәк төзәлерләр, бүгенге көнем бәлки чак кына икенче төслерәк, күләгәсезрәк булыр иде. Хәлемне аңлап, хәзер яшьлегемне кире кайтара алсалар, бу юлы, бәлки, икенче төслерәк яшәгән булыр идем.

Сугыштан югалтусыз чыгып булмый. Безгә дә күп газаплар, күп югалтулар килде. Аларның күбесе, ихтимал, онытылыр. Ләкин иң авырлары онытылмас.

Тавышлар: мәхәббәт табылыр, син яшәгәндә ул үлми. Мәхәббәтсез яшәү юк. Ул алда. Табылмас әйберләр бүтән, бүтән.

Тавышлар, тынгысыз тавышлар...

Мәхәббәтем, дусларым, яшьтәшләрем васыяте, аларның таләпләре, җырлары... Ил тормышы, халык тормышы — үзем кичергән еллар. Алар күңелдә мәңге калачаклар, алар күңелдә мәңге яңгыраячаклар — үлемсез рапсодия булып. Күңелдә — шул рапсодия. Миннән башка аны беркем дә яза алмаячак. Мин үзем булдыра алмыйм — композитор стихиясенә юл ачачак елларны мин югалттым.

Миндә Бетховен үлде...

Үземнән башка беркемне дә гаепли алмыйм һәм теләмим.

Агыйдел рапсодиясе.

Беркем беркайчан ишетмәячәк аны.

Еллар: 1964—1966.

—✦—

*Г. Хуҗиев*

*Үзган елның көзендә арабыздан вакытсыз югалган каләмдәшебез шагыйрь Гали Хуҗиевның соңгы елларда иҗат иткән һәм үлем алдыннан язып калдырган шигырьләре.*

## Рөхсәт ит син миңа...

Дай припасть к руке твоей, Россия,
Вечная заботница моя!
(НИКОЛАЙ РЫЛЕНКОВ)

Килә иде язның илчеләре;
Кемдер атты... Өн дә салмыйча,
Бер мескен кош таштай килеп төште,
Канатларын җыя алмыйча.
Һәм бетте ул... Ачы кыйгаклашып,
Казлар ерак очып үттеләр;
Бу якларга яз капкасын ачып,
Үз юлларын дәвам иттеләр...

Бер китәрбез без дә бу дөньядан,
Югалгандай очар яз кошы.
Соңгы күкрәү ерак авышкандай,
Тынар безнең йөрәк тавышы.

И Россиям, үстем синдә туып,
Чит күрмәдең газиз улыңны.
Гражданиның һәм солдатың булып
Уздым бөтен гомер юлымны.

Тырыштым мин ихлас бу тормышта
Бары синең өчен янарга.
Рөхсәт ит син миңа соң сулышта
Кулларыңа синең авarга.

*1966*

## Яшәү дәвамы

Карыйм да улыма,
Яшьлегем сагынам;
Корылган зарядтай,
Җыр булып кабынам:

Без иртә шакыдык
Капкасын бүгеннең,

Һәм иртә татыдык
Дөньяның хикмәтен.
Яшәдек астында
Яшенле күгенең,
Тир түгеп ашадык
Туган җир икмәген,
Туган җир икмәген.

Солдаты булдык без,
Сарылдык коралга.
Башлангач яңадан
Кан коеш-тартышлар.
Сынадык йөрәкне
Иң кырыс сынауда,
Юл ярды безгә дә
Штыклар, картечьлар.

Очарга талпынып,
Каерылды канатлар;
Эзләдек заманның
Иң гадел җавабын.
Салдылар башларын
Никадәр ир-атлар,
Яклашып тормышның
Бүгенен, дәвамын.

«Сез дә бит — тормышның
Бүгене, дәвамы», —
Шулай дип төбәлгән
Күзләре аларның
Гомернең маягы
Офыктай еракта,
Пөзәбез аңарга,
Чиге юк ярларның...

Инде бит тасырның
Икенче яртысы,
Һәм безнең гомер дә
Авышты шул якка.
Тормышның дәвамын
Күңелеңнен яктысы
Бармаса әйдәшеп
Еракtан-еракка,
Ничек соң беләсең
Вөҗданың җавабын;
Нәрсәдә күрәсең
Яшәвең дәвамын?

Карыйм да улыма,
Яшьлегем сагынам;
Корылган зарядтай,
Җыр булып кабынам:
Ишетәм аңардан
Заманым җавабын
Һәм күрәм аңарда
Яшәвем дәвамын.

*1966*

## Учак

Очкыннарга күмеп тирә-ягын,
Учак яна аккош күлендә.
Өзгәли җил аның ут-яулыгын,
Сөйләшкәндәй давыл телендә.
Өзгәли җил аның ут-яулыгын;
Торам күпне уйдан кичереп.
Сугыштагы полк байрагының
Җилфердәвен искә төшереп,
Өзгәли җил аның ут-яулыгын;
Ахак төсле учак күмере.
«Үз полкымның байрак чугындагы
Бер җеп була алса гомерем,
Ялгашыр ул җиңү юлыбызны,
Ялгашыр ул имин тормышка». —
Шулай диеп солдат барысын узды,
Юлны бикләп яңа сугышка.
Дөрли әле тәнге ут чишмәсе;
Ахак төсле учак күмере.
Күңелләргә өмет-нур өстәүче
Учак була алса гомерем,
Узган чакта заман циклоннарын,
Соңынача янып бетсен ул;
Тормышына шулай башкаларның
Яктылык һәм җылы илтсен ул.
Дөрли әле тәнге ут чишмәсе;
Ахак төсле учак күмере
Күңелләргә өмет-нур өстәүче
Учак булсын иде гомерем...

*1966*

## Каеннар

Ялгыз калсаң төнге урманда,
Аваз салсаң дустың чакырып,
Юл күрсәтер сиңа каеннар,
Ак төсләре белән яктырып.
Юлларымда шулай каеннар
Һаман очрап торса иде, дим,
Һәрвакытта дуслар күңеле дә
Әнә шундый булса иде, дим.

*1966*

## Аның рәсеме

Өй түремдә тора таныш рәсем,
Кайберәүләр каршы әйтсә дә.
Исән чагы әле хуҗасының:
Дирижерлык итә сәхнәдә.

Күзләрендә чагыла Идел күге,
Шулай димәс, белмим, кем аны.
Күзләрендә чагыла күңел күге,
Сыйдыргандай бөтен дөньяны.

Гел талпынып күңелем, яз кошыдай,
Аның үзен көтә шикелле.
Ә ул күптән җырым язмышына
Дирижерлык итә шикелле.

Юк, тынмаган күңел давыллары
Йөрәкләрдә тибеп торудан.
Булмый икән шулай, аннан ары
Туктый алар давыл булудан.

Аңлый ул да үем-исәбемне,
Күз төбәсәм аңа сагынып.
Ишетәм кебек моңын Халисәмнең
Кырларыннан туган ягымның,
Кырларыннан Кайбыч ягының.

Гүя, шулай бөтен рухы белән
Тормышымны бара әйдәшеп.
Һәркайсыгыз аны миндәй белә,
Бу — үлмәс ир, тере Сәйдәшев.

*1966*

## Тормыш корабында

Җилле-давыллы дәрья ул — тормыш;
Юлга кузгалгач, тукталыйк нишләп, —
Йөзәбез ерак.
Олы җилкәнгә
Күпме күңелләр
Җилкәнен өстәп.

Әйтерсең, җирнең магнит кыры без,
Тартыла безгә бөтен киң җиһан.
Киерелә җилкән,
Бөтен корабның
Бергә сулаган
Күкрәге сыман.

Дәрдмәнд корабы түгел инде бу,
Тартмый упкыннар, бездән җан сорап.
Яңа кыйтгалар
Ачкан шикелле,
Таңга юл тотып,
Йөзәбез ерак.

Мин — гади юлчы шушы корабта;
Күңелемдә гадел мәхәббәт гөеп, —
Гадел юлдашка
Ышанып йөзәм,
Каршы җилләргә
Йөземне куеп.

Өстемдә илнең йолдызлы күге:
Узасы дәрьям тирән дә, киң дә.
Яңа язмышлар
Ачышкан кебек,
Иртәгәбезне
Ачышам мин дә.

Йөзәбез ерак дулкын сыртында;
Көн туган саен — сынаулар яңа.
Хәтәр давылга
Басабыз каршы;
Уттай җилкәндә
Каныбыз яңа.

Каныбыз яңа һәрбер маякта;
Үтәбез юлның иң авыр чагын.
Заман җилкәнен
Югары тотып,
Якты киңлеккә
Йөзәбез тагын.

Мин — гади юлчы шушы корабта;
Узасы дәрьям тирән дә, киң дә.
Җырларым җиткән
Күңелләр аша
Иртәгәбезне
Ачышам мин дә.

*1966*

## Гомер китабы

Һәркемнең бар гомер китабы,
Әлифбасы аның бик ачык:
Сайлаганыңмы юлның авырын, —
Син тормышка, димәк, гел гашыйк.

Гаҗәп бит ул мондый гашыйклык:
Тормыш күпме кырыс булса да,

Нинди авыр җиргә куйса да,
Җыермасаң ана кашыңны,
Ул да сиңа кашын җыермас,
Һәм яшәвең эзсез җуелмас.

Башы аның — бишек җырында,
Мәхәббәтең анда кабынган.
Солдат аны сугыш кырында
Каны белән язып калдырган.

Каны белән... Аңлыйм мин аны
Һәм баш иям андый дастанга.
Уч төбенә алып дөньяны,
Үз күңеленнән тәрәз ачканда,
Яза аны һәркем үзенчә;
Бөтен хикмәт шунда, безнеңчә:
Аны күпме тырышып эзлисең,—
Нинди эшләр белән бизисең:
Җыр итепме йөрәк тавышың?
Басу тулы иген игепме?
Үзгәртешеп сулар агышын,
ГЭС утларын эшкә җигепме?
Яшәү — янып алга омтылыш;
Әйтер фикерем шушы тирәдә:
Никадәрле биек очса кош,
Баласы да шуңа өйрәнә.

Һәркемнең бар гомер китабы,
Анда синең бөтен үткәнең.
Коелгандай имән яфрагы,
Ябылалар аның битләре.

Гомерем кырын ничә барладым,—
Күп түгелме кысыр җирләре.
Юлым ерак... Күңелем корабын
Ерак әйди заман җилләре...

Кабатланмый тәүге мәхәббәт —
Яшь хыялның чыңга ашканы.
Кузгатмый ул кемнең йөрәген,
Шундый булсын гомер дастаның!

*1965*

## Без—кичәге фронт кешеләре

Без — кичәге фронт кешеләре,
Ир башыннан ниләр кичмәгән.
Иманнарнең нинди ишләре соң
Җил-давыллар күреп үсмәгән!?

Танкист дусның әрнеп әйткән сүзе
Бүгенгедәй әле исемдә:
«Белим дисәң солдат хезмәтен син,
Янып кара танк эчендә...»
Сугыш белән бу көн аралары
Ерак инде.

Әмма әле дә
Дусларымның авыр яралары
Сызлый, гүя, күчеп тәнемә.

Кеше күңеле — гаҗәп барометр,
Күрсәтсә ул җилне-давылны,
Тешен кысып, аңа кагылмый тор,
Аңлый белсән нәрсә авырны...
Фронтовиклар — дусның бер дигәне,
Каш җыера торган түгелләр.
Тамырлары кебек бер имәннең,
Аерылгысыз безнең күңелләр.

Чын дус итсәң кемне ут астында,
Ул — ташламас якын дус һаман.
Эссе елны, җәйнең уртасында,
Яңгыр юктан янып сусаган
Җирдәй сусый
Күңеле чын дустының
Синең олы күнел хисенә.
Ерак юлда очар кошчык та бит
Мохтаҗ була үзенең ишенә.
Бутамасын тагын заманнарны,
Сугыш уты дөрләп, көйрәп тә.
Планетаның азмы яралары
Болай да бит сызлый йөрәктә,
Болай да бит сызлый йөрәктә...

## Бер уч туфрак

Җәйләрен дә, кышларын да
Гел беренче эшелонда
Иңләп үттем Кобзарь җирен,
Фронттәшларым белән бергә.
Походларда тозлы тирем
Азмы тамды шушы җиргә.

Узып кургаш бураннарын,
Безне көткән туганнарның
Тоеп күңеле сулкылдавын,
Карпатларны иңләп үттем.
Гади поход сумкамда мин
Бер уч изге туфрак йөрттем.

Васыять итеп туганымнан,
Бөек Кобзарь туфрагыннан
Алдым аны ерак юлга.
Утта янып-көйгәнгәме,
Анда нәфрәт йөргәнгәме,

Хиросима көле кебек
Чиксез кайнар иде ул да,
Авыр иде, Хиросима
Кайгысы да кушылганга.
Уттай көйдереп алды сыман,
Йөрәгемә кысылганда.

Ут-су аша уздык ерак,
Эльбагача житте туфрак.
Походлардан илгә кайткач,
Туганнарым — Тукай, Такташ
Каберенә сиптем аны,
Күрмәсен, дип, дөнья тагын
Утлы, хәтәр циклоннарны.
Күтәрелеп күмер-көлдән,
Тормыш кабат яңарганда,
Олы дуслык чәчәкләре
Шытсын, дидем, аңардан да...

*1965*

*Радик Фәизов*

# ГАФУР

*Хикәя*

Балачакның шунысын бик ачык хәтерлим, иртән капка төбеннән кемнеңдер «эһем!» дип йөткереп үткәненә уянып китә идем. «Йокла, улым. Әле Гафур гына кузгалды», — ди иде әни. Кояш чыкмаган, ә өй эче яп-якты инде. Өй буендагы өянкедә сыерчык сайраганны тыңлап ятам. Күз алдыма озын сакаллы, кулына таяк тоткан, иске бишмәтен киндерә белән бәйләгән бер кеше килеп баса. Бу — таң белән малайларны уятып йөрүче Гафур үзе була инде. Ул бик әйбәт кеше, таягын селтәп куркытмый. Кесәсеннән кызыл билле прәннек эзләп, миңа күз кыса.

Урамдагы гөрелтегә мин тагын йокымнан айнып китәм. Гөрелте көчәя бара. Гүя, бик күп абыйлар безнең капка төбен утын тукмагы белән төеп уйныйлар. «Курыкма, улым. Гафур тайларын болынга алып китте», — ди әни. Хәзер инде минем күз алдына бик зур атка атланган, аяклары җиргә тиеп торган баһадир егет килә. Ул кулындагы озын чыбыркысын селти, озын итеп сызгыра. Аннары нәкъ өянкедәге сыерчык кебек сайрап җибәрә. Әй кызык та була инде. Аннары... Мин чынлап уянып китәм. Әни инде күптән эштә, кояш та манара биеклеге күтәрелгән.

Мин Гафурны күрмим, бары тик ишетәм генә. Күрше апалар да: «Бүген Гафур йөткергәнгә уянмыйча калдым. Сыер саварга соңара яздым», дип сөйләшәләр.

Тиздән мин аны күрдем. Бик ялына торгач, бер якшәмбе көнне әни базарга үзе белән мине дә алып барырга булган иде. Без капкадан гына чыккан идек, таныш йөткерү ишетелде. Безнең яннан, әле җәй көне булса да, аягына ыштыр чолгап башына бүрек кигән бер егет йөгереп үтте. Аның кәзәки итәкләре мәзәк җилферди, ә елмаюы нәкъ минем иптәш малайларныкы төсле иде.

— Базаргамы, Зәкия апа? — диде ул һәм, җавап көтеп тормастан, югары очка йөгерде.

— Нишләп алай итә ул, әни? Дәү кешеләр йөгереп йөрмиләр ич инде, — дидем мин.

— Акылга сау түгел ул, улым, — диде әни.

— Алайса, ник тайлар көтә ул?

— Аның да тамагы бар ич, улым. Бу дөньяда эшләмичә бирмиләр, — диде әни.

Үсә төшкәч, мин Гафурны көн дә күрә башладым. Кояшта янып каралган йөзле, кырынып та җибәрсә, шактый күркәм кеше иде ул. Мәктәптә укымаган, акча исәбен дә белми иде. Өйләнмәде. Уенны чыннан аермый иде. Кызлар һәм яшь хатыннар аны шаярталар, кулларын җәеп кочарга килгән булалар. Ә Гафурның коты алына. Ул ямьсез кычкырып,

абына-сөртенә качып китә. Әмма кичләрен үзе егетләр белән урамга чыга. Гармунга кушылып, матур гына итеп мәхәббәт җырлары да җырлый. Мондый вакытта капка төбендә утырган кайбер хатыннарның күзенә яшь килә. Авыл халкы Гафурны кызгана иде.

Яшьрәк вакытында Гафур җиң сызганып эшләде. Мин аның урамда очраган һәр кешегә яңа костюмын күрсәтеп, нәни балалардай куанып йөргәнен хәтерлим. Бу — тайларны яхшы караганы өчен колхоз биргән бүләк иде. Аннары Гафур күп еллар көтү көтте. Кыскасы, ул үзен дә, инде картайган әти-әнисен дә туйдыра иде. Олыгайган саен шактый арулана төшеп, акылы да төпләнә барган кебек иде. Сугыш кузгалгач, аны хәтта солдатка да алдылар. Бөтен авыл халкы озата чыкты үзен. «Карап кына йөре, энем. Сине сугышка ук кертмәсләр әле. Юк-бардан куркып кеше көлдермә», — дип киңәш бирделәр.

Әмма Гафур солдат хезмәтенә ярамады, күрәсең. Китүенә бер ел да үтмәде, әйләнеп кайтты. Картлар һәм хатыннар тагын Гафур янына җыелдылар. Ул бик йончыган, ябыгып, картаеп киткән иде. «Кайларда йөрдең, Гафур? Ниләр күрдең?» — дип сорадылар аннан. «Шинше урманнарын да үтеп киттем. Бик күп озын моржалар күрдем. Алардан кап-кара төтеннәр чыга. Эт күрмәгәннәрне күрә икән адәм баласы...» — диде ул һәм елап җибәрде. Ә берничә көннән Гафур яңадан җиң сызганып эшли иде инде.

Сугышлар тынып, дөньялар рәтләнә төшкәч, авыл халкы Гафурга карата бер гаделсезлек күрсәтте. Бу вакытта инде аның әти-әнисе дөнья куйган, тәрбиячесе юк иде. Дөрес, Гафурдан беркем дә җылы почмагын, кайнар ашын кызганмады. Аны хәтта мәҗлесләргә дәштеләр, өс-башын карадылар. Әмма ни өчендер аңа эш бирми башладылар. Гафурны эшкә китереп кушарга, аны үз җае белән өнди белергә, аның турында чынлап кайгыртырга кирәк иде. Кайгырту бер генә яклы булды. Ә Гафур үзе исә җиңел тормышның «тәмен» бик тиз сизеп алды. Ул хәзер инде көннәр буе койма буйларында кояшта кызына, янгын өендә ләчтит сата, өй борынча сөйрәлеп йөри торган булды.

Шулай да, үзе кайчандыр җырлап көтү көткән киңлекләргә тагын чыгарга берничә кат талпынып карады ул. Үзебезнең авылда көтү бирмәгәч, башка авылларга барыпялланды. Ләкин инде яшьлек үткән. Гафур җилдәй өлгер егет түгел иде. Аңа нindидер кулай бер эш, күңел юанычы табып бирергә, ә хәер сорап сузган кулын йомшак кына читкә этәргә кирәк иде. Ләкин халык аны «кызганды», берсе алдында икенчесенең саран күренәсе килмәде.

Мир өстендә яшәү Гафурга зыяннан башканы китермәде. Ул бик тиз картайды. Холкы да бозылып, үзен туйдырган кешеләр белән үк сүзгә килеп йөри башлады. Аракы да эчәргә ияләнеп алды. Беренче стаканнан соң ук исерә, ә икенчедән соң үзен-үзе белми башлый иде. Ә бу хәл аңа бер көтү авыру иярүгә сәбәп булды. Гафур инде бөтенләй эшли алмый иде. Гафур инде «Әпүр»гә әйләнде.

Колхозлар берләшкәч, аңа безнең күрше авылдагы бер буш йортны бирделәр. Тамагын, өстен-башын карауны колхоз үз өстенә алды. Ләкин кеше моңа мохтаҗ түгел иде инде. Кырык биш тә тулмас борын Гафур үлеп китте.

Аны бар йоланы җиренә җиткереп, үзебезнең авыл зиратына, әти-әнисе каберенә янәшә күмделәр. Җиназасына бөтен авыл халкы җыйналды. Күп кешеләрнең күзендә яшь ялтырый иде. Ә минем ул кешеләргә: «Гафурны иртә күмдек. Аның яшьләй үлүенә без гаепле. Безнең киң күңеллелек кешелектән чыгарды аны», дип әйтәсем килде.

# *Кадерле хатын-кызлар! Сезне яз бәйрәме — 8 март белән котлыйбыз!*

*Хатын-кызлар, сездә генә өмет,*
*Сездән башка җирдә ни кызык бар?!*
*Бер могҗиза булып җирдә бетеп,*
*Айда гына булса хатын-кызлар,*
*Ул чагында барча ирләр инде.*
*Космонавтка әйләнерләр иде,*
*Тәвәккәлләп, карамый ай-вайга,*
*Күптән менәр иде алар айга.*



*Ләбибә Ихсанова*

# МИН ӘЛЕ БУ

*Хикәя*

Һай, ул көннәр! Искә дә төшерергә куркыныч көннәр иде ул Хәлимә өчен.

Бервакыт Гомәр китте. Вагын-төяген жыештырды да, бу йортның ишеген яңадан ачып кермәскә дип, чыгып китте. Көтелмәгән хәл түгел иде бу. Соңгы чиккә җитеп тартылган мөнәсәбәтләрнең көннәрдән бер көнне шулай шартлап өзеләсен алар икесе дә көтеп йөриләр иде инде. Кайчан килер бу көн, ничек каршы алырлар ул хәлне — алар әнә шунысын гына күз алларына китерми.ләр иде. Гомәрнең китүе борчылумы, үкенүме, киләчәге өчен курку хисе уяттымы яшь хатынның күңелендә? Хәлимә әле аны ачык кына итеп тоя да алмый, ул әле бу турыда уйларга да курка иде.

Вакыт-вакыт ул Гомәрнең чит-ят җирләрдә ялгыз башы каңгырып йөрүен күз алдына китерә дә кызганып куйган төсле дә була. Ияләнгән иде шул Хәлимә. Кайчакта бит яхшыга һәм бәхеткә генә күнекмисең. Тәңкәнә тиеп беткән әйберләр дә, аерылганнан соң онытылмыйча, бәгырьне телгәләп тора.

Сәер тормыш белән яшәде ул вакытта Хәлимә. Әйтерсең, алар, юлда очрашкан таныш түгел ике кеше, бер чакрыммы, икеме, өчме... дәшмитынмый бер-берсенә ияреп килгәннәр, килгәннәр дә, бер чатка житкәч, әйләнеп тә карамыйча, икесе ике юлдан китеп барганнар. Әнә шул минуттан кинәт кенә ялгыз кала Хәлимә. Бөтен ягын күңелне изә торган авыр тынлык билэп ала. Ә алда бушлык, офыкка кереп югалган ялгыз, озын юл ята. Куркытамы аны бу ялгызлык? Нигә тыныч түгел аның йөрәге? Ни дип әле ул, аерылып, башка юлдан киткән кеше турында уйлана? Үзен белмәгән, белергә дә теләмәгән, аның белән бернинди уртак хис, уртак тойгы, уртак омтылышы булмаган юлдашының дәшмитынмый атлап килүе шулкадәр кирәк идемени соң Хәлимәгә? Аның тын алуларына кадәр ишетеп тору, аяк тавышларын тоеп бару җиңелрәк булдымы әллә?

Бер карасаң, Хәлимә бу хәлне артык чәбәләнми, борчылмый, сабыр гына каршылаган төсле дә булды. Чыннан да, нәкъ шул ялгызлыкны тансыклап, үз уйлары белән генә калып, үзе теләгәнчә, үз җаена гына атлап бару минутларын көтеп килмәдемени соң ул? Хәзер барысы да аның үз иркендә түгелмени? Телисең икән, кычкырып җырла, үксеп ела — ник алай итәсең дип әйтүче булмас. Әмма арыган йөрәк, бушап калган күңел җырларга да, еларга да теләми. Әле тоеп та, сизеп тә булмаган билгесез бер нәрсәсен югалткандай, яшертен генә, сизелер-сизелмәс кенә сызлана. Ул әнә шул каршылыклы хисләренең зурая баруын да абайламый, төштә күргәндәй томанлы бер тормыш белән яши бирә. Хезмәттәш иптәшләре кызгана бугай аны. Сорашмыйлар, кызыксыну күрсәтмиләр, юк-бар белән йөдәтмиләр. Башын иеп, дөньядан аерылып йөргән Хәлимәнең тулып ташкан күңеленә ялгыш кагылып рәнҗетүдән куркалар сыман. Тик болай итеп яшь хатынның хәлен тагын да кыенлаштыруларын гына аңламыйлар. Тиргәсеннәр иде, шауласыннар иде алар, авыру кеше янына килгән күк тын гына йөрмәсеннәр иде, бу уңайсыз хәлдән качып котылырга теләгәндәй, аның күзенә күренми үтәргә тырышмасыннар иде. Җиңелрәк булыр иде Хәлимәгә.

Шулай сөмсере коелып йөргән айларында командировкага җибәрделәр аны. Бу сәфәрдән ачылып, күңеле күтәрелеп кайтмасмы дип уйладылар. Ул үзе дә юл ерак дип тормады, көн пычрак димәде, китте дә барды.

Әллә нинди салкын булды ул яз. Кырлар яшәреп, шомырт агачлары шау чәчәктә утырса да, өстән пальто төшмәде. Кай көннәрне ялт итеп кояш та чыга. Атналар буе коеп яуган яңгырдан бүртеп беткән, инде бер генә тамчыны да үзенә сеңдерә алмаган лычкылдык җир өстеннән баш әйләндергеч җылы пар күтәрелә. Кинәт кенә авыр булып, кирәксез булып калган пальтоны, җылы шәлеңне салып ташлыйсы да, җиңел күлмәктән генә җилфердәп, җил-җил итеп атлыйсы килә. Әмма син шуны уйлап та бетермисең, салкын җилләр исеп, баш очына әллә каян гына кара болытларны алып килә дә аяк астына ярма карлар сибә башлый. Кары, чәчәге, кояшы, яңгыры бергә буталган әллә нинди сәер көннәр булды ул.

Хәер, язына ни әйтәсең. Хәлимәнең үзенең дә күңеле шуңа ошаган иде түгелме соң ул чакта? Командировкадан бераз ачылып, хәсрәтен оныта төшеп кайткандай булды ул. Тирә-ягындагы тормышны да тоеп яши башлады сыман. Әмма йөзе һаман уйчан булды хатынның. Айлар

да үтмәде, янадан аның күңелен бозлары, салкыннары белән кара булыт килеп каплагандай булды. Май аеның теге көннәре сыман, үтереп тә бетермичә, тергезеп тә җибәрмичә, озак азаплады аны. Сәбәпсез түгел иде, әлбәттә. Командировкада йөргәндә беренче кат очрашып та, күңелгә әллә ничек бик тиз үтеп кергән, һаман-һаман искә төшеп, моңа кадәр таныш булмаган сәер һәм татлы хис белән яшь хатынның йөрәген җилкендергән бер кеше иде аның сәбәпчесе. Ләкин Хәлимә аңа танышы турында хезмәттәшләренә әйтә алмады, барысы турында да үзе генә белде, үзе генә көйде, үзе янды.

Әйе, ул аны чын сагыну белән сагынды, бөтен барлыгы белән көтте. Командировкада йөргән көннәренең бер генә сәгатен кайтарып алырлык булып көтте. Шунысы гаҗәп, бергәләп тормыш корган, ничәмә еллар буе бергә яшәгән Гомәре аның бер вакытта да шундый хисләр уятмаган иде. Юкса аның белән дә матур вакытлар, бәхетле минутлар булмый калмагандыр. Күңел якынлыгы өчен уртак түбә генә җитми, күрәсең. Ә аның белән... Хәлимә үзе дә сизми кабынды да тоташ ялкынга әйләнде. Айлар буе йокысыз төннәр кичерде, сөенде, газапланды. Инде менә тынычланган сыман иде, инде күңеле утыргандай булган иде. Бер звонок... Көтмәгәндә шалтырап сискәндерде дә, җәйге эссе чиләдә җәйрап яткан тын урамнан бөтерелеп килгән өермәдәй, бар тынычлыгын алып китте...

— Мин әле бу...

Кем? — дип сорамады Хәлимә. Ул! — дип уйлауга, тыны кысылып, хәлсезләнеп урындыкка утырды. Йөрәге тибүдән тукталгандай булды, ә куллары, тырнаклары агарганчы, чытырдатып телефон трубкасын кысты. Менә бит ул, көтеп-көтеп тә инде онытыла башлаган, инде кирәксезгә, әһәмиятсезгә әйләнә язган минутлар! Никадәр сагынылган идегез, никадәр ялыктырган идегез сез. Звонок шалтыраган саен дерелдәп киткән яшь хатын йөрәгенә шул тавыштан да сөйкемлерәге булмас иде ул чакларда. Алмалы урамнары да ул әйләнеп килгәндә генә шаулап-гөрләп торадыр, кешеләр дә тоташ бер шатлык эчендә йөзеп йөриләрдер сыман иде. Аның район үзәгенә әйләнеп килгән чакларын газетадан укып белә иде Хәлимә. «Маяк» колхозында куйган тәҗрибәләре турындагы мәкаләләрен укый, бил тиңентен ашлык арасында төшкән фоторәсемнәрен кисеп алып куя. Ул көннәрдә татлы бер сагыш белән моңаеп аның шалтыратуын көтә. Әллә ни күп вакыт та кирәк түгел ләбаса моның өчен. Бер генә минут... Хәлимә өчен дип бер генә минутын бүләк итсен икән лә ул. Трубканы алып, аның хәлен генә сорашсын, я үзе турында бер-ике генә авыз сүз әйтсен икән. Хәлимә үзе дәшмәс тә иде, шул салмак, сабыр тавышны, күкрәк түреннән килгән калын тавышны тыңлап кына кинәнер иде. Аннары, бөтен бер җир шарын кочардай булып, куанып, яктырып йөрер иде. Әйе, көтте ул тавышны Хәлимә, бик көтте. Ләкин ул шалтыратмады. Ә хатынның йөрәге аның саен телгәләнде, өмет һәм сагыш, гарьләнү һәм көтү биләде Хәлимәнең күңелен. Күзләреннән күзенне ала алмаслык эчке бер җылылык, нур бөркеп караулары белән күз алдына килә дә ул төн йокыларын качыра иде.

Кайчагында Хәлимә аның да үзе шикелле ут йотып йөрүен тели. Мәхәббәт газабы да булмасын ди ул... Куйган тәҗрибәләренең берәрсе әз генә уңышсызрак чыксын, я салкын тидереп, берәз гына башы авыртып торсын. Бар нәрсәдән канәгать булып, үз бәхетенә үзе кинәнеп, тыныч кына яшәмәсен, берәз гына булса да, бер-ике көнгә генә булса да тормышның ачысын татып карасын. Шул вакыт дөньяда Хәлимә дигән кешенең дә барлыгын, җан тынычлыгын югалтып, өзгәләнеп яшәвен бер исенә төшерер иде, бәлки. Шулай дип уйлый да ул, соңыннан, баласына рәнҗеп тә, каргышы төшүдән шикләнгән ананың тәүбәгә килүе сыман, куркып та куя.Юк, юк, шулкадәр күп көч куйган хезмәтнең уңыш-

сызга чыгуын ни акылың белән теләмәк кирәк. Тегендә, Ык буе колхозларында йөргәндә, аның бил тинентен сазга батып басулардан кайтканын Хәлимә үз күзе белән күрде лә. Язылачак фәнни хезмәте турында сөйләгәндә күзләренең очкынланып-очкынланып януын Хәлимә әле дә оныта алмый. Юк, барлыгыннан канәгать булып дөньяда бер омтылышсыз, тыныч күңел белән яши торган кеше түгел ул. Ничек кызып-кызып бәхәсләшә һәм, Хәлимә үзенекен әйткән саен, яңа дәлилләр китереп, сүзен дөресләргә тырыша. Әмма яшь галимнең фәнни дәлилләренә каршы Хәлимә бала чактан канына сеңгән крестьян интуициясе белән тойган фикерләрен китереп куя да бәхәснең тагын да тирәнәюенә сәбәп була иде.

Командировкадан кайткач, Хәлимә сәгатьләр буе китапханәдә утырып китаплар актарды. Бәхәстә өстен чыгар өчен дәлилләр эзләве генә түгел иде. Гомәрен шул фәнгә багышлаган кешене тегеннән-моннан җыйган гыйлемең белән генә җиңеп буламы соң? Аны борчыган сорауларга ачкыч таба алмаммы, әз генә булса да аңа ярдәмем тимәсме дип утыруы булды Хәлимәнең. Шулар турында уйлый башласа, аның борчулы йөзен күрде, кызыклырак бирәр материалга юлыкса, ул да шатланадыр кебек тоелды.

Йокысыз үткәргән озын төннәрендә Гомәрне исенә төшергәләде. Аерылышкан көннәрдә уйланылмагангамы, менә хәзер, артта калганнарны күңел күзеннән кичергәндә, шуны белде Хәлимә: Гомәр белән алар бервакытта да эшләре турында сөйләшмәгәннәр ләбаса. Рухсыз тормышның күңелсез бер күренеше идеме бу? Әллә икесе ике профессия кешесе булганга шулай килеп чыкканмы? Алай дисәң, Казаннан килгән галимнең «Маяк» колхозында куйган тәҗрибәләре нигә дип шулкадәр кызыксындырды соң әле аны? Ул бәхәснең очына чыгу өчен «Маяк» колхозы урамнарында сөйләшеп үткәргән озын кичләр дә җитмәде. Ык буенда паром көткәндә башланып киткән бу диспутны алар әле тагын дәвам итәргә булганнар иде ләбаса. Ык буенда... Бәлки, әнә шул бәхәсләр, маршрутын үзгәртеп, Хәлимә йөрисе авылларга боргандыр әле аның юлын. Су буенда сөйләшеп торганда башка якка юл тотасын әйткән иде бит. Ә менә Хәлимә эшен бетереп кайтканчы ул аннан аерылмады. Тик шул гынамы соң аның сәбәбе? Ике кеше арасында кабынып киткән бәхәснең очына чыгу теләге генәме? Юктыр. Юлда очраган бер кешенең сүзенә алданып китеп барырга җилбәзәк малай түгел лә ул. Аның йомышы Хәлимә йөргән авылларда да бар иде, билгеле. Аның өчен эшне «Маяк»тан башласа да, «Авангард»тан тотынса да, барыбер иде. Ә шулай да баштагы уен үзгәртеп, Хәлимә белән китте ул. Хәлимә башта моңа әһәмият бирмәде, соңыннан, аннан аерылып, район үзәгенә әйләнеп кайткач, Ык буйларында йөргән чакларын исенә төшергәндә килде аның күңеленә. Ә ул вакытта барысы да бик гади, үзеннән-үзе килеп чыкты түгелме соң?

Алар килеп җитәр алдыннан гына бу як ярдан кузгалып киткән паром кайчан әйләнеп килер әле. Ә елга өстеннән үзәккә үтәрлек салкын җил исә. Яр буеннан коры-сары җыеп учак якты ул. Аннары, паром бәйли торган баганага сөяләп, җилгә аркан торган Хәлимәне ут янына чакырды. Тәмам туңган иде яшь хатын. Чытлыкланмады, ялындырмады, килде дә күшегеп күгәргән кулларын дөрләп янган ялкынга сузды. Бөтен тәне буйлап рәхәт җылылык таралды, бит алмалары кызарып чыкты, күз караларында ялкын телләре чагыла иде аның. Әнә шул вакытны үзенә карап хәйран калган юлдашының карашын тотып алды ул. Бер генә минутка уңайсызланып елмаеп куйдылар. Аннары бик гади итеп, күптәнге танышлар сыман, чын күңелдән сөйләшеп киттеләр.

Бары шул гынамы? Мөнәсәбәтләрне катлауландырырлык берни дә булмады алар арасында. Шуның белән бергә нәрсәдер бар иде, бар иде.

Юкса, «Авангард» колхозыннан башланачак сэяхэтен «Маяк»ка бормас иде ул. Көндезге эшлэр бетеп, кичлэрен клубта очрашкан вакытларны түземсезлек белэн көтеп алмас иде. Бер кичне ул, уңайсызланып кына, Хэлимэнең тормышын сорашты. Хатын, бер дэ яшермичэ, Гомэр белэн яшэгэн чакларын, аннары аерылышып китүлэрен сөйлэп бирде. Ә үзе сорашмады, курыкты. Хатыным, балаларым бар, дип әйтүеннән курыкты. Шулай итеп Хэлимэ аның шэхси тормышын белми калды. Ә ул үзе сөйлэмэде. Башын игэн, кулын артка куйган, салмак кына атлап килэ. Юлдашының күңелсез хикэясен бүлдерми, эмма әйтеп бетергесез бер игътибар белэн тыңлый. Юата белми иде, ахры, ул кеше. Андый сүзлэрне ишетмэде Хэлимэ ул кичне. Эмма юлдашың бөтен йөрэге белэн тойгыларыңны уртаклашып барганда юату сүзлэренең кыйммэте күпме генэ соң. Шуның өчен дэ күңел пэрдэсен күтэрүенэ үкенмэде Хэлимэ. Була бит кайчакта, беренче хискэ бирелеп, эч сереңне сөйлэп ташлыйсың да, нилектэн икэнен үзең дэ белмисең, үкенеп куясың. Ә Хэлимэ, киресенчэ, иңен басып торган авыр йөктэн бушангандай жиңелэеп калды. Авыру кешенең беренче мэртэбэ торып, саф һавага чыккан вакытыдай, күңеле күтэрелеп китте. Аннан аерылганда да, командировкадан кайтканда да шат иде Хэлимэ. Ә менэ ул яңадан Алмалыга килеп тэ, дэшми-тынмый, бер хэбэр бирми китеп баргач, рэнжү билэп алды хатынны. Аннары бу хэл яңадан кабатланды, яңадан... Бер утка, бер суга төшкэндэй, айлар буе жаны телгэлэнеп яшэсэ дэ, Хэлимэ сүндерергэ, сүрелдерергэ телэми иде бу ялкынны. Газапласын әйдэ, эрнетсен. Тик жансыз кешедэй яшэгэн чакларына гына кире кайтармасын. Кайсы вакытларны ул аны аклап та куя: бэлки, ул да уйланадыр, хислэрен сынарга телидер, шуңар гына хэбэр бирмидер...

Ә вакыт үтэ торды. Күңел дулады, дулады да тынып калды. Инде барысы да беткэн, онытылган иде. Һэм менэ хэзер телефон трубкасына ябышкан көе өнсез калды. Ә трубкадан күкрэк түреннэн килгэн салмак кына тавыш ишетелэ:

— Мин эле бу...

Аның тавышы. Бэхеткэме ул, үкенечкэме?

—●●—

*Саҗидә Сөләйманова*



## Көз

Каз канаты —
Кыз канаты.
Киек казлар оча, кызлар!
Сырлы оя, җылы абзар
Теләмиләр киек казлар.

Ишек алды — каз базары,
Каңгылдаша йорт казлары, —
Очты-очты киек казлар,
Шагыйрь, сагынып, җырлар язар.

Ә минә йорт казларына
Тиздән — өмә казанына.

Каз канаты каурый-каурый,
Мич агарта, коймак майлый.

Ак болыттай мамык — йомшак,
Яшь кияүгә мамык түшәк.

Каз канаты кат-кат була,
Канат кагар бер чак була.
Очты-очты киек казлар!
Каз өмәсе җитә, кызлар!
Каз канаты —
Кыз канаты.

## Серләремне сиңа сөйлим

Серләремне сиңа сөйлим,
Агыйделкәй, акмый тор.
Айкамый да, чайкамый да,
Төпләреңдә саклый күр.

Агыйделкәй һай агым су,
Тарая да киңәя.
Серләремне тыңлады да
Салып куйды тирәнгә.

...Төнбоеклар көнгә чыккан
Агыйделнең төбеннән.
Төнбоеклар ник боек дип,
Таллар суга иелгән.

Талларга кунып, сандугач
Сайраган таң атканда...
Эч серләремне кошлардан
Ишеттем үз бакчамда.

Агыйделкәй, серләремне
Сиңа гына сөйләдем.
Саесканнар авызыннан
Ишетмәсен сөйгәнем.



*Мәрзия Фәйзуллина*

## Тапшырылмаган хатлар

Тапшырылмый калган бу хатларны
Күптән инде кулга алмадым,
Ун ел элек язылганнар алар,
Кыйммәтен тик хәзер аңладым.

Җибәримме әллә соң булса да,
Алар табар бәлки иясен,
Мин-минлегем әйтә: яндыр барысын,
Юкка-барга нигә көясең?!.

Хатларымны җыйдым бер урынга,
Яндырырга шырпы кабыздым,
Шырпы сүнде, чөнки бер-бер артлы
Күз яшемне аңар тамыздым.

Мин төшендем шулчак — алар яшәр
Минем белән бергә гомергә,
Мин аларны түгел, алар мине
Әйләндерер көлгә, күмергә.



*Гөлшат Зәйнашева*

## Үз илемдә

Яз да сайрый, көз дә сайрый
Бер нәни кош бакчамда.
Шул кошны сагынып кайтам
Кая гына барсам да.

Бакчам гади, үсми анда
Кипарислар, хөрмәләр.
Миңа таллар кипаристан
Матуррак күренәләр.

Исем китми читтә үскән
Әфлисунга, бананга:
Мин гашыйк, ачы булса да,
Миләш белән баланга.

Мин гашыйк илемдә үскән
Талларның барчасына.
Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да!.

●

*(Илһам Шакировка багышлана)*

Ник чәчәгең сары, диеп
Сорадым көнбагыштан.
Җавап бирде көнбагышым:
«Сагыштан, — дип, — сагыштан...»

Ник тамасың, дип сорадым
Язгы җитез тамчыдан.
Җавап бирде язгы тамчы:
«Ярсудан, — дип, — ярсудан...»

Ник моңлы син, дип сорадым
Суда йөзгән аккоштан.
Җавап бирде миңа аккош:
«Тумыштан, — дип, — тумыштан...»

●

Тәрәз төбемдә гөлем бар.
Күчереп утыртсам сула.
Йөрәгем — шул гөл яфрагы,
Ерак калса ил туфрагы —
Өзелеп төшәрдәй була.

## *Сәлисә Гәрәева*



●

Әй, бер заман үсеп буйга җиттем,
Канатланды күңел, очынды!
Тоеп ямен яшәү дигән хиснең,
Мин кояшка суздым учымны!..

Мин синеке, дөнья!
Бер чәчәгең,
Бер йолдызың таңга елмайган;
Яктылыкка җәеп кочагымны,
Юлга чыктым ерак Тулбайдан!..

Йөрәгемдә Иделләрдәй тирән
Мәхәббәт бар җаны сафларга,
Шул тойгыны җиткерәсе иде
Түкми-чәчми ватандашларга!..

●

Юлларга чыгам ашкынып,
Юлларга чыгам янып,
Очам ТУлар канатында,
Тизлектә ләззәт табып.

Кояшка карап очам мин,
Чәчләр сибелә җилгә,
Очам хыял кочагында
Киләчәк дигән илгә.

Яшьлегем! Син рулем минем,
Мин хуҗа юлларыңа,
Иң изге теләкләр белән
Тапшырыл кулларыма.

Тапшырыл син йөрәгемә,
Киерел ал җилкән булып,
Канатлы хыяллар белән
Үрелсен тормыш юлым!

●

Ул көнче.
Шикләнә һәр сүздән,
Төйнәлгән йодрыклар йон гына...
Кайчандыр шат, көләч иптәше —
Басынкы,
Яши тып-тын гына.

Ир ярын кисәтә, уч янап:
Турылык сакла! — ди, — кич-иртә;
Хисләре хурланган яшь хатын
Тын гына җыр көтә, яз көтә.

# Карлы юллар

Сезнең якка йөгерек атлар уза,
Дагалары бәреләэ юлларга.
Ул яшәгән якка киттеләр, дип,
Күмелгәнче карыйм шуларга.
Сагынуымны җырда сөйли-сөйли,
Күңелем белән сиңа тартылам,
Карлы юлдан узган чаналарның
Сәлам әйтеп калам артыннан.
Дистәләрчә чакрым карлы юллар —
Шулар булә безнең араны.
Дустым килмәс,
кил сә белмәс, диеп,
Ятлар белән йөрмә, кара аны!..
Алмаштырсан мине, боегырмын,
Җырым сөйләр йөрәк сагышын,
Карлы юллар аша, еллар аша
Эзләп табар сине тавышым...
Сезнең якка йөгерек атлар уза,
Дагалары әллә алтыннан,
Сөйгәнемә сәлам әйтегез, дип,
Карап калам шулар артыннан...

●

Кайтып киләм туган якларыма,
Әй, күңелдә хисләр ташуы!
Сагындырган сары гәрәбәдәй
Бодай уңган Тулбай басуы.
Дулкыннарга тияр-тимәс кенә
«Ракета»да очам Казаннан;
Туган җирем!
Сине сөю җырын
Күңелдәге кебек язалмам!
Ә күңелдән тау чишмәсе кебек
Җырланмаган җырлар ургыла;
Тау чишмәсе булып шаулар идем,
Әйтелмәгән хисләр урынына.

●

Син еракта.
Белмим кайдалыгың.
Эзләреңә басып йөрелмәс.
Күңелләрдә сагыну яшәсә дә,
Чәчләребез чәчкә үрелмәс.
Үкенү дә түгел, кайгыру да...
Син яшьлектә калган язларым,
Мин хәтерлим сине.
Син дә шулай
Уйлыйсыңдыр җирдә мин барын..

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

# БЕЗНЕҢ АНКЕТА

*Татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу уңае белән, «Казан утлары» журналы редакциясе прозаикларыбызга түбәндәге сораулар белән мөрәҗәгать иткән иде:*

*I. Галимҗан Ибраһимов безнең культурабыз үсеше тарихында нинди урын тота?*

*II. Галимҗан Ибраһимов иҗатына хас сыйфатларның кайсылары, Сезнең фикерегезчә, татар совет әдәбиятында бүген дә үстерелеп килә?*

*III. Сезнең үз иҗатыгызга Галимҗан Ибраһимовның йогынтысы турында нәрсә әйтә аласыз?*

*Журналыбызның бу санында язучыларның анкета сорауларына җибәргән җавапларын урнаштырабыз.*

*Гомәр Бәширов*

## ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ АКСАКАЛЫ

**Галимҗан Ибраһимов иҗатына хас сыйфатларның кайсылары хәзерге әдәбиятта да үстерелә икән?**

Минемчә, безнең әдәбиятта ул сыйфатларның байтагысы яшәп килә. Әмма алар арасында иң әһәмиятлеләре, минем уемча, Г. Ибраһимовның күпчелек әсәрләренең нигезенә салынган киң колачлылык, әдәби әсәрдә халык тормышының иҗтимагый әһәмияте зур булган актуаль проблемаларын күтәреп чыгу. Бу сыйфатлар безнең хәзерге талантлы әсәрләребездә лаеклы урын алып торалар.

Г. Ибраһимовның әдәбиятта халыкчанлык һәм төрле халыкларның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсенә дә яна, демократик караш кертүен мин аеруча басым белән әйтер идем. Чөнки без, өлкән буын вәкилләре, элегрәк төрле телләрдәге әдәби әсәрләрнең байтагысында еш кына моның киресен очрата идек. Кайбер язучыларның, тыштан никадәр демократ булып күренергә тырышсалар да, «кара халык»ка һәм башка милләт вәкилләренә, хаким сыйныфлар, изүчеләр манарасыннан торып, кимсетеп, түбәнсетеп карауларын, аларны кешегә санамыйча, төрле мыскыллы исемнәр тагуларын әле хәзер дә оныта алмыйбыз. Патша Россиясендә, вак милләтләрне рәхимсез изүгә, тын да алырга ирек бирмичә басып яткыруга корылган кыргый деспотлык шартларында безнең кебек изелгән милләт кешеләренә бу нәрсә аеруча авыр тәэсир итә иде. Бәхеткә каршы, безнең классикларыбыз, шулар арасында бигрәк тә Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов, бу мәсьәләдә революциягә кадәр үк үзләрен дөнья әдәбиятының бөек гуманистлары биеклегендә тоттылар. Без аларның иҗатында гади халыкка һәм башка милләт вәкилләренә тирән мәхәббәт, аларның, нинди генә милләттән булуларына

карамастан, кешелек дәрәҗәләренә һәм җәмгыятьтә тоткан урыннарына зур ихтирам сизәбез. Алар гади халык һәм бүтән милләт кешеләре турында, алпавыттан яки морзадан чыккан кайбер элекке әдипләр кебек, өстән аска карап түгел, бәлки ул халыкларның үз эченнән торып, үзләренеке, үз тиңнәре итеп яздылар. Алар авыл мужигын да, шәһәр эшчесен дә, татар кешесе белән дала казагын да, рус агае белән чуваш күршеләрне дә гомумкешелек югарылыгында итеп күрделәр.

Г. Ибраһимов хезмәт ияләре арасыннан күтәрелгән Шаһбаз, Фәхри, Булат һәм йөзләгән башка геройларын әдәбиятның түренә меңгергән кебек, татар прозасын да кыю рәвештә, батырлар тәвәккәллеге белән, зур дөньяга, киң реалистик юлга, халыкчан юлга җитәкләп чыкты. Мондый кыю адым ясар өчен, билгеле, Көнчыгыш һәм Көнбатыш культураларын тирән үзләштереп, халыкларның барыр юлларын алдан ук күрә алырдай зирәк акыл һәм зур белем кирәк иде.

Шуның белән бергә, Г. Ибраһимов аңлавында халык, хәзерге кайбер әсәрләрдәге кебек, үткән тормышы да, үз гореф-гадәте дә булмаган ниндидер төссез, чырайсыз масса яисә бик күп кешеләр җыелмасы гына түгел иде. Г. Ибраһимов һәм әдәбиятыбыз тарихында тирән эз калдырган башка шундый бөек талантларның традицияләрен дәвам иттерү ул — халыкны чыннан да халык итеп, ягъни аны үзенә хас тарихи, мәдәни, иҗтимагый үзенчәлекләрнең иясе итеп бирү дигән сүз.

Билгеле, халыкның мәдәнияте югарырак баскычка күтәрелгән һәм әдәбият алдына да катлаулырак бурычлар куелган саен, уңай традицияләрнең дә тирәнәя һәм үстерелә баруы таләп ителә.

Г. Ибраһимовның күпчелек әсәрләрендә халык уллары, заманы таләп иткәнчә, нигездә сыйнфый көрәш белән мәшгуль иделәр. Хәзер исә, шул ук юл белән барып, тагын да әчкәрәк керәсе иде. Аерым кешенең шәхси хөрлеге белән исәпләшмәгән, гади кешенең җәмгыять тормышында нинди әһәмиятле роль уйнавын һич игътибарга алмаган вакытлар да бар иде. Кешеләрнең психологиясенә сеңеп калган мескенлек тойгысы, кешенең үзен бик кечкенә бәндә итеп, нәни бер винтик кенә итеп хис кылу тойгысы, шул заманнарның мирасы буларак, кайбер кешеләрдә хәзер дә яшәп килә. Бу нәрсә безнең замандашларыбызның рухи үсешләренә тоткарлык ясаучы, зарарлы искелек калдыгы түгелмени? А. М. Горький бу турыда ифрат акыллы һәм тирән мәгънәле фикерләр әйткән иде:

— Кеше үзенең кол түгеллеген, бәлки хөр кеше икәнлеген үзе тирәнтен аңлап җиткергәннән соң гына чын-чыннан хөр кеше була ала.

Замандашларыбызга әнә шул искелек калдыкларыннан тәмам арынып җитәргә, хөр рухлы, батыр йөрәкле, киң карашлы кеше булып, һәм халкына, туган иленә, коммунизм идеяләренә тугрылыклы булып үсәргә ярдәм итү, минемчә, хәзерге әдәбиятның иң җаваплы һәм мактаулы бурычларыннан берсе.

Мин үзем Г. Ибраһимовның теленә һәм стиленә элек-электән үк гашыйк кеше. Минем карашымча, Галимҗан әдәби тел өлкәсендә, безнең әдәбиятыбыз тарихында исемен мәңгеләштерердәй, аеруча күркәм урын тота. Ул әдәбиятка бик күп яңа тасвир чаралары кертте, әдәби телне һәр җәһәттән ифрат баетты һәм тагын да камилләштерде. Кыскасы, әгәр Г. Тукай халыкның поэтик рухын, аның тел байлыгын, ул телнең матурлыгын, тапкырлыгын һәм эчке мөмкинлекләренең чиксез икәнлеген шигырьдә ачкан булса, шуларны ук Г. Ибраһимов прозада ачты. Галимҗанның иҗат җимешләре әдәби кыйммәте ягыннан әле безнең көннәрдә дә, ягъни күп милләтле совет әдәбияты бөтен дөньяга танылырдай зур талантлар үстергәннән соң да, иң камил һәм яхшы әсәрләрдән санала. Моның төп сәбәбе, билгеле, аның көчле һәм зур художник булуында. Әмма әсәрләренең телен һәм стилен эшләүгә бик күп көч һәм иҗат ялкыны салуы да аларны әнә шулай озын гомерле итте. Аның «Казакъ кызы», «Алмачуар» һәм башка шундый иң яхшы әсәрләрендәге кебек сокландыргыч бай, матур аһәңле музыкаль телне, нәфис һәм тапкыр телне иң талантлы дип йөртелгән әсәрләрдә дә сирәк очратасың. Бу яктан мин Галимҗанны виртуоз дирижерга охшатыр идем. Андый дирижерның кечкенә таягы гына түгел, бәлки, музыканың тылсымлы көченә гашыйк булган хәлдә, ниндидер бер экстазга бирелеп, бөтен гәүдәсе, бөтен барлыгы «уйнарга» тотына һәм ул авазларның үзләренә генә хас тылсымлы дөньясына, сәмави биеклеккә үзе белән тыңлаучыны да алып менеп китә. Галимҗан да шулай. Ул халык теленең «телен» белә, аның иң нечкә тибрәнүләрен, мең төрле яңгырашын ише-

теп, сизеп тора. Ул халыкның гади сүзләреннән, оста дирижер кебек, нәфислегенә һәм музыкаль яңгырашына сокланып туя алмастай сүзләр музыкасы тудыра. Син аның әсәрләрен, һәйбәт музыка тыңлаган, ниндидер бәхеткә ирешкән кебек, рәхәтләнеп, куанып, бөтен дөньяңны онытып укыйсың.

Күп еллар буенча татар язучыларының дусты һәм акыллы киңәшчесе булып килгән Александр Фадеев, Г. Ибраһимовның әсәрләрен генә түгел, хәтта исемен телгә алу да тыелган бер вакытта, аның зур художник, тиңсез оста стилист булуы турында сөйләгән иде. Минемчә, нфрат үзенчәлекле оста стилист булуын Галимҗан әле хәзер дә дәвам иттерә. Моны раслау өчен, тирәнгә китеп тикшеренүләрнең, озын-озын үрнәкләр китерүнең кирәге булмастыр. Сез аның әсәрләре ничек башланып китүен генә исегезгә төшерегез, шул беренче сүзләрнең ничек яңгыравына гына колак салыгыз:

— «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» («Кызыл чәчәкләр»).

Яисә:

— «Фәхрине үтереп ташладылар» («Тирән тамырлар»).

Күрәсез, фәкать бер генә җөмлә, кыска гына җөмлә! Әмма нинди тирән мәгънәле, нинди ялкынлы җөмлә! Шул беренче сүз үк сине, магнит кебек, үзенә тарта, каршыңа берьюлы ничәмә-ничә катлаулы сораулар китереп куя, шундук әсәрләндерә һәм дулкынландыра да башлый. Әле ул гынамы? Син шул бер җөмләдән үк моның бүтән беркемнеке дә түгел, бәлки Галимҗан теле, аның стиле икәнлеген дә абайлап аласың.

Телнең шушы сихри көчен шулкадәр тирән аңлау һәм аны шул дәрәҗәдә оста куллана белү — Галимҗан кебек зур талант ияләренә генә хас сыйфат.

Минем аңлавымча, замандашларыбызның, бигрәк тә яшьләрнең, туган илгә һәм халыкка мәхәббәт кебек патриотик хисләрен үткенәйтүдә, аларның эстетик зәвыкларын тәрбияләүдә Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләре, һичшиксез, зур урын тотарга тиеш иде. Мин аның сайланма әсәрләре һәр укымышлы кешенең (һәр эшче һәм колхозчының дип үк әйтмик инде) өстәлендә булырга тиешле дип уйлый идем. Хәзерге яшьләрнең гомуми әзерлек дәрәҗәсе ярыйсы ук югары, карашлары шактый ук киң булуыннан чыгып фикер йөрткәндә, аларның Г. Ибраһимов кебек классик язучы иҗатына күбрәк игътибар итүләре көтелә иде. Ләкин, кызганычка каршы, алай түгел. Без социалистик культурабыз үсешендә Г. Ибраһимовның нинди зур урын тотуын миллионлаган укучыга һаман да төшендереп җиткерә алмыйбыз әле. Пушкин белән Толстойны белмәү, нинди генә халыктан булуларына карамастан, безнең заман яшьләре өчен зур кимчелек саналырга мөмкин. Безнең шартларда Г. Тукай белән Г. Ибраһимов та шундый ук минимумга кермиме икән? Кызганычка каршы, яшьләрнең күпчелек өлеше Г. Ибраһимов иҗаты белән бөтенләй таныш түгел. Шул ук вакытта, аларның һәртөрле алдавыч эффектларга корылып, тиз уңучан арзанлы буяуларга буялган, әдәби кыйммәтләре бик шикле булган, икенче, өченче дәрәҗә әдәбият белән генә мавыгуларын, билгеле, куанычлы хәл дип әйтеп булмый. Күрәсең, классикларның иҗатларын популярлаштыруга җитдирәк керешергә кирәктер.

Бөек талантларның башкаларга йогынтылары турында сүз кузгалдымы, гадәттә, юбилейлар вакытында еш рак язылучан «кизү» мәкаләләр искә төшә. Ул мәкаләләрдә авторның бөтен сәләте һәм тырышлыгы теге яки бу әдип, шагыйрь талантының оригиналь ягын ачыклауга, аны чын художник иткән, халыкка танытка н үз алымын, үз авазын ачып бирүгә түгел, бәлки бардыр дип, булырга тиешле дип яисә булуы ихтимал дип гөман кылынган нинди дә булса берәр «йогынты» эзләүгә сарыф ителә. «Чынлап торып еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга», диләр бит. Бик тырышып казына торгач, чыннан да, нәрсәдер охшый яисә охшаган сыман тоела башлыйдыр, күрәсең. Менә бер заман сиңа «фәнни сөземтә»: теге шагыйрь фәләннең йогынтысында «кеше» булган, фәлән әдип фәләнгә ияреп дөньяга чыккан...

Шулай, бик мавыгып төрле йогынтыларга бүлгәли торгач, кайвакыт безнең бик сәләтле, бик оригиналь әдип һәм шагыйрьләребез дә, канатлары каерылган коштай, бөтенләй мескенләнеп, боегып калалар.

Мин андый мәкаләләрне укымаска тырышам. Әдәби иҗатның бу үтә нечкә һәм четерекле ягын бик зарури булганда гына, анда да бик саклык белән генә кузгатырга ярый торгандыр дип саныйм. Минемчә, «йогынты» дип йөртелгән бу нәмәстәкәй чын талант иясенең иҗатында хәлиткеч урын биләми. Чөнки теге яки бу әдипнең яки шагыйрьнең үз табигый сәләте юк икән, андыйны хәтта даһилар да «кеше» итә алмас

иде. Йогынты эзләүгә караганда, эзлеклелек турында фикер йөртү әдәбият өчен файдалырак булмас идеме икән? Чөнки берәү дә буш урынга килми, нинди генә талант иясе дә үзеннән элек килүчеләр ирешкәнне өйрәнмичә алга китә алмый.

Галимҗан Ибраһимов минем иң яраткан остазларымның берсе. Хәер, мина гына, хәтта татар язучыларына гына түгел, аның бай һәм талантлы иҗаты башка бик күп төрки әдәбиятларга да озак еллар буенча үрнәк булып килде. Ләкин бу мәсьәлә аерым язучыга, хосусан минем үземә төбәп куела икән, мин, гаҗиз калып, кулларымны гына җәям: чөнки минем иҗатыма Галимҗанның йогынтысы нинди булуы турында кемне дә булса кызыксындырырлык берәр юньле фикер әйтә алуыма ышанмыйм. Минем мона кадәр ул турыда һич уйлаганым булмады. Минем инануымча, көчен һәм хикмәтен тирәнтен аңлаган кеше өчен, бөек язучының талантлы әсәре ул — чиксез мәгънәви кыйммәткә һәм тылсымлы көчкә ия булган бик кадерле рухани байлык. Талантлы әдәби әсәр — кеше күңелен илһам нуры, өмет чаткылары белән нурландырып, тормышка мәхәббәт һәм дәрт бөркеп торучы якты кояш та. Яшәешнең гади күз белән күреп, үз акылың белән генә асылын төшенә алмаган катлаулы серләрен ачарга, кеше рухының баш әйләндергеч дәрәҗәдә буталчык һәм четерекле борылышларын күрергә ярдәм итүче көчле телескоп та. Ул сине кайгырта белүче, кирәк чагында акыл бирүче йөз яшәр зирәк киңәшче дә.

Галимҗан Ибраһимовның бай иҗатында аңысы да, монысы да, тегесе дә, бусы да — һәммәсе дә бар. Мин аның бөек таланты каршында ихтирам белән баш иям.

*Мирсәй Әмир*

# ГҮЗӘЛ ТОЙГЫЛАР УЯТУЧЫ ӘДИП

1. Бу сорауга җавап бирү өчен, Г. Ибраһимовның әдәби һәм гыйльми эшчәнлеге, шулай ук аның дәүләт эшлеклесе буларак күрсәткән хезмәтләре турында зур бер китап язарга туры килер иде. Чөнки гомумән татар халкының рухи культурасы тарихында, аеруча социалистик культурабызның үсешендә аның урыны әйтеп бетергесез күләмдә зур. Әдәбият-сәнгать, халык мәгарифе, гуманитар фәннәр мәсьәләләренә бәйләнешле кайсы гына тармакка кагылсаң да, Галимҗан Ибраһимовның актив катнашына тукталмыйча, ул тарихны язып булмас иде. Һәм моның шулай икәнлеге практикада да күренде бит: Ибраһимовка кагылмыйча, хәтта кагылмыйча гына да түгел, аңа таянмыйча, совет әдәбияты тарихы чынлап та еллар буенча языла алмый торды түгелме соң?

2. Гражданлык пафосы, халыкчанлык, партиялелек — шулардан килә торган актив көрәшчелек позициясе. Һәм мин бу мәсьәләгә кагылган сорауны «Казан утлары» редакциясе биргәнчә: «...бүген дә үстерелеп килә?» дип кенә куймас идем, шуңа тагын: «Һәм үстерелергә тиеш?» дип тә өстәр идем. Чөнки безнең хәзерге кайбер язучылар иҗатында (проза жанрына карата гына әйтүем түгел) бу кирәкле сыйфатларга житәрлек ригая ителмәү сизелә. Галимҗанны зур классик иткән сыйфат аның әдәби осталыгы гына түгел, ә бәлки заманының алдынгы идеяләре өчен актив көрәшче дә булуы.

3. Г. Ибраһимовның йогынтысы минем иҗатыма үз ихтыярымнан тыш килеп керде. Күрәсең, мин аны заманында һава сулаган кебек сулаганмындыр. Чишмәдән су эчкән шикелле эчкәнмендер. Г. Ибраһимовның күп әсәрләрен мин бала чагымда укыганмын. «Укыдым» димичә, «укыганмын» дип язуым очраклы түгел. Ярлы семьяда үскән гади авыл малае буларак, бала чагымда миңа әдәби культура җитмәгән. Кулыма эләккән бер китапны йотылып укый идем. Ләкин аларны кем язганлыгы турында кызыксыну бөтенләй юк иде. Ни өчен миндә ул кызыксыну тумагандыр, моңа мин хәзер дә ачык җавап бирә алмыйм. Күрәсең, мин китапларны да, урмандагы агачлар шикелле, болындагы чәчәкләр, шаулап агып яткан елгалар, күгелҗем таулар һәм тыңлап туйгысыз әкиятләр, җырлар шикелле, үзләреннән-үзләре барлыкка килгән табигый байлыклар дип караганмындыр. «Менә сиңа шәп җырлар», «Менә бигрәк шәп

җырлар», «Менә тагын шәп җырлар», «Җырлар әхтәрисе», «Көлке капчыгы», «Әбугалисина», «Мең дә бер кичә», «Кыйссасел-әнбия», «Көйле иман», «Зәки шәкерт...», «Аг каракларыһ һәм башка күп китаплар бар иде минем өчен. Хәтта «Яшь йөрәкләр» исемле корьән калынлык китап та бар иде. Ләкин авторлары юк иде миңа аларның. Шулай да Габдулла Тукаев дигән шагыйрь барлыгын белә идем. Ихтимал, монысына авылыбызның бер бай кызы турында таралган хәбәр сәбәпче булгандыр: «Мин Габдулла Тукаевка булса гына кияүгә чыгам дип әйтә икән», дип сөйлиләр иде.

Үзем укыган китапларны өч төрле «жанрга» бүлеп йөртә идем: «көйле китап — көйсез китап», «кызык китап — кызганыч китап», «кызык та түгел, кызганыч та түгел» китаплар. Хәер, бер мин генә түгел, миңа тиңдәш башкалар өчен дә уртак «терминнар» иде бу.

1923 елда Стәрлетамакка килеп, 9 еллык үрнәк-тәҗрибә мәктәбенең 4 нче сыйныфына алынып, интернатка урнашкач кына, анда да әдәбият белән кызыксынучы башка малайлардан ишеткәч, хәтта кайбер укучыларның үзләре шигырь язганны күргәч кенә, миндә әдәби китапларны да җирдә яши торган гади кешеләр яза икән, дигән караш барлыкка килде шикелле. «Кызыл чәчәкләр»не инде мин Галимҗан Ибраһимов китабы икәнен белеп укыдым. «Татар хатыны ниләр күрми»не дә — шулай (аның әүвәлге, беренче варианты турында сүз бара). Безнең арада ул китапта язылган хатынның чын тормышта булган кеше икәнлеге турында яхшы белүче малайлар да бар иде. Шундый зур язучының үзенең дә Стәрлетамактан ерак түгел Солтанморат авылында гына туган кеше икәнлеген белү минем өчен искитәрлек яңалык булды. Хәтта тора-бара шул ук мәктәптә минем белән бергә укып йөрүчеләр арасында Г. Ибраһимовка нәсел тиеш бер егет белән кыз барлыгы да беленде. Гаяз Ибраһимов һәм аның апасы Фәрдәнә Ибраһимова. Гаяз хәзер исәндерме, белмим. Фәрдәнә исән булырга тиеш. Ул Уфада яши иде. Фәрдәнә мәктәптә чыга торган кульязма журналга мәкаләләр, хикәяләр яза иде. Каләме бик матур кебек иде. Үзе дә болай бик үткен, укуга сәләтле кыз иде. Мин аны бик шәп язучы булып китәр дип уйлый идем.

Әдәби китаплар, шулар арасында аеруча зур урын тоткан Г. Тукай, Г. Ибраһимов әсәрләре миндә бала чагымнан ук әдәбиятка сүнмәс мәхәббәт һәм зур ихтирам хисе тудырдылар.

Мәктәп иптәшләрем йогынтысы астында әдәби китапларның да җитди хезмәт җимеше булуына, аларны язу өчен дә пәйгамбәр дәрәҗәсендәге кеше булу мәҗбүри түгел икәнлегенә төшенү миңа кулыма каләм тотарлык кыюлык бирде, һәм мин яза башладым.

Г. Ибраһимовның элек (бала чагымда) укылган китапларын мин күп еллар буенча кабаттан укымадым. Хәтергә ничек кереп калган булсалар, шулай сакланалар кебек иде.

1928 елда «Безнең юл» журналында минем «Бәхет порошогы» дигән хикәям басылды. Журналның ул вакыттагы редакторы Гомәр Гали үзенең Галимҗан Ибраһимов белән очрашуын һәм бөек язучының, шул хикәям унае белән, минем исемемне телгә алганлыгын әйтеп куандырды. Галимҗан ага: «Ул хикәя чынлап та яшь язучы әсәреме, «Мирсәй Әмир» берәр өлкән, тәҗрибәле язучының псевдонимы түгелме?», дип сораган ди. Бу минем өчен, әлбәттә, чиксез зур тантана иде. Үз көчемә үзем ышаныбрак, каләмемә тагын да ныгытыбрак ябыштым. «Агыйдел» повесте басылып чыккач (1936), Г. Ибраһимов, мине зур иҗади уңышым белән котлап, үз исемемә махсус хат язып җибәрде. Ул анда повестьны бик ошатканлыгын әйткән, миңа яхшы теләкләр теләгән һәм замечание төсендә төп геройларымның берсенә «Гаяз» исеме бирүемне ошатмавын белдергән иде. Нигә шундый әйбәт образга әшәке кешенең исемен бирдең, дип сорау куйган иде ул. Һәм мөмкин булганда ул геройның исемен алыштырырга киңәш биргән иде (Ул, әлбәттә, үзенең килешмәс дошманы булган Гаяз Исхаковны күздә тота иде). Мин аның бу замечаниесы турында бик күп уйладым, шулай да героемның исемен алыштырырга кирәк тапмадым. Чөнки «Гаяз» исеме башка укучылар өчен бик табигый яңгырый, ул вакыттагы яшь буын укучы Галимҗан ага әйткән Гаязны юньләп белми дә иде инде.

1936 елда без, Фатих Кәрим белән икәүләп, Ялтада аның үзе белән очраштык. Зур язучының Ялтада яткан килеш Казандагы, Мәскәүдәге һәм бөтен Союздагы әдәби хәрәкәтне җентекләп күзәтеп баруы, яшь язучыларыбыз турында да яхшы хәбәрдар

булуы безне гаҗәпкә калдырды. Казандагы әдәби хәрәкәтнең эчендә кайнап та үзебез белмәгән кайбер яңалыкларны анардан ишетеп, кызаруыбыз хәтеремдә...

Хәер, мин редакция биргән сораулар рамкасыннан читкәрәк чыгып, истәлекләр дөньясына кереп барам бугай. Аларны икенче вакытка калдырып, тизрәк максатка якынрак килик.

Соңгы елларда, Галимҗан агабызның иҗат хәзинәсе үз урынына кайтарылгач, мин аның әсәрләрен яңадан укыдым. Менә шунда инде бала чакта укылган ул әсәрләрнең, гәрчә алар ул вакытта миңа бөтен тирәнлекләре белән ачылып җитмәгән булсалар да, үз иҗатыма никадәр көчле йогынты ясаганлыгын бик ачык күрдем.

Композициядә булсын, җөмлә төзелешендә булсын, сурәтләү чаралары куллануда булсын — аның алымнары минем әсәрләремдә еш очрый икән. Үзем уйлап тапкан, тормышны үзем күзәтү нәтиҗәсендә ачкан дип ышанып йөргән кайбер яңалыкларым да Галимҗан агадан алынган ачкыч белән ачылганнар икән.

Мин боларны, әлбәттә, борчылып әйтмим. Киресенчә, аңа рәхмәт әйтеп искә төшерәм. Ул, бөек язучы, үзенең чын мәгънәсендә сәнгатьчә эшләнгән гүзәл әсәрләре белән мине, үземә дә сиздермичә, тормышка язучы күзе белән карарга өйрәткән, миндә гуманизм хисләрен уяткан.

Бер миндә генә мени?! Мин моны Бәширдә дә, Әпсәләмовта да, Фатих Хөсни һәм башка бик күп замандашларымның иҗатында да хәзер бик ачык күрәм. Галимҗан Ибраһимов татар әдәбиятында социалистик реализм методының нигез ташын салучы дисәк, бик дөрес булыр.

*Фатих Хөсни*

# БАСКЫЧЛЫ ЮЛ ЮК!

Без түбәннән күтәрелдек.

Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестенда төп лейтмотив әнә шул. Алай гына да түгел. Әсәрнең җәяләр эчендәге икенче исеме дә шул. Хәтта бу мотив, язучының әлеге хикәясенә генә дә сыеп калмый, ул — бөек әдипнең үзе аша, аның тормышы, иҗтимагый эшчәнлеге, бөтен иҗаты аша кызыл җеп булып сузылып үтә. Күз алдыгызга китерегез: гади авыл мулласының баласы, ишле семьяда үскән, татар мәдрәсәләрендә генә укыган, тынгысызлыгы аркасында «сөйкемсез сояк»ка әйләнеп, алардан да яки куылган («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы») яки үзе ташлап чыккан, кыскасы, үсү, дөньяга чыгу юллары чәчәкләр белән бер дә өртелмәгән бу кеше соңыннан татар әдәбиятының «йөзек кашы»на, танылган әдипкә, галимгә, академикка, Хезмәт батырына әйләнә.

Без түбәннән күтәрелдек.

Бу мотив, тагын да киңрәк мәгънәдә алганда, бер Галимҗан Ибраһимов яки аның иҗаты белән генә дә чикләнми. Бу — безнең барыбызга да карый, барыбыз өчен дә уртак. Әйе, төрлебез төрле юл белән, төрлебез төрлечә, төрле дәрәҗәдә, әмма без барыбыз да түбәннән күтәрелгән кешеләр.

Нәрсә аркасында? Кем күтәрде?

Барыннан да элек, әлбәттә, революция күтәрде. Ләкин бу гаять дәрәҗәдә гомуми аңлату һәм, күп кенә очракларда, без шуның белән генә чикләнеп калабыз да. Янәсе, революциягә хәтле тоташ грамотасыз булган татар халкы революциядән соң тоташ укый-яза белә торган халыкка, үзенең профессорлары, художниклары, композиторлары, язучылары булган халыкка әйләнде. Яки аерым бер әдипнең, сәнгать кешесенең әдәби бәйрәмен билгеләгәндә дә без, күбесенчә, әнә шундый гомуми сүзләр белән шуып-узып китәргә яратабыз: ...аның төп иҗаты революциядән соң чәчәк атты һ. б.

Дөресме болай аңлату? Хезмәт ияләренә һәм материаль һәм мәгънәви яктан иксезчиксез мөмкинлекләр ачучы бөек тарихи фактор буларак, революциябезнең әһәмиятен басым ясап күрсәтү өчен, әлбәттә, дөрес һәм ул шулай әйтелергә, шулай күрсәтелергә тиеш тә.

Ләкин һәр очракта да бер хакыйкатьне күздән ычкындырмаска кирәк: революция аерым кешеләрне кул очларыннан житәкләп йөртүче «нянька» түгел, һәм аның һәр очракта алай назлап торырга вакыты да булмавы мөмкин. Революция безнең кешеләребезгә үсү, түбәннән күтәрелү мөмкинлекләре ачты, шартлар тудырды. Ә бу шартлардан дөрес файдалана белү, бик зур дәрәжәдә, кешенең үз көченә, үз сәләтенә, үз ихтыярына да бәйләнгән. Бу хакыйкатьне дөрес куя һәм аның турында курыкмыйча әйтә белү — революция ачкан киң мөмкинлекләрдән кешенең ничек һәм ни дәрәжәдә оста файдаланып, шул казанышларны арттыру юлында үзеннән нинди өлеш кертканлеген билгеләү өчен кирәк.

Әдип Галимжан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу көннәрендә башка килгән һәм мине тирәнтен уйландырган бер нәрсә шул: бу әдибебез безнең татар дөньясында революция ачкан мөмкинлекләрдән иң оста файдалана белүчеләрнең берсе булды, бер үк вакытта революцион казанышларны арттыру юлында үзеннән иң күп өлеш кертүчеләрнең дә берсе ул булды. Үзеннән соң калдырган хезмәтләрен алып карагыз: матур әдәбият, тел, тарих, публицистика, мәгърифәт өлкәләрендә һәм татар совет культурасын үстерүдәге практик эшчәнлеге нихәтле!

Шушында аның революцияне аңлавы, кабул итүе, революциягә бирелгәнлеге. Шушында ук аның шәхси тырышлыклары, сәләте, художник буларак, үзенчәлекле таланты, йокысыз төннәре, иртә какшаган сәламәтлеге. Ә кем белә, бәлки, кеше күрмәгәндә генә түккән күз яшьләре дә шушында ук тамып калгандыр...

Пушкин безгә үзе күтәрелгән югарылыкка менү өчен баскыч калдырмады, дигән фикерне әйтә Н. В. Гоголь. Тирән мәгънәле һәм әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүче кешеләрнең барысына да кагыла торган фикер. Әйе, безнең беребезгә дә сәнгатьнең нур сибеп торган биеклекләренә менү өчен әзер баскыч калмады, һәм безнең эштә аның булуы да мөмкин түгел. Әлбәттә, Галимжан Ибраһимов та мондый әзер баскычны эзләмәде. Шулай да, үзе кичергән шул кыска һәм мәшәкатьле гомерендә исемен дан белән бизәрлек зур хезмәтләр калдырырга өлгергән икән, моның сере, минемчә, ике чыганакта. Беренчедән, югарыда әйтелгәнчә, әдипнең революцияне «тыңлый», аны ярата һәм үзен аңарга тоташы белән багышлый белүендә. Икенчедән, бусы моның шулай ук бик әһәмиятле, әдипнең, революция куйган интернациональ бурычларны дөрес аңлаганы хәлдә, үз халкына, үз татарына, аның тарихына, аның гасырлар буена жыела килгән борынгы мәдәниятенә, аның теленә, жыры-музыкасына балаларча бирелгәнлегендә.

Үсеп утырган күп тармаклы агачны күз алдыгызга китерегез. Әлбәттә, ул кояшка, яктылыкка, жылыга омтыла. Ләкин аның үсүе, тармаклана, учарлана баруы өчен бу гына житми. Аның әле жир астына — еракка, еракка киткән калын-калын яки күзгә күренмәс нечкә тамырлары бар, шул тамырлары аша ул жирдән дым, азык, яшәү көче ала. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, бездә әле, кызганычка каршы, тормышның өстәге, күзгә ташланып яткан яклары белән генә канәгатьләнеп, үз халкының узганына, аның мәгънәви байлыкларына исләре китмичә карауча каткан «агачлар» да юк түгел. Алдан ук ышанып торырга мөмкин: андыйларның гомере озын түгел, һәм нинди дер кодрәт белән, кайдандыр бик озын баскыч табып, артларыннан этәреп торсак та, без андыйларны кеше күңеленә нурлар сибеп торучы сәнгать «гарше-көрсиләренә» менгезә алмаячакбыз.

Ә менә Галимжан Ибраһимовка андый ясалма баскычлар кирәк булмады. Ул менде. Үз аяклары, үз тырышлыгы, үз таланты белән менде. Ул үзенең яшәвендә дә, көрәшендә дә, иҗатында да, шатлык-хәсрәтләрендә дә үзе булып, нәкъ менә Галимжан Ибраһимов булып калды. Минемчә, бу зур әдипнең татар совет әдәбиятында тоткан урыны, бигрәк тә бүгенге яшь каләмнәр өчен булган бөек әһәмияте — аның, башка берәүне дә кабатламыйча, нәкъ үз дөньясында, үз туфрагында утырып, тамырларны еракка — аска, ботакларны өскә — кояшка сузып күтәрелә белүе белән билгеләнергә тиеш. «Без түбәннән күтәрелдек»нең асыл мәгънәсе дә әнә шунда.

Безнең бүгенге әдәбиятыбызда бу бөек әдипнең кай якларын аеруча сакларга, үстерергә кирәк дигән сорауга җавап та шушы сөйләнгәннәрдән чыга. Сакларга кирәк бәтен якларын. Бүгенге көндәге кайбер таләпләргә бик үк туры килми дигән булып, классик әдипнең аерым әсәрләрен әле теге, әле бу ягыннан кымтырыклый, кискәли башласак, бу соң мәңгелек яшеллегендә шаулап, үсеп утыручы учарлы агачны, ботак-

ларын кисеп, кайрысын кубарып, аннан шоп-шома телеграф баганасы ясау булмасмы? Сон булса да әйтеп китәргә кирәк, мәрхүм әдипнең соңгы өч томлыгын төзүче иптәшләрнең, редакторларының әдиптән шундый телеграф баганасы ясарга омтылу тенденцияләре күренгәләп калды.

Икенче мәсьәлә: кайсы яклары үстерелергә тиеш? Монда да бер селтәнү белән генә өзеп әйтү кыен. Чөнки без бу очракта гаять күп кырлы һәм бөтен кырлары үзенчә җемелдәүче бай иҗат белән эш итәбез. Шулай да, мин үзем бу әдипнең өч ягына аеруча әһәмият бирелергә, безнең бүгенге әдәбиятыбызда үстерелергә, тагын да көчәйтелергә тиеш дип табам.

Моның беренче һәм иң изгесе: үз туфрагына, үз халкына Галимҗан Ибраһимов кебек бирелгәнлек. Халкының тормышын, җырын, гореф-гадәтләрен, үткәнен, хәзергесен һәм киләчәген, шул җирнең законлы баласы буларак, ярату, аның өчен шатлана һәм хәсрәтләнә белү.

Моның икенчесе: үзебездә — олыларыбызда да, яшьләребездә дә — Галимҗан Ибраһимовта кайнаган гражданлык активлыгы кебек активлык булдыру. Ой, бик күбебезгә җитми әлегә бу сыйфат.

Моның өченчесе — бусы, бәлки, сәнгатьчә тасвирлаудагы осталык мәсьәләләренә кайтып калады: табигать стихиясен, табигатьтәге бертуктаусыз үзгәреп торган чагылышларны эпик тасвир белән, геройларның кылган эшләре, психологик чарпалашлары белән органик урә белү, табигать күренешләрен кешегә, җәмгыятькә хезмәт иттерә белү. Г. Ибраһимовтан моның классик үрнәкләрен китерергә мөмкин һәм әдип иҗатының бу ягы, минемчә, аерым тукталып өйрәнүне сорый.

Алынган теманы тарайта барып, ниһаять, Г. Ибраһимов минем үз иҗатыма кайсы ягы белән тәэсир итте, диңән сорауга килсәк, мин монда нәкъ әнә Гоголь телгә алган баскычны искә төшерер идем. Юк, Галимҗан Ибраһимов безнең беребезгә дә ул менгән дәрәҗәгә ансат кына менеп кунакларлык баскыч калдырмады. Безнең һәркайсыбызның үз биеклекләребез бар, без ул биеклекләргә үз аякларыбыз белән, үз йөгебезне үзебез күтәреп, өмет һәм хыяллар белән канатланган килеш, вакыт-вакыт очып, вакыты белән арып тукталa-тукталa, үзебез менәбез. Бик үк җиңелдән булмаган безнең бу сәфәребездә Галимҗан Ибраһимов безгә, бәлки, үзенең нәкъ халыкча янгырый торган матур теле, ару-талуны оныттыра алырлык бизәкләре, йокыга һәм уйхәсрәткә бирелмәскә, гел югарыга омтылырга өндәп торучы хәер-догасы белән ярдәм итә торгандыр. Ахыр чиктә, моның өчен дә без аңарга бик-бик бурычлы.

*Габдрахман Минский*

# БАЙ МӘКТӘП

Культура тарихы шундый гүзәл бер фактны — бер милләт язучысын башка тугандаш милләтләр дә үзенеке итеп тану фактын белә. Моны, минемчә, язучының иҗатындагы гаҗәеп бер хикмәтле көч белән аңлатырга кирәктер. Бу — халыклар дуслыгы көче — заманнар алышу, я үзгәрүгә дә бирешмәгән һәм бер җәмгыять тә ансыз яши алмаган мәңгелек бер көч! Бу яктан безнең татар әдәбияты үзенең ике классигы белән, хаклы рәвештә, горурлана. Аларның беренчесе Габдулла Тукай, икенчесе Галимҗан Ибраһимов. Шуңа күрә дә культурабыз үсеше тарихын халкыбызның бу ике улыннан башка күзаллау мөмкин түгел. Моны исбатлау өчен иҗатларыннан үрнәкләр китерергә ихтыяҗ юк шикелле, чөнки ул үрнәкләр шул хәтле билгеле һәм шул хәтле халыклашкан, бу урында аларны тагы бер кат кабатлау, мең дә беренче кабатлау кебегрәк булып чыгар иде.

Галимҗан Ибраһимов культурабыз үсеше тарихында зур эрудицияле галим һәм ялкынлы революционер, җәмәгать эшлеклесе буларак та күренекле урын тота.

Галимҗан Ибраһимов иҗатына хас сыйфатларның иң мөһиме — халыклар дуслыгы идеясе — бүгенге әдәбиятыбызда аеруча зур үсеш алды. Бу табигый да, чөнки җәмгыятебезнең нигезе шуңа корылган. Халыклар дуслыгы турында көндәлек газеталарда очрап торган хәбәрләр, мәкаләләр, тарихи очерклардан алып фәнни диссертацияләргә кадәр язарга мөмкин. Алар бездә языла һәм үзләренә йөкләнгән бурыч-

ны үтиләр дә. Әмма матур әдәбиятта, аеруча аның эпик формасы романда, культура үсеше тарихына казаныш булып керерлек иҗади уңышлыкларга ирешү өчен, язучының дөньяга карашы, эчке культурасы, таланты һәм әдәби осталыгы кирәк. Бу мәсьәләдә Галимҗан Ибраһимовның әдәби осталыгы без язучылар өчен даими үзләштерә барырга тиешле икенче бер сыйфат. Ә бу сыйфат әдәбиятыбызда сизелерлек үсеш алган роман жанрының камилләшүе өчен бик кирәк булачак. Шушы әйтелгән фикерне атаклы француз язучысы Луи Арагон сүзләре белән түгәрәкләсәк: «Г. Ибраһимовның романнары... Татарстан республикасы совет язучыларына юл әзерләде».

Яшьлегебездә кайсыбыз гына әдәбиятны, аның бай сихри дөньясын Тукай шигырьләре, Ибраһимов хикәяләре аркылы ачмаган икән! Кайсыбыз гына, кулларыбызга каләм алып, уйларыбызны ак кәгазь битенә күчерә башларлык дәрәҗәгә җиткәч, бу ике әдиптән өйрәнмәгән дә, алар кебек язарга хыялланмаган икән! Минем ише, Казан арты авылларында булу түгел, хәтта күрмәгән, каз өмәләрен белмәгән башлап язучының 1926 елда язган «Яңалыкка таба» хикәясендәге вакыйгалар турыдан-туры Галимҗан Ибраһимовтан өйрәнеп, аның хикәяләрендә тасвирланган авылларда «йөреп», каз өмәләрен «күреп кайткач» язылган иде.

Аннары, бер-ике елдан соң, Татарстан авылларында йөреп, аның самими күңелле, сабыр табигатьле, хезмәт сөйгән ирләрен, ачык чырайлы, ананда́й ягымлы кунакчыл әбкәйләрен, апайларын, тел яшергән яшь киленнәрен, алма битле сылу чибәрләрен, базык гәүдәле батыр егетләрен очратканда, мин аларны моңарчы инде бер күргән танышларымдай итеп сиздем. Ә бит мин аларны моңарчы бары тик Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә генә күрдем. Зур художник буларак, Галимҗан Ибраһимовның тормышны, табигатьне бар нечкәлекләренә кадәр шул хәтле тәэсирләндерерлек итеп сурәтләү, хикәяләү осталыгы да әнә шунда, минемчә.

Шул ук елларда, мин үземә таныш балыкчылар һәм эшчеләр тормышыннан «Балыкчылар», «Давыл алдыннан» кебек зуррак күләмле хикәяләремне яздым. Бу хикәяләремне дә мин Галимҗан Ибраһимовтан өйрәнеп, аның ничек итеп сурәтләү чараларын вакыйгаларга эчке бәйләнештә, логик мөнәсәбәттә бирү юлларын өйрәнеп яздым. Образларны фотографларча тышкы төсмерләп түгел, ә хәрәкәт, көрәш аркылы күрсәтү, ачу юлларын да аңардан өйрәнергә тырыштым. Тәнкыйть тә, укучы да җылы каршылаган шушы әсәрләрем өчендер инде, ул елларда Галимҗан ага, үзенең бер мәкаләсендә исемемне телгә алып, остазлык фатихасын биргән иде.

Иҗат тәҗрибәмдә Галимҗан Ибраһимовтан өйрәнгән тагын бер сыйфат, бу — әсәрне башлау (экспозиция) һәм мавыктыргыч бер сюжет кормасында хикәяләп бару (повествование).

Гомумән, әйтергә кирәк, әдәби осталыкка караган бу алымнарның классик үрнәкләре дөнья әдәбиятында гел очрап тора һәм ул үрнәкләрне әдәби осталык теорияләреннән дәрес биргәндә мисалга китерә торалар. Мәсәлән, шундый үрнәкләрнең берсе мәшһүр «Ревизор» комедиясенең экспозициясе (башланып китүе). Хәтерлисездер, пәрдә ачыла. Шәһәрнең түрәләре шәһәр башлыгы Городничий кабинетына җыелганнар. Көтәләр. Городничий керә һәм болай ди:

— Мин сезне, әфәнделәр, бер күңелсез хәбәр әйтер өчен дип чакырдым — безгә ревизор килә!

Рус әдәбиятының классигы Гоголь тарафыннан гаҗәп оста эшләнгән экспозиция бер үк вакытта завязка булып та хезмәт итә.

Галимҗан Ибраһимов иҗатында шуның ише оста эшләнгән экспозицияләр күренекле урынны тоталар һәм алар сине, укучы буларак, әсәрнең беренче юлларыннан ук үзенә алып кереп китәләр. Хәтерлисез, әлбәттә! Мәсәлән, «Тирән тамырлар»ның башлануы: «Фәхрине үтереп ташладылар», яисә «Яшь йөрәкләр»нең башланып китүе: «Кояш тотылгандай булды...» һәм шуннан соң китә вакыйга, башлана язмышлар, кое-ра көрәш һәм бу көрәштә, бу язмышларда кешеләр дә, тереклек тә, табигать тә катнашып кына калмыйча, мәгълүм бер идея функциясен дә үтиләр.

Узган җәй, якшәмбеләрнең берсендә, транзисторлы радиоалгычымны асып, Дербышки урманында йөргән чагым иде. Шул чакны Казан радиостудиясе Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе буенча радиоинсценировка тапшырды. Шуны тыңлагач... «хәйран калдым!» дисәң бик аз булыр, тетрәндем мин. Әйе, әйе, чын мәгънәсендә рухи бер матурлык көчен сизеп, шул көчнең эчке музыкасын ишетеп, тетрәндем.

Бу хикәяне бер укыган идем ләбаса! Дөрес, ул чагында да бу хикәя искитмәле бер куаныч китергән иде миңа. Хәтта мин үземне шактый көннәр хикәянең герое Закир итеп хыялланып та йөрдем. Күптән иде бу хәл, малай чакта. Бу юлы, бик күп еллар узгач, яшьләребез алтынчы дистәгә тулганда, бу хикәя белән мин кабат очраштым. Эфирда. Бу юлы мин Галимҗан Ибраһимов иҗатына хас булган һәм кыйммәтле алмаз ташыдай тирән катламда яшеренеп яткан яңа бер сыйфатны... ишеттем. Әйе, әйе, ишеттем! Мин Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең эчке музыкасын ишетеп хәйран калдым, әнә шул тетрәтте мине.

Әлбәттә, мин гади бер язучы гына. Галимҗан Ибраһимов кебек зур әдипнең иҗат лабораториясе хәтсез бай да һәм җитәрлек өйрәнелмәгән дә. Моны өйрәнү минем вазифама керми. Бу җитди эш һәм әдәбият белгечләре эше. Тик шуны әйтәсе килә, Галимҗан Ибраһимов кебек зур художник язучыларның әдәби осталыклары безнең өчен генә түгел, ә бездән соң киләчәк яшь каләмнәр өчен дә бай бер мәктәп булып хезмәт итәчәк...

*Атилла Расих*

# КИЛЕР БУЫННАРГА ДА ОСТАЗ УЛ

Галимҗан Ибраһимов татар совет культурасы үсеше тарихында үзенә аерым бер урын алып тора. Бөек Октябрь революциясеннән соңгы чорга күз салсак, кырыгынчы елларның башларына кадәр культурабызга иң зур йогынты ясап торган шәхес — ул дип расларга мәҗбүр булырбыз. Бу чорда культура өлкәсендә нинди генә асыл кешеләребез хезмәт итмәсен — аларның берсе дә Галимҗан Ибраһимовка тиң түгел. Чагыштыру рөхсәт ителсә, алар барысы да, кояш тирәсендә әйләнеп йөргән планеталар сыман, данлыклы әдип янында әйләнделәр дияр идем мин.

Шунысы гаҗәп, татар совет культурасының шул бөек фигура йогынты ясамаган берәр өлкәсе бармы икән? Юктыр, мөгаен.

Галимҗан Ибраһимов иҗатына хас сыйфатлар турында сөйләгәндә, иң элек мин аның социалистик реализм методын башлаучыларның берсе булуын әйтер идем. Теоретик рәвештә соңрак эшкәртелгән бу прогрессив ысул тәҗрибәгә нигезләнгән иде. Тәҗрибәне исә — социалистик реализмның практикасын — алдынгы совет язучылары башкарды. Шуларның иң күренеклеләреннән берсе Галимҗан Ибраһимов булды. Әгәр ул метод хәзерге көндә әдәбиятыбызда үстерелә икән — димәк, Галимҗанга хас сыйфатларның иң зурысы үстерелә, тәрәккый итә дигән сүз. Әлбәттә, мәсьәләгә таррак рамкадан, әдәби әсәрдәге компонентлар үзенчәлеге күзлегеннән чыгып та якын килергә була. Ул чагында без түбәндәгеләрне күрсәтергә тиеш булабыз:

«Безнең көннәр» белән прозабызга килгән күп планлылык, социаль тормышны тирәнтен каерып күрсәтү һәм образларны романтик күтәренке итеп бирү — ул, минемчә, бездә әле дә дәвам итә, үсә. «Казакъ кызы»ндагы лиризм, гүзәллеккә игътибар шулай ук дәвам итә. «Тирән тамырлар»дагы халыкчанлык, әсәрне киеренке сюжетка кору һәм композицион камиллеккә ирешү бүгенге проза осталарын иң күп уйландырган мәсьәләләрдән. Галимҗан Ибраһимовның барлык әсәрләренә диярлек хас оптимизм, җиңелчә юмор, яктылык һәм гуманизм, образларның калку да, үзенчәлекле дә булуы — безнең прозабызда һаман үсә, көчәя бара. Инде тел турында, аның халыкчанлыгы һәм шул ук вакытта аны тирән мәгънәле итәргә омтылу турында, стиль камиллеге турында сөйләгән дә юк...

Галимҗан Ибраһимовның иҗаты минем үземә бик зур йогынты ясады. Тукайны, Бабичны сөйгән кебек ук, мин бала чактан бирле Ибраһимовка да гашыйк. «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар»ның беренче басмасы минем китап шкафымда әле дә саклана. Мин аларны укып хәзер дә еш-еш рәхәт минутлар кичерәм. Миңа аерата «Казакъ кызы» ошый. Мин бала чагымда казакъ далаларын күреп үскән кеше. Ихтимал, шуңа күрәдер, ул әсәрне кулыма алган саен, мин дөньямны онытам. Мин аны мавыгып, бер сулыштан укып чыгам һәм соңыннан кайчак пошынып та куям. Безнең прозада осталык ягыннан бу әсәргә тиң нәрсәләр юк бит әле, дим. Җавапларымның азагында шул кадәресен дә әйтим, мин Галимҗан Ибраһимовтан өйрәнүемне дәвам иттерәм, бу бөек әдип татар язучыларының бер буынын гына өйрәтмәс әле дип уйлыйм мин.

*Сөббух Рафиков*

# БЕРЕНЧЕ ЙОЛДЫЗЛАР

Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулу мөнәсәбәте белән «Казан утлары» журналы тарафыннан җибәрелгән анкета бик вакытлы, һәм ул олы язучыбызның әдәби эшчәнлегенең яңа сыйфатларын ачуда әһәмиятле урын тотар дип уйларга кирәк. Әлеге сораулар, күңелне тирәнтен дулкынландырып, башта күп төрле уйлар кузгатты, фикерләр тудырды.

Галимҗан Ибраһимов — бик күптән, мин әле туган авылымда революциядән соң ачылган беренче баскыч мәктәптә укыганда ук, Габдулла Тукай белән бергә, күңелгә кергән исем. Өстемә киндер күлмәк, киндер ыштан кигән кечкенә малай чагымда, саламнары күренеп торган саргылт кәгазьгә басылган мәшһүр «Алмачуар» хикәясен укуым һәм шуннан алган тәэсирләрем, тойгыларым ташу аркасында, мич башында чабата-оекләр арасында мышык-мышык «балавыз» сыгуым бүгенгедәй хәтеремдә. Соңыннан инде, бераз үсә төшеп, Чаллыдагы Карл Маркс исемен йөртүче икенче баскыч мәктәптә укый башлагач, бу якты, нурлы һәм мәрхәмәтле исем безнең яшь йөрәкләргә тагын да тирәнрәк үтеп керде. Ул вакытларда әле дәреслекләр дә аз басыла, һич житешле түгел иде. Без әдәбият теориясен Галимҗан Ибраһимовның революциягә хәтле үк басылып чыккан «Әдәбият кануннары» дигән китабы буенча үттек. Шулай итеп, халкыбызның данлыклы язучысы үзенең әдәби әсәрләре белән безнең күңелләргә кереп канат җәйде, безнең замандашларның уй-фикер һәм белем офыкларын киңәйтүгә үзенең гыйльми хезмәтләре, үткен публицистикасы белән дә ярдәм итте.

Әдипнең күпкырлы эшчәнлеге безнең һәммәбезне дә тирәнтен куандыра, һәм ул татар әдәбиятының горурлыгы булып тора. Алай гына да түгел, Галимҗан Ибраһимов, рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре аша, рус һәм башка халыкларга да күптән таныш язучы. Хәзер, Галимҗан Ибраһимов турында сүз барганда, аның әсәрләре русчага соңгы елларда гына тәрҗемә ителде, дип раслау еш очрый. Әмма бу дөреслеккә туры килеп бетми. Чөнки әдип үзе исән чакта, ягъни утыз җиденче елга кадәр үк, «Татар хатыны ниләр күрми»не, «Безнең көннәр» һәм «Тирән тамырлар» романнарын илебез укучылары рус телендә күрделәр. Шул заманнарда ук үзәк матбугат ул әсәрләргә югары бәя бирде.

Әйе, Галимҗан Ибраһимов әсәрләре безнең күңелләрдә бик тирән эз калдырган, бик җылы урын алган... Табигатьтә елгаларның төрлесе була... Аларның күбесе язгы ташулар вакытында ярларны тутырып аксалар да, аннары кайталар, саегалар. Җәйге эсселәрдә бөтенләй кибеп беткәннәре дә була. Һәркайчан тулып, ташып торган елгаларга салынган сукмаклар беркайчан да өзелми. Андыйлар кешеләрнең йөрәк тибешләренә янадан-яңа куәтләр биреп торалар. Галимҗан Ибраһимов иҗаты да әнә шундый мул сулы елга кебек.

Аның табигать күренешләрен, әдәби каһарманның эчке кичерешләренә бәйләп, гаять үзенчәлекле итеп тасвирлавы, көмештәй чишмә кебек саф тавышлы һәм моңлы, аһәңле, матур, бай теле, әйтерсең лә тылсымлы бер көч белән сине үз артыннан ияртеп бара. Табигатьтәге төрле күренешләрне әсәрнең идея эчтәлегенә тыгыз бәйләп, нинди генә төсләрдә кулланмый ул! Бу урында «Безнең көннәр» романының беренче рус революциясенә аваздаш булып, диңгезнең ярсып кайнавы, тау-тау дулкыннарның шаулавы белән символик төстә башланып китүен хәтергә төшереп үтү дә җитәдер. Аның әсәрләре укыган саен яңа яклары белән ачыла баралар. Бөек язучының иҗади эшчәнлегенә чын мәгънәсендә таң каласың. Ни хәтле җәмәгать эше, берсен икенчесе алмаштырып торган киңәшмәләр, җыелышлар... Ул һәммәсенә дә житешкән. Ни хәтле язган! Бу дистәләрчә роман һәм повестьларның авторы, татар әдәбиятының гайрәтле арсланы бүген дә безнең арада тулы тавыш белән җырлый.

Бер уйлап карасаң, Галимҗан Ибраһимовның иҗат юлы, иҗат итү гомере әллә ни озын түгел бит. 1928 елда Г. Ибраһимовның 20 еллык юбилее уздырылуын өлкән буын кешеләре хәтерлиләр булыр. Аның барлык әсәрләре, шул җөмләдән иң соңгы роман-

нарыннан берсе булган «Тирән тамырлар»ны да кертеп, әлеге егерме ел эчендә язылганнар бит. Бөек Ленинның үзен күреп, аның тирән мәгънәле киңәшләрен тыңлаган ул. Ут, өермә, давыл, ялкынлы көрәш, гаять киеренке тынгысыз хезмәт ташкынында кайнап үткән чиксез матур, чиксез гүзәл юл бу, кабатланмас матур гомер бу!

Минем тагы шундый чагыштыру ясыйсым килә. Хәзер безнең татар әдәбиятының офыклары киң, күге зәңгәр, йолдызлары күп һәм алар якты балкыйлар, якты яналар. Алар һаман ишәяләр. Безнең сөекле әдәби агабыз Галимҗан Ибраһимов үзенең онытылмаслык әсәрләре белән әдәбият күгендә шул якты йолдызларның иң нурлыларыннан берсе һәм иң беренчеләре рәтендә яктырып тора. Аның әсәрләре, иң беренче калыккан йолдызлар кебек, күңел түрендә урын алганнар.

Язучы үзе яшәгән заманның зур һәм катлаулы вакыйгаларын сүз художнигы, сүз остасы буларак ничек сурәтли, ничек киң полотнода яктыртып калдыра — аның үзеннән соң яшәгән буын кешеләре әдип иҗатына әнә шул яктан килеп бәя бирәләр. Галимҗан Ибраһимов әсәрләре тирәсендә фикер йөртсәң, без аның бу авыр һәм җаваплы бурычны намуслы үтәвен бик ачык күрәбез. Ул киләчәк буыннарга чын мәгънәсендә бик бай һәм тирән эчтәлекле әдәби мирас калдырды. Аның әсәрләре, заман сынауларын үтеп, безнең көннәрдә дә тулы тавыш белән яшиләр. Һәм ышаныч белән әйтергә була: бездән соң да яшәрләр.

Халкыбызның культура үсеше тарихында Галимҗан Ибраһимовның тоткан урыны зур һәм мактаулы, әлбәттә. Һичшиксез, язучы һәм галим буларак, ул — татар халкының данлыклы улы, зур шәхес. Әмма, киңрәк мәгънәдә фикер йөрткәндә, Г. Ибраһимов иҗаты бер татар халкы тормышын күрсәтүгә генә дә кайтып калмый. Узган җәй Габдулла Тукай юбилее тантанасына безнең кунагыбыз сыйфатында катнашкан атаклы казакъ язучысы Сабит Мукановның Г. Ибраһимов иҗатына карата әйткән шундый сүзләре искә төшә:

— Габдулла Тукай һәм Галимҗан Ибраһимов — минем беренче остазларым, — диде ул.— «Казакъ кызы» романы — безнең казакъ халкының, бигрәк тә аның хатынкызларының Бөек Октябрьга кадәр газаплы авыр тормышларын тулы һәм дөрес чагылдырган, киң планда язылган әсәр. Ул безнең өчен беренче карлыгач. Ул казакъ әдәбиятының алтын фондына кертелгән әсәр.

Хөрмәтле Сабит ага Мукановның бу сүзләренә аңлатма биреп торуның кирәге юктыр дип уйлыйм.

Татар әдәбиятының тамырлары бик борынгы заманнардан башланса да, Галимҗан Ибраһимовка хәтле бездә чын мәгънәсендә тулы канлы, җитлеккән романнар һәм повестьлар юк дәрәҗәсендә аз иде. Бу бушлыкны ул тутырды. Үзенең реаль тормыштан алып язылган, чорның катлаулы һәм тарихи вакыйгаларына багышланган әсәрләре белән Галимҗан Ибраһимов — татар прозасын яңа үрләргә, яңа баскычка күтәрүдә иң зур өлеш керткән әдип.

Тормышта һәр нәрсә үзгәргән, батыр һәм ышанычлы адымнар белән алга барган кебек, татар прозасы да үзенең колачларын киң җәеп җибәрде. Бигрәк тә сугыштан соң киң полотнода язылган әсәрләр елдан-ел ишәя, күбәя торды. Хәзер татар әдәбиятында ел саен күп исемдә яңа романнар, повестьлар чыгу гадәти күренеш булып китте. Аларның хәтсез өлеше рус теленә тәрҗемә ителеп, әдәбиятның олы юлына чыктылар. Бүгенге әдәбият турында сүз барганда, без Галимҗан Ибраһимовны тирән ихтирам белән искә алабыз. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки хәзерге заман язучыларының күпчелеге бик уңышлы рәвештә Галимҗан Ибраһимов традицияләрен дәвам иттерәләр. Бу, билгеле, механик рәвештә бармый. Иң кыйммәтлесе, иң әһәмиятлесе—язучыларның дәвергә, чорга хас булган зур вакыйгаларны киң колачлы әсәрләр аша ачып салырга тырышуларында һәм бу катлаулы авыр бурычны уңышлы башкарып чыгуларында. Гомәр Бәшировның «Намус», Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел», Фатих Хөснинең «Утызынчы ел», Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Мәңгелек кеше», «Сүнмәс утлар», Нурихан Фәттахның «Бала күңеле далада», Атилла Расихның «Язгы авазлар», «Ике буйдак», Шәйхи Маннурның «Муса», Ибраһим Салаховның «Күкчәтау далаларында», Гариф Ахуновның «Хәзинә», Идрис Туктаровның «Ике егет» романнарын, Әмирхан Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», Габдрахман Минскийның «Яшьнең беренче көне», Салих Батталның «Сигезенчесе кем», Рафаил Төхфәтуллинның «Йолдызым», Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын

жир» повестьларын күздән кичерсәк, минемчә, аларның һәркайсында диярлек бөек әдип башлаган изге юлны дәвам иттерү, ул башлаган традицияләрне үстерү, һәр язучының үзе керткән яңалык белән татар әдәбиятын һаман югарыга, алга үстерү омтылышы көн кебек ачык. Билгеле, язучыларның һәркайсы үзенчәлекле, үзләренең индивидуаль алымнары бар. Бу безнең күңелләргә куаныч сала, бу инде татар прозасының ныклы нигезләрдә икәнен күрсәтә. Әйе, бүгенге татар язучылары Галимҗан Ибраһимов традицияләрен, үзләренең иҗат ялкыннарын кушып, көчәйтеп дәвам иттерәләр.

Инде минем үземә калса, һәм укучы, һәм язучы буларак, Галимҗан Ибраһимовны Лев Толстой, Михаил Шолоховны яраткан кебек үк яратам, остазым итеп саныйм. Болай дөньяда яшәвемә ярты гасырдан артса да, әле минем әдәби иҗат юлым әллә ни озын түгел. Утыз җиденче елга кадәр өч-дүрт еллап каләм тибрәтеп калдым. Аннан соң, ил өстенә килгән авыр афәт буранына юлыгып, егерме ел буе сөйгән эшемнән аерылып торырга туры килде. Хәзер иҗат канатларымның ныгый баруын сизәм. Гомәр Бәширов әйтмешли, четерекле бу хезмәт — иҗат итү — газаплы да, татлы да. Өстәл артына утырып, кулыма каләм алуга, Галимҗан Ибраһимов, гүя яктырып, каршыма килеп утыра. Барыннан да элек аның әсәрләрендәге самими төгәллек, вакыйгаларның тыгыз үрелүе, аның үзенә генә хас, бай образлы теле, каһарманнарның берберсеннән бик нык аерылып торулары, аларның һәр адымда диярлек үз фигыльләре, үз гореф-гадәтләре белән хәрәкәт итүләре тирәнтен таңга калдыра мине. Ниһаять, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендәге төсләрен билгеләп бетерергә мөмкин булмаган туган як табигатенең күңелләргә якын, тере, җанлы гәүдәләнешенә гомерем буе гашыйк мин. Октябрь кояшы күңелемә салган ут яктысында, мин үз әсәрләремдә телгә алган бу сыйфатларны үстерергә, яңа яктан килеп, үземчә ачарга омтылам.

*Нурихан Фәттах*

# МОНДЫЙ КЕШЕЛӘР СИРӘК ТУА

1. Галимҗан Ибраһимов татар халкының, татар культурасының иң олы патриотларыннан берсе булды. Шуңа күрә дә ул гомерен, талантын, белемен тулысынча туган халкына, туган әдәбиятка, культурага хезмәткә бирде. Галимҗан Ибраһимов язучы гына түгел, чын мәгънәсендә тарихчы да, телче дә, тәнкыйтьче дә, шул ук вакытта революционер һәм дәүләт эшлеклесе дә. Мондый кешеләр дөньяга сирәк туа.

2. Бүгенге көндә татар прозасы моңарчы күрелмәгән уңышларга иреште. Безнең язучылар тормышны киңрәк, тирәнрәк аңларга, тулырак тасвирларга тырышалар. Менә шушы киңлекне, тирәнлекне мин Галимҗан Ибраһимовтан килә торган гүзәл сыйфатларның берсе дип аңлыйм.

3. Үз иҗатымда турыдан-туры Галимҗан Ибраһимов тәэсире турында мин берни әйтә алмыйм. Минем буын әдәбиятка килгәндә, Г. Ибраһимов әсәрләрен уку тыелган иде. Нинди бөек Галимҗан Ибраһимов булуы турында, аның нинди искиткеч әсәрләре турында без пышын-пышын гына сөйләшә ала идек. Шулай да, Г. Ибраһимов иҗаты үзеннән соңгы буын язучыларына шундый нык тәэсир иткән икән, ул тәэсир «соңгы буын» язучылары аша, билгеле, миңа да күчкән булырга тиеш.

—◆—

# Дуслар җыры

*Жобан Молдагалиев*

## *Татарстан турында шигырьләр*

### Кырык кыз

Ибай фермалары нинди,
Кырык савымчы, кырык кыз!
«Казакъ кызы, сау бул инде,
Башкайларны җуйдык без!»

Шушы җыр уйга уралды,
Каршы алгач кырык кыз.
Хур кызлары дип аларны
Сокланып карап тордык без.

Кырык пар ут күз елмаеп
Кырык пар уктай кадалса,
Түзәрме йөрәк тын калып?
Яхшы — читтә калалса...

Ятсыну дигән кая ул,
Жанымны кызлар актарды:
Хәтерләрдән чыгарды шул
Йортны, өйдә чакларны.

Аткандай нурлы таң көлеп,
Чәчәк аткан кырлары,
Кызлар да гөл бит мәңгелек —
Балкыды Шәле урманы.

Оҗмахта түгел фәрештә,
Фермадан аны эзлә син.
Шунда, язгы яшел кичтә,
Уздырдык шигырь кичәсен.

Пушкин бар, Тукай, Абай бар,
«Камажай», «Бибисара» бар —

Ярышты ул кич осталар
Көрәшчегә бәрабәр.

Халык тын торды, ул кичнең
Өркетмәде яңгыры,
Анда таралмады һичкем,
Балкып торгач җан нуры.

Җыр юл куймады бер эшкә,
Шул иде минем көткәнем.
Тик вакыт төшерде искә
Инде лимит беткәнен.

Һәркем әйтте үз арманын: [1]
«Сөйдем Шәле урманын,
Кунагы булмый, ферманын
Нигә улы булмадым?»

«Хуш, хуш!» диеп саубуллаша
Кырык кыз, кырык карындаш,
Кырык ел хәтта узса да,
Юк, юк, сагынмый булмас.

Барлык казакъ кызларына
Сәламнәр яуды шунда.
Авырлыгыннан машина
Көчкә кузгалды юлга...

## Мәңге биесәче

Атылган укка тиңлимен
Күзләреннең карасын,

Юк, кара күмер димимен
Кара очкын карашын.

Белмәсәң кара очкынны,
Белмисен ул күзне син,
Күрдем бүген җирдә юкны, —
Гүя ят дөньяда мин.

Биюче кызык әйләнә,
Ә сәхнә гөмбәз кебек.
Уйнаклый, оча ул әнә
Сахрада җәйран-киек.

Кагына, кагына ике кул,
Аккош канаты төсле.
Канатсыз килеш оча ул, —
Сәнгать кодрәте көчле!

Сулыш та алмый зал, тынган,
Карый кыз биегәнне:

[1] Арман — теләк.

Яшәреп яз гөле сыман,
Карт әкият терелгәнме!..

Тал чыбыктай сыгыла биле,
Ул сөйли шигъри телдә.
Биюдән жыр отар идем,
Күз алмый озын төндә.

Уйнап йөзгән ак күгендә
Гел янып сөенсәче,
Баемый, батмыйча бер дә,
Эх, мәңге биесәче!..

## Сагынам

*И*лемә канат кагам мин,
Төшеп кунак тагыннан [1],
Хуш-сау бул, татар туганым,
Сагынам сине, сагынам.

Җиләкләр, чәчәкләр җыйдым
Урман, кырдан, багыннан.
Рәхәт үткәргән бу елның
Һәр көн гомерен сагынам.

Мәхәббәт балы эчердең
Сый-хөрмәтле табыннан.
Мин чын дуслыкны төшендем,
Шуңа бигрәк сагынам.

Мин берсе булып игезнең
Китәм туган ягыннан,
Казанны, Казан дингезен
Сагынам, бигрәк сагынам.

Кырык кыз калган фермадан
Таралсын жыр тагын да,
Шул урынны һаман-һаман
Оныталмыйм, сагынам.

Кыскарак икән яхшы көн
Бер сапламлык җебеннән,
Тоелды көн озын булып
Киткәч татар җиреннән.

Килермен очып бер вакыт
Алма-Ата — алма багыннан.
Сагыну, дуслар, зур бәхет —
Өзелеп, өзелеп сагынам.

1964

[1] Тагыннан — тәхетеннән.

*Халиҗан Бекхожин*

## Җырчыга

*(Татар шагыйренә)*

Җырладың син бишегемдә ятканда,
Җырладың син моңлы, дәртле чакларда.
Синең назлы җырың белән тирбәлдем
Ерак кырда, куйларымны бакканда.

Син урманда сандугачтай сайрадың,
Сайравыңны җан сере дип уйладым.
Мин моңая идем Иртыш ярында
Җырлый-җырлый ямьле «Сарман» буйларын.

Хәтеремдә омтылуым, түзмәвем,
Күрше татар урамнарын гизгәнем...
Син җырласаң, китә тәнем чымырдап,
Сихерләде микән «шаян күзләрең»?

Өй артында, арасында чиянең,
Талгын аккан татар җырын сөямен.
Чияләр дә баш ияләр җырыңа,
Чын күңелдән мин дә башым иямен.

Җырларыңа моң салдымы «Асыл яр»?
Әллә анда сагыш һәм күз яше бар?
Әллә көнләп бүгенгесен татарның
Тибрәндеме үткәндәге гасырлар?

Аңлыйм синең мәхәббәтең назларын,
Кочагыма алам хисле сазларың,
Янгырасын дәртле аһән җырыңда,
Җыр ярата якын дустың — казагың.

Алма-Ата, 1963.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

—✦—

*Ибраһим Салахов*

## Мин даланы сөям

Син сөйлисен... мактап дингез буен,
Дулкыннарга кояш батканын,
Чинар агачлары матурлыгын,
Хризантема чәчәк атканын.

Син сөйлисен... Анда сфинкслар
Көмеш нурлар белән коена.
Адым саен шаулап фонтан ага,
Шатлык үзе җиргә коела.

Син сөйлисен... Юк кирәкми, дустым,
Башка матурлыкны беләм мин.
Бүген меңә дала диңгезеннән
Алтын башак белән киләм мин.

Кай җирдә бар мондый гүзәл киңлек!
Кай җирдә бар мондый тигезлек.
Кай җирдә бар икән язмыш белән
Бәхет бергә килгән игезлек?!

Син арысаң әгәр, тукта юлда,
Һәр йорт көтә сине кунакка,
Табак тулы кымыз куеп алга
Сый һәм хөрмәт итә бу якта.

Өрек төсле пешкән бавырсаклар,
Тәмле каймак белән май гына...
Думбраның моңы чыңлаганда
Урын калмас сагыш, кайгыга.

Син сөйлисен... ерак матурлыкны,
Үпкәләмә, дустым, баралмам.
Мин даланы сөям, — дала җырын!
Башка җырлар белән яңалмам.

*1959*

## Юлда...

Юк, иркәләп үстермәде язмыш,
Төрле якка этте, ташлады.
Боз диңгезе буйлап чана тарттым,
Төяп авыр-авыр ташларны.

Мин бозларга егылып хәлем җыйдым,
Көрт эченә чумып тын алдым.
Бары әнием җылысын тоеп кына
Аягыма басып торалдым...

Мин алтынны анда таптап йөрдем,
Алмазларны өйдем көрәкләп.
Ләкин...
Тик бер кабым икмәк табалмыйча
Кан саркыды минем йөрәктән.

Иелгәндә җилкәм чатнап китә,
Сөял анда — каеш эзләре. —
Вагранкалар тарттым мин җигелеп,
Перфоратор тоттым тезләнеп.

Бер аягым таш астында калды,
Ә бер кулым алтын астында.
Тик шулай да бирешмәдем.
Язмыш!
Мин тагын да синең каршыңда.
Күзләремнән минем яшь эзләмә,
Ярдәм кулы миңа кирәкми!
Бөек еллар!
Тынмас, шаулы җырлар,
Сезгә бирәм кайнар йөрәкне.

## Иҗат газабы

Тәрәзәмдә шәүлә — кызыл ялкын —
Дөрләп яна мәрмәр өлгеләр.
Челпәрәмә китереп ватар идем!
Соңга калдым,
Инде өлгермәм...

Ут үрелә һаман бүлмәмә,
Мин кызарам, янам...
— Кайда сез?!,
Су бирегез миңа, сүз бирегез!
Юк! Кирәкми, барыбер файдасыз

Башым сызлый. Чигәләрем чатный,
Каләм төшә минем кулымнан,
Йокысыз төннәр уза, атлый алмыйм
Бер адым да шигырем юлыннан.

Юк, ялгышам ахры, алай түгел,
Дистәләгән битләр язылган...
Тик, эзләгән чишмә табылмагач,
Ни файда бар кое казудан?!

*1960*

## Барыннан да син сылу

*(Казакъчадан)*

Җәйге көндә балкыган
Яшькелт келәм — җир сылу.
Аккош йөзеп туймаган
Айдай күлем, син сылу.

Дөньядагы иң сылу —
Гомерлек дус, тиң сылу,
Үзем сөйдем, яраттым —
Барыннан да син сылу...

Нурын түгеп кырларга
Туып килгән көн сылу.
Җемелдәгән йолдызлы
Зәңгәр күкле төн сылу.

Дөньядагы иң сылу —
Гомерлек дус, тиң сылу.
Үзем сөеп яраткан,
Барыннан да син сылу...

Нәфис тәнле, бал телле,
Җан ауларлык сылулар,
Күрсәң гашыйк булырлык
Дөньяда күп сылу бар...

Алардан да кадерле
Гомерлек дус, тиң сылу,
Үзем сөйдем, яраттым,
Барыннан да син сылу.

*1962*

# Вьетнам шагыйрьләре

*Бөек азатлык байрагын югары күтәргән героик Вьетнам халкы АКШ илбасарларына каршы зур көрәш алып бара. Ватаныбызның барлык халыклары белән бергә татар совет язучылары да ялкынлы Вьетнамның изге көрәштә җиңеп чыгуына теләктәшлек белдерәләр. Алар Вьетнам әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итәләр һәм аның көрәшенә багышлап әсәрләр тудыралар.*

*Татарстан китап нәшрияты күптән түгел генә, җәмәгатьчелек тәртибендә, «Җиңелмәс Вьетнам» исемле китап чыгарды. Аны сатудан килгән акча героик Вьетнам халкына ярдәм фондына тапшырылачак. Ул китапта безнең язучыларыбыз үзләренең иҗатлары белән актив катнаштылар.*

*Бу санда без Вьетнам шагыйрьләренең берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

*Чанг Хыу Тхунг*

## Бишек җыры

Йокла син, улым!
Йокыга кит, балам!
Ак юллар күп ул —
Җирне чорнаган...
Аяк очында,
Йомгак шикелле
Уралып, тын кич
Йокыга талган.

Йокла син, улым!
Тышта — адымнар...
Атлый тынычлык,
Ул безгә килгән.
Чайкала үлән
Әкертен җилдән.
Дьен Бьен Фуда инде
Дошман җиңелгән,
Дошман бирелгән,
Йокла, улкаем.

Йокла, улкаем!
Йодрык төйнәмә.
Шәп хәбәр чаба
Ил буйлап әнә.
Шәп хәбәр чаба
Чыңнар таратып:
Елга буйлап та,
Дельта иңләп тә,
Килмәс кабат ут,
Килмәс кабат ут.

Йокла син, улым!
Болыннар, кырлар
Йоклыйлар тыныч:
Шулай йокыга
Тала Вьетнам,
Йокла син, балам.
Ил кырларында
Бүтән акмас кан,
Котырмас сугыш.

Кермәсен сугыш,
Улым, төшенә.
Джунгли буйлата
Сүз килә сиңа:
Шушы тын төндә
Тыныч яз йөри,
Илгә яз кайта,
Йокла, улкаем.

Йокла, улкаем!
Ишет, еракта
Ләйсән яңгырлар
Сибәли инде.
Бакчалар безнең
Тагын чәчәктә.
Тынычлык шулай
Иркәли илне.

Йокла син, улым!
Дөнья — якты, киң.
Йокла, улкаем,
Йокла, бәгырем син.

*Ә. БАЯНОВ тәрҗемәсе.*

*Нгуен Дин Тхи*

## Дөге

Авыллар ялтырап яталар кояшта,
Коенып нурларда.
Әй энем син минем, туганым нәнием,
Күр, әнә авыллар яналар кояшта,
Кайтасың манчылып син ап-ак тузанга,

Таң нуры эчендә балкыган,
Өлгергән дөгеләр аркылы юл буйлап.
Ә анда яңгырлар сибәли, алтындай
Тамчылар төшәләр ялтырап һәм уйнап.

Юлы да алтынга мангандай бит менә.
И рәхәт тә шуннан атларга!
Күлмәгең дә синең ябышкан тәнеңә
Бик озак юл йөреп кайтканга.

И җирем син минем, сыкрадың газапта,
Сызлата сине күп дәһшәтләр борчуы.
Күр, әнә җемелдәп тын ага
Еракка сузылган кыр юлы,

Ул уза башаклар дулкыны аркылы.
Тетрәтә җирләрне тупларның атуы,
Аларның гүләве кояшка тоташа,
Туктаусыз сирена шыгыраша.
Ә дөге күтәреп кайтучы кешеләр
Аптырап карыйлар казылган җирләргә
Һәм янган өйләргә.

И җирем син минем, тапталган, кыйналган,
И халык, ач халык, күр инде!
Җирендә синең кан сугарган
Өметнең беренче башагы күренде.

Ул өмет башагы алтындай ялтырый,
Ерактан солдатны чакырып эндәшә.
Ул әйтә йөрәккә: «Күтәрел көрәшкә!»
Күрәмсең, авыллар ялтырый кояшта,
Әй, энем, нәнием, күр әнә,
Алтындай җемелдәп
Дөгеләр дулкыны тирбәлә!

*НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе.*

*То Хыу*

## Кешелек язы

Үзәкләргә үтеп исә жил,
Агачларны ташлый аударып.
Тик озакка түгел, сизәм мин,
Соңгы җилләр... килә яз алып.

Бу яз булыр ләгънәт-каһәрсез,
Ятим балаларсыз, михнәтсез,
Яңа калкып чыккан кабересез,
Изаланмас халык икмәксез.

Ашкына яз хуш ис таратып,
Чәчәк-киемнәрен ябынып.
Тиздән, дуслар, язгы таң атыр, —
Алсуланыр офык кабынып.

Җыр яңгырый ак таң туганда,
Тарала тиз — көчле канаты;
Һималайдан уза Уралга,
Ә моңында — ирек, азатлык.

Язны көттек нәфрәт ташканда,
Китмәгәнен белдек озакка...
Кан сугарган җиргә баскан да
Карый Кеше алга, еракка.

*КАСЫЙМ ФӘСӘХОВ тәрҗемәсе.*

*Минь Ле*

## Үлем килсә әгәр...

Әгәр минем тәнгә үлем бәреп керсә,
Авылларны янки басып алган кебек,
Әгәр минем башка напалм уты капса,
Әгәр көйсәм тамугларда янган кебек —
Син, шашынып елап, мине ташлап китмә,
Янымда бул, шул минутта ялгыз итмә.
Минем күзләр барыбер сиңа яктырырлар,
Иреннәрем сине генә чакырырлар.
Күренсеннәр: кара күзең, кара толымың.
Мин барыбер сине генә яратырмын.
Үлгәндә дә сине сөю символы мин,
Мәхәббәтнең сиңа илткән киң юлы мин!..
Партизанны җәзалыйлар. Ул үлгәндә
Яннарында аның туган иле тора.
Син дә китмә! Газабымны минем бүлеш,
Син дә шулай хәлләремне минем сора.
Көчле итсен сине дә шул түземлелек,
Үлемсезгә бүләк ит син үлемсезлек!

*ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе.*

# Г. Ибраһимовның тууына 80 ел

*Камил Фасеев*

# БӨЕК ОКТЯБРЬ ҺӘМ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ КУЛЬТУРА

В. И. Ленин Октябрьга кадәрге хезмәтләрендә үк барлык милләтләрне «иң югары социалистик берлеккә» туплаучы интернациональ культура өчен көрәш бурычын куйган иде.

Бөек Октябрь шуна киң юл ачты. Социализм алып килгән культура революциясе халыкларның рухи дөньясын тарихта моңарчы күренмәгән югарылыкка күтәрүне күздә тотты. Ә моңа ирешү милли үзенчәлекләрнең пролетар интернационализм идеясе белән аерылгысыз берлектә баруы, милли культураларның бер-беренә даими унай йогынтысы, төрле милләт интеллигенция кадрларының кулга-кул тотынып эшләүләре аркасында гына мөмкин иде. Партия иҗат работникларының игътибарын шуңа юнәлтте, аларны шул рухта тәрбияләде.

Татар культура эшчәннәренең төп күпчелеге Совет властеның беренче елларында ук интернациональ бурычларны дөрес аңлады, милли чикләнүгә каршы булды, башка милләт культуралары белән бәйләнешне ныгытты. «Җир йөзен дуслык, туганлык гөлләре белән тутыру өчен, мәдәниятны, хәятны якты, матур, азат нигезләргә корыр өчен»[1] көрәшкә чыккан революцион интеллигенция яңа культураның «милләтчелекләр, динчелекләргә каршы» эчтәлеген һәм көчен «динамика, көрәш, сыйныфчылык, коллективизм, хезмәт һәм интернационализм»[2]да күрде.

Культураның, сәнгатьнең иҗтимагый роле — ачыктан-ачык халык интересларын яклауда, партияле, сыйнфый булуда. Шуна күрә партиясез, битараф, «объектив» әдәбият һәм сәнгать турында сөйләнеп, Советлар белән аның дошманнары, интернационалистлар белән милләтчеләр арасында буталып йөрүчеләр партияле интеллигенция тарафыннан тәнкыйть утына алынды. «Кемне кем?» дигән лозунг астында кискен көрәш шартлары, дип язды Г. Ибраһимов, «әдәбиятның, фәлсәфәнең, сәнаиг нәфисәнең сыйнфый көрәштә битарафлыгы, сафлыгы хакындагы сүзләргә урын калдырмыйлар»[3].

Битарафлык пәрдәсе артына буржуаз милләтчеләр яшеренергә ярәталар. Эшчекрестьян массалары белән тыгыз бәйләнгән, Коммунистлар партиясе политикасының хаклыгына чын күңелдән ышанган язучылар милләтчеләрнең мәкерле демагогиясен фаш иттеләр, иҗат эшен әзлекле сыйнфый позициядә торып алып бардылар. «Сезнең... татар татарны куралмый, дигән сүзегез — солтангалиевчеләр сүзе. Татарның кулагы, эшчесе барны хәтерегездән чыгармагыз! Татар эшчесе татар буржуасын куралмаска тиешле»[4], дип, Һади Такташ «милләт татулыгы» хакына контрреволюцион юлга басучыларга «Камил» драмасында үзенең ачы нәфрәтен, аларга каршы сугышка чыгуын белдерде.

Үзе әйткәнчә, «вак буржуаз арасыннан чыгып, Коммунистлар партиясенең юлбашчылыгы астында тәрбияләнеп, пролетариат идеологиясен үзләштерүдә зур эволюция ясаган» Такташ, башка алдынгы язучылар кебек, әдәбиятның бурычын социализм төзелеше чорында сыйнфый көрәштә туган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыруда, яңа кеше тәрбияләүдә, коммунизм идеяләрен массаның йөрәгенә сеңдерүдә күрде. Моның өчен язучы, шагыйрь, драматург «пролетариат сыйныфының иң югары идеяләре белән сугарылган, пролетариат сыйныфының авангарды торган идея югарылыгында торырга, диалектический материализм белән нык коралланган булырга тиешле, шулай булганда гына ул бүгенге бөек төзелешнең иртәсе алып килгән җиңүләрне күрә ала һәм шул җиңүләр өчен булган көрәштә туган актуаль мәсьәләләрне вакытында күреп, массага юнәлеш бирерлек бер фикер-теләк белән чыга ала»[5].

---

[1] Г. Ибраһимов. Бөек бәйрәм. «Мәгариф» журналы. 1918 ел, 1 сан, 2 бит.

[2] Г. Ибраһимов. Пролетариат әдәбияты турында. Мәскәү. 1924 ел, 49—50 битләр.

[3] «Эш» газетасы. 1920 ел, 7 ноябрь.

[4] Һади Такташ. Әсәрләр. Казан, 1942 ел. 216 бит.

[5] Шунда ук, 321 бит.

Һәм бу эшне шагыйрь тар милли рамкалар белән чикләмәде, культурала, әдәбиятта пролетар интернационализм принцибын яклады. 1929 елда эшче районнарында, Бакуда булып кайткач, Такташ һәрбер милли әдәбиятның халыкара әһәмиятен һәм бигрәк тә социалистик әдәбиятның уңышлары бары тик интернациональ нигездә генә мөмкин икәнлеген тагы да яхшырак аңлады. «Без,— диде ул,— безнең әсәрләребез белән кызыккан унлап милләтнең меңнәрчә эшчеләрен күрдек. Алар безгә милләт, тел аермалыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап, интернациональ әдәбият тудырырга социаль заказ бирделәр... әсәрләребезне тудырганда СССРда яшәгән бөтен эшчеләр сыйныфы өчен тудыру юлы белән баруны күрсәттеләр»[1].

Социалистик эчтәлекле милли культураны милләтчеләр барлык чаралар белән утка тотарга тырыштылар. Буржуазиягә халыкларны бер-береннән аеручы, алар арасында бер-берсен күралмаучылык һәм дошманлык тудыручы, массаларны төп социаль мәсьәләләрдән, сыйнфый көрәштән читләтүче «культура» кирәк. Төрле милләтләрнең иң яхшы традицияләрен эченә алган, азатлык өчен революцион көрәш идеяләре һәм интернационализм рухы белән сугарылган культураны ул күралмый. Бу, барыннан да элек, татар буржуазиясе идеологларының демократик культурага, бөтен дөнья культурасының иң югары казанышы булган марксизмга нәфрәтендә, аны инкарь итеп, дини «культура»ны алга сөрүендә чагылды.

Буржуаз милләтчеләр татар халкын русның һәм Европа илләренең прогрессив культурасыннан читтә, ислам дине йогынтысы астында тотарга теләделәр. Үзләре өчен, капиталистик дөньяда бөтенләй үк «югалып калмас өчен» Европаның буржуаз культурасын кабул итәргә риза булганда да, алар төп ориентацияне «ислам культурасы»на юнәлттеләр, массалар өчен шуннан ары узуны харам дип санадылар. «Исламның бөтен матур тугры тәрбияләре бездә калырга тиешләр... Европалашуны да без үзебезнең әлеге төрек табигате, исламның матур әхлагы аша сузып алырга теләгәнгә, без киләчәктә төрек, мөселман халкының мәдәни бер ботагы булырга омтылабыз»[2].— Гаяз Исхаков бу сүзләрне Октябрь революциясенә кадәр язган иде. Революциядән соң да шундый ук фикерне, икенче төрлерәк формада, алга сөрүдән милләтчеләр баш тартмадылар. Г. Газиз тарафыннан 1923 елда программа төсендә алга куелган «төрек культурасы»— иске «иттифакчылар» линиясенең дәвамыннан башка нәрсә түгел иде. «Чыңгызның басмасы, уйгурларның хәрефләре, әлифбалары, чыгтай балаларының дәүләтендә туган бөек әдәбият, мыгмырчылык сәнгате вә аның хәзерге калдыклары һәммәсе дә безне бер җепкә тезә торган нәрсәләрдер»[3], дип язды ул.

«Төрек милләте культурасы» менә шул икән! Биредә без төрки халыкларның культурасын билгели торган төп элементларны, аларга хас культура үзенчәлекләрен, социаль һәм милли азатлык өчен көрәшкә туплый, иҗтимагый тормышны алга этәрә торган факторларны күрмибез. Киресенчә, «бердәм милли культура» дигән булып, милләтчеләр һәммә иске-москыны, консерватив күренешләрне якладылар, халыкларны берләштерүче түгел, бәлки берберсенә каршы куючы мотивларны күтәреп чыктылар, халыклар тормышында үсә торган прогрессив, интернациональ күренешләрне инкарь иттеләр.

Бу — очраклы нәрсә түгел. Рус һәм Европа культурасына татар буржуазиясенең нәфрәте Октябрьдан соң бигрәк тә көчәйде, чөнки социалистик революция шул культура үсешендә туган марксизм-ленинизмның гүзәл тантанасы булды. Халык интересларына хезмәт итүче культураның чәчәк атуы буржуаз идеология белән араны тәмам өзеп, марксизм-ленинизм байрагы астында гына мөмкин икәнлекне интеллигенция яхшы аңлый иде инде. Культураның һәр тармагы, әдәбият, сәнгать коммунизм идеясенә хезмәт итсә генә «үзен социализм төзелеше практикасы белән, партия җитәкчелеге астында, массаның шул эштәге көрәше белән иң актив рәвештә бәйләсә генә үсә ала»[4], дип язды Гомәр Гали. Бу фикер иҗат эшчәннәренең күпчелеге өчен уртак иде.

Интеллигенция кадрларының ачыктаначык партия артыннан баруы, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин кебек олы буын әдипләренең пролетар интернационализм һәм фәнни коммунизм позицияләренә басуы, табигый рәвештә, халык дошманнарының марксизм-ленинизмга атакасын көчәйтте. Һәм бу «поход»ның башында әлеге дә баягы Гаяз Исхаков, Муса Бигиевлар торды.

Ак эмигрантлар органы «Азат шәрык» журналында Гаяз Исхаков марксизмны тудырган Көнбатыш культурасын сүгеп, аңа, янәсе, «ислам дине бишеге» генә булган Көнчыгыш культурасын каршы куеп чыкты. «Шәрык мәдәнияты,— ди ул,— исламият кебек бөек дини тәгълимат мәйданга китерде, адәмнәрнең рухи, мәгънәви тәрбияләренә олы тәэсир ясады... Гарәп мәдәниятының мәгънәви кыйммәт уларак мәйданга китергән тормыш фәлсәфәсе — материализмдыр. Мальтузианизм һәм марксизм назарияләре белән Гарәп мәдәнияты әхлакый, дини нигезләрне хәяттән бөтенләй чыгарып ташларга теләде, мәсләк уларак боларга һичбер кыйммәт куймады».

Марксизмны инглиз побы Мальтусның реакцион теориясе белән тиңләвен Г. Ис-

[1] Шунда ук, 313 бит.
[2] «Ил» газетасы. 1914 ел, 32 сан.

[3] Г. Газиз. Милләтчелекнең бәгъзы әсаслары. Казан. 1923 ел, 16 бит.
[4] Гомәр Гали. Сайланма әсәрләр. Казан. 1958 ел, 201 бит.

хаковның наданлыгы белән генә аңлату әз булыр иде. Биредә буржуаз милләтченең турыдан-туры намуссызлыгы, әзлекле революцион тәгълиматны ничек кенә булса да каралтырга, иң әшәке, иң кешелексез теория дәрәҗәсенә куярга теләве ачык чагыла. Материализмның дошманы аны тудырган Европа культурасын тирги. Көнчыгыш культурасы исә аңа исламны тудыру һәм «олылавы» белән кадерле һәм «изге». Көнбатыш һәм Көнчыгыш культуралары турында сүз йөрткәндә буржуаз автор хакыйкать белән хисаплашырга теләми, чөнки дини фәлсәфә Көнчыгышта гына тумаган кебек, материализм да Көнбатыш җимеше генә түгел. Г. Исхаковлар «үзебезнең диннәребезне Гарепнең һөҗүменнән сакларга» дип ничек кенә кычкырсалар да, материализмның, марксизмның Көнчыгышка да атлаган җиңүле адымнарын туктата алачак түгел иде инде.

Милләтче донкихотларның дәгъваларына беренче лаеклы отпор бирүче Галимҗан Ибраһимов булды. «Бичаралар, — дип язды ул, — матди мәдәният, техника, сәнагат сезнең кул күтәреп дога кылуыгызны, ялваруыгызны көтми, ул, сез алырга теләсәгез, теләмәсәгез дә, Шәрыкка күптән кереп бара. Киләчәктә бу, әлбәттә, көчәячәк... Сезнең котыгызны очырган материализм, шул «каһәр» марксизм, иске караңгылык богауларын, иске мөкатдәс диннәрне җимереп, адәмнәргә якты юл күрсәтә, коммунизм азатлыгына таба көрәш башлый»[1].

Социалистик революция нәтиҗәсендә, Коммунистлар партиясе җитәкчелеге астында Россия халыклары бертигез милли азатлыкка ирештеләр, аларның үзара дуслык, туганлык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре ныгыды, милли һәм дини низагларга урын калмады. Бу хәл капитал агентларын халык арасында милләтчелек һәм динчелек агуын элеккечә иркенләп тарату мөмкинлегеннән мәхрүм итте. Шуңа күрә алар Коммунистлар партиясе башкарган бөек тарихи хезмәтне инкарь итәргә, ленинчыл милли политиканы ничек кенә булса да пычратырга маташтылар.

Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Гаяз Исхаков ише «милли каһарманнар»: пролетариат диктатурасы милләтләрне, аларның гореф-гадәтләрен, диннәрен, телләрен, культураларын бетерә дип күрсәтмәк булдылар.

«Милли ирек юк», «миллият фикере үлә» дигән уйдырмалар ярдәмендә буржуаз милләтчеләр татар интеллигенциясенең башын әйләндереп, татар культурасын халыкларның марксизм-ленинизм тарафыннан яктыртылган олы юлыннан, бердәнбер дөрес һәм туры интернациональ магистральдән читкә сөйрәмәкчеләр иде. Әмма аларның бу эше барып чыкмады, бу провокациягә әләгүчеләр дә бармак белән санарлык кына булды. Дошманнарга вакытында тиешле отпор бирелде. Г. Ибраһимов, һ. Такташ һ. б. фикерен дәвам итеп, Гомәр Гали болай язды:

«Пролетариат революциясе, пролетариат диктатурасы чорында иҗтимагый шартлар пролетариат идеологиясе нигезендә культураларны, милли әдәбият, милли сәнгатьләрне бетерүгә таба түгел, көчәйтүгә, үстерүгә таба алып баралар; ул шартлар шул культураның, әдәбиятларның үсүләренә, ныгуларына ярдәм итәләр»[2].

Хакыйкатьнең тирәге — реаль фактларда. Үзләренең демагогиясен буржуа ялчылары бернинди факт белән дә раслый алмадылар. Коммунист язучылар исә провокаторлар ялганына каршы конкрет тормыш фактларын куйдылар. «Адәм дөньясының иң тирән яткан түбәнге катлауларын кузгату, боларны сәяси мәйданга күтәрү сәбәпле, социализм революциясе аңа кадәрле бөтенләй мәгълүм булмаган яки аз мәгълүм булган милләтләрне яңа тормышка уятып чыгарадыр,— дип язды Г. Ибраһимов. — Иске патшалык заманында Россиядә илледән артык милләтләр һәм этнографик группалар бар дип кем уйлар иде? Октябрь революциясе богауларны өзде, мәйданга бик күп онытылган халыкларны чыгарды. Шуның белән аларга яңа тормыш, яңа хәрәкәт бирде»[3]. Әгәр патшалар Россиясендә үзләренең әлифбалары да булмаган һәм караңгылык-наданлык базында интеккән бик күп милләтләр хәзер культураның киң һәм якты юлына аяк басканнар икән, үз телләрендә сөйләргә, укырга, язарга, идарә итәргә, әдәбиятларын һәм сәнгатьләрен үстерергә хокук алганнар икән, бу инде сүздә түгел, практикада милләтләрнең азатлыгына һәм рухи күтәрелешенә ирешү дигән сүз.

Татар культурасының һәр тармагында Октябрьдан соң ирешелгән уңышлар буржуаз фальсификаторлар уйдырмаларының көлен күккә очырды, пролетар интернационализм рухында үсүче яңа культураның көчен һәм тормышчанлыгын раслады. «Революциянең мәдәни төзелеш бабындагы адымнары хәзер инде гаять киң, гаять кызу атланалар»[4], дип, Фатих Әмирхан 1922 елда ук Советларга каршы элементларның ялганын кире какты.

* * *

Социалистик революция әдәбиятның үсеш юлын, иҗтимагый-тәрбияви функциясен өр-яңа нигезгә куйды. Интернациональ бөек максат өчен көрәшче халыкның тормышын интернационализм рухында чагылдыру аның төп эчтәлегенә әйләнде. Октябрь революциясе нәтиҗәсендә авыл һәм шәһәр хезмәт ияләре көнкүрешендә һәм аңында туган зур үзгәрешләрнең, йөрәкләрендәге яңа хисләрнең әдәбиятта

[1] Г. Ибраһимов. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар. Мәскәү. 1924 ел, 58—59 битләр.

[2] Гомәр Гали. Пролетариат әдәбияты өчен көрәштә. Казан. 1931 ел, 29 бит.

[3] Г. Ибраһимов. Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак. Казан. 1927 ел, 20 бит.

[4] «Татарстан» газетасы. 1922 ел, 1 октябрь.

ачык һәм көчле чагылуы — бөек борылышның гүзәл гәүдәләнеше иде.

Октябрьда туган яңа стройның милли культуралар үсүенә һәм чәчәк атуына тарихта тиңе булмаган куәтле этәргеч бирүен хезмәт халкы эченнән, заводтан, фабрикадан, шахтадан, авылдан әдәбият мәйданына Н. Исәнбәт, М. Крымов, Х. Туфан, Қ. Нәҗми, Ш. Усманов, М. Максуд, һ. Такташ, Г. Кутуй, А. Шамов, М. Җәлил, Ә. Ерикәй, Г. Минский, Г. Иделле, М. Әмир, С. Баттал кебек яшь кадрлар килүендә бик ачык күренә. «Мондый бер хәрәкәтне тик пролетариат революциясенең бөек масса кузгалышы гына тудыра алды... Коммунистлар партиясенең тугры юлбашчылык тәэсире генә мондый зур иҗади кайнашны күрергә насыйп итте» [1]. Яшь каләм осталарының көче — эшче-крестьян интересларын ачыктан-ачык яклауда, капитализмнан социализмга күчү чорындагы сыйнфый көрәштә халык ягында торып актив катнашуында, идеализмнан, милләтчелектән ваз кичеп, марксизм идеологиясен үзләштерүендә, пролетар интернационализм рухында тәрбияләнүендә иде.

Татар милләтчеләре һәм руханилары, гади халык «диннән язып» сәнгать югарылыгына күтәрелә алмасын өчен, кулларыннан килгәннең барысын да эшләделәр, массаларның талантларын буып тордылар. Шуңа күрә царизм вакытында татарлар арасында: «Қайчан чыгар бездән рәссамнар, кайчан тыңларбыз татар композиторларын?» дигән хәсрәтле өмет кенә бар иде. Ә инде 1922 елда Г. Ибраһимов: «Революция дулкыннары татар эшче-крестьян тормышы диңгезенең төбендәге җәүһәрләрне кузгата, аларның якты дөньяга чыгуларына ярдәм итә тора», дип, сәнгатьнең төрле тармакларында — әдәбиятта, музыкада, сынлы сәнгатьтә, театрда халык эченнән чыккан яшь кадрларның иҗат эшенә керешүе турында шатланып язды.

1918—1920 елларда ук инде, дәүләт театрына әверелгән «Сәйяр» труппасыннан башка, Қазанда уннан артык рәсми татар театр труппалары һәм кырыкка якын һәвәскәр коллектив эшли, кантоннарда, волостьларда, мәктәпле авылларның барысында диярлек спектакльләр куела. Шулай итеп, татар театры тулы гражданлык хокукына ирешә, массаларның культура дәрәҗәләрен күтәрү, коммунистик тәрбия бирүнең көчле чарасы булып мәйданга баса. «Татар театрының аз бер зыялы катлау арасыннан миллионлы эшче-крестьян арасына чыгуы Октябрь революциясе аркасында ясалган казанышларның иң зурларыннан саналырга тиешләр» [2], дип язды Фәтхи Бурнаш.

Театр сәнгате үсешендәге иң әһәмиятле нәрсә — аның эчтәлеге, репертуар юнәлеше. Октябрь революциясен Горький пьесасын сәхнәгә куеп каршы алган татар театры, милләтчеләрнең каршылыгын сындырып, халыклар дуслыгы идеясен көчлерәк пропагандалый башлады, тамашачыларны иң яхшы милли драматургиядә генә түгел, рус һәм бөтендөнья драматургиясе үрнәкләрендә дә тәрбияләде. Гомумән театр чын мәгънәсендә тормышчан һәм халыкчан сәнгатькә әйләнде.

Татар музыка культурасы үсешендә дә шундый ук алга сикереш ясалды. Һәм бу күренешне социалистик җәмгыятьтә туган яңа шартлардан, дуслыкка, хезмәттәшлеккә корылган милли мөнәсәбәтләрдән башка аңлату мөмкин түгел. Эксплуатациядән азат кеше инде искечә үз өенә, үз ихатасына бикләнеп яши алмый, аның тормышка карашы киңәя, рухи ихтыяҗлары үсә, ул гомер-гомергә күнегеп килгән нәрсәләр белән генә канәгатьләнә алмый.

Яңа тормыш, яңа уй-хисләр, социалистик төзелештәге хезмәт пафосы сәнгатьнең иске чикләрен вата, аның каршына яңа бурычлар куя, музыканың яңгыраш мәйданын киңәйтә, яңа җәмгыять кешеләренең зәвыгын канәгатьләндерерлек рәвештә үсә баруын таләп итә. Бу хакта Қәрим Тинчурин 1928 елдагы мәкаләләренең берсендә болай яза: «Татар халык музыкасының диапазоны, ул замандагы җәмгыять тормышының шартлары эчендә, бүлмә, табын тирәсеннән еракка китә алмаган... Культурага нигезләнгән җәмгыять тормышының кануннары бүлмә эчендә, табын әйләнәсендә туган шул көйләрне меңәр кеше тулган зур залларның, театрларның сәхнәләреннән тыңларга куша» [3].

Профессиональ татар музыка сәнгате шушы җирлектә үсте. Татарстанның 5 еллык юбилее көненә житешкән беренче «Сания» операсыннан башлап, бүген инде бөтен илебездә генә түгел, дөньяга таралган опера, балет, музыкаль комедия, симфония, сюиталар һәм бик күп сандагы җырларның тууы, шуларны халыкка житкерүче махсус опера һәм балет театры, Дәүләт филармониясе, музыкантлар, җырчылар, биючеләрнең гаять зур армиясе барлыкка килү, — болар халык рухи тормышының сокландыргыч югары баскычка күтәрелүе, иң алдынгы кешелек культурасына кушылуы турында сөйлиләр.

Музыканың әнә шул интернационалистик юнәлештә үсүе җиңел генә булмады, әлбәттә. Бу өлкәдә көрәшнең никадәр кискен булуын Қәрим Тинчуринның югарыда телгә алынган мәкаләсеннән ачык күрергә мөмкин. С. Сәйдәшев белән бергә иҗат иткән күренекле драматург халык көйләрен эшкәртү, оркестрга салу, пентатоника (биш тавыш) белән генә чикләнмичә, ярты тавышлар кулланып музыка язу эшенә динче, милләтче мещаннарча иске карашны менә ничек тасвирлый: «1) Берәр халык көе гармонизировать ителсә — көй аңланмый, көе бозылган, диләр; 2) Берәр көй тавышларга куелып дуэт, трио, квартет яки

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960 ел, 212 бит.

[2] Ф. Бурнаш. Ун ел эчендә татар театры. «Безнең юл» журналы. 1927 ел. 10 сан, 44 бит.

[3] К. Тинчурин. Татар музыкасы тирәсендә. «Безнең юл» журналы. 1928 ел, 11—12 саннар, 33 бит.

хор тарафыннан җырланса — чиркәү җыры тавышы килә, диләр; 3) Халык көе куелган, эшләнгән тавыш белән җырланса — рус тавышы, рус бугазы, диләр».

Шулай итеп, сәнгатьнең зур эшчәннәре милли чикләнүнең зарарын моннан 35—40 ел элек үк бик аңлашырлык итеп күрсәткәннәр, яшь композиторлар белән бер сафта бу чиргә каршы көрәшкәннәр. Шуның белән бергә, алар милли культураларның ярдәмләшүен аларны бутау, милли үзенчәлекне югалту дип тә аңламаганнар, мондый хатадан сак булырга чакырганнар. «Бездә халык көйләре турында кәләпүштән картуз ясап булмый дигән фикердәге кешеләр бар, — ди К. Тинчурин.— Мондый кешеләрнең фикеренчә, халык көйләрен культуралаштыру — аның аһәңен бозып руслаштыру була, имеш. Дөрес, рус культурасының татар культурасы үсешендә ярдәме, тәэсире бик зур. Ләкин культураны ала белүдә, аны массага сеңдерә белүдә һәм аның өстендә эшли белүдә хикмәт. Формасы, настроениесе белән татар күңеленә ят булган бар нәрсәгә уйламыйча, тикшермичә кәләпүш кертү белән генә культуралашу булмый, әлбәттә».

Билгеле булганча, татарлар арасында рәсем сәнгате үсеше аеруча зур каршылыкларга очрады. Динчеләр һәм фанатик милләтчеләр культураның бу тармагына юл бирмәделәр, катгый рәвештә тыеп килделәр. Шәригать канунары буенча җанлы нәрсәләрне рәсемгә төшерү «кяферлек», гафу ителмәслек гөнаһ саналды. Татар өйләрен бизәгән «художество әсәрләре» — коръән сүзләрен язган яки «пәйгамбәр» комганы төшерелгән шамаиллар, «җәннәт бакчасы», тәмуг утлары, Мәккә, Стамбул, Бохара күренешләре, «аллага мәхәббәт» хисе белән тулы күзләрдән аккан яшь дәрьясы, хан мәчетләре, солтан сарайлары, «Нух» көймәләре һ. б. иде. Боларны таратудан максат — «мөселман» кешесенең игътибарын реаль тормыштан читләштереп, бөтен күңелен «бер аллага», өметен төрек солтанына, ышанычын милли байларга һәм руханиларга юнәлтү булды. Портрет, тематик картина, скульптура турында сүз йөртү дә мөмкин түгел иде.

Рәссамчылыкка киң юлны Совет власте гына ачты. Казан художество мәктәбенә татарлардан беренче булып 1919 елда Бакый Урманчы алына, биш-алты еллан анда укучылар саны 20 гә җитә. Рус художникларының турыдан-туры ярдәме белән татарлар арасыннан Б. Урманчы, У. Арсланов, Н. Вәлиуллин, С. Ахун, Б. Альменов кебек талантлы рәсемчеләр үсеп чыга. Ә соңрак совет художниклары составына татарлардан яна зур отряд килеп кушыла.

«Революция дәвере татарларның яшь буынын бөтенләй яңа рух белән тәрбияләгәннән соң, алар рәссамчылык сәнгатенә ачык күңел белән карый башладылар һәм бу турыдагы иске фикерләрдән бөтенләйгә ваз кичтеләр. Алар матур сәнгатьтә һичбер төрле дини тәгассебнең һәм башка шундый шартларның юклыгын хәтерләрендә тотып, тормышның барлык теләкләренә хезмәт итә торган матур сәнгатькә якын килеп, рәссамлык сәнгатенә, сурәткә кызыга һәм шул юлда күп кенә эшли дә башладылар»[1]. Рәссамчылык бөтенләй яңа нигездә туды. Социалистик төзелеш героикасын, хезмәт кешеләрен, күп милләтле совет семьясын, сөекле Ватаныбың гүзәл күренешләрен сурәтләгән әсәрләр ярдәмендә художниклар халыкның эстетик тойгыларын, дөньяга карашларын киңәйтү, патриотизм һәм интернационализм рухында тәрбияләү буенча зур эш башкардылар.

* * *

Милли культура үсеше юлында ачыктан-ачык контрреволюцион чыгышларга отпор бирү белән бергә, интеллигенция арасындагы буталчык һәм ялгыш карашларга каршы да көрәшергә туры килде. Буржуаз һәм вак буржуаз иллюзияләрдән арынып бетмәгән интеллигентләр гына түгел, партия һәм совет кадрларының да кайберләре социалистик җәмгыятькә хас булган диалектик процессны: бер яктан, милләтләрнең күтәрелүен һәм милли культураларның үсүен, икенче яктан, милләтләрнең якынлашуын һәм культураның интернациональләшүен аңлап җиткермиләр иде. «Без интернациональ максатлар өчен көрәшәбез һәм бер үк вакытта милли культураларны үстерүгә дә ярдәм итәбез. Монда каршылык юкмы? Беренче бурыч икенчесе белән сыешамы?» Мондый сорауны шактый еш ишетергә туры килә иде.

Милли культура үсеше һәм аның эчтәлеге мәсьәләләрен партия әледән-әле тикшереп, интеллигенция кадрларына марксистик-ленинчыл юнәлеш биреп торды. Әлбәттә, ул аерым зур дискуссияләр талап итүче мөстәкыйль мәсьәлә түгел һәм социалистик үзгәртеп кору процессында уңышлы хәл ителә бара иде. «Милли җөмһүриятләрдә милли мәдәниятның үсеше турында сөйлибез икән, — дип язды партия Өлкә Комитетының беренче секретаре М. Хатаевич, — монда без иң элек һәм иң башта күпчелеккә мәдәни тәрбия бирүне, аларны иҗтимагый төзелешкә һәм социализм төзелешенә тартуны күздә тотабыз... Бу — хезмәт ияләре күпчелеген пролетариатның интернациональ идеологиясен һәм мәдәниятын үзләштерүгә илтү өчен иң яхшы юл»[2].

1927 елда (январь — февраль) партиянең Татарстан Өлкә Комитеты культура хезмәтчеләренең махсус киңәшмәсен җыйды. Анда төп доклад белән Галимҗан Ибраһимов чыкты һәм аның тезисларын киңәшмәдә катнашучыларның күпчелеге нигездә хуплады. Аерым китап итеп бастырылган бу докладында («Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак?») марксист галим пролетариат диктатурасы чорында

[1] П. Дульский. Татар рәссамнары тирәсендә. «Безнен юл» журналы, 1926 ел, 4 сан, 39 бит.

[2] М. Хатаевич. Милли мәдәниятның китеш юллары. «Кызыл Татарстан» газетасы, 1927 ел, 24 май.

милли культураларның язмышы, Коммунистлар партиясенең бу өлкәдә тоткан политикасы һәм аеруча татар культурасының алга үсеше мәсьәләләренә анализ ясады. Дөрес, бу доклад кимчелекләрдән һәм хаталардан азат түгел. Автор кайбер күпертүләргә юл куя, культураның милли характерына артык дәрәҗәдә басым ясап һәм «руслашучыларга» һөҗүм итеп, культураларның үзара бәйләнеше мәсьәләсенә аз тукталa, «мәдәниятның милли формаларының үз алдына аерым торуларын һәрвакыт әйтеп килә, әмма аңар пролетар мөндәриҗә бирү ягыннан тиешенчә игътибар итми»[1].

Моннан Г. Ибраһимов мәсьәләнең бу ягын аңламаган яки инкарь иткән дигән нәтиҗә ясау дөрес булмас иде, чөнки мона кадәрге һәм соңгы хезмәтләрендә ул бу мәсьәләләрне киң һәм дөрес яктыртты. Гомумән, Г. Ибраһимовның бу әсәрен татар культурасын марксистик-ленинчыл позицияләрдән торып тикшерүче беренче житди хезмәтләрдән санарга, ә Ш. Типеев һәм Г. Толымбайский тарафыннан аны буржуаз милләтчелектә гаепләүнең урынсыз икәнлегей әйтергә кирәк. Ш. Типеев, мәсәлән, Ибраһимовның: «социализм чорында милли мәдәниятлар бетмәячәкләр, баеп, зураеп күтәреләчәкләр» дигән сүзләрен «вак буржуа милләтчелеге» дип атады һәм үзе үк яклаган фикерләренә каршы килде[2]. Толымбайский исә Ибраһимовның «татар культурасы», «татар интеллигенциясе», «татар крестьяны» кебек атамаларын «сыйнфый каршылыкларны күрмәү», «безгә чит караш үткәрү» дип, дөрес аңлатмады[3], чөнки Г. Ибраһимов хезмәтләрендә милләт эчендәге социаль каршылыклар турында һәрвакыт басым ясап әйтелде.

Партия Өлкә Комитеты 1927 елның язында Г. Ибраһимов китабын махсус тикшереп, аңа объектив бәя бирде, булган кимчелекләрен күрсәтү белән беррәттән, аны «партия фикеренә якын» дип тапты. Үз вакытында бу әсәрнең шактый зур уңай роль уйнавында шик булуы мөмкин түгел. Анда күтәрелгән мәсьәләләрнең бер яклырак яктыртылуы да аның максаты башлыча милли нигилизмны тәнкыйтькә алу, интернациональ социалистик культураның төрле милли төсләрдә үсүен аңлату ихтыяҗыннан килә булса кирәк.

Вульгар социологизм чире белән авыручы кайбер пролеткультчылар социалистик культураның милли формасын гомумән инкарь итеп чыктылар. 1927 елда партия Өлкә Комитеты җыйган киңәшмәдә Г. Ибраһимов докладына каршы Сәлах Атнагулов үзенең тезисларын куйды, «культураның милли дип йөртелүе — капитализм җимеше» дип чыкты. С. Атнагулов тезислары киңәшмә тарафыннан кире кагылды, чөнки алар социализм шартларында культура үсеше перспективаларын бозып күрсәтәләр иде. Бу хакта М. Хатаевич: «Минемчә, әгәр дә иптәш Ибраһимовның китабын Атнагулов тезислары белән чагыштырып карасаң, төбендә Ибраһимовның китабы партиянең карашына якынрак булыр. Чөнки иптәш Атнагулов үз тезисларында мәсьәләгә бик җиңелчә, ассимиляция карашы буенча якын килә»[4], дип язды.

Милли культура турында үтә сул фикерләр авторларын аңлы рәвештә бөек держава шовинизмын яклауда гаепләү дөрес түгел иде, әлбәттә. Дискуссия вакытында Г. Ибраһимовның аларга шундый гаеп ташлавы, руслашкан «яңа тип морзалар» дип атавы урынсыз. Мәсьәлә чыннан да катлаулы һәм, революцион лозунгларны белеп тә, марксистик-ленинчыл хәзерлеге җитмәгән кадрларның күбесе өчен ачык түгел иде әле. Октябрьдан соң искиткеч тизлек белән үсә башлаган милли культураларны күз алдына китергәндә кайбер күңелләрдә: «Интернациональ максатлар өчен туган революция милли теләкләргә генә кайтып калмыйммы?» дигән шөбһә тууы гаҗәп түгел иде.

Һәм партия оешмасы тапшыруын үтәп, марксист публицистлар бу мәсьәләне җентекләп тикшерделәр, социализм шартларында культураларның милли үзенчәлекләрен инкарь итүнең марксизм-ленинизм белән сыеша алмавын аңлаттылар.

Элек изелгән һәм артта калган милләтләрне социализм рельсларына бастыру, рухи караңгылыктан әле генә азат ителгән киң масса хезмәт ияләрен укыту, социалистик культурага тарту, коммунистик идеология белән сугару, политик, мораль һәм эстетик тәрбия бирү, һәрбер милләтнең үз эченнән оештыручы һәм җитәкче кадрларны тәрбияләү эше ана телендә, интернациональ рухтагы милли мәктәпләр, милли культура җирлегендә барганда максатка ирешү җиңелрәк, дигән положение яклaнды һәм моңа каршы чыгучылар тәнкыйтьләнде. «Хәзерге көндә, күчү дәверендә дә бар булган милли мәдәниятны юк дип әйтү суллык авыруыннан һәм мәгънәсез сул фразалар ташлаудан башка бер нәрсә дә түгел»[5], дип язды Ш. Типеев. Милли культура, милли әдәбият, милли сәнгать дип баш катырып торасы юк, алар турында сөйләүнең мәгънәсе, кирәге юк, дигән фикерләргә карата Г. Гали дә: «Милли культура, милли әдәбият сүзләреннән курыкмаска, шуларны үстерү юлында җиң сызганып эшләргә кирәк... Ләкин мондагы һәрбер эштә эчтәлекнең интернациональ булуы беренче шарт»[6], дип җавап бирде.

---

[1] М. Хатаевич. Милли мәдәниятның киңәш юллары. «Кызыл Татарстан» газетасы. 1927 ел, 24 май.

[2] Ш. Типеев. Милләт, милли культура. Мәскәү. 1929 ел, 76 бит.

[3] Г. Толымбайский. Искермәгән бер уңлык турында. «Безнең юл» журналы. 1929 ел, 11 сан, 24—28 битләр.

[4] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1927 ел, 24 май.

[5] Ш. Типеев. Милләт, милли культура. 82 бит.

[6] Г. Гали. Пролетариат әдәбияты өчен көрәштә. Казан. 1931 ел, 29 бит.

Милли культура лозунгысы — ниндидер аерым шәхесләрнең яки группаларның капризы түгел, бәлки социалистик җәмгыять төзү, күп милләтле халыкларны яңа тормышка тарту бурычларыннан килеп чыга. Аның нигезендә социаль экономик сәбәпләр ята. Милли культура лозунгысының эчтәлеге инде хәзер тамырдан үзгәрә, чөнки эксплуататор сыйныфлар юкка чыгарылу белән милләт эчендә социаль тигезлек урнаша, эшчеләр сыйныфы милләтнең җитәкче көченә әйләнә. Димәк, милли культура капиталистик җәмгыятьтәгечә буржуазия коралы түгел, бәлки хезмәт халкының хәзинәсе сыйфатында, эшчеләр сыйныфы һәм аның марксистик партиясе җитәкчелегендә үсә. Ул инде пролетар интернационализмга каршы килми генә түгел, бәлки массаларны шул рухта тәрбияләү өчен уңай форма һәм чара булып хезмәт итә. Шулай итеп, социализм шартларында гына милли культура тулы мәгънәсендә хокук ала.

Октябрь революциясеннән соңгы дәвер милли культураларның халыклар язмышында, социализм өчен көрәштә тоткан ролен һәм әһәмиятен бик ачык танытты. «Революциянең алдында торган интернациональ максатлар белән бу аерым халыклар мәдәниятларының милли булулары арасында каршылык юк, — диде Г. Ибраһимов үзенең докладында. — Социализм эчендә күәтләнеп барган бу аерым мәдәниятлар үзләренең формалары буенча милли булсалар, мөндәриҗә белән пролетариатча булачаклар һәм бу мәдәниятлар, пролетариатның юлбашчылыгы астында, гомум адәмнең киләчәк якты тормышка баруына хезмәт кылачаклар». Социализм төзүче башка халыклар белән бергә, татар халкы да дөнья культурасына милли культурасын үстерү аша ирешәчәк. Аның максаты — халыкара хәзинәдән алынган аң-белем һәм сәнгать ярдәмендә ана телен, оригинал культурасын баету, аны социализм төзелешендә рухи корал булырлык дәрәҗәгә күтәрү, коммунизмга башка халыклар белән бергә, югары цивилизацияле бер отряд булып бара алырлык хәлгә җиткү.

Шулай итеп, милли культура үсеше турында сөйләгәндә марксист теоретиклар аны гомумкешелек культурасыннан, башка социалистик милләтләр культураларыннан аеруга юл куймадылар, аны интернациональ культура отрядының бер кисәге дип карадылар. «Татарның мәдәни хәрәкәте, мәдәни үсеше бөтен кешелек мәдәниятының, кечкенә булса да, бер ботагы бит ул»[1], дип язды Габдрахман Сәгъди. Ләкин әнә шул ботак гомумкешелек хәзинәсенә яхшы җимешләр бирсен өчен төп шарт — аны дөрес үстерүдә, бакчачының эшчеләр сыйныфы, Коммунистлар партиясе булуында.

Социалистик культураның эчтәлеген милләтчелек һәм дини идеология түгел, бәлки интернациональ элементлар тәшкил итәләр, аның максаты халыкларны аеру, читләштерү һәм сугыштыру түгел, бәлки якынлаштыру һәм берләштерү, туганлаштыру һәм татулаштыру, гомуми культура-ан дәрәҗәләрен күтәрү. Буржуаз милләтчеләр халыкларның милли культураларын бер-берсенә каршы куеп, чит итеп күрсәтәләр, Коммунистлар партиясе милли культуралар арасындагы бу «кытай стенасын» танымый, аларның уңышлы үсүен, киләчәктә бергә кушылуын үзара якынлашу һәм ярдәмләшү юлы белән генә мөмкин дип саный. Марксистлар бу положениене киң рәвештә яктырттылар һәм якладылар. «Барлык кешелек дөньясы, — дип язды Ш. Типеев, — икътисади яктан берләшеп һәм кешеләрнең тормышларындагы, үсешләрендәге тарихи аермалыклар бетеп, шулардан килеп чыккан гадәт-йолалардагы башкалыклар җуелып, кешеләрнең киңрәк туфракларда берләшүләре белән милләтләр, милли мәдәниятлар тәмам бергә кушылырлар»[2].

Бу мәсьәләгә караган кыйммәтле, массаларны пролетар интернационализм рухында тәрбияләүдә зур әһәмияткә ия булган фикерләрне без Г. Ибраһимов хезмәтләрендә тагы да ачыграк күрәбез. «Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак?» дигән китабында ул шундый нәтиҗәләр ясый: халыклар үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, көнкүреш үзенчәлекләре, тарихи язмышлары буенча бер-берләреннән аерылалар, аерым милләтләр тәшкил итәләр икән, бу объектив факт икән, димәк, шуңа карап, аларның культуралары да үзенчәлекле була, билгеле бер формада гәүдәләнә. Рус, үзбәк, казакъ, әрмән, татар, грузин, башкорт, әзербәйҗан һәм башка халыкларның культуралары үзләренең милли нигезләрендә, үз телләрендә үсә, үз тормышларының хасиятләре белән сугарыла. Ләкин социал-экономик тормышның гомумилеге, халыкларның социализм юлында берләшүе нәтиҗәсендә бу төрле телдә, төрле төстә, төрле калыпта булган культуралар идея эчтәлекләре, төп принциплары, максатлары ягыннан гомуми нигездә берләшәләр. Пролетариат революциясе аркылы коммунизмга бару интернациональ байрак астында гына мөмкин. Шуңа күрә барлык хезмәт ияләре, тел аермаларына карамыйча, бердәм коллектив булып, капитализмга каршы көрәшәләр. Социализм төзү юлында уңышлы эшләү өчен культураны, аң-белемне, сәнгатьне марксизм-ленинизм нигезендә үстерергә, яшь буыннарны гомуми интернациональ максатлар рухында тәрбияләргә, мәктәпләргә, семья тормышына, гомумән бөтен көнкүрешкә һәммә телдәге хезмәт халыкларының якты киләчәкләре өчен уртак булган мәнфәгатьләрдән карап юлбашчылык итәргә, һәрбер милли культураның бөтен халык өчен уртак булуына ирешергә кирәк. Иҗтимагый тормышның тимер кануннары шуны таләп итә. Телләре теләсә нинди генә булса да, барлык хезмәт халыкларының максатлары бер, тыгыз берләшеп хәрәкәтләнгәндә генә

[1] Галимҗан Ибраһимов. XX еллык юбилей җыентыгы. Казан. 1928 ел. 47 бит.

[2] Ш. Типеев. Милләт, милли культура. 89 бит.

алар якты идеалларының тантанасына ирешерләр.

Г. Ибраһимовның бу фикерләре Коммунистлар партиясенең милли культураларга карата ленинчыл политикасына, аның Программасының төп положениеләренә туры килә. Һәм күренекле татар галименең 20 нче елларда бу катлаулы мәсьәләне дөрес аңлавын һәм аңлатуын әйтеп үтү күңелле. Г. Ибраһимов культураның милли үзенчәлеген һәм гомуми интернациональ эчтәлеген, милли культураларның чәчәк атуы һәм шул ук вакытта бер-берсенә якынлашуы диалектикасын нигездә дөрес яктыртты, шуның белән, бердән, буржуаз милләтчелек идеологиясенә, икенчедән, милли нигилизмга каршы көрәшкә лаеклы өлеш кертте.

* * *

Коммунистлар партиясе, В. И. Ленин өйрәтүләренә турылыклы рәвештә, интернациональ культура өчен эзлекле көрәш алып барды һәм бара. Буржуаз милләтчеләр алга сөргән «милли культуралар көрәше» теориясен тар-мар итү һәм кайсы да булса бер милли культураның башкаларны йотарга маташуына юл куймау[1] турында партия һәрвакыт кисәтеп килде, социалистик эчтәлекле милли культураларның үзара йогынты ясап чәчәк атуына җитәкчелек итте.

Әйе, барлык социалистик милләтләрнең культуралары — бертигез хокукта, бертигез ихтирам ителәләр. Әмма бу — тарихның иҗтимагый-экономик шартларына бәйле рәвештә үз үсешендә алгарак киткән, көчле демократик традицияләргә бай булган, башка культураларга тирәнтен уңай йогынты ясап, гомум социалистик культура үсешен әйдәп баручы культурага ихтирамның зуррак булу мөмкинлеген һич тә инкарь итми. Илебезнең күп милләтле культурасында шундый күркәм урынны бөек рус культурасы били. Башка милләт кешеләренең аңа Октябрь революциясенә кадәр үк туган мәхәббәте совет чорында тагы да тирәнәйде һәм көчәйде. Чөнки, беренчедән, аңа якын килү юлларындагы киртәләр алып ташланды; икенчедән, аны хаким һәм изүче милләт культурасы дип күрсәтергә урын калмады; өченчедән, аның үз эчтәлеге дә, башка милли культуралар кебек үк, үзгәрде, эксплуататорлар керткән реакцион элементлардан арынды, революцион-демократик традицияләренең үсүе һәм социалистик идеология белән сугарылу хисабына тагы да баеп, кешелек культурасының иң алдынгы казанышы булган ленинизмның символы сыйфатында балкыды.

Халыкларның интернациональ бердәмлеген ныгытуда рус халкының һәм культурасының роле бәя биреп бетергесез. Ул социалистик милләтләрне берләштерүче көч булды. Шуңа күрә татар хезмәт ияләренең һәм интеллигенциясенең бөек рус халкына, аның революцион традицияләренә, теленә, культурасына мәхәббәте аеруча зур. Г. Ибраһимов 1927 елда әйткән түбәндәге сүзләр татар хезмәт ияләренең рус туганнарына карата булган иң ягымлы, иң җылы хисләрен чагылдыра:

«Русның теле бик бай, әдәби, гыйльми теле бөтенләй эшләнгән һәм матур. Рус әдәбияты дөньяның иң алдынгы әдәбиятларыннан санала. Рус мәдәнияты безгә караганда бик күп, бик күп дәрәҗәдә югары. Соңгы ун ел исә рус әдәбиятына, рус гыйлеменә, рус мәдәниятына бик көчле рәвештә пролетариат элементы кертеп, аеруча зур яңа кыйммәтләр арттырды. Бу югары (гали) мәдәният безгә якын булу гына түгел, һәммә яктан безне чолгап алган... Мең еллар буенча без бу мәдәниятка күрше яшәдек, 3—4 йөз ел инде бөтенләй моның уртасында калдык. Бу мәдәният бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез һәммәсе бу рус мәдәниятының бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр. Икътисади, сәяси яктан без бөтенләй диярлек берекканбез. Хәзер безнең тормышыбызның һәммә ягында бу югары рус мәдәниятының элементлары туктаусыз арта баралар, рус мәдәнияты туктаусыз дулкыннар белән безгә керә, тула бара»[2].

Татар культурасы эшчәннәренең рус совет культурасына тирән мәхәббәтен чиксез күп мисалларда күрергә мөмкин. Социалистик культураны, әдәбиятны һәм сәнгатьне алга үстергәндә безнең интеллигенциябез, бер яктан, үз халкының үткән заман культурасындагы иң яхшы традицияләргә, икенче яктан, башка халыкларның, беренче чиратта рус халкының культурасында булган югары үрнәкләргә таянып эш итте. Бу — татар хезмәт ияләренең интернациональ теләкләренә, руслар белән тарихи дуслыгына, рус культурасын үстерүгә даими омтылышына җавап бирә иде. 1927 елда басылып чыккан «Көрәш еллары» исемле әдәби җыентыкка Мәхмүт Максуд, Муса Җәлил, Афзал Таһиров, Мансур Крымов, Афзал Шамов һ. б. тарафыннан язылган сүз башында бу хакта матур әйтелгән: «Канлы фронтта бергә, тезү фронтында бергә, культура фронтында бергә! Төрле телдә сөйләшүче пролетариатның һәм пролетариат партиясе җитәкчелегендә баручы крестьяннарның тоткан юллары әнә шул булганга күрә, электә охшашы күрелмәгән бердәмлек тормышка үткәрелде. Бер оешмада күмәк көч белән эшләү, белем һәм тәҗрибәләрне уртаклашу киң мәгънәсе белән юлга куелды[3].

Интернациональ эчтәлекле, пролетариатның һәм аңа ияргән крестьян массасының сыйнфый теләкләре белән сугарылган, милләтче буржуаз әдәбиятына капма-каршы әдәбиятны үстерү юлында күрше милләт

---

[1] «Правда» газетасы. 1929 ел, 9 февраль.

[2] Г. Ибраһимов. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар. 24 бит.

[3] Көрәш еллары. Мәскәү. 1927 ел. 3 бит.

халыкларының иҗат көчләре белән бер сафта бару кирәклегенә Һади Такташ зур игътибар бирде. 1930 елның 20 июлендә чуваш язучылары белән очрашканда ул төрле милләтләрнең культура эшчәннәрен берләштергән җиңелмәслек армия төзү турында сөйләде, аларны бер үк фронтның солдатлары итеп атады. «Безне аерган нәрсә — телләр аерымлыгы, — диде Такташ, — ләкин бу аерымлык безгә бөек пролетариат культурасын тудыруга комачаулamый. Шулай ук аерым милләтләрнең культура эшчеләре тудырган уңышлыклар белән файдаланырга да киртә була алмый.

Чуваш язучылары тудырган, пролетариат өчен кыйммәтле булган әсәрләр татар пролетариатына рухи азык булган кебек, татар пролетариат язучылары тудырган әсәрләр дә чуваш пролетариатының социализм өчен булган көрәшендә көчле корал булып хезмәт итә ала...» [1]

Культура, сәнгать һәм әдәбият — халыкларны бер-беренә якынайта, яхшырак аңлаштыра һәм берләштерә торган көчле чаралар. Шуңа күрә совет культурасын төзүдә актив катнашкан алдынгы язучылар, тәнкыйтьчеләр, галимнәр милли культураның интернациональ эчтәлеген баету өчен көрәштеләр, бу принципны теоретик яктан нигезләделәр һәм практик рәвештә тормышка үткәрделәр.

[1] Һ. Такташ. Әсәрләр. Казан, 1942 ел, 317 бит.

«Без формасы белән татарча, мәгънәсе белән пролетариатча булган культурабызны алга әйдәгәндә үз күлебездә генә йөзеп калмаска тиешбез, — диде Гомәр Толымбайский.— Кирәк театрда, кирәк әдәбиятта, кыскасы, культураның бөтен тармакларында да милли чикләнүчәнлек булырга тиеш түгел... Үзебезнең ярлы булган культура дөньябызга культураның СССРдагы халыклар арасындагы бәйлыкларын (шулай ук читтәге кирәкләрен дә) тәртипле һәм хәзергегә караганда зуррак бер темп белән кертергә тиешбез» [2].

Даими аралашу, тәҗрибә алмашу, үзара ярдәмләшү социалистик культура үсешенең төп законына әйләнде. Милли культура, әдәбият, сәнгатьнең мәйданы киңәйде, аһәңе моңарчы һичкайчан күрелмәгәнчә көчле яңгырады, эстетик һәм иҗтимагый-политик кыйммәте үсте.

Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә социалистик эчтәлек белән сугарылган интернациональ культура мәйданга килде. Иске җәмгыятьтә үк шытып, тирән тамырлар җибәргән демократик культура бөек Октябрьдан соң гаять уңдырышлы яңа туфракта матур чәчәк атты, социалистик милләтләрне тагы да ныграк берләштерүче көчле чарага әйләнде.

[2] «Безнең юл» журналы, 1929 ел, 2 сан, 25 бит.

*Гөлчәчәк Әдһәмова*

# КИҢ ДАЛА—ЧАЛ ТАРИХНЫҢ ҖАНЛЫ ШАҺИТЕ

Мәкаләләренең берсендә Галимҗан Ибраһимов:

«Тел, әдәбият, шигырь, мәдәният — болар һәммәсе үзләренең рухларын үзгәртергә, башка милләтләргә дошманлык, милли тәгассәп урынына, дуслык, туганлык, кардәшлек рухы белән сугарылырга, халыкны да шул рухта тәрбия итәргә тиешледер», — дип язган иде.

Иҗат эшчәнлегенең беренче адымнарыннан башлап, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул үзе әлеге мәкаләдә уздырган карашларына тулысынча турылыклы булып калды. Алай гына да түгел, Галимҗан Ибраһимовны без чын мәгънәсендә халыклар дуслыгы җырчысы итеп саныйбыз, әсәрләрен исә интернационализм идеяләренең гүзәл гәүдәләнеше дип карый алабыз. Шуның матур бер мисалы — «Қазакъ кызы» романы.

Мәгълүм булганча, «Қазакъ кызы»н әдип 1909 елның җәендә үк яза башлый һәм 1911 елда тәмамлый да. Ләкин төрле нәшриятларга мөрәҗәгать итүенә карамастан, ул елларда әсәрне дөньяга чыгарырга мөмкин булмый. Еллар буе цензура киртәләрен үтә алмый таушалып йөри торгач, роман бөтенләй югалып кала. Үзендә сакланып калган карамалары буенча, 1912—13 елларда Ибраһимов «Қазакъ кызы»н яңабаштан язып чыга. Ләкин монысы да казага очрый: Киев вакыйгалары уңае белән барган тентү вакытында жандармерия кулына эләгә.

«Қазакъ кызы» романы бары тик Бөек Октябрь революциясеннән соң, Совет власте шартларында гына дөньяга чыга һәм чыгу белән күпләрнең игътибарын үзенә тарта. Әсәрнең берничә ел эчендә татар, рус, үзбәк, казакъ телләрендә күп мәртәбәләр басылуы үзе генә дә аның ни дәрәҗәдә популярлык казануын ачык аңлатса кирәк. «Қазакъ кызы»ның башка телләргә тәрҗемә ителүе уңае белән, матбугат битләрендә басылган мәкалә һәм рецензияләрнең генә саны да дистәләр белән исәпләнә»[1].

Казагыстан җирләренең Россиягә кушылып бетүе уңае белән, XIX йөз урталарында дала тормышында тирән үзгәрешләр күренә башлый. Гасырлар буе ярым йокымсыраган хәлдә тереклек иткән ыруглар арасында күп төрле каршылыклар туа, ызгыш-талашлар көчәя, алар бүлгәләнә башлыйлар. «Казакъ кызы» шундый картиналарны тасвирлау белән башланып китә дә:

«... Болар, меңләгән җылкылары, яхшы нәсел дөяләре, исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында, ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәт-рәхәт күчеп йөриләр иде. Бәхетләре ким түгел иде. «Мәгәр каным Чингиздән килә» дип мактанучы кайбер кабиләләр, соңгы заманнарда, җир-суга тарлык кылып, үзләренең җәберләрен арттыра башладылар. Тик менә шул аларның күңелләрен борчый иде. Болай барса, ике арада яман гауга чыгу куркынычын алга китерә иде»[2].

Әдәбият тарихында барлык кешеләр һәм һәркем тарафыннан сөелеп укыла торган үзенә аерым бер төр әсәрләр бар. Мондый әсәрләр турында сөйләгәндә, гадәттә аларны бер сулыш белән, бер тын алуда язылган, диләр. Галимҗан Ибраһимовның «Қазакъ кызы» да шундый әсәрләр рәтенә керә. Бу роман әдип каләменең зур мөмкинлекләре, могҗизалар тудыра алырлык куәте турында сөйли. Әйтергә генә ансат: 7 — 8 табаклык әсәрдә бөтен бер халыкның тулы язмышы, бер социаль укладтан икенче укладка күчү вакытындагы хәле чагылган. Баштан ахырга кадәр гел фаҗигале язмышлардан, контраст тоннардан үрелгән бу әсәр. Әнә — күпме мал-мөлкәтле булырга, күпме бәхетле булырга тырышып та, Байтүрәгә кол булудан узмаган Азым әкә. Әнә — киң сәхрәдә япа-ялгыз калган дивана кимпер, Сарсымбайның икенче хатыны, ялчы Җолкынбай... Аерым геройлар язмышы һәм вакыйгалар бергә кушылган да халык язмы-

---

[1] Б. Ильясова. «Казакъ кызы». «Кызыл Татарстан» газетасы. 1925 ел. 9 январь саны; Г. Рәхим. «Казакъ кызы». «Безнең юл» журналы. 1925 ел. 5 сан; Җосыпбәк. Китаб сини. «Ак жул». 1925 ел. 23 апрель; Г. Губайдуллин. Новые произведения Г. Ибрагимова. Вестник Научного общества татароведения. 1925. Казань. Рус телендә. 1—2 саннар; З. Бәшири. Г. Ибраһимовны өйрәнү һәм «Казакъ кызы» китабы. «Безнең юл». 1928 ел. 2 сан; Л. Климович. О старом Казахстане. «Художественная литература». Рус телендә. 1935 ел. 1 сан; Г. Шарипова. Аса көрнекте суреткер. «Казакъ әдәбияты». 1957 ел. 15 март саны һ. б. һ. б.

[2] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. II том. Казан. 1956. 260 бит.

шына әйләнгән. Ә ул язмыш авыр, караңгы, фаҗигале. Автор бөтен җаны, йөрәге белән шул вакыттагы казакъ тормышының агышын, тормышның төп тенденциясен тойган, һәр кеше язмышына, һәр вакыйгага шул тенденцияне сала алган.

Караңгы, фаҗигале хәлләр уртасыннан, әсәрнең буеннан-буена, Арысланбай белән Карлыгач-Сылуның гүзәл һәм искиткеч көчле, сокландырырлык һәм тетрәтерлек мәхәббәт язмышы уза. Мәкаләдә игътибарны без күбрәк әнә шул мәхәббәт линиясенә тупларга тырыштык.

Әсәрнең «Казакъ кызы» дип исемләнүе һәм үзәккә гасырлар буе дәвам иткән кысынкылыкка, хатын-кызны төрлечә кимсетүгә, мәсхәрәләүгә каршы көрәшкә күтәрелгән казакъ кызы образы куелуы тикмәгә түгел. Көнчыгыш хатын-кызларының дин, төрле гореф-гадәтләр, иске йолалар өстенлек иткән социаль җирлектә соң дәрәҗәдә изелеп яшәве прогрессив акыл ияләрен үткән гасырда ук тирән уйландыра башлаган. Шул чорда ук рус язучылары көнчыгыш хатын-кызларының азатлыкка омтылышын сурәтләгән күп кенә әсәрләр иҗат иткәннәр.

А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, И. И. Козлов, А. И. Подолинский, А. И. Якубович, Ф. Н. Глинка кебек әдипләр иҗатында көнчыгыш халыклары вәкилләре образлары зур урын били. XIX йөз рус әдәбияты тарихында күренекле урын тоткан кешеләрнең берсе — В. И. Даль (1801 — 1872) казакъ, башкорт халыкларының реаль тормыш-көнкүрешләрен сурәтләүгә зур өлеш кертә. В. И. Даль, «Бикә һәм Мәүляна» исемле әсәрен язганда, сигез ел буе Оренбург тирәсендә яши. (В. И. Дальның казакъ халкы тормышын сурәтләүгә багышланган «Майне» һәм «Полуношник» исемле әсәрләре дә бар.) Һәм шул чорда ул казакъ халкының гадәт-йолаларын, халык авыз иҗатын бөтен нечкәлеге белән өйрәнә. XIX йөзнең 30 елларында В. А. Ушаков тарафыннан язылган «Кыргыз-кайсак» әсәре бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинскийның югары бәясен ала. «Кыргыз-кайсак» әсәрендәге ана образы мисалында казакъ хатын-кызларының (Октябрь революциясенә кадәрге чорда казакъларны да кыргыз дип йөрткәннәр) фаҗигале язмышы сурәтләнә. «Бикә һәм Мәүляна»да исә үз язмышы белән килешмәүче, ирекккә омтылучан дала кызы Мәүляна турында сөйләнә.

Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр күбрәк күчмә хәлдә яшәгән, язуы, алфавиты да булмаган казакъ халкы борын заманнарда ук хатын-кыз азатлыгы темасын чагылдырган гаҗәп матур әсәрләр иҗат итә. Казакъ халык әдәбияты хәзинәсендә дин, шәригать кануннарына, һәр төрле йолаларга каршы көрәшкә күтәрелгән батыр йөрәкле хатын-кыз образларының тулы бер галлереясе бар.

Көчле характерлы Җөнара («Җөнара походлары» исемле легендадан), тапкыр Гөлҗанат («Сәүдә ишан» исемле поэмадан), гүзәл Җибек, кыю Баян («Баян-Сылу һәм Козы Көрпеш) һәм башка образлар шәхес ирекге өчен көрәшкә күтәрелгән көнчыгыш хатын-кызлары өчен якты маяк булып балкыдылар.

Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» һәм Дальның «Бикә һәм Мәүляна» әсәрләрендә уртак идея үткәрелә. Бу бик табигый. Чөнки, халык язмышына тыгыз бәйләнгән социаль проблема буларак, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе көнчыгышта өлгереп җиткән иде. Һәр ике язучы шуны тирән төшенгән булганнар. Ихтимал, Г. Ибраһимов В. И. Даль тарафыннан иҗат ителгән әлеге әсәр белән таныш булгандыр. Бәлки, бөтенләй күрмәгәндер дә. Бу мәсьәләдә эзләнергә, тикшерергә кирәк. Киләчәк моны ачыклар...

Казакъ әдәбиятының рус культурасы тәэсирендә тәрбияләнгән күренекле вәкилләре Чокан Вәлиханов, Абай Кунанбаев, Ибрай Алтынсариннар да хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенә карата әһәмиятле фикерләр әйткәннәр. Абай Кунанбаевның ике дистәдән артык әсәре хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенә багышланган.

Орынбай, Шоже, Сугомбай, Биржан, Җамбул кебек талантлы акыннар халык күңелен биләгән мәсьәләләр турында җырлыйлар. Сара, Аксылу, Манат, Болык, Рысжан кебек хатын-кыз акыннар иҗатында да ирек, хокук даулау мотивлары кыюрак, тирәнрәк чагыла башлый.

XX йөздә исә С. Торайгыров, С. Кубаев, М. Сералин һәм башка демократик карашлы язучыларның әсәрләрендә хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе үзәк темаларның берсенә әверелә.

Дала тормышын яхшы белгән, төрки халыкларның культура үсеше, тел-әдәбият, сәнгать мәсьәләләре белән аеруча якыннан кызыксынган киң колачлы әдип Галимҗан Ибраһимовның XX йөз башында «Казакъ кызы» романын язуы әнә шул тарихи җирлеккә барып тоташа булса кирәк.

Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романында XIX йөз ахыры өчен характерлы булган вакыйгаларны бөтен катлаулылыгы белән тасвирлый. Әсәрдә феодаль кабиләләр арасында барган көрәш, күчмә халыклар тормышындагы үзенчәлекле күренешләр, хезмәт ияләренең авыр-газаплы тормышы, социаль тигезсезлекләр сурәтләнә, аларның, әкренләп, сыйнфый каршылыкларга әверелә бару процессы күрсәтелә.

Далада яшәүче төрле ыруглар арасында кузгалган ызгыш-талашларны күрсәтү белән бергә, Галимҗан Ибраһимов, инде бер тапкыр әйтелгәнчә, хатын-кыз мәсьәләсенә дә зур урын бирә.

Әсәрдә без казакъ хатын-кызларының да башка көнчыгыш хатын-кызларына хас газаплар кичерүләрен, авыр физик хезмәт башкаруларын, шул ук вакытта аларның үзенчәлекле тормыш-көнкүреш шартларын да күрәбез. Революциягә кадәр казакъ халкының күпчелеге, нигездә, терлекчелек белән шөгыльләнеп, күчмә кабиләләр рәвешендә яшәгәннәр. Мондый тормыш шартларында хатын-кызлар, төрле өй эшләре белән генә чикләнмичә, хайван карау һәм башка шундый хезмәтләрне дә башкарганнар. Шуңадыр күрәсең, башка көнчыгыш хатын-кызлары белән чагыштырганда, алар

купмедер куләмдә ирекләрәк булганнар. ирләрдән йөз яшермәгәннәр, пәрәнҗә капламаганнар. Ләкин йөз яшермәү, пәрәнҗә йөртмәү генә мәсьәләне уңай якка хәл итә алмый әле. Далада гасырлар буе сакланып, уталеп килгән кыргый йолалар бар. Узып кара син аларны, буйсынмый кара син аларга! Күпме казакъ баласы шул йолаларның корбаны булган. Чират — Карлыгач-Сылуга хәзер инә. Карлыгач әле яшь ярымлык чагында ук, «Йөз баш терлек, дүрт йөз алтын, ике сандык асыл зат бәрабәренә, Кара айгырлар ыругысының ай ярымлык ир баласы Калтайга әйттерелгән булган. Айлар, еллар үтә. Калтай белән Карлыгач үсеп буйга җитәләр. Тик кызның күңеле анда түгел, Калтайны күрәсе дә килми аның: «... буе тәбәнәк, йөзе яман шадра, борыны томшак, күзе кыйшык, тәненнән яман ис килеп тора! Ул бәндә белән, карагым җиңгәм, ничек гомер итәрмен?! Кайбер адәм бар: йөзе булмаса, сүзе, акылы белән күңелеңне ала, гайрәте, ирлеге белән йөрәгеңне тарта! Ул Калтай дигәннең яман куллары белән күкрәгемә маймыл кебек сузылудан башка эше дә юк, сүзе дә юк!» (264 бит).

Хәр табигатьле Карлыгач патриархаль җәмгыять шартларындагы әхлак нормалары белән килешә алмый. Мул тормышта назланып-иркәләнеп үскән кыз гасырлар буе яшәп килгән традицион гадәтләргә каршы көрәшкә күтәрелә. Ул башка берәүне — Арысланбайны сөя. Һәм үз сөйгәне белән кавышу өчен зур тәвәккәллек күрсәтә, күп көч сарыф итә.

Карлыгачның мәхәббәт хисләре тәэсирендә үз бәхете өчен көрәшкә омтылуы, табигый рәвештә, иҗтимагый төс ала. Тора-бара бу вакыйга турә сайлау мәсьәләсенә ялганып китә. Булачак сайлаулар вакытында Кара айгырлар белән кода булудан файдаланырга исәп тоткан Сарсымбай кызы Карлыгачның үз карашлары булуын, мәсьәләне үзе теләгәнчә эш итәргә карар кылуын башына да китерә алмый. Карлыгач белән Арысланбайның үз мәхәббәтләре өчен көрәшүләре исә Сарсымбайның зур планнарына каршы төшә. Шул рәвешчә, шәхес иреге, мәхәббәт өчен барган көрәш феодаль гадәтләргә, патриархаль тормыш тәртипләренә каршы көрәшкә әверелә. Әсәрдә Арысланбай белән Карлыгач чорның алдынгы вәкилләре булып күз алдына киләләр. Бу образлар һәм аларның карашлары, хәрәкәтләре аркылы автор Россиядән искән саф җилләр тәэсирендә дала шартларында туган яңа күренешләрне сурәтли. Әсәрнең финалында Арысланбай белән Карлыгач мәхәббәте тирәсендә барган көрәшнең гасырлар буе дәвам иткән феодаль мөнәсәбәтләргә каршы юнәлдерелгән иҗтимагый характеры ачыклана. Билгеле, казакъ йортында хөкем сөргән патриархаль тәртипләр алдында баш имәгән Карлыгач-Сылу образын сурәтләү белән генә хатын-кыз азатлыгы проблемасы хәл итеlә алмый. Бу катлаулы мәсьәләне хәл итү өчен, тормышның социаль нигезен үзгәртү зарурлыгы әсәрнең башыннан ахырына кадәр кызыл җеп булып сузылып бара. Әсәрдәге һәр образның язмышы соңгы чиктә шул мәсьәләгә килеп бәйләнә. Азым әкәне, Сарсымбайның токал исеме белән йөртелгән икенче хатынын яки Айбала киленчәк образын алыгыз...

Айбала үзен чолгап алган патриархаль тәртипләр белән килешеп яшәргә теләми. Яшь хатынның икенче кеше белән интим мөнәсәбәткә керүе, гомумән, аның яшәп килгән әхлак тәртипләреннән читкә чыгуы турыдан-туры социаль тормыш күренешләренә барып тоташа. Токалның Минди карчыкка сөйләгән сүзләрендә көнчыгыш халыкларында гадәт булып әверелгән, шәригать законнарына нигезләнгән полигамиягә карата ачы нәфрәт ярылып ята.

Байтурә һәм Биремҗан аксакал тирмәләрендәге хәлләрне сурәтләгәндә дә, озак вакытлар сөргендә йөреп кайткач, Сарсымбай йортына сәлам бирергә килгән кунак егет Арысланбай хөрмәтенә үткәрелгән мәҗлесне тасвирлаганда да язучы социаль тигезсезлекләрне ассызыклап бирә. Шул ук вакытта әдип далада яшәгән һәртөрле тәртипсезлекләрне, искелек калдыкларын тар-мар итәргә сәләтле яңа көчләрне дә күрсәтә. Көрәш мәйданына әлегә кадәр феодаль кабиләләр арасында барган талашларга катнашы булмаган, зур көч — халык ачуы белән ярсыган Җолкынбайлар килә.

Автор аңа әсәрдә үзәк урыннарның берсен бирә. Җолкынбайның тормыш юлы шактый катлаулы. Ул көн-төн эшли, ләкин аның хезмәте тиешенчә бәяләнми. Байның артык комсызлыгы, Җолкынбай белән һич исәпләшмәве аркасында, ул шәхси тормышын да кора алмый. Бу образның кылган эшләре һәм сөйләгән сүзләре аркылы автор далада өлешсез каңгырып йөргән хезмәт кешеләренең уяну күренешен хәбәр итә.

Әсәрнең финалында инде без Җолкынбайның көрәшчеләр сафына басканлыгын, бай вәгъдә иткән бәхетле көнне көтү белән чикләнмичә, үз өлешен даулап яуга чыккан көчле фигура итеп күрәбез.

«Кола айгыр, төнге кунакны алып, кызыл уттай яңа башлаган ерак таңга таба кар ерып юналде», ди әдип. Ягъни, Җолкынбай хаксызлык хөкем сөргән җәмгыятькә каршы һөҗүмгә бара. Биредә атның ил агасы Биремҗан аксакалдан алынуы да зур бер хакыйкатьне ача. Җолкынбайның Биремҗанга килүе, аксакалның аңа ат бирүе һәм озатып калу күренеше белән автор аларның шәхси дуслыгын гына түгел, бәлки халык язмышы өчен борчылган, халык бәхете өчен көрәшкә омтылган ике буын хезмәт иясе вәкилләренең уртак теләген чагылдыра. Г. Ибраһимов иҗатына хас булганча, бу очракта да табигать күренешләре геройларның настроениеләренә тәңгәл килә: «Буран бөтенләй тукталган, ерак күк йөзендә йолдызлар яналар». Хаклык даулап көрәш юлына киткән Җолкынбайга табигать тә теләктәшлек итә.

*Илдар Юзеев*

# КАЙБЕР УЙЛАНУЛАР

«Казан утлары» журналының һәрбер санын даими укып баручы буларак, анда басылган кайбер әсәрләр турындагы уйларымны мин башкалар белән дә уртаклашмакчы булдым. Соңгы елларда «Казан утлары» журналының укучылар арасында популярлык казану сәбәпләренең берсе — зур күләмле әсәрләрнең һәр санда дип әйтерлек басыла баруында. Кызганычка каршы, журналның узган елгы саннарында андый күләмле әсәрләр аз булды.

Драматург Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» трагикомедиясе сәхнәдә уңыш казанды. Пьесага карата матбугатта төрле фикерләр әйтелде инде. Тәнкыйтьче Ф. Мусин «Советская Татария» газетасында (31 август, 1966 ел) мондый фикер белән чыкты:

«Геройлар тормышының табигый агышын күрсәтергә омтылып, Ш. Хөсәенов «Зөбәйдә — адәм баласы» пьесасында персонажлар арасындагы кискен конфликттан баш тарткан. Аның максаты — тормышта булган вакыйгаларны объектив рәвештә күрсәтүгә генә кайтып кала, әсәрдә авторның үзе сурәтләгән күренешләргә идея-эстетик хөкеме йомшак бирелгән».

Бу бәя белән килешеп булмый. Персонажлар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне биргәндә, бигрәк тә Зөбәйдәнең бер халәттән икенче халәткә күчеш моментларында драматург тапталган юлдан бармый, аның үз почеркы бар. Ана тарафыннан китереп ташланган бала белән Зөбәйдә арасында параллель кую ата-ананың бала алдында мораль җаваплылыгын — пьесаның төп проблемасын — басым ясап ачарга ярдәм итә. Үзе сурәтләгән күренешләргә актив мөнәсәбәтен автор драматургик алымнар ярдәмендә дә, Зөбәйдә һәм Булат аша ачыктан-ачык та белдерә. «Зөбәйдә — адәм баласы» пьесасы — соңгы еллар драматургиясенең уңышлы әсәре дип саналырга хаклы.

Соңгы еллар прозасы тормышны идеаллаштырып, бизәп күрсәтүдән арына бара. Прозаиклар тормышның катлаулырак якларына мөрәҗәгать итәләр, чынбарлыктагы авырлыкларны ахырда җиңеп чыгучы авыр язмышлы кешене үзләренең төп геройлары итеп алалар. Бу реалистик тенденция Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» повесте, Газиз Мөхәммәтшинның «Хөсәен абзый», Мәдинә Маликованың «Кыр ягы», Радик Фәезовның «Әнием куллары» исемле хикәяләре өчен бигрәк тә характерлы.

Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» повестенда аталарның матур традицияләрен дәвам итү темасы кузгатылган. Бу мөһим темага язучы үзенчә якын килгән. Атаның якты образы, үзе бер уңай герой булып, Гаязны әйдәп бара, авыр минутларда киңәш бирә, абынганда кулын суза. Ата традициясе — балта һөнәренә ия булу гына түгел, ә җәмгыятькә файдалы булып, намуслы яшәү. Повестьның сюжеты җыйнак реалистик вакыйгаларга корылган. Теле үзенчәлекле, әсәр җиңел укыла. Автор үзе сурәтләгән якның пейзажын, анда яшәүче кешеләрнең гореф-гадәтләрен, сөйләмен оста бирә алган. Персонажлардан бигрәк тә Локман, Нух, Кави, Таһирҗан, Әсләм истә калалар. Гомумән, бу повесть, нигездә, уңышлы язылган һәм ул укучылар тарафыннан кызыксынып укыла.

Төп герой Гаяз гадәттән тыш зур авырлыклар алдында торып кала. Гаязның шул авырлыкларны җиңеп чыгуы укучыны ышандырырлык итеп, тормышчан язылган. Автор вакыйгаларны тыныч кына, ашыкмыйча, салкын кан белән, барлык вак-төякләргә кадәр тәфсилләп хикәяләү манерасын сайлап алган. Бу — аның стиле, үзенчәлеге. Мондый алымның әдәбиятта тулысынча яшәргә хакы бар. Әмма Сарьян кайвакытта үзенең бу алымы белән артык мавыгып китә. Гаязның һәрбер кенеңгөпченеп язу укучыны ялыктыра, кызыксынуны киметә. Вакыт-вакыт хәрәкәт ныклүпәнәя, герой көнкүреш ыгы-зыгысы арасында күмелеп кала. Гаяз белән Локманның кул юуларын автор шулкадәр тәмләп сөйли, хәтта шуның белән мавыгып китеп, сюжет җебен ычкындырасың. Сәмигулла абзыйның койкадан егылып төшеп, маңгаеннан кан китү, ул үлгәч, аның мәетен саклап утыру, Таһирҗанның кан төкерү күренешләре дә барлык вак-төякләре белән язылган. Әсәрдә авырулар, үлүләр артык күбәеп китеп чиркандыра башлый. Гаязның әтисе үлә, Таһирҗан кан төкереп ята, Сәмигулла абзый каты авырып үлә, Шагалиев ревматизм белән авырый һ. б.

Әгәр бөрәр художникка М. Шолоховның «Миңле командир» хикәясендәге (ул хикәя журналда үрнәк буларак басылган) Николай Кошевойның портретын ясарга кушсалар, ул нәкъ Шолохов сурәтләгән образның портретын кәгазьгә төшерә алыр иде. Укучыга исә Гаязның портретын күз алды-

на китерү кыен. Гаяз. повестьның төп герое буларак, тискәре геройларга караганда көчсезрәк чыккан.

Әсәрнең төп герое Гаяз үз тормышын, туган-тумачаларының тормышын көйләү тирәсендә күбрәк әйләнә, тормышның төп агышы аңа аз кагыла кебек. Гаязның Халидәгә булган мәхәббәте дә салкын, тормыш-көнкүреш ваклыгыннан романтик югарылыкка күтәрелә алмаган. Соңыннан аларның мәхәббәтен акча мөнәсәбәтләренә кайтарып калдыру да Гаязны бизәми.

Газиз Мөхәммәтшин да хикәясенең төп герое итеп катлаулы язмышлы Хөсәен абзыйны ала. Авыл тормышын, аның кешеләрен яхшы белгән язучы игътибарын характер тудыруга юнәлтә. Хөсәен абзыйның һәрбер сүзе, һәрбер хәрәкәте укучыны ышандыра, ул үзенең бөтен кимчелекле яклары белән укучының күз алдында. Автор героеның йөрәгендә яткан кешелеклек сыйфатларына таянып, аның кимчелекле якларын дусларча гафу итә-итә, әле мыек астыннан гына елмаеп, әле аның өчен сызланып яза. Хөсәен абзый үзенең характеры аркасында авылдашлары алдында көлкеле ситуацияләргә тап була, әмма югалып калмый. Чөнки Хөсәен абзый каравыл өендә генә ятмый, тормышның төп агышы аны үз агымына ияртеп алып китә. Хөсәен абзыйның кеше буларак үсүе, үзгәрүе дә табигый. Тормыш белән бергә ул да үсә, яңара. Башка хикәяләрендәге кебек үк биредә дә Газиз Мөхәммәтшинның теле шаян, халыкчан. Бу хикәя — журналдагы уңышлы әсәрләрнең берсе.

Газиз Мөхәммәтшин күпчелек хикәяләрен беренче заттан сөйләп бирү алымына кора. Әмма аңа бер төрле алымны күп кабатлаудан сакланырга кирәктер. Бу алымның сюжет таркаулыгына, яки сөйләү белән мавыгуга алып китә торган көйсез бер гадәте бар сыман. Бу хикәядә шул кимчелекләр сизелеп кала.

Уңышлы булып чыгарга мөмкинлеге булган «Кыр ягы» хикәясе нәкъ менә сюжетны оештыра белмәү нәтиҗәсендә ахырынача кадәр эшләнеп бетмәгән. Хикәянең авторы Мәдинә Маликова тормыш күренешләрен оста гына тотып ала белә, теле матур, җинел ага. Сорур апаның мәхәббәттә бәхетсезлеге укучыны ияртеп алып китә. Хикәядә ул үзәк линия булырга тиеш иде. Әмма яшь автор хикәянең уртасында үзенең кызыклы язмышлы героинясын онытып да икенче вакыйгаларга күчә. Аннан соң колхозга практикага килгән студентка Дилбәрнең балаларны колхозга алып чыгу, шофер Нурзаһит белән мөнәсәбәте тасвирлана башлый. Вакыйга бөтенлеге булмау нәтиҗәсендә хикәя ике кисәккә аерыла. Сорур апаның язмышына авторның мөнәсәбәте дә сизелми.

И. Салаховның казакъ тормышын бик яхшы белеп язган «Колагир» хикәясе романтик стиле, композицион бөтенлеге, сюжетның киеренкелеге белән җәлеп итә. Бик күп хикәяләрдәге әдәби штампка әйләнеп беткән телгә күнеккәнгәдер инде, бу хикәянең теле башта авыр шикелле тоела. Татар теленең төрле бай оттенокларын, казакъ халык иҗаты белән баетылган көтелмәгән образлы җөмләләрне соңыннан кабат-кабат укыйсың.

Өметле яшь прозаиклар Радик Фәизов һәм Альберт Хәсәновларның «Әнкем куллары» һәм «Яшь наратлар» исемле хикәяләре лирик җылылык белән язылганнар. Әмма аларга традицияләргә ябышып ятмыйча, яңа алымнар табып язу турында уйланырга кирәктер.

Сатира жанрыннан безнең прозаикларыбыз бөтенләй дип әйтерлек читләштеләр. Әжурналда басылганнарының кайберләре хәзерге укучының югары таләпләренә җавап бирерлек түгелләр. Касыйм Хәмзиннең «Проблемалы дәрес» хикәясендә классында икешәр ел утырган хулиган малай күрсәтелгән. Укытучы аңа, тәртип бозган өчен, «нахал!» дип аяк тибеп кычкыра. Искәндәр укытучысына «син үзең нахал!» дип җавап бирә. Укытучы аны класстан куып чыгарырга уйлый, Искәндәр чыкмый. Шуннан соң укытучы һәм укучылар Искәндәрне бөгәрләп салалар, барсы да аның өстенә өереләләр, «массага каршы барма икенче» дип, староста аның өстенә үк менеп атлана. Алар, укытучы җитәкчелегендә, теге малайны физик көч кулланып «тәрбияләләр». Авторның ышандырмый торган бу вакыйгага позициясе дә билгеле түгел. Хикәянең теле сатира-юморга дәгъва итә алмый.

Хикәя жанрында хәлләр әллә ни мактанырлык түгел. Тәҗрибәле язучылар сирәк язалар, ә хикәя жанрына килүчеләр соңгы берничә елда бик аз күренә.

Журнал битләрендә бер-берсен кабатламый торган төрле шагыйрьләр катнашкан. Г. Афзалның «Ышанычыз», «Шәрип урманы» Ә. Маликовның «Яндырылган хатлар», «Алда өр-яңа язлар», Н. Дәүлинең «Онытма», Г. Зәйнашеваның «Китмә, сандугач», Р. Фәйзуллинның «Сине күптән күргәнем юк», «Вулканнар бар дингез төбендә», Р. Гатауллинның «Вьетнам турында уйлыйм», «Малайлар», Ф. Яруллинның «Сабый чак», «Теләк», Р. Гәрәйнең «Ферма буйларында эзләр бар», Г. Рәхимнең «Рас», Б. Хәлимовның «Таң букеты» шигырьләре һәрберсе үзенчә язылулары белән истә калалар.

Күптән түгел безнең арабыздан киткән мәрхүм Гали Хуҗиевның «Таныш күзләр, таныш карашлар» исемле иң соңгы шигырендә гражданлык хисләре тирән моң белән бирелгән. Иҗтимагый тормышта шагыйрьнең иң алда барырга тиешлеген күрсәтү өчен, ул Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләр белән сөйләшү формасын алган.

Җәлилләрдән безгә калган иң кадерле васыять-традиция — тирән эчтәлекле, ачык, тегал, камил формалы шигырьләр язу. Әмма традицияләрне үстермичә торып, бүгенге укучының күңелен яулап алуы авыр. Шагыйрьләребез шигъри фикерне яңа сурәтләү ысуллары белән бирү юнәлешендә туктаусыз эзләнәләр. Берәүләр яшәүчәнлеге гасырлар буенча исбат ителгән традицияләрне баету, яңа баскычка күтәрелү юнәлешендә иҗат итәләр. Икенче юнәлеш, яшь-

ләр арасында киң таралып, ирекле шигырь формасына табынуда чагылды. Равил Фәйзуллинның кайбер уңышлы экспериментларыннан соң, яшьләрнең күбесе ирекле шигырьгә ябырылды. Хәзер ирекле шигырь белән язмаган яшь шагыйрь бик сирәк. Шигырьдә бертөрлелектән качарга омтылып, яшь шагыйрьләрнең күбесе икенче чиккә ташландылар: алар барысы да бертөрле яза башладылар.

Андый характердагы шигырьләрнең күпчелегендә ритм да булмый, рифма турында әйтеп тә торасы юк, ул игътибарсызлык аркасында ялгыш кына килеп эләгә. Ирекле шигырьгә беркем дә каршы килми, әлбәттә. Әмма укучыга әйтер шигъри фикерең булсын, үзенчәлегең «бу мин!» дип әллә каян кычкырып торсын!

Күп кенә шигырьләр яңа дип аталган формага төренәләр. Борис Хәлимовның шигырьләрен мин кызыксынып укыдым. Урыны-урыны белән матур гына образлар да бар. Әмма аның «Мәхәббәт турындагы монолог»ы бернинди дә тойгы уятмый. Чөнки шигырьдә конкрет фикер, хис юк. Ялтыравык образлар белән мавыгып, автор лирик геройның эчке дөньясын ача алмаган. Ә форма нинди катлаулы! Бердәм ритмик система сакланмаган, автор юлларны ничек тели, шулай җимергән. Димәк, яңа форма дәгъва итеп язылган шигырь үзенең формасын таба алмаган әле.

Рөстәм Мингалимовның «Кайту» шигырендә дә көтелмәгән поэтик детальләр ялтырап китә. Тышкы яктан караганда, шигырь яңа булып күзгә ташлана. Әмма шигырьнең эченә керсәң, анда мәгънәсез сүз тезмәләренә генә очрыйсың. Поэтик детальләр табу осталыгын яшь шагыйрь фикер әйтүгә җикми.

Ирекле шигырьдә поэтик фикере белән көчле булган Равил Фәйзуллинның соңгы шигырьләрендә сыйфат ягыннан үзгәреш сизелә. Соңгы вакытта ул халык җырларында еш очраган традицион форманы күбрәк куллана. Шунысы кызык, Равил бу форма аша җитди фикер әйтүдә үзен ирекле сизә. «Бераз үзгә, бераз бүтән», «Сине күптән күргәнем юк» шигырьләрендәге поэтик эчтәлек төгәл формага чагылышын тапкан. Равилнең халык иҗатына игътибар итә башлавы да аңарда матур яңа сыйфатлар туура сәбәп булыр әле.

Шул ук шигырьләр белән янәшә торган «Минем телем» исемле әсәрдә исә поэтик аһәң, матурлыкны тоеп булмый. Тел турында язылган шигырьдә әдәби телгә бигрәк тә игътибарлы булу кирәк иде.

«Галәми ул,
бик гади ул.
Минем телдә иген үсә.
сөт парлана, җеп эрләнә,
сабын кайнатып, тире иләнә,
туендыручылар,
киендерүчеләр дигәндә
минем телем исеңә төшсен»,

— кебек строфаны укучы ничек аңларга тиеш?

Кайвакытта Равил шигырьнең формасына да игътибарсыз карый. «Иңемә кулларың орынгач» исемле әсәрне ни өчен шигырь дип атарга? Образлы фикерләү генә әле шигырь була алмый. Ирекле шигырьнең шагыйрь үзе генә белгән серле кануннары була. Равилнең байтак шигырьләрендә ул система табылган иде. Ритмикасы булмаган, әмма поэтик фикерләве булган мондый характердагы шигырьләрне шигырь жанрына кертеп автор ялгышмый микән? Әдәбиятта яшәргә тулы хокукы булган нәсер дигән жанр да бар бит әле.

Үзенең поэтик тавышын табып өлгергән Рәдиф Гатауллин да, ирекле шигырь стихиясе шаукымына бирелеп, урыны-урыны белән үз принципларыннан ычкынып китә. «Сочинның матурлыгын сөйләмә миңа» исемле әсәрне дә рәхәтләнеп поэтик прозага — нәсер жанрына озатырга мөмкин. Рәдифнең «Лирик сөйләшүләр» циклына безнең зуррак таләп белән килергә хакыбыз бар. Тулаем алганда матур тәэсир калдырган ул циклында Рәдиф вакыт-вакыт элеккеге шигырьләрен кабатлый шикелле.

Ни өчен соң әле без сүзне күбрәк шигырь формасы тирәсендә алып барабыз? Чөнки яшь шагыйрьләрнең эчтәлек һәм форма мәсьәләсендә берьяклы әзләнүләре күңелне борчый. Классик поэзиядә шагыйрьләр кулы тимәгән күпме формалар баетылуны, яңартылуны көтеп торалар.

Журналның «Әдәбият тарихына материаллар» бүлегендә Дәрдмәнднең 6 шигыре бирелгән. Һәрбер шигырь коеп куелган, һәр шигырьнең башкаларына охшамаган үз формасы табылган. Иҗек төрлелеге, кыскалык, янәшә рифмалар, аралаш рифмалар, эчке рифмалар, җырлап торган музыкаль ритм h. б. h. б.

Яки Зыя Мансур тарафыннан җиренә җиткерелеп тәрҗемә ителгән Гомәр Хәйям робагыйлары... Коеп куйган формалы андый шигырьләрне язу шагыйрьдән югары шигырь культурасы һәм әдәби осталык сорый.

Гамил Афзал «Ышаныгыз» исемле шигырендә эчтәлек белән форманың бердәмлегенә ирешә алган. Шигырьнең һәр юлында тыгыз фикер ята. Героика темасы бөтен кырыслыгы, дәһшәте, оптимизмы белән ачылган. Шагыйрь традицион форманы, шигырьнең эчтәлеге таләп иткәнчә, яңартып җибәрә.

«Хейнкель»гә винтовкадан аттык,
Елга булып акты ал каныбыз.
Киртә булып танк астына яттык,
Ышаныгыз!

Строфаның икенче юлы баштан ахырга кадәр «ышаныгыз» сүзе белән рифмалаша. «Ышаныгыз» сүзе шигырьне композицион яктан җыйнаучы, иң нагрузкалы поэтик сүзгә әйләнә. Уңышлы кулланылган аралаш рифмалар шигырьне тагын да ныгыту ролен үтиләр.

Рәшит Гәрәйнең шигырьләрендә истә калырлык юллар байтак.

Яшерен-батырын түгел: көнләү хисе
Үземдә дә минем җитәрлек.
... Эх, бер шигырь яза алсаң иде
Сабантуйга бүләк итәрлек.

Яки:

Ферма буйларыннан үтәм көн дә,
Ферма буйларында эзләр бар.
Безнең ферма кызы чит авылга
Китә икән, — дигән сүзләр бар.

Р. Гәрәй шигырь техникасына, ритм-рифмаларның матур яңгырашына нык игътибар итә. Әмма аның 7 нче санда басылган шигырьләрендә яңа поэтик фикерләр көткәннән азрак. Рәшит яңа темаларны яңа сурәтләү чаралары белән ачуда, яңа фикер һәм формалар эзләүдә кыюсызлык күрсәтә кебек. «Сабан туен көткәндә» шигырендә бүгенге авылдагы сабантуй сурәтләнә, әмма барлык детальләр дә элеккеге авылдан күчкән сыман. Озын колга тотып, егетләр кулъяулык, сөлге җыялар, әби-карчыклар кыз чакларын сагыналар, килен төшкән вакытларын искә төшерәләр. Бүгенге сабантуйның детальләре шигырьдә юк. Шуңа күрә шигырь яңа булып яңгырамый.

Себер турындагы ике шигырьдә дә («Сәлам сезгә Себердән», «Тайга эчендә») Рәшитнең үзе генә күргән поэтик бизәкләре аз. Рәшит элек язган Минзәлә урманнарыннан бик аз аерыла ул.

Табигать турындагы шигырьләрне укыгач, поездда очраган бер кеше искә килеп төшә. Ул Татарстандагы туган авылына ялга кайткан, һәм Башкортстандагы эш урынына — балалар укытырга китеп бара иде. «Нишләп сез Башкортстанга киттегез?» дип сорадым мин аңардан. Ул болай җавап бирде: «Башкортстанга мине Фатих Кәримнең шигырьләре алып китте. Фатих Кәримнең гүзәл Дим буе турында язылган шигырьләрен укыдым да, педагогия институтын тәмамлагач, Дим буена киттем. һәм ялгышмадым, нәкъ Ф. Кәрим сурәтләгән Дим буен күрдем».

Пейзаж шигырьләренең дә укучыга тәэсир итү көче зур икән. Ә безнең шагыйрьләребез табигать лирикасына бик үк игътибар биреп җиткермиләр.

Рәшит Гәрәйнең быелгы 2 нче санда басылган шигырьләре исә фикернең яңалыгы, яңача сурәтләүләре белән әйбәт тәэсир калдыралар һәм Рәшитнең эзләнүен күрсәтәләр.

Темага яңача килү, традицияләрне яңарту буенча эзләнүләр Самат Шакир шигырьләрендә җитми. «Миләүшә» шигырен укыганнан соң, укучының күңелендә яңа хисләр уянмас. Ватан сугышы елларында үк язылган шул ук сөйгәнен сугышта югалту вакыйгасы. Озак еллардан соң лирик герой нәкъ әнисенә охшаган кызны күрә дә сөйгәне дип ялгыша. Мондый теманы бүгенге көндә хәл иткәндә, авторга заманның поэтик югарылыгыннан карарга кирәк иде. Вакыйганың, алымның һәм поэтик чараларның иске булуы шигырьне яңа хис-фикерле булудан мәхрүм иткән.

Шагыйрь беренче чиратта яңа эчтәлек алып килүе, тирән фикер әйтүе белән поэзияне баетырга тиеш. Безгә армый-талмый нәкъ менә шул юнәлештә эзләнергә кирәктер. Мәхәббәт турында, әлбәттә, яшь шагыйрьләрнең язуы һәм күбрәк, тагын да яхшырак язуы хәерле. Әмма безнең халкыбызның тормышы мәхәббәт белән генә чикләнми бит әле. Яшь шагыйрьләр үзләренең сәләтләрен эчтәлеккә бай һәм катлаулы булган халык тормышын күпьяклырак күрсәтүгә җиксеннәр иде.

*Узган ел Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгы һәм үзешчән сәнгать осталарының 1967 елда үздырылачак Бөтенроссия смотры уңае белән Татарстан Республика халык йорты һәм «Казан утлары» журналы иң яхшы бер пәрдәлек пьесаларга, скетчларга, интермедияләргә һәм агитбригадалар өчен сценарийларга ябык конкурс игълан иткән иде.*

*Конкурска кырыкка якын әсәр килде. Жюри комиссиясе, аларның һәрберсен җентекләп тикшереп, беренче премиягә лаек әсәрләр юк, дигән нәтиҗәгә килде.*

*Бер пәрдәлек пьесалар өчен 300 сум күләмендәге икенче премия С. Шәкуровның «Ана» драмасына, 200 сум күләмендәге өченче премия Т. Миңнуллинның «Бәхетле кияү» комедиясенә һәм И. Кәтиевнең «Ялкын» драмасына; скетчлар өчен: В. Монасыйповның «Нәкъ үзе», «Суйдылар» исемле әсәрләренә 75 һәм 50 сум күләмендәге икенче, өченче премияләр. М. Харисовның «План» скетчына 75 сум күләмендәге икенче премия; интермедияләр һәм агитбригада сценарийлары өчен: Г. Нәбиуллинның интермедияләр циклы һәм «Урак өсте» сценариена 150 һәм 100 сум күләмендәге икенче, өченче премияләр бирелде.*

*Премиягә лаек булган әсәрләрдән М. Харисовның «План» скетчы (девизы — Галимов), Г. Нәбиуллинның интермедияләр циклы (девизы — Н. Гыйльми) журналда инде басылып чыккан иде.*

*Түбәндә без укучыларга конкурста премия алган пьесаларның тагын берсен тәкъдим итәбез.*

## Сәет Шәкуров

# АНА

## Драма 1 пәрдәдә

**КАТНАШАЛАР:**

Сөембикә — ана.
Сәлимгәрәй Шамилов — анын улы, колхоз председателе.
Сания — Шамиловның хатыны.
Харис — Шамиловның шоферы.
Фәридә.
Рафикъ.

Шамиловның өе. Зал. Шәһәрчә җиһазландырылган. Полированный мебельләр, келәмнәр, телевизор, радиоалгыч, пианино һәм шәһәр укымышлылары квартирасында нәрсәләр булырга мөмкин булса, бар да бар. Бар нәрсә үз урынында пөхтә, чиста һәм зәвык белән урнаштырылган. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә берәү дә юк. Стенада сәгать суга. Бераздан — ишектә звонок. Эчке бүлмәләрнең берсеннән ашыгып Сания чыга.

Сания. Кайттылар бугай. *(Зал аша ашыгып үтешли, трюмо янында туктап кыяфәтен, чәчләрен төзәтеп ала.)* Ниһаять! *(Ашыгып ишекне ача, аннан атылып Шамилов килеп керә.)*

Шамилов. Кайттылармы?

Сания. Аңламыйм.

Шамилов *(як як бүлмә ишекләрен берәм-берәм ачып карап чыга).* Алып кайтмадылармени әле?

Сания. Кемнәр? Кемне?

Шамилов. Әнкәйне.

Сания. Соң бит син үзең аны каршыларга киткән кеше.

Шамилов. Киткән идем дә... бара алмыйча калдым бит менә. Харисның үзен генә җибәрдем.

Сания *(шелтә белән)*. Бу ни дигән сүз?

Шамилов. Шулай килеп чыкты бит менә. Идарәдән кузгалып кына китәбез дигәндә, теге корреспондентлар тагы килеп чыктылар.

Сания. Корреспондентлар алар һаман килеп торалар. Үзләренә кирәк азыкны алар синнән башка да эзләп табарлар. Аларга синең тагылып йөрүеңнең кирәге юк.

Шамилов. Тагы шул Фәхрия карчык жалобасы буенча килгәннәр. Сигез авылның сигезен дә йөреп чыгарга туры килде.

Сания. Булмаса, үзем генә барыйм, дидем... Ана бит ул!

Шамилов. Шушы кыяфәтеңдә сине ничек станциягә кадәр машинага утыртып җибәрергә кирәк.

Сания. Аңламыйм мин сине, Сәлимгәрәй. Бердәнбер әниең, ун мең километр җирдән, дөньяның икенче читеннән, сагынып, улын күрергә, аның семьясын, тормышын күрергә... Ниһаять, туган илен, колхозын... Әйе, әйе, үзе беренче булып, беренче нигез ташын салган колхозын күрергә, җитмеш яшенә җитүенә карамастан, бөтен юл газапларын үз җилкәсенә алып...

Шамилов. Соң бит мин яздым аңа... үзем барып алам, дидем... Телмәде. Җитәкче кеше, колхозда кызу эш вакыты, эшеннән бүленмә, диде.

Сания. Һич югында каршы алуны оештырырга кирәк иде. Ялгыз машинада түгел, биш-алты машина белән, картларны, замандашларын җыеп, чәчәкләр белән... Әгәр оештырсаң, алар бармаслар идемени?

Шамилов. Исләре китә... шул замандашлары бит инде аларны...

Сания. Үзең белмәгән нәрсәләр турында сөйләмә, зинһар.

Шамилов. Әнә бит, Фәхрия карчык. Заманында әткәйләрне һәлак иткән, ә хәзер минем өстән...

Сания. Зинһар, җитәр. Инде станциядән биш әйләнеп кайтыр вакыт үтте. Берәр чарасын күр.

Шамилов *(телефон трубкасын алып)*. Гаражны бирегез. Гараж? Рәхим, синме бу? Харис нишләптер озаклады. Станция юлында ватылып ятмый микән? «Газик» кая анда? Ә шоферы? Алайса, үзең генә утырып станциягә каршы бар әле.

Сания. Нишләп ул?

Шамилов. Юк, үзем, үзем барам. Тиз генә «газик»ны монда китер. *(Трубканы куя.)*

Сания. Мин дә барам.

Шамилов. «Газик» беләнме?

Сания. Я тагын берәр корреспондент очрар.

Шамилов. Җүләрләнмә. Поезд соңлагандыр. Хәзер барып җитәрбез. Мин анда «Волга»га чәчәкләр дә салып җибәргән идем.

Сания *(ирония белән көйгә салып)*.

Чәчәкләр сез ана сөйләгез...
Чәчәкләр, чәчәкләр...

Хәзер ул станциянең сикәлтәле юлында, ялгыз машинада, улы урынына җансыз чәчәкләр кочаклап, чәчәкләр белән сөйләшеп кайтадыр инде... Эх, аналар, аналар!.. Без дә тиздән ана буласы кеше бит!.. *(Тиз генә киенә башлый.)*

Шамилов. Сания! *(Тышта звонок.)* Кайттылар.

Икесе дә ишеккә ташланалар. Ишек ачыла.
Аннан ике кулына ике зур чемодан күтәреп Харис керә.

Сания. Ә әнкәй? Әнкәй кайда?

Шамилов. Машинадамы?

Харис. Ул әле кайтып житмәдемени?

Шамилов. Ни сөйлисең син? Машинадан узып ничек кайтып житсен ул?

Харис. Мин аны...

Шамилов. Кая куйдың?

Харис. Куймадым. Ул үзе мине кире борды.

Шамилов. Кая?

Харис. Кире станциягә, районга.

Шамилов. Нәрсәгә?

Харис. Без инде авылга кайтып житкән идек. Чуен күперен чыккан-да, каршыга Фәхрия карчык очрады. Ул аны танып алды да машинаны туктатты.

Шамилов. Кем? Фәхрия карчыкмы?

Харис. Юк, әниегез. Тегесе башта таный алмыйча торды. Аннары бер-берсен танып алгач, кочаклашып елашырга тотындылар. Алар элек дуслар булганнар икән.

Шамилов *(ирония белән)*. Әйе, дуслар... Шәп дуслар!

Сания. Шуннан, шуннан?

Харис. Шул. Фәхрия карчык районга, райсобеска бара икән. Өен салырга ярдәм сорап. Әниегез сүз әйтергә дә ирек бирми... «Бу нинди оятсызлык, карчык кешене таякка таяндырып, район кадәр жиргә жәяү йөртү», ди. Тегесе утырмый машинага... тәки утыртты. Әниегезне әйтәм, ай-яй-яй! «Хәзер бу әбиеңне районга утыртып алып барасың, анда аның эшләре беткәнче көтәсең, аннан утыртып өенә, ишек алдына кадәр кайтарып куясың», диде дә китеп тә барды.

Шамилов. Кая?

Харис. Кая булсын, авылга, монда, өегезгә. Без бит инде кайтып житкән идек... Ике йөз метр гына калган иде...

Шамилов. Эх, син! Сиңа рульгә утырырга түгел. Алашага утырып су ташырга гына. Мичкә өстендә.

Харис. Бар, тыңламый кара аның сүзен... Эссе табага бастыра!..

Шамилов. Һәм утырырсың да син алашага. Иртәгә үк, белеп тор. *(Кычкырып.)* Кайда соң ул?

Харис. Белмим. Мин районда Фәхрия карчыкны көтеп ике сәгать тордым.

Сания. Бәлки, юлда берәр иске танышы очрап, шунда кереп утырмый микән?..

Шамилов. Эзләргә, табарга, йорт саен кереп йөрергә. Мин бу урамнан, ә син югары урамнан... Только кара аны: тавышсыз-тынсыз гына. Кемне эзләгәнеңне берәүгә дә әйтмә. Аңладыңмы? Нәрсә торасың? Марш! *(Харис чыга. Саниягә.)* Ә син кая? Өйдә генә тор. Икенче урамнан кайтып төшүе бар.

Чыгып китә.

Сания *(ялгыз)*. Адәм мәсхәрәсе!.. Эш дип, килгән кешеләр дип, әниеңә шундый игътибарсызлык күрсәт әле син, ә? Башыма сыйдыра алмыйм. Хәзер ул ананың йөзенә ничек күренергә кирәк? Кайда йөри икән инде, мескенем? Әни әйтә торган иде, картайган саен кешегә балалар акылы керә, дип. Шулай балалар шикелле үпкәләп йөрүеме? Үпкәләсә дә урыны бар мондый игътибарсызлыкка. Игътибарсызлык кынамы соң бу? Ваемсызлык кынамы? Үзенә килгәндә, бер дә игътибарсызлык күрсәтми бит ул. Бик сизгер, хәтта кирәгеннән артык. Торган саен аңлашылмаган яклары ачыла бара бу Сәлимгәрәйнең. *(Телефон трубкасын ала.)* Миңа мәктәп директоры Исламовны бирегез әле, зинһар! Исмәгыйль ага, исәнмесез! Өйдә үзегез генәме соң? Юк, берәр килгән кеше булып әңгәмәгездән бүлмәдемме дип соравым. Карагыз әле, Исмәгыйл

ага, сез бу авылда күптән укытасызмы? У-у-у, 35 нче елдан бирле! Димәк, сез Сәлимгәрәйнең әнисен беләсез. Кайтырга тиеш иде шул. Көтәбез. Рәхмәт, рәхмәт. Ярый, Исмәгыйл ага, гафу итегез, алайса әнкәй кайткач, безгә иркенләп килеп утырырсыз. Әйе, шул заманнарны искә төшереп, сөйләшеп, дим. Ярый, рәхмәт. Хушыгыз. *(Трубканы куя.)* Боларда да юк дигән сүз... Машина белән йөреп тапмаганны, телефон белән генә табып буламы соң? *(Кинәт ишек алдында кабаланып эт өрә башлый.)* Кайттылар бугай. *(Чыгып йөгерә, тавышы тыштан ишетелә.)* Шарик, Шарик, тик тор. Кемнәр ул? Курыкмагыз, бәйдә ул! Әйдәгез, әйдә, менә коридорда ут яндырдым, кем бу? Әнкәйме? Әнкәй бәгырем! *(Тавыш: «балам».)*

Сания. Әйдә, әнкәй бәгырем, әйдә, түрдән уз. Бу якка, залга. *(Сөембикәне җитәкләп алып керә. Ул аппак чәчле, арыган, йончыган карчык.)* Кая, чишендерим.

Сөембикә. Бер генә минут... Башта утырып тын алыйм, кызым. *(Сания урындык бирә.)* Чакыр, зинһар... анда, коридорда... мине озата килгәннәр иде...

Сания. Кемнәр ул? Керегез монда! *(Фәридә белән Рафикъ керәләр.)*

Фәридә. Без ул, Сания апа, исәнмесез! Без китәбез. Менә әбине генә озата килгән идек. Рафикъ белән.

Рафикъ. Өегезне белмим, ди. Аннан карагы. Ишек алдында эт тә бар.

Сөембикә. Утырыгыз, балалар... Бер генә минут... тынлык...

Озак пауза.

Шулай... Шулай... Бабагыз, мәрхүм... ерак юлдан кайткач... яки ерак сәфәргә чыкканда, утырып ала иде... Бу дини гадәт түгел... Болай, фикер туплау өчен... Я, ярый... Менә хәзер торсак та, чишенсәк тә була. *(Тора. Сания аны чишендерә башлый.)* О... кызым! Синең хәлләр бу чиккә килеп җиткән икән!.. Син хафаланма инде. Мин үзем, үзем чишенәм.

Сания. Зарар юк, әнкәй.

Фәридә. Ярый, әбекәй, Сания апа, без китик инде.

Сөембикә. Ничек китәсез, ди? Сез бит әле йомышыгызны йомышламадыгыз, балам.

Рафикъ. Калсын инде, әбекәй, иптәш Шамилов та өйдә юк...

Фәридә. Без, Сәлимгәрәй Гумировичтан...

Сөембикә. Иптәш Шамилов та түгел, Гумирович та түгел... Мин ничек дип әйткән идем әле?

Фәридә. Сәлимгәрәй абый.

Сөембикә. Сәлимгәрәй абыйлары шул... Әйе, Сәлимгәрәй абыйлары. Кайтмадымени әле?..

Сания. Сезне эзләп чыгып киткәннәр иде, әнкәй.

Сөембикә. Мине эзләүнең кирәге юк, кызым. Еллар буе күз алдымнан китмәгән авылымның урамына кайтып кергәч кенә югалмам инде мин. Я, ярый, кайтыр әле. Бу балаларга ни дип җавап бирәбез соң, кызым?

Рафикъ. Юк инде, әбекәй, кирәкми.

Сөембикә. Кирәк инде ул, балалар, кирәк. Кайтышлый мин клубка, уку йортына кергән идем. Анда аларның телевизорлары юк икән.

Фәридә. Юк инде, Сания апа, без... ни...

Сөембикә. Сәлимгәрәй абыегыз кайткач килерсезме? Я, ярый алайса. Анысы да әйбәт, без Сания апагыз белән аның исенә төшереп куярбыз бу турыда. Сания кызым, син ишекләрдән, капкадан озатып чыгарып җибәр инде балаларны. Анда ишек алдыгызда этегез ябышмасын. Бигрәк усал нәрсә күренә. Бер очтан аны да сарайга бикләп кереп кур. Төнлә өрсә, мин йоклый алмамдыр төсле. Әйдәгез, балалар, мин сезгә бераз көнчыгыш кучтәнәче бирим. Минем анда улым да, киленем

дә геологлар. Тайгага барган саен әрбет чикләвеге алып кайталар. Әйдәгез.

Сания белән бергә балаларны озата чыга һәм алгы булмәдән кире әйләнеп керә.

Сөембикә *(ялгыз. Тәрәзә яңагына килеп сөялә. Ишек алдын, бакчаны күзәтә.)* Менә кайтып та життен, карчык. Үз авылын шушы була инде синең. Төп йортың. Тик нигезе генә үз урынында түгел... корылмалары да.

Ишектән атылып Шамилов кайтып керә. Аның артыннан Сания керә.

Шамилов. Әнкәй!

Сөембикә. Балам! *(Кочагын җәеп аңа килә.)* Балакаем!

Шамилов. Әнкәй, зинһар, гафу ит. Каршыларга дип барырга чыккач...

Сөембикә. Утыр, утыр, улым. Менә каршыма... Кызым, син дә утыр. Менә шулай... Кая чәчләреннән сыйпыйм әле, ичмасам...

Шамилов. Әнкәй!..

Сөембикә. Чәчләрең каты икән синең, улым. Әтиең чәчләренә охшаган... Син ничә яшьтә әле.

Шамилов. Егерме сигездә.

Сөембикә. Әйе. Егерме сигез ел. Син жиде айлык бала булып калган идең... Тәпи дә йөрми идең әле ул вакытта...

Озын пауза. Саниягә.

О... кызым... күрәм, синдә күз яшьләре арзан икән. Укытучы кызы, интеллигент. Аңлыйм. Үзең дә укытучы бугай... Ләкин бит күз яшьләре белән балалар тәрбияләп булмый. Кая булмаса... өстәлең дә әзер икән, самоварың да кайнагандыр. Табын янына утырышыйк. Мин юлдан кайткан кеше, чәйгә сусадым.

Шамилов. Менә әнкәй, түр башына утыр.

Сания самовар чыгара.

Сөембикә. Бик куесын гына ясагыз әле миңа, балалар.

Шамилов. Менә әнкәй, варенье белән эч.

Сөембикә. Варенье яратам мин, улым, бик яратам. Үз бакчагыз вареньесымы? Әллә кибеттән алдыгызмы?

Шамилов. Юк, әнкәй, үз бакчабыз вареньесы.

Сөембикә. Әйбәт. Караңгыда гына булса да бакчагызга күз салдым. Коймаларыгыз бик биек күренә. Этегез дә бик усал икән. Бала-чага кереп йөри алмый торгандыр бакчагызга.

Шамилов. Аның бала-чагасы гынамы соң. Яшьләре дә сорап тормыйлар... Менә, эт тотарга туры килә. Абыйлар исән-саулармы соң?

Сөембикә. Бик исән-саулар. Күп итеп сәлам тапшырдылар. Кая, кызым, тагы бер чинаяк яса инде. Тәмле булып китте әле бу чәй, үз бакчагыз вареньесы белән. Бакча дигәннән, улым, клубыгыз бик күңелсез күренә. Шуңа бакча тирәсенә тартыладыр инде яшь күңел. Телевизорыгыз да юк икән клубта. Бүген Казаннан спектакль тапшыралар, ди. Драмтүгәрәк членнары кемгә барып карарга белмичә аптырап йөриләр икән.

Шамилов. Һаман кул тими шул клубка телевизор кайтарырга.

Сөембикә. Күңел салсаң, кул тия улым, күңел салырга кирәк. *(Телевизорга күрсәтеп.)* Әнә үзеңә тигән бит, күңел салгач, утыр, утыр, кузгалма. Аны мин түгел, яшьләр әйтәләр. Май бәйрәмендә үк кайтартам дигән иде иптәш Шамилов, диләр.

Шамилов. Шулай иде шул.

Сөембикә. Октябрь бәйрәме дә узып киттеме? *(Пауза.)* Бүген әниегез кайткан кичне, клубтан яшьләр китертеп, телевизор карыйбыз булып чыгамени инде биредә?

Шамилов. Нишләп биредә? Телевизор бер бездә генә түгел бит.

Сөембикә. Алар шулай әз-әзләп йорт саен бүленеп карамакчы булалар икән. Күмәк карау булмый инде ул, йорт саен бүленеп карагач.

Сания. Завхоз кебекләре аның бөтенләй үк өенә дә якын җибәрми әле.

Сөембикә. Аның теге, радиоузелда эшләүче Рафикъ дигәннәре антеннасын да күптән үткәреп куйган икән клубка.

Шамилов. Шул арада каян барысын да белеп өлгердең әле, әнкәй? Рафикъларына кадәр...

Сөембикә. Мин туры шул урамга кайттым бит. Клуб урынында элек әтиеңнәр укыган мәдрәсә — соңыннан мин укыткан мәктәп иде. Ә мәктәп янәшәсендә безнең йортыбыз иде. Хәзер аның нигез урыны гына калган.

Шамилов. Ул урында көнкүреш йорты салачакбыз, әнкәй.

Сөембикә. Төп нигеземдә озак итеп хәл җыеп утырдым да клубка кердем. Шунда миңа синең бу урамга йорт салуыңны әйттеләр һәм менә китереп тә куйдылар. Элек бит бу урам юк иде. Яса әле, кызым, тагын берне. Куерак итеп. Менә шулай, улым, мин бүген кич, үзебез генә сөйләшеп утырырбыз дигән идем. Киленне бит әле минем беренче күрүем. Сиңа да сүзләрем бик күп. *(Пауза.)*

Шамилов *(урыныннан тора, ишекле-түрле бераз йөренә, аннан телефон трубкасын ала)*. Клубны бирегез. Фәридәме? Хәзер үк Рафикъ белән килеп минем телевизорны алып китеп торыгыз бүген клубка. Юк, алай йорт саен йөрмәгез инде. Райсоюзга без мебель өчен акча күчергән идек, иртәгә шул акчага клубка телевизор алып кайтыр завхоз. Әйе, хәзер үк. *(Трубканы куя.)*

Сөембикә. Син басып торма, кызым, утыр. Килен дигәч тә син теге... Үзенә дә яса чәй. О... менә, тозлаган помидорларыгызга кадәр бар икән. Кая, улым, абыең сиңа күчтәнәч тыккан иде. Теге якта сары чемодан төбендә булыр. Андагы бүләкләрне иртәгә, ятырагач тапшырырмын инде үзегезгә. Ә менә шул шешә янында пергаментка төргән балыгын ал. Владивосток балыгы, кета. Сизәм, кызым, авыз суларың килеп китте. Мондый вакытта нәфес тарта торган ризык. Бир киленгә, турасын.

Шамилов. Ә менә монысы әнкәй, синең алда бик килешеп бетмәс инде.

Сөембикә. Минем алда, мине үз гомеремдә икенче генә мәртәбә күрү хөрмәтенә килешер. Абыең күчтәнәче. Биш йолдызлысы. Синең анда, әнә теге почмакта, өч йолдызлылары да байтак җыелган икән.

Шамилов. Бушлар алар. Диссертация өстендә утырганнан соң, аз-аз чәйгә салып... Кая инде алайса, абый кадәр абый хөрмәт итеп җибәргән икән!.. *(Сала, эчә.)*

Сөембикә. Һаман язабызмы әле?

Шамилов. Нәрсәне?

Сөембикә. Диссертацияне дим?

Шамилов. Язабыз, инде, язмый нишлисең? Акыл сатучылар күп булды бит. Киңәш бирүчеләр.

Сөембикә. Шул җөмләдән әнием дәме?

Шамилов. Әнине әйтмим. Абый хатларын. Имеш, диссертация ул, бураэнада туа. *(Коньяк сала, эчә.)* Туды менә, шәп! Аспирантурада калган булсам, әллә кайчан тәгәлли идем инде мин ул диссертацияне.

Сөембикә. Шәһәрдә торып авыл хуҗалыгы темасына диссертация?!..

Шамилов. Таңнан торып, кара төнгә кадәр басу иңләп, диссертация тудырып булмый, әнкәй!

Сөембикә. Бу корылмалар аша басу жиле үтеп керә алмыйдыр шул.

Шамилов. Корылмаларның ни катнашы бар?

Сөембикә. Корылмалар аша кешеләр күренми. Син кешеләрнең, кешеләр синең йөрәгеңә үтеп керә алмаса, үзеңнең белемеңне кешеләрнең буразнада җыйган тәҗрибәсе белән уртаклаша алмасаң, нинди диссертация турында сөйләргә мөмкин?

Шамилов. Тагы шул хаттагы сүзләр...

Сөембикә. Абыең хатындагы сүзләр, минем дә сүзләрем иде ул, балам! Бәлки моңа кадәр, фәкать хатлар аша гына сөйләшә алуыбыз күп нәрсәгә сәбәпче булгандыр да.

Шамилов. Нинди нәрсәгә?

Сөембикә. Булмаса... тагы берне яса инде, кызым. Бу йортка килен булып төшүеңә бер ел тулдымы әле синең? Димәк, безнең семья тарихы сиңа билгеле инде?

Сания. Ничек дип әйтергә...

Сөембикә. Алай ничек дип әйтергә белмәгәч, белү түгел инде бу. Кимендә җиде бабаңның тарихын белергә тиеш син, дия иде миңа кайнатам. Хәер, бу мәсьәләдә сиңа шелтә ташлап булмый, кызым. Аның егерме елын мин үзем дә искә алырга яратмыйм. Ә менә аннан соңгысы өчен миңа көенергә туры килмәгәе...

Сания. Ни өчен, әнкәй?

Сөембикә. Иреккә чыгу белән үк, монда кайтмавым өчен.

Шамилов. Аңламыйм?!

Сөембикә. Мин үзем дә бернәрсә дә аңламыйм хәзергә. Яшәп карыйк — күрербез. Бәлки, бу ана йөрәгенең кирәгеннән артык шикләнүчән булуыннандыр. Һәрхәлдә, беренче тәэсир мине бик үк шатландыра алмады.

Шамилов (*урыныннан тора. Тәмәке кабыза. Йөренә*). Ачыграк мөмкин түгелме, әнкәй?

Сөембикә. Ачыкка, ачык итеп җавап та бир инде син алайса, улым: ни өчен син югары белемле агроном, белгеч, үзеңнең бөтен гомереңне фәнни эшкә багышларга хыялланган кеше, колхозга агроном булып түгел, ә колхоз председателе булып, җитмәсә этиең авылына, этиең төзеп, 37 нче елга кадәр этиең җитәкләп алып килгән колхозга килдең?

Шамилов. Мин бу турыда сезгә яздым шикелле.

Сөембикә. Язуга килгәндә, беребез дә бурычлы булып калмадык.

Шамилов. Эшкә килгәндә дә мин бурычлы булып калмадым һәм калмам да. Моннан өч ел элек кенә безнең колхоз районда иң артта калган колхозларның берсе иде. Ә хәзер районда гына түгел, республикада беренче урынны алып тора. Өлкә газеталарында гына түгел, үзәк газеталарда да...

Сөембикә. Укыдым, чыгарма газеталарыңны. Владивостокта торсак та, без, абыең, җиңгән белән Казанда чыга торган барлык газета-журналларны укып барабыз. «Колхоз председателе иптәш Шамиловка» Өлкә Комитетының да, Үзәк Комитетның да котлау телеграммаларын укыдык. Тиздән герой исеме бирүләре ихтималына да шикләнмибез.

Шамилов. Соң, шулай булгач?!

Сөембикә. Дәүләткә планнан тыш ничәдер мең пот икмәк, ит, май артык сату белән генә, барлык сводкаларда беренче урында бару белән генә колхоз председателенең бурычы үтәлми бит әле, улым. Колхозчыларын ничек яши дип тә сорыйлар. Син миңа, бирегә председатель булып килер алдыннан, сез төзегән колхозга, этиемнең эшен дәвам итәр-

гә барам, дип яздың. Бер ел да үтмәде, мин авылдан менә мондый хат алдым.

Шамилов. Нинди хат?

Сөембикә. Укып бир әле, кызым, үзенә. *(Хат бирә.)*

Сания *(укый)*. «Без сезне һәрвакыт сагынып искә алабыз. Сезнең безгә, авыл халкына, колхозның беренче төзелгән авыр елларында күрсәткән хезмәтегезне, изгелегегезне һич онытмыйбыз. Районыбызга яна килгән агроном иптәш Шамиловның сезнең улыгыз икәнен белгәч, без район оешмаларыннан аны үзебез сорап алдык. Сезнең кебек, әтисе Гомәр агабыз кебек булыр дип уйладык. Ләкин ялгыштык. Ул артык рәхимсез, усал...

Сөембикә. Җитәр, кызым, аңлашылды булса кирәк.

Шамилов. Укы, укы!

Сөембикә. Нәрсәсен укыйсың инде аның? Синең йорт саен кереп, колхозчыларның сукаланмый калган җирләрдән төн йокламыйча качапоса җыйган күз яшедәй актык печәннәрен алып чыгып китүең, эштән кайтучыларның кукуруз җирен утап, култык астына кыстырган үләннәрен алып калуың, нәтиҗәдә бер ел эчендә өч йөз хуҗалыкның йөз иллесе сыерсыз калу турында калганнары.

Шамилов. Ләкин бит ул елны район оешмаларыннан күрсәтмә шундый иде. Быел менә печәнне хезмәт көненә бүлеп бирәбез.

Сөембикә. Пленум карарыннан соңмы? Карарсыз, күрсәтмәсез син үзең кешегә нәрсә кирәген күрә белмисеңмени? Күрергә тиеш түгелмени? Ләкин бит үзеңә кирәген күрсәтмәсез дә күргәнсең. Ел да үтмәс борын Җидегән урамына җиденче председательнең җиденче йорты итеп, хәтта барысыннан да уздырып, менә нинди сарай салдырып куйгансың. Колхозга гомере буе тир түккән Фәхрия карчык житмеш терәүле жимерек йортта тора.

Шамилов. Ах, менә эш нәрсәдә икән? Тагын шул Фәхрия карчык! Ләкин күрәм, синең әнкәй, хәтерең югалып бара икән хәзер. Әткәй белән сине гөнаһсызга гаепләп, төрмәгә утыртучыларның, шунда әткәйнең үлеп калуына, синең 20 ел буе газап чигүеңә сәбәпчеләрнең берсе шул Фәхрия карчык түгел идемени?

Сөембикә *(өстәл сугып)*. Җитәр, тукта! *(Кинәт йөрәгенә тотып тынып кала.)*

Сания. Әнкәй, бәгырем! Әнкәй, ни булды?

Сөембикә *(үзен кулга алып)*. Гафу ит, кызым, әдәпсезлек күрсәттем. Чыгырымнан чыктым. Гомеремдә беренче мәртәбә!

Сания. Әнкәй, тынычлан. Сәлимгәрәй, су!..

Шамилов. Валидол бир.

Сөембикә. Кирәкми, улым. Андый нәрсәләр белән узындырмадым инде мин үземне. Ә менә тәмәке төтенен...

Шамилов. Гафу ит, әнкәй. *(Форточканы ача.)*

Сөембикә. Абыең беркайчан да минем алда тартмады. Чыгып тарта иде. Әнә, этең дә чиный сарайда... Ашарына бирен кер.

Шамилов. *(Форточканы яба, эт тавышы акрынаймый, ишеккә бара. Кире борыла. Телефон трубкасын ала.)* Хәлимә, амбарны бир әле. Ало... Бу Шәйхиме? Кем анда синең бүген каравылда? Шулаймени? Алайса карт кешегә иптәш тә булыр, син хәзер үк төшеп минем этне, шунда амбарлар янына алып менеп бәйлә әле. Әйе, хәзер үк! *(Трубканы куя. Тышта эт өрә. Ишектә звонок.)*

Сания. Фәридәләр килде бугай.

Шамилов телевизор күтәреп чыгып китә.

Сөембикә. Я, алла, миннән туган бала сөйлиме соң бу сүзләрне?! Фәхрия карчыкмени соң, кызым, чоры шул иде бит, чоры! Ул вакытта

әле бөтенләй надан бер авыл хатыны, өстәл сугып кычкыру, янауларга түзә алмыйча, үзе дә асылын аңламаган килеш, ялган бер ялага куркып кул куйган икән, шуның өчен мин аңа шушы көнгә кадәр үпкә яки ачу сакларга тиешмени? Еллар буе аның үзенең вөждан газабы кичерүе генә аз булды микәнни? Юк... бу мин дә, этисе дә түгел. Гел түгел!

Сания. Ул бит сезнең тәрбияне күрмәгән, әнкәй.

Сөембикә. Бу хәл мине вөжданым каршында акламый. Аның өчен минем җаваплылыгымны киметми. Дөрес, мине этисен эзли барган җиремнән Казанда, апам квартирасында кулга алдылар. Ул — җиде айлык бала — апам кулында калды. Шул чак җиде яшьлек абыйсын балалар йортына урнаштырганнар. Дөрес, апам үзенә-үзе гашыйк иде. Ләкин мәктәп, комсомол, институт, ниһаять, аспирантура кайда? Алар да аның зирәклегенә сокланып, үз-үзен яратуына юл куйганнармы? Ә мин соң, һәр хатында аның мин-минлеген сизмәдеммени? Хатлар аша, абыйсы аша мин аның мәктәбен, институтын кисәтеп тора алмый идеммени? Ниһаять, мин котылу белән үк, ул минем яныма килде. Нигә миңа шунда ук аның белән кайтмаска иде. Нигә миңа абыйсы янында калырга иде? Нигә, ни өчен? Менә син әйт әле миңа, яратасыңмы аны? Яратып чыктыңмы аңа?

Сания. Яратып.

Сөембикә. Ә ул сине?

Сания *(дәшми)*.

Сөембикә. Яратамы ул сине?

Сания *(авыр сулап)*. Белмим. Минемчә, аның моңа вакыты калмый.

Сөембикә. Менә күрдеңме? Хатынына илтифат итәргә, аның турында уйларга аның вакыты җитми. Дан, шөһрәт артыннан куа. Шулаймы?

Сания. Белмим, белмим. *(Күзенә тулган яшьләрен яшерү өчен алъяпкычы белән йөзен каплый, башын аска ия.)*

Сөембикә. Болай булгач, соң булса да бик вакытлы кайтканмын икән әле мин, кызым! Болай булгач, сезнең семьяга кирәкле кеше икән әле мин, кызым!

Шамилов керә. Күңелсез хәлне күреп туктап кала. Аннан килеп форточканы яба.

Нәрсә? Бу инде синең, үзеңчә, этиең, әниең үчен алу булып чыгамени шул җитмеш яшьлек карчыктан? Шуның өчен аны таякка таяндырып район юлын таптатуың булып чыгамени?

Шамилов. Нишләп алай булсын? Ул үзе әйтмәгәч, мин аның районга барасы барын каян белим?

Сөембикә. Йорты җимерелергә торганын белмисеңмени? Синә шушы өч ел эчендә ул тирәдән үтәргә туры килмәдемени бер дә? Ялгыз, ятим карчыкның кереп хәлен белеп чыгарга, аның ихтыяҗлары белән кызыксынырга син тиеш түгелмени?

Шамилов. Ул бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел, дәүләттән пенсия ала...

Сөембикә. Йортын да дәүләт салып бирсенме? Картайса — дәүләт, инвалид булып эшкә ярамаса — дәүләт, йорты янса — дәүләт, сыеры үлсә — дәүләт, атасыз бала туса — дәүләт... Синеңчә, савым сыер түгелләр ич ул дәүләт? Дәүләт ул шул ук халык, шул ук колхоз, шул ук колхозчылар түгелмени? Районда гына түгел, республика күләмендә беренче урында бара торган миллионер колхоз үз картларының, үз ятимнәренең, инвалидларының ихтыяҗын үз өстенә ала алмыймени? Миллионер колхозның моңа хәле җитмимени? Яки, хәле җитеп тә, югарыдан күрсәтмә, карар, указ көтәме?

Шамилов. Коточкыч нәрсә сөйлисең син, әнкәй. Мин бит хөкүмәт карарларын үзгәртә дә, яңарта да алмыйм.

Сөембикә. Ни өчен сайлап куйды соң сине халык? Үз фикерең хө-

күмәткә житкерү, аның исеменнән уңайлы тәкъдимнәр кертү, үз жирләгендә өлгергән мәсьәләләрне эштә сынап исбат итү өчен түгелмени? Такыр юлдан такылдап баручы житәкченең кемгә кирәге бар? Иртәме, соңмы, халык аны барыбер ул юлдан алып ташлый. Жидегән урамында сигезенче корылмага да урын барлыгын онытма.

Ш а м и л о в. Урамына да, корылмасына да мохтаж түгел мин, әнкәй. Мин агроном һәм бүген үк...

С ө е м б и к ә. Гаризамны өстәлгә китереп салам! Шулаймы? Юк инде, Жидегән урамын артык сузуның кирәге юктыр хәзер. Халык сайлаган икән, аның ышанычын акларга кирәк. Халык белән килде-китте уйнамыйлар. Башлаган эшне ахырына кадәр очлап чыгарга кирәк. Әтиең нигезендә көнкүреш йортын торгызырга кирәк. Фәхрия карчыкның да, башкаларның да йортларын минә үзеңнеке кебек, авылның бөтен урамнарын минә Жидегән урамы кебек итәргә кирәк. Киткән тәкъдирдә дә, халык сине сагынып искә алырлык итеп китәргә кирәк. Әтиең кебек! Син мине аңладың булса кирәк?

Ш а м и л о в. *(Беренче мәртәбә йомшак итеп, елы итеп, бәхетле итеп балаларча елмая).*

С ө е м б и к ә. Аңласаң бик яхшы... Бик рәхмәт. Мин дә жиңеләеп калдым. Өстемнән тау төшкәндәй булды. Соң, жүләрем минем! Башта ук шулай елмаеп каршылаган булсаң, кесәмдә бу жан өшеткеч хатлар, кайтыр юлымда Фәхрия карчыкларның зары тормаса, мин сиңа кайтып керү белән үк шулай дорфа бәрелер идеммени? Балам минем! *(Шамиловның чәчләреннән сыпырып маңгаеннан үбә һәм күзендәге яшьләрен күрсәтергә теләмичә, ишеккә бара.)*

С а н и я. Әнкәй, син кая?

С ө е м б и к ә. Мин, кызым, Фәхрия карчыкка барып утырыйм әле. Ана күчтәнәч, бүләкләр дә тапшырасым бар. Йортын сипләү турында да әйтеп шатландырыйм үзен. Син киенмә, кызым, киенмә. Озатма мине. Мин шулай, ялгызым гына бер урам әйләним әле...

С а н и я. Карангы бит.

С ө е м б и к ә. Мин үз авылымда күземне йомып та йөри алам.

Китә. С а н и я аны озата чыга. Шамилов тирән уйда. Тәмәке кабыза. Тагын форточканы барып ача. С а н и я керә. Ишек янагына сөялеп, хәрәкәтсез кала. Авыр тынлык.

С а н и я *(озак паузадан соң).* Я, нәрсә дисең?

Ш а м и л о в. Диярлек нәрсә калдымы соң?

С а н и я. Менә нинди аналар да була икән!

Ш а м и л о в. Әйе. Бу — ана! Барыбыз өчен дә ана! *(Иркәләп Саниянe үзенең тезләренә утырта.)* Ярый әле улыбыз дөнья күреп өлгермәгән иде. Әтисе турында нинди хатирә калган булыр иде бала күңелендә.

С а н и я. Ниһаять, аңладың. Безнен улыбыз хәзер беркайчан да мондый күңелсез әңгәмәнең шаһите булмас. Бер кайчан да! Шулай бит?

Ш а м и л о в. Шулай.

С а н и я. Рәхмәт. *(Үбә.)*

П ә р д ә.



# ДНЕПРНЫ КИЧҮ

*Г. Сафиуллин,*

Советлар Союзы Герое,
запастагы генерал-лейтенант.

Аннары мин + 2,0 биеклегенә, майор Токарев белән майор Степнойга, шалтыраттым, аларга минем өчен күзәтү пунктын әзерләп бетерергә, күзәтү пунктыннан армия командующиена һәм штабларга элемтә чыбыклары сузарга куштым.

Арттарак сугыш кырын күзәтерлек урын булмаганга, күзәтү пунктларын турыдантуры роталарның алгы сызыгына урнаштырырга мәҗбүр идек. Бу яңа пунктлардан сугыш бара торган урыннар гына түгел, уннарча километр ераклыкта бөтен тирә-як, юллар, калкулыклар һәм көнчыгыш яр күренеп тора, биредән сугыш белән турыдантуры җитәкчелек итәргә унай иде. Дошман самолетларының беренче чиратта торак пунктларын бомбага тотуын искә алып, штаблар өчен авылдан читтә дошманга күренмәслек урыннар әзерләнде.

Полковник Журавлев һәм безнең карамакка бирелгән ИПТАП (истребительно-противотанковый полк) командиры полковник И. В. Козяренко минем күзәтү пунктыма килделәр.

— Икс көн буена нигә монда эшсез торырга, — дип бернечә тапкыр ризасызлык белдерде Козяренко. — Паромнарда елганы кичәргә була. Дивизияләргә хәзер ярдәм кирәк, без аргы якта булырга тиеш.

— Ашыкмагыз, иптәш полковник, өлгерерсез әле. Сезгә дә эш җитәрлек булыр.

Моңа кадәр дивизияләр дошман танкларына үзләрендә булган кораллар белән каршы тордылар. Утыз 76 миллиметрлы туптан торган куәтле ИПТАП полкын алда торган мөһимрәк бурычларны хәл итү өчен саклый идек. Чөнки без белә идек: дошман безне яулап алынган плацдармнан алып ташлау өчен бөтен көчен куячак. Ә ул сугышларда танкка каршы ата торган туплар бик кирәк булачак.

Хәзер инде бу полкны да аргы якка күчерергә вакыт җитеп килә иде, дошман танклары килеп җитеп, безнең гвардиячеләргә каршы һөҗүм башласалар, соң булуы мөмкин.

Мин бу турыда армия командующиена шалтыраттым.

— Каршы килмим,— диде М. С. Шумилов.— Полк командирына әйтегез: полкны ут позициясенә үзе урнаштырсын. Орудиеләрнең бер өлешен резервта тотыгыз. Иртәнгә кадәр танкларны да аргы якка чыгарыгыз.

Безнең карамакка 27 «Т — 34» танкларыннан торган 27 нче һәм 201 нче аерым армия танк бригадалары бирелгән иде. Азын аз, шулай да танк — танк инде ул!..

## Шәхси рекогносцировка

Кояш баер алдыннан, үзәнлекләргә көзге әңгер-меңгер җәелгән вакытта, полковник Журавлев, полковник Колесник һәм минем ординарец Новгородов белән бергәләп, моторлы көймәгә утырып, «Восточный» утравыннан кузгалып киттек.

Яр буеннан караганда Днепр ул кадәр киң түгел һәм тын булып күренә. Ә көймәгә утырып эчәнә кереп китсәң, очы-кырые юк кебек, өстендә зур-зур дулкыннар

---

¹ Дәвамы. Башы 2 санда.

йөгерешә, су бөтерелә, кайный. Шушы ашкынулы зур елганы аннан-моннан гына эмәлләнгән примитив салларда, әллә никадәр корал һәм йөк төяп кичкән сугышчыларның батырлыгына гаҗәпләнми мөмкин түгел иде.

Безне причалда майор Степной каршы алды. Караңгы төшкәнче, күзәтү пунктыннан дошман оборона тоткан җирләрне, корпус частьлары урнашкан урыннарны карарга ашыктык.

Күзәтү пунктыннан Барадаевка авылы ап-ачык күренә. Ул елга буйлап алты километрга сузыла. 147,4 биеклегеннән көньяктарак авылның көнбатыш өлеше урнашкан, без аңа «Көнбатыш Барадаевка» дип исем куштык. Авылның бу өлеше үзәктән тирән чокыр белән аерылып тора. Көнбатыш Барадаевка аша Кременчуг — Верхнеднепровск юлы уза.

Юл аркылы чыктык та, тирән коры елгалар аша үтеп, калкулыкның көньяк итәгенә мендек. Биредә сугыш шактый кызу булган күренә: җир өсте снаряд һәм бомба чокырлары белән тулган, нығытылган позицияләрдә җимерек пулеметлар һәм орудиеләр, дошман солдатлары һәм офицерларының мәетләре аунап ята, кая карама — бөтен тирә-якка снарядлар һәм патроннар чәчелгән иде.

— Бу биеклекләр өчен сугыш ике сәгать дәвам итте, — дип сөйләп китте майор Степной. — Дошман әллә ничә тапкыр контратакага күтәрелде, танклар җибәрде, бомбардировщиклар чакырды. Берсенең дә файдасы булмады. Батальоннар, нығытмаларны флангтан үтеп, тылдан һөҗүм иттеләр. Дошман йөздән артык солдат һәм офицерларының үле гәүдәләрен калдырып чигенде.

— Дивизияләрдә югалтулар ничек?

— Шактый.

Мин, М. С. Шумиловка шалтыратып, корпусның бүгенге көнгә билгеләнгән бурычын үтәве турында хәбәр иттем.

— Армиянең Хәрби Советы һәм фронт командующие И. С. Конев корпус сугышчыларын бурычны үтәүләре белән котлыйлар, — диде ул. — Нык торыгыз. Биеклекләрне дошманга һич бирергә ярамый. Алар оператив әһәмияткә ия. Бу бурычны һәр сугышчыга җиткерегез!

— Котлавыгыз өчен рәхмәт. Гвардиячеләр Хәрби Советның ышанычын аклар.лар.

Полковник Колесник, төнне частьларда үткәрергә һәм, политаппарат работникларын җыеп, бурычны аңлатырга дип, Лосев дивизиясенә китте. Мин курган өстеннән шартларга һәм урынга бәя бирергә керештем.

Дивизияләр һәр җирдә дә үз полосаларында биеклекләргә килеп җиткәннәр иде. Батальоннар яулап алган рубежларны ныгыталар, окоплар казыйлар. Төньяктарак 235 нче гвардия полкының өч 76 миллиметрлы тубы туры наводка белән атарлык позиция алган, ә алардан сулдарак 238 нче гвардия полкының 45 миллиметрлы ике батальон тубы урнашкан. Батальоннарның икенче эшелоны бу тирәдә шактый сыек, полк командирлары монда аз санлы роталарны урнаштырганнар.

Роталар өстенә һәм биеклекләргә дошманның 150 мм лы артиллерия батареясы өзлексез атып тора.

Көньякка таба дошман урнашкан яклар бинокльдән ачык күренә. Алгы сызыктан 6—10 километр ераклыкта Пушкаревка, Акимовка, Михайловка авыллары, район үзәге Лиховка һ. б. торак пунктлары җәелеп ята. 25 нче гвардия корпусы дивизияләре хәзерге позицияләрдә нык торсалар, безнең гаскәрләр өчен бу зур мөмкинлекләр бирә: дошман безнең частьлар тупланган районнарны күзәтә алмый. Аннары үзәнлектәге күп санлы чокыр-чакырлар дошман танклары өчен табигый киртәләр булып тора. Ә дошман гаскәрләренең туплану районнары һәм юллар биредән ачык күренә.

Майор Степной белән 81 нче гвардия дивизиясе командиры полковник Николаев янына килдек. Гадәттә тыныч характерлы, ягымлы Николаев без килгәндә ачулы, кырыс иде.

— Оборона өчен урынны файдалана белмиләр менә, — дип каршы алды безне полковник. — Өлкән лейтенант Мельник роталарны куаклыклар артына урнаштырган. Алда берни дә күренми.

— Сезнең уң күршегез — Василенко дивизиясе ни эшли?

— 147,4 биеклеге районында дошманга каршы сугыша.

— Уң флангны 223 нче полк һәм аның артиллериясе белән каплагыз. Уң фланг сезнең шәхси җаваплылыкта, — дип кисәттем мин аны.

Караңгы төште. Мин сәгатемә карадым. Кичке уңынчы ярты иде. Лосевка шалтыраттым, андагы хәлләрне белештем. Анда барысы да тәртиптә, полклар яулап алынган рубежларны ныгыту эшләре белән мәшгуль иде. Утрауга кайтырга вакыт.

Фронтта тынлык. Бер генә дә ату тавышы ишетелми. Анда-санда ишетелгән команда тавышлары, еракта гы автомашиналар гөрелтесе генә тынлыкны боза.

* * *

28 сентябрьгә каршы төндә корпус штабына 53 нче укчы дивизия штабыннан ике офицер килеп, үз дивизияләренең Яңа Орлик авылы тирәсенә туплануын хәбәр иттеләр. Алар алда торган бурычлар белән таныш түгелләр икән һәм шуңа күрә безнең белән элемтә урнаштыру өчен килгәннәр.

— Дивизия нинди хәлдә? — дип сораштым мин.

— Дивизия тулы составта, әле яңа гына формалашкан.

Армия командующие моңа тикле әллә нәрсә тапкыр шалтыратса да, яңа дивизия киләсен әйтмәгән иде. Армия штабыннан да бу турыда хәбәр итмәделәр.

Бу яңа дивизия кайсы корпус полосасында сугышка кертелә соң? Яулап алынган плацдармның күләме буенча фикер йөрткәндә, өстәмә көчләр безнең 25 нче гвардия корпусына таләп ителә: аның плацдармы бүтәннәргә караганда киңрәк тә, тирәнрәк тә. Шул турыда әйтеп, мин командующийга шалтыраттым.

— 53 нче дивизия иртән сезнең корпус полосасына туплана,—диде М. С. Шумилов.— Дивизия командиры белән бәйләнешкә керегез һәм дивизияне корпус составына кертегез. Иртән сезнең карамакка жиденче понтон батальоны килер. Сычевның инженер-сапер батальоны белән берлектә, понтоннардан күпер салыгыз да 29 сентябрьгә каршы төнне дивизияне, корпусның барлык артиллериясен аргы якка күчерегез. Һөҗүмне дәвам иттерергә әзерләнегез. Тиздән сугышчан приказ алырсыз.

Өстәмә резервлар белән ныгытуга без канәгать идек. Димәк, безнең корпус яулап алган плацдармга армиянең Хәрби Советы зур игътибар юнәлтә.

Корпусның штаб начальнигы А. Д. Овсянников, 53 нче дивизия командиры белән бәйләнешкә кереп, штабка дивизиянең инженерларын һәм минем барлык урынбасарларны чакырды.

Полковник Колесникка мин үзем шалтыраттым.

— Алексей Петрович, бик тиз генә штабка килеп җитегез, — дидем. — Дивизияләрдә үзегезнең ярдәмчеләрегезне калдырыгыз.

— Ни булды?

— Яңа хуҗалык килде. Сезгә анда барырга кирәк. Армия штабыннан яңа боерык алынды.

28 сентябрьдә, 01 сәгатьтә 7 нче гвардия армиясе штабыннан түбәндәге приказ алынды:

«...Составына 72 нче, 81 нче гвардия дивизияләре һәм 53 нче укчы дивизиясе, танклар группасы, 115 ИПТАП кергән 25 нче гвардия корпусына 29 сентябрьгә каршы төнне хәлиткеч һөҗүмгә әзерлек халәтен алырга. Полоса элеккечә. Якын бурыч — 182,3; 170,1 биеклекләрен һәм Барадаевка хуторларын алу. Көн ахырында Комсомольск, Берестка, Попово рубежына чыгу. Корпусның әзерлеге — 8.00.29.9.43 ел».

Корпус һәм дивизияләр командованиесе, штаблар һәм политаппаратура алдында киеренке эш тора иде. Инде таң алды булуга карамастан, барысы да аяк өстендә, барысы да бурычны үтәргә әзерләнә иде.

Чакырылган барлык генераллар һәм офицерлар корпус штабына җыелды. Алар арасында 53 нче укчы дивизиянең командованиесе — генерал Овсеенко, политбүлек начальнигы подполковник Конгуров, дивизия командиры урынбасары полковник Василевский һәм штаб начальнигы майор Кондратенко да бар иде.

Мин 53 нче дивизиянең составы белән таныштыру өчен сүзне Овсеенкога бирдем.

Тәз гәүдәле, пөхтә киемле, чибәр йөзле, урта яшьләрендәге бу генерал дивизиянең формалашуын, аның составына 12 нче, 223 нче, 475 нче укчы полклары, 36 нчы артиллерия полкы һәм башка махсус частьлар керүен сөйләде. Дивизия кешеләр белән дә, корал белән дә тулысынча тәэмин ителгән. Сугышчыларның 50 проценттан артыгы 1941—42 елларда сугышларда катнашкан.

Дивизияне һәм артиллерия, миномет полкларын уң якка күчерү чараларын хәл иттек.

Дивизия командирларына, рекогносцировка үткәрү өчен, сәгать тугызда Днепрның уң ягына чыгарга приказ бирелде. Ләкин фронттагы хәлләр безнең карарга төзәтмәләр кертте. Иртәнге 8 сәгатьтә дошман 72 нче һәм 81 нче гвардия дивизияләре полосасында артиллерия һәм авиация әзерлеге башлады. Рекогносцировканы 15 сәгатькә күчерергә туры килде.

Немецларның артиллерия әзерлегеннән соң күп тә үтмәде, Николаев хәбәр итте:

— Дошманның бер батальон пехотасы, 15 танк ярдәмендә, 233 нче полк позициясенә, 20 танк белән бер полк пехотасы 238 нче полк позициясенә атака ясады, — диде ул. — Попово ягыннан урман авызына таба, 49 нчы корпус юнәлешенә, бик күп автомашиналар баруы күренә.

Лосевтан да хәбәр килде:

— Барадаевка хуторыннан 24 нче гвардия корпусы белән безнең арага дошманның ике батальон пехотасы белән 18 танкысы һөҗүм итте. Дошман һөҗүме кире кагылды. Барадаевка хуторларына таба күп автомашиналар килгәне күренә, — диде ул.

Көне буена дошман өч тапкыр контратакага күтәрелде. Фашист авиациясе сугышчан позицияләрне, гаскәрләр тупланган урыннарны, кичүне берничә мәртәбә бомбага тотты. Димәк, дошман резервларын китерә башлаган.

15 сәгать 30 минутта минем күзәтү пунктына җыелдык. Биредән алгы сызык яхшы күренә. 222 нче гвардия полкы фронты алдында дошманның дүрт танкысы пыскып ята. Барадаевка һәм Попово хуторлары сугыш тетене һәм тузаны аша бик начар күренә. Ул яктан дошман артиллериясе безнең позицияләрне утка тотуын дәвам итгерә.

Рекогносцировка бер сәгать буена дәвам итте. Дивизияләрнең һөҗүм полосаларын, аларның бурычларын, флангларны каплау районнарын, резервларның бурычларын ачыкладык. Аннары мин дивизия командирларына үземнең карарымны белдердем:

— Курганнардан көньяктарак дошман оборонасын өзәргә, Барадаевка, Ново-Александровка хуторларына һөҗүм итәргә, көн ахырына Комсомольск, Берестка районына чыгарга. Дивизияләрдә икенче эшелон һәм танкка каршы резервлар булдырырга. 53 нче дивизиягә, танк группасы белән бергә, Погребная, Одинец районына һөҗүм итәргә, аннары Никитовка хуторын алырга. 81 нче гвардия дивизиясенә башта Ново-Александровканы, аннан соң Михайловканы азат итәргә. 79 нчы гвардия дивизиясенә, 24 нче гвардия корпусы белән үзара бәйләнешкә кереп, Барадаевка хуторларын алырга һәм көн ахырына Берестка янына чыгарга... Артиллерия налеты — ун минут.

Ләкин бездә дошманның резервлары турында тулы мәгълүмат юк иде. Ә уң як күршебез — 49 нчы корпус бездән алты километр арттарак һәм шуңа күрә корпусның бер өлеше белән уң флангны капларга кирәк иде.

Армия командующие М. С. Шумилов күршеләрнең артта калуы турында әйткәнне бер дә яратмый, артка карамауны, әгәр фланглар ачык кала икән, аларны үз көчләрең белән каплауны һәм үз бурычыңны үтәүне таләп итә иде. Безнең корпуста да шундый ук тәртип иде. Командующийның бу таләбен яхшы белгән дивизия командирлары, әйткәнне көтмичә, флангларны томалау чараларын күрәләр иде.

* * *

53 нче дивизия частьларын Днепрның уң ягына күчерү, дошман авиациясенең өзлексез бомбага тотып торуына карамастан, бик оешкан төстә башкарылды.

Фронт штабы начальнигы урынбасары, кичү тәмамлангач:

— Сезгә һәм сапер-понтон подразделениеләре коллективына хезмәтләре, тырышлыклары һәм батырлыклары өчен рәхмәт белдерәм, — диде. — Инженер частьларының личный составы һәм шулай ук Соколов белән Сычев иптәшләр үзләре дә югары хөкүмәт бүләкләренә лаек. Алар сугышчан приказны тормышка ашыруны тәэмин иттеләр. Алар турында мин фронтның Хәрби Советына җиткерәчәкмен.

Командующий приказында атаканың кайчан башланасы сәгате минуты белән күрсәтелмәгән иде. Бу нәрсә армия составындагы корпусларның әзерлегенә бәйле иде. Мин, корпус һөҗүмгә әзерләнеп беткәч тә, телефон буенча армиянең штаб начальнигына шалтыраттым.

— Артиллерия әзерлеген һәм атаканы барлык корпуслар берьюлы башлыйлар,— диде генерал Лукин. — Атакага әзерләнеп бетү — якынча ун сәгатьтә. Артиллерия әзерлеге 15 минут. Приказ алырсыз...

Димәк, атака башланырга дүрт сәгатьләп вакыт бар икән әле. Инде ике тәүлеккә якын безнең беребезнең дә күз йомганы юк. Тагын кайчан йокларга туры киләчәген дә билгесез. Хәлләр сәгать саен үзгәреп тора.

Колесник белән блиндажга кердек. Плащ-палаткаларга төрендек тә печән өстенә аудык.

Ике сәгатьтән соң безне уяттылар.

Сентябрь иртәсе. Днепр өсте томан эчендә. Саргая башлаган куак яфраклары иртәнге мул чыктан авыраеп, салынып төшкән.

— Мөгаен, артиллерия әзерлегенә кадәр томан таралмас, — диде полковник Журавлев, безнең янга килеп.

— Әле бер сәгатьтән артык вакыт бар, — дидем мин. — Кояш чыккач, таралыр. Таралмаса да зарар юк. Дошманның авиациясе әзрәк комачаулар. Дивизионнарның барысын да сынадыгызмы әле?

— Сынадык.

Колесник 53 нче дивизиягә китеп барды. Журавлев белән мин Лосев күзәтү пунктына юнәлдек. Ул без кергәндә телефоннан сул күршебез генерал Козак (Днепрны кичкәч, аңа генерал званиесе бирелде) белән ике араны каплау мәсьәләләрен хәл итә иде.

72 нче гвардия дивизиясе атакага тулысынча әзер иде инде. Барадаевка өчен барган сугышларда шактый югалтуларга дучар булган полклар инде тулыландырылган, тиешле кораллар белән тәэмин ителгән иде.

Армия штабыннан шифрланган телеграмма килеп җитте. Артиллерия әзерлегенең башлану вакыты һәм дәвамлылыгы элеккечә калган, атака башлануы 9 сәгатькә билгеләнгән иде.

Нәкъ 8 сәгать 45 минутта артиллерия әзерлеге башланды. Дивизияләрдәге артиллерия полкларыннан тыш, анда 263 нче аерым армия миномет полкы, полклардагы һәм батальоннардагы минометлар, армия туп-артиллерия бригадасы катнашты. Корпусның һөҗүм итү полосасындагы бер километр фронтта йөзгә якын орудие һәм миномет туры килде. Бу кадәр көч мондагы шартларда дошман оборонасын өзү һәм һөҗүмне тәэмин итү өчен җитәрлек иде.

9 сәгатьтә, ЭРС полкы залпыннан соң, атака башланды. Полклар дошман траншеяларына бәреп керделәр һәм, 15 минутка сузылган каты кул сугышыннан соң, аны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Дошман алдан әзерләнгән тыл рубежларына — Погорелка,

Барадаевка хуторлары, Пролетарка h. б. торак пунктларына чигенде. Дошман бу торак пунктларыннан көньяк-көнбатыштагы биеклекләрне дә ныклы оборонага әзерләгән иде. Өлешчә 175; 167; 8; 165; 4 биеклекләрендәге күп санлы ДЗОТлар һәм ДОТлар безгә билгеле иде инде.

Шул ныгытмалар, танклар һәм авиация ярдәмендә фашистлар, Барадаевка хуторлары янына килеп җиткәч, безгә каршы өч тапкыр контратакага күтәрелде. Шуларга карамастан, 15 сәгать тулганда корпус якын бурычны үтәде, үз полосасындагы торак пунктларын азат итте һәм Безымянний инеше кырындагы биеклекләрне штурмлауга кереште. Каты сугышлардан соң, 147,4 биеклеген алып, Тарасовка авылын азат итте. Ләкин аннары һөҗүмне дәвам иттерә алмады. Шуның нәтиҗәсендә безнең корпусның уң як флангысында 10—12 километр ара ачык калды. 53 нче дивизиянең 223 нче полкы, аның танкка каршы артиллерия дивизионы һәм 115 нче ИПТАП полкының ике батареясы бу араны каплап торырга тиеш иде.

17 сәгатьтә армия командующиена мин хәлне аңлаткач, ул:

— Корпуска яулап алынган рубежларда ныгып урнашырга. Ә үзегезгә минем күзәтү пунктына яңа боерык алырга килергә,— дип боерды.

* * *

Текә уң як ярдагы чокырларга, куаклыклар арасына полкларның санитар роталары урнашкан иде. Биредә яралыларны карыйлар, аларга беренче медицина ярдәме күрсәтәләр. Җиңелчә яралыларны бәйлиләр дә кабат частьларга җибәрәләр, ә авыр яралыларны катерларда һәм көймәләрдә сул якка, медсанбатларга озаталар.

Санитар хезмәте күрсәтү начальнигы подполковник М. М. Романовский яралыларны эвакуацияләү белән җитәкчелек итә, санитар роталарның һәм медсанбатларның эшен тикшерә. Без ярга чыкканда, ул санитар роталар урнашкан урында иде. Мин яралыларның саны турында сораштым.

— Барадаевка һәм курганлы биеклекләр өчен сугышкандагыга караганда ике мәртәбә кимрәк, — дип җавап бирде.

Яралылар арасында Иделдән Днепрга кадәр данлы сугыш юлы үткән батырлар да шактый иде. Сигез разведчик составында Днепрны беренче булып кичкән Николай Попов — кечкенә, ләкин нык гәүдәле, житез хәрәкәтле, кояшта һәм җилдә йөзе янып бронза төсенә кергән солдат — каты яраланган иде.

— Аерыласы килми, — дип ыңгырашты ул. — Иделдән үк бит... Барыбер үз полкыма кайтам мин...

Яралы сугышчылар һәм командирларның барысы да диярлек орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр иде. Мин Романовскийга медсанбатларда яралы сугышчыларның һәм офицерларның исемлеген төзергә, исемлектә аларның кайсы частьтан булуларын, кая җибәрүләрен күрсәтергә куштым. Бу исемлек Днепрны кичкән, плацдарм яулап алу һәм аны киңәйтү өчен сугышларда зур батырлыклар күрсәткән, Ватан өчен каннарын койган сугышчыларны һәм командирларны хөкүмәт бүләкләренә тәкъдим итү өчен кирәк иде.

## Яңа юнәлеш

Командующийның күзәтү пунктында Хәрби Совет члены генерал Мухин, армиянең артиллерия командующие генерал Петров һәм армия штабының оператив, разведка бүлекләре офицерлары бар иде.

Плацдармдагы хәлләр турында доклад ясагач, командующий миңа яңа сугышчан приказ тоттырды.

— Корпус бүген үз бурычын үтәде,— диде ул.— Караңгы төшү белән корпуска перегруппа үткәрергә, дивизияләргә яңа һөҗүм полосаларына басарга һәм иртәгә иртән үк Лиховка юнәлешендә хәлиткеч һөҗүм башларга, көн ахырына аны азат итәргә. Иртәнгә гаскәрләр сугыш кирәк-яраклары һәм азык белән тәэмин ителер.

Мин сугышчан приказны укып чыктым да:

— Сездә дошманның резервлары турында нинди мәгълүматлар бар? — дип сорадым.

— Сездән яшерәсе юк. Авиаразведка мәгълүматлары буенча, якын көннәрдә яки иртәгә үк, дошманның пехота һәм танк дивизияләре килеп җитәчәк. Разведканы һәм күзәтүне көчәйтегез!

Командующий һәм Хәрби Совет члены 53 нче дивизия белән кызыксындылар. Ә дивизия бер генә көн сугышты, аның турында характеристика бирү кыен иде. Шулай да мин:

— Дивизия үз бурычын үтәде. Җитәкчелек итү оешкан төстә барды, полклар яхшы хәрәкәт иттеләр, — дип җавап бирдем.

М. С. Шумилов һәм А. В. Мухин 53 нче дивизиягә корпусның штаб һәм политбүлек работникларын җибәрүне, аларның дивизия командованиесенә ярдәм күрсәтүләрен, личный составны өйрәтүләрен таләп итте.

Кайту юлында мин «Восточный» утравына тукталдым. Соколов һәм Сычев җитәкчелегендә саперлар, понтонерлар иртән сүтелгән күперне торгызалар иде. Диви-

зоннар карамагындагы саперлар көймәләрдә һәм салларда сугыш кирәк-яраклары һәм азык ташыйлар, уң як ярдагы яралыларны күчерәләр. Сул якта артык калырга минем вакытым юк иде, кичү графигын тикшереп, беренче чиратта сугыш кирәк-яракларын күчерергә куштым да, моторлы көймәгә утырып, уң як ярга киттек.

30 сентябрьгә бурыч куйганда, мин командующийдан корпусның фронты ни өчен кинәт кенә көньяк юнәлештән көнбатышка күчерелүе турында сорамадым. Чөнки бу Хәрби Совет приказы, аны тикшерергә беркемнең дә хакы юк иде. Шулай да, үземнең күзәтү пунктыма барганда, мин бу турыда нык уйландым: эш нәрсәдә соң? 49 нчы корпус һәм 24 нче гвардия корпусы элекке юнәлештә һөҗүм итә дә, нигә соң без көнбатышка таба борылабыз? Көньяк-көнбатышка таба һөҗүмне дәвам итү яхшырак булмас идеме икәнни? Мөгаен, бу армиянең Днепрның уң ягындагы плацдармын киңәйтү һәм уңайлы рубежлардан дошманны алып ташлау өчен кирәктер. Чыннан да шулай шул: 49 нчы корпусның уңышлары шәптән түгел, аңа каршы торган дошманның көчләре зур, танклар белән нык көчәйтелгән. Мондый шартларда 25 нче гвардия корпусының һөҗүм юнәлеше күп нәрсә бирми. 49 нчы корпуска да, безгә дә флангларны каплау өчен ярты көчне төп юнәлештән алырга кирәк. Әгәр инде көнбатышка һөҗүм итеп, Лиховканы азат итсәк, безнең частьлар 49 нчы корпуска каршы сугышта торган дошман гаскәрләре тылына чыга һәм, аңа резерв китерү юлларын кисеп, зур әһәмияткә ия булган биеклекләрне һәм курганнарны кулга төшерә. Хәрби Совет нәкъ менә шул максатны күздә тоткан булса кирәк, һәм бу бик дөрес.

Үз күзәтү пунктыма кайткач та, мин җентекләп командующий приказын өйрәнергә һәм үземнең карарым өчен нәтиҗәләр ясарга керештем.

Бер чирек сәгать үткәч, минем янга барлык чакырылган командирлар килеп житте. Барысының да йөзе тузанлы, күзләре йокысызлыктан кызарган иде. Барысы да алгы сызыктан килгәннәр иде.

Командующий приказы нигезендә кабул ителгән карарымны аларга белгерттем: дивизияләргә һәм безнең карамакка бирелгән частьларга перегруппировка үткәрергә, яңа позицияләргә күчәргә һәм иртән ун минутлык артиллерия әзерлегеннән соң:

— 53 нче дивизиягә, 475 нче полктан башка, танк группасы белән, 172,2 биеклегендә дошман оборонасын өзәргә, Погребнойдан төньяк-көнбатыштарак булган биеклекләрне кулга төшерергә, Лиховка шәһәренең төньяк-көнбатыш кварталларын алырга һәм дошманның көньяк-көнбатышка чигенү юлларын буләргә;

— 81 нче гвардия дивизиясенә +1,5 биеклегендәге курганнар районында дошман оборонасын өзәргә, Лиховка шәһәренең үзәк өлешен алырга;

— 72 нче гвардия дивизиясенә һөҗүмне Лиховканың көньягына юнәлдерергә.

Корпус һөҗүмгә 8 сәгать 30 минутта тулысынча әзер булырга тиеш иде. Корпус штабы начальнигы полковник А. Д. Овсянников, артиллерия штабы начальнигы полковник Гуляев белән бергә, төнге 12 гә кадәр сугыш гаскәрләренең үзара бәйләнеше, артиллерия әзерлеге планы өстендә утырдылар.

Тиешле срокта корпусның частьлары һөҗүмнең башлангыч рубежына чыктылар. Перегруппировка, рубеждан рубежга күчү, көнен дә, төнен дә дәвам иткән каты сугышлар сугышчыларны шактый ардырган иде. Ләкин, шуңа да карамастан, алардан зарлану сүзләре ишетелмәде, һәрберсе һөҗүмгә атлыгып тора иде.

Подразделение һәм частьлар командирларына ярдәмгә корпусның штабы, политбүлеге үзенең работникларын җибәрде. Оператив бүлек офицеры майор Сайгетдинов 238 нче гвардия полкына, политбүлек инспекторлары майор Сурков белән майор Астарханов 72 нче гвардия дивизиясенә, разведка бүлеге начальнигы майор Воронцов 53 нче дивизиягә китте. Алар командирларның эшен тикшерү белән генә чикләнмәделәр, ә турыдан-туры анда башкарылган эшләрнең үзәгендә булдылар.

Майор Воронцов 53 нче дивизиянең 475 нче полкын яңа туплану районына алып чыгуны үз өстенә алды. 24 сәгатькә бу полк, алдан күрсәтелгән рубежга чыгып, корпусның көньяк-көнбатыш флангысын каплады. Бу бик авыр бурыч иде. Дивизия командиры генерал Овсеенко майор Воронцов турында:

— Полкның тиешле рубежга чыгуы турында мин бик нык тынычсызланган идем. Майор Воронцов ярдәмендә полк нәкъ 24 сәгатьтә тиешле урында оборонага урнашты, — дип белдерде.

Воронцовка шул полкта калырга рөхсәт бирдек.

30 сентябрь иртәсе аяз һәм җилле иде. Днепр өстендәге һәм үзәнлекләрдәге томан тиз таралды. Күзәтү пунктыннан полкларның һәм артиллериянең позицияләре ачык күренә иде. Төнен сугышчылар окоплар казып урнашканнар, материаль частьларны дошман күрмәслек итеп маскировкалаганнар. 172,2 биеклегеннән һәм +1,6 курганнарыннан дошман минометлардан, пулеметлардан аткалап тора. Дивизияләр атакага сигнал көтә.

Армия штабыннан генерал Лукин:

— Артиллерия әзерлеге тугыз сәгать утыз минутка күчерелә. Бүтән үзгәрешләр юк, — дип хәбәр итте. Авиаразведка Поповодан төньяк-көнчыгышка урнашкан урманда һәм аннан көнбатыштарак автомашиналар хәрәкәтен ачыклады. Корпус, ничек кенә булмасын, юлны кисәргә, урман тирәсендәге курганлы биеклекләрне кулга төшерергә тиеш. Бу — якын бурыч.

Армия артиллериясе нәкъ 9 сәг. 30 минутта көчле ут ачты. Бер үк вакытта туры наводка белән танкка каршы туплар һәм пулеметлар да дошман өстенә ут яудырдылар. Ниһаять, атакага сигнал булып, ЭРС полкы залпы яңгырады. Корпус сугышчылары дошман өстенә ыргылдылар. Каты сугыш башланып китте. Кырык минуттан соң:

— 223 нче полк, танклар ярдәмендә, 172,2 биеклеген һәм урман янындагы +1,6 курганнарны алды, — дип генерал Овсеенко хәбәр итте.

Биеклекләр һәм курганнар тирәсен дошман куәтле ДЗОТлар һәм ДОТлар белән ныгыткан иде.

177,0 биеклегеннән көньяктарак дошманның танклары күренде. Лиховка шәһәреннән безнең танкларга каршы дошманның 25 танкы чыкты, ә төньяк-көнбатыштарак тагын 15 танкы күренде. Немецлар полклар өсгенә көчле артиллерия уты яудырдылар. 81 нче гвардия дивизиясенең сул флангысына каршы бер батальон пехота һәм 10 танк белән контратакага күтәрелделәр.

53 нче дивизия һәм 81 нче гвардия дивизиясе арасына 115 ИПТАП полкы урнаштырылган иде. Бу полк урман авызына таба көчле ут ачты.

Командующийга хәлне аңлатып доклад ясадым, дошманның туплану районнарына авиация җибәрүне сорадым.

— Авиация дошман резервлары килү юлында эш алып бара. Сезгә армиянең бөтен артиллерия бригадасы ярдәмгә килер. Көньяк-көнчыгыш якка игътибар юнәлтегез, — диде М. С. Шумилов.

Ун минут та үтмәгәндер, дошманның артиллерия позицияләренә һәм танкларына таба армия артиллерия бригадасы көчле ут ачты. Дошман танклары тупланган урында ялкын күтәрелде. 115 ИПТАП полкы дошман танкларына каршы сугышка керде. Беренче минутларда ук дошманның алты танкысы утка төренде. Дошман каушап калды. Моннан файдаланып, 72 нче гвардия дивизиясенең ике полкы, көньяк-көнбатыштан әйләнеп чыгып, курганнарга атакага ташланды. 53 нче һәм 81 нче дивизияләрнең хәле җиңеләйде. Дошман Поповодан төньяктарак 177,0 биеклегендә алдан әзерләнгән ныгытмаларга чигенде.

Көндезге сәгать 1 дә дошман самолетларының беренче группасы — утыз «Юнкерс — 88» һәм «Хейнкель — 111» бомбардировщиклары — безнең позицияләрне, Днепр аша кечү урыннарын бомбага тота башлады.

Кичкә таба дивизияләрнең һөҗүм темпы шактый кимеде. Ләкин полкларга яулап алынган рубежларда гына калырга ярамый иде. Дошман биеклекләрдәге һәм курганнардагы уңайлы позицияләрдән корпусның һөҗүм итү полосасын аркылыга да, буйга да ачык күреп тора һәм көньяктан төньякка сузылган юллар да аның кулында. Шуңа күрә дошманны бу позицияләрдән кысрыклап чыгару, юлларны кисү, һич булмаганда, якын бурычны гамәлгә ашыру өчен бөтен көчне куярга кирәк иде. Сугышлар төнен дә дәвам итте. Алдагы батальоннар позицияләрен яхшырту өчен һөҗүмне дәвам иттерделәр.

Таң белену белән сугышлар тагы да катырак көч белән башланып китте. Дошман самолетлары бүген корпусның сугышчан позицияләрен генә бомбага тотты. Дошман, танклар ярдәмендә, яңадан-яңа контратакалар ясап торды. Көне буена фашистлар фронттан ун тапкыр, көньяктанрак — 475 нче полкка ике тапкыр контратака ясадылар.

Кичке сәгать бишкә дошманның барлык контратакалары кире кагылды, 177,0 биеклеге, картада + 1,5 билгесе белән билгеләнгән курганнар алынды, төньяк Попово азат ителде.

Дошман әсирләрен китерделәр. Алар күп түгел, төрле частьларның солдатлары һәм офицерлары иделәр. Әсирләрдән әһәмиятле мәгълүматлар алдык.

Безнең корпуска каршы дошманның әлек Днепрның сул ягында оборона тоткан, хәзер тулыландырылган 168 нче, 320 нче һәм 106 нчы пехота дивизияләре сугыша икән. Лиховкадан көнчыгыштарак безгә каршы тагын яңа килгән 9 нчы танк дивизиясенең һәм «Бөек Германия» СС танк дивизиясенең алдынгы частьлары, 39 нчы, 355 нче һәм 161 нче пехота дивизияләре сугышка кергән. Фашистларга өстәмә рәвештә яңадан-яңа көчләр өстәлеп тора.

Мин шулар турында әйтеп, командующийга доклад ясадым.

— Корпуска яулап алынган рубежларда ныгып урнашырга, — диде ул. — Частьларны тәртипкә китерергә, танкка каршы артиллерияне һәм танкларны алгы сызыкта сугышчан позицияләрдә тотарга, иртән үк дошманның контратакаларын кире кагу өчен әзер булырга!..

## Рубежларны саклау өчен сугышлар

1 октябрьга каршы төндә 53 нче дивизия сугышчылары тарафыннан әсир ителгән дошманның 9 нчы танк дивизиясе солдатлары һәм офицерлары гитлерчыларның пехота дивизияләре Лиховка шәһәренең көнчыгыш ягында тупланулары турында әйттеләр. 9 нчы танк дивизиясе һәм «Бөек Германия» СС танк дивизиясе туплануында дәвам итә. Дошман гаскәрләре иртән безгә контрудар ясарга, плацдармны юк итәргә приказ алганнар.

Корпус частьлары төнен перегруппировка үткәрделәр, позицияләрне ныгыттылар. Күзәтү пунктлары да көчәерелде.

Мена күзгәдәй ялтырап яткан Днепр суы өстенә чыгып килгән кояш нурларыннан алсуланган аяз күк йөзенен шәүләсе төште. Тирә-як тып-тын.

Ләкин иртәнге матур табигать белән хозурланырга һичкемнен исендә дә юк, гаскәрләр дошман һөҗүмен көтә иде.

Генерал М. С. Шумилов, телефоннан шалтыратып, уң флангка аеруча игътибар юнәлтергә кирәклеген әйтте.

— Бүгеннән башлап сезгә ярдәмгә истребительләр җибәрелә,— диде ул.— Ә штурмовиклар һәм бомбардировщиклар дошман гаскәрләренең туплану районнарына бомба ударлары ясаячак. Үзара бәйләнешне оештыру өчен Сезгә авиоберләшмәдән вәкил килер.

Менә Лиховка шәһәре янындагы урман өстендә дошманның уннарча истребительләре озата килгән йөзләрчә бомбардировщиклары күренде. Алар, группаларга бүленеп, сугышчан сафларны, тылны, кичү урыннарын бомбага тотарга керештеләр. Ул да булмады, Яңа Орлик янындагы урман артыннан безнең штурмовиклар, бомбардировщиклар һәм истребительләр килеп чыкты. Аларның бер өлеше Поповодан көньяктарак гитлерчыларның туплану районына, икенче өлеше Лиховкадан көнчыгыштарак дошман танкларына бомба яудырырга кереште. Безнен истребительләр дошман истребительләренә һәм бомбардировщикларына ыргылдылар. Берничә дошман бомбардировщигы койрыкларында утлы төтен күренде һәм алар берәм-берәм түбән кадалып, җиргә төшеп шартлады.

Безнең самолетлар бомбага тоткан урыннарда көчле ялкын күтәрелде. Күк өсте, бөтен тирә-як моторлар гүләве, шартлау авазлары белән тулы иде.

Дошман, безнең сафлар өстенә 15 минут дәвамында артиллерия уты яудырганнан соң, бөтен фронт буйлап һөҗүм башлады. Гитлерчылар, без уйлаганча, төп ударны 177,0 биеклеге, + 1,5 курганнары һәм Барадаевканың көнбатыш читенә ясадылар, шуның белән 53 нче дивизияне һәм 81 нче гвардия дивизиясен чигенергә мәҗбүр итәргә, Попово—Тарасовка юлын кулга төшерергә теләделәр. Бу юнәлештә 53 нче дивизия оборонасын ике полк пехота һәм 45 танк атакалады. Көньяк-көнчыгыштан 81 нче һәм 72 нче дивизия обороналарына да ике полк пехота, 45 танк һөҗүм ясады.

Сугыш һәр куаклык, һәр калкулык өчен барды. Корпус сугышчылары безнен сафларга бәреп кергән гитлерчыларга каршы әледән-әле контратакага күтәрелделәр.

Гитлерчыларның атакасына көч биреп, дошман авиациясе, зур югалтуларга карамастан, бомба яудырып торды. Әмма психик атакалар да, бомба ударлары да дошманга уңыш китермәде. Нәтиҗә шул булды: гитлерчылар бик күп көчләрен югалттылар, ә корпус гвардиячеләре үз позицияләреннән чигенмәде.

Бу көнне безнең 25 нче гвардия корпусы артиллерия, миномет һәм танк полклары белән көчәйтелде. Корпус полосасында армия артиллерия бригадасы дошманга ут яудырды. Болар безгә зур ярдәм иде.

Дошманың барлык атакалары кире кагылгач, кичен мин командующийга көн йомгаклары турында доклад ясадым. Минем йомгаклар түбәндәгечә иде:

Беренчедән, гитлерчылар, Тарасовка авылына каршы йодрык туплап, 49 нчы корпус һәм 1 нче механик корпус частьларын плацдармнан алып ташларга, аннары 25 нче гвардия корпусының уң флангысына удар ясарга, дивизияләренең тылын кисәргә, Кременчуг — Верхнеднепровск юлын кулга төшерергә һәм армиянең кичү урынына чыгарга теләде. Шушы төп максатны гамәлгә ашыру өчен дошман Поповодан көнбатыштарак, Лиховка шәһәреннән көньяктарак урнашкан урманнарга танк резервларын китерә.

Икенчедән, гитлерчылар, үзләренең максатларын тормышка ашыру өчен, бүген иртән безнең корпусның Лиховка шәһәренә һөҗүмен контратакалар белән туктатырга, аны Попово — Тарасовка юлыннан алып ташларга омтылдылар. Чөнки 25 нче гвардия корпусы дошманның удар группировкасының уң флангысына куркыныч тудыра иде.

М. С. Шумилов, минем докладны тыңлаганнан соң:

— Сезнең йомгаклар белән мин килешәм. Төнлә Барадаевканың көнбатыш кырыен һәм авылга көнбатыштан, көньяк-көнбатыштан килә торган юлларны ныгытыгыз, анда танклар, 53 нче дивизиянен танкка каршы дивизионын урнаштырыгыз. Иртән шартларга карап хәрәкәт итегез,— дип приказ бирде. Аннары болай дип өстәде.

— Минем команда-күзәтү пунктына фронт командующие И. С. Конев килде. Ул корпусның сугыш хәрәкәтләрен даими күзәтеп тора, 25 нче гвардия корпусы плацдармына төп игътибарны юнәлтә. Нык торыгыз!

Иртән дошман сайлап алынган авиация берләшмәләрен сугышка кертте. Бомбардировщиклар башлыча 53 нче һәм 15 нче дивизия сафлары өстенә туктаусыз бомба яудырдылар. Шул ук районнарга гитлерчылар 10 минутлык артиллерия налеты ясадылар.

Аннан соң төтен, тузан эченнән дошманның танклары һәм бронетранспортерларга утырган пехотасы күренде. Алдан «Тигр» һәм «Пантера» танклары киләләр, аларга үзйөрешле «Фердинанд» орудиеләре ярдәм итә иде.

177,0 районында һәм аннан көнчыгыштарак 53 нче дивизия оборонасын дошманның бер дивизия пехотасы һәм сиксән танкысы атакалады. Шул ук вакытта 15 нче гвардия дивизиясенә дә Тарасовка юнәлешендә ике полк пехота, кырык танк һөҗүм итте һәм шул ук вакытта 81 нче һәм 72 нче гвардия дивизияләре арасына ике полк пехота белән илле танк ябырылды. Корпусның сул флангысын каплап торган 53 нче дивизиянең 475 нче полкына каршы дошманның тагын ике полкы һөҗүм ясады.

Сугыш кызганнан-кыза барды. Дошман яңадан-яңа резервлар ташлады, ничек тә ярга чыгарга, ә аннары корпус частьларен тылдан аерырга омтылды. Дошман авиациясе сугышчан сафларны өзлексез бомбага тотты, атакалар көчле артиллерия уты белән бергә ясалды.

Гвардиячеләр бөтен фронт буйлап туган җирнең һәр метры өчен батырларча сугыштылар. Шушы катлаулы сугыш шартларында полк, батальон командирлары, барлык офицерлар үзләренең оештыру һәм батырлык сәләтләрен тагын бер тапкыр күрсәттеләр. Кыен моментларда алар, кулларына автоматлар алып, үз артларыннан сугышчыларны әйдәп, домшанга атакага ташландылар, куркусызлык, фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр. Полкларның, батальоннарның сугышчан сафларында штабның элемтә офицерлары һәм политбүлек работниклары даими эш алып бардылар, командирларга ярдәм иттеләр.

2 октябрьда сугыш тынган арада, Колесник белән бергә, 81 нче гвардия дивизиясенең политбүлек начальнигы Д. Г. Большанов донесениесен укып чыктык.

«81 нче гвардия дивизиясенә махсус задание белән җибәрелгән корпус командованиесенең элемтә офицеры майор Сайгетдинов полкның сугышчан сафларына китте,— дип язылган иде анда. — Дошман атакасы вакытында 238 нче гвардия полкы командиры майор И. А. Акимов яраланып сафтан чыкты. Майор Сайгетдинов полк белән командалык итүне үз өстенә алды. Аның җитәкчелегендә бер көндә дошманның җиде атакасы кире кагылды. Кичкә таба дошман полк оборонасын өзәргә маташып карады, полкка каршы кырык танк, бер полк пехота ташлады һәм безнең сугышчан сафларга бәреп керде.

Майор Сайгетдинов полкны контратакага күтәрде. Дошман зур югалтулар белән чигенергә мәҗбүр булды. Сугыш кырында дошманның сигез танкы, шулар исәбендә, ике «Тигр» янып калды».

Бу сугышта күрсәткән батырлыгы һәм инициативасы өчен Сайгетдинов «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнде.


Каты сугышлар бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр өч көн буена дәвам итте.

3 октябрьда көн уртасында 15 нче гвардия дивизиясе оборонасына гитлерчылар йөз танк һәм бер дивизия пехота көче белән һөҗүм итте. Шуның нәтиҗәсендә дошман 49 нчы корпусның бу дивизиясе оборонасын Тарасовка районында икегә аера алды. Дивизиянең бер полкы Барадаевканың көнбатыш өлешеннән авылның үзәгенә, 25 нче гвардия корпусы полосасына, чигенде һәм шунда оборонага урнашты.

(Ахыры бар.)

*Гайшә Шәрипова*

# КӨНДӘЛЕК БИТЛӘРЕННӘН



*Г. Ибраһимов*
*(авторның альбомыннан)*

Фоторәсемнән алҗыган, талчыккан кыяфәтле кеше карап тора. Аның ничә яшьтә икәнлеген тәгаен генә әйтү дә кыен. Тормышта ул сурәттәгедән яшьрәк булса кирәк... Каш арасындагы тирән буразналар, тартылган яңаклар һәм эчкә баткан җитди күзләр бу кешенең куркыныч авыру белән көрәшүе турында сөйли. Көрәш көннәр, хәтта айлар гына да түгел, ә озак еллар буе дәвам итә, ахры. Бу тигезсез көрәштә кем җиңәр? Авыру куркыныч, ләкин кеше артык нык характерлы. Ныклык, ихтыяр чаткылары бәркелеп торган күзләргә карап, син бер генә карарга киләсең: барысы да үз урынында булыр, кеше бу көрәштә һичшиксез җиңүче булып калыр...

Рәсем астындагы язуны укыйм: «Хөрмәтле иптәш Гайшә Шәриповага. Г. Ибраһимов. 1936 ел. 7 март. Ялта».

1936 ел. Фаҗигале үлемгә нибары бер адым калган! Озакламый аның иҗат мирасы ун елларга сузылган торгынлык чоры кичерәчәк.

Ләкин еллар Г. Ибраһимов иҗатын оныттыра алмадылар. Фотообъектив аның йөзен соңгы мәртәбә төшереп алганнан соң дистәләрчә ел үткәч, ул, үзенең әсәрләре аша, яңадан әйләнеп кайтты.

1936 елда Г. Ибраһимовка нибары 49 яшь иде. Бу — язучы кеше өчен күп түгел. Бу — еллар буе җыелып, тупланып килгән тормыш тәҗрибәсен кыю рәвештә иҗатта куллана башлау чоры. Аның иҗатының соңгы чоры аеруча уңышлы, нәтиҗәле еллар булырга тиеш иде...

1935 ел азакларында Мәскәү дәүләт матур әдәбият нәшриятында Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын русча басып чыгару турында сүз кузгалды. Аннан

алдан гына ул елларда даими рәвештә чыгып килгән әдәби альманахларның берсе шулай ук Г. Ибраһимов әсәрләреннән өзекләр сораган иде. Өзек сайлау автор карамагына тапшырылды. Шул уңай белән Галимҗан ага миңа «Безнең көннәр»дән бер өзек җибәрде. Мин, тәрҗемә итеп, аны редакциягә китердем. Ул елларда әле СССР халыклары әдәбиятларын рус телендә бастырып чыгару өлкәсендә беренче адымнар гына ясала һәм, әйтергә кирәк, эштә байтак кына көтелмәгән хәлләр дә килеп чыга иде.

Инде күп еллар үтсә дә, заманында шактый киң таралган бер сәер хәлне искә төшереп китәсем килә. «Тирән тамырлар» басылып бетеп, дөньяга чыгарга әзерләнгән чакта мин романдагы «Фәхрине үтереп ташладылар» дигән беренче фразаның төшеп калуын күрдем. Редактор мине тыңлап торды да: «Нигә инде беренче юлда ук картаны ачарга? Вакыты җиткәнче геройның язмышы серле, билгесез килеш калсын. Ул җөмләне без төп ситуация ясыйбыз», дип үзенекен сөйли башлады. Редакторның бер-берсеннән шактый ерак торган ике әйберне бутавы көн кебек ачык иде. Детектив роман өчен «сер саклау» алымы котылгысыз булса да, тарихи-революцион романда иң элек тормыш дөреслеге кыйммәт.

Байтак тарткалашканнан соң, редактор минем белән килешкәндәй булды һәм мин тынычланып чыгып киттем. Берничә көннән басылып чыккан китапны кулыма алгач, аптырап калдым. Анда автор һәм тәрҗемәче өчен гаять кадерле беренче җөмлә юк иде...

«Безнең көннәр» романы белән дә шундыйрак хәл килеп чыкты. Тәрҗемә ителгән өзекнең нәшрият редакторлары тарафыннан редакцияләнгән вариантын күргәч, мин тагын аптырап калдым. Өзек бу юлы да механик рәвештә нык кына кыскартылган иде.

Кыен хәлдән чыгу өчен, мин азмы-күпме файдалы юл таптым шикелле. Нәшрият кешеләрен тәрҗемә ителгән һәм редакцияләнгән текстларны Ялтага — автор хөкеменә җибәрергә күндердем. Бу шулай эшләнде дә.

Ләкин кульязмаларны Мәскәүдә һәм Ялтада укыштырганчы шактый вакыт узды. Билгеләнгән срок үтеп китте. Шулай итеп, 1935 ел да артта калды, 36 килеп җитте, кыш яз белән алмашынды. Ниһаять, язның беренче көннәрендә Г. Ибраһимовтан зар булып көткән хатны китерделәр.

Минем өстәлдә хәлсез, авыру куллар белән язылган кыска гына хат ята: «Иптәш Шәрипова. Сезнең хатыгыз белән үк диярлек альманах редакциясеннән дә хат килеп төште. Алар миңа ике текст җибәрүләре һәм җавап көтүләре турында язалар. Шулай ук миннән нинди төзәтүләр кертүемне дә сорыйлар. Җавап хатымны аларга да, Сезгә дә җибәрәм. Шуңа күрә монда русча язылган (ягъни редакциягә— Г. Ш.) хатның эчтәлеген кабатлап тормыйм. Сезнең тәрҗемәгез, минем төзәтүләрдән соң, яңадан машинкада басылды. Әгәр кыскартулар урын җитмәү, өзекнең артык зур күләмле булуы аркасында ясалган булса, мин соң чиктә беренче ике бүлекне төшереп калдырырга һәм өченче бүлектән башлап китәргә тәкъдим итәм.

Бик тиз вакыт эчендә җавап бирегез.

Сәлам белән Г. Ибраһимов.
1936 ел. 13 апрель. Ялта».

Шушы ук конвертка альманах редакциясенә язылган хатның копиясе дә салынган иде. Менә ул: «СССР халыклары иҗаты Альманахы редакциясенә.

Кадерле иптәшләр, ип. Шәрипова аркылы Сездән «Безнең көннәр» романыннан сайланган өзекнең ике текстын алдым. Мине бу материаллар белән алдан таныштыруны кирәк дип табуыгыз өчен чын йөрәктән рәхмәт белдерәм. Аларны Сезгә кире кайтарганда, автор буларак, берничә искәрмә биреп китүне кирәк дип саныйм:

1. Өзекнең элекке исеме миңа ошамый. «Беренче адымнар» дип исемләрбез.

2. Редакцияләнгән һәм Сез «бераз гына җыйнакландырылган» дигән беренче текст мине канәгатьләндерми. Монда редактор эше, идеологик һәм стилистик җитешсезлекләргә юнәлдерелүдән бигрәк, механик рәвештә кыскартуга кайтып калган. Урыны-урыны белән хәтта фразалар арасында бөтенләй бәйләнеш өзелә. Шушы әдәпсез кыскартулар нәтиҗәсендә, өзек күп җирдә 1905 елдагы вакыйгалар турында газета-протокол очеркына әйләнеп китә.

3. Ип. Шәрипова тарафыннан тулы тәрҗемә ителгән икенче текст монда карап чыгылды, төп нөсхә белән чагыштырылды, редакцияләнде һәм кайбер урыннарда кирәкле кыскартулар ясалды. Шул төзәтелгән текстны яңадан бастырып, альманах өчен Сезгә җибәрәм.

4. Әгәр редакторның кыскартулары күләм мәсьәләсеннән килеп чыккан булса, мин, соңгы чик итеп, альманахка беренче ике бүлекне кертмәскә, өченче бүлектән генә («Карт жандарм») башларга тәкъдим итәм. Бу «җыйнакландырылган» тексттагы гаять дәрәҗәдәге кыскартуларга караганда, максатка ярашлырак булыр.

Җавап көтәм. Ком. сәламе белән
Галимҗан Ибраһимов.

1936 ел. 13. IV. Ялта».

Хат башка кеше тарафыннан күчерелеп язылган. Г. Ибраһимов дата белән имзасын гына кулы белән куйган. Хатны грамотасыз кеше күчергән. Г. Ибраһимов үзе сәламәт булса, әлбәттә, бу эшне башка кешегә тапшырмаган булыр иде.

Г. Ибраһимов хатларын беркайчан да үзе күнеккән гарәп алфавиты белән язмады. Бөтен хатлары да шул чакта кулланылышка кергән латин шрифты белән языла иде. Г. Ибраһимовка, һичшиксез, яңа хәрефләргә күнегү кыен булгандыр.

Г. Ибраһимовның хатларында, әледән-әле авыруның яңадан көчәюе, санаторийда булу турында сөйләүче җөмләләр очрый иде. Хатын кемгә дә булса әйтеп яздырган очракларда хат азагына имзаны Г. Ибраһимов һәрвакыт үзе куя иде.

Г. Ибраһимов тәрҗемәдә мөмкин кадәр төгәллек таләп итә иде. Бу өлкәдә аның үз карашлары булды, миңа язган хатларында ул тәрҗемә мәсьәләләренә еш туктала иде.

Г. Ибраһимовның тәрҗемә буенча фикерләрен бер системага салу — татар әдәбият фәненең төп бурычларыннан берсе. Бу өлкәдә әдипнең миңа, үзенең тәрҗемәчесенә, язган хатлары тикшерүчеләргә байтак ярдәм итәр дип уйлыйм.

«Безнең көннәр» романын тәрҗемә итү уңае белән башланган сүзне түбәндәге эпизод белән тәмамлыйсым килә.

Ялтадан әдипнең сайланма әсәрләренең «Безнең көннәр» романы басылган III—IV томнары килеп төште. Романны тәрҗемә итү миңа тапшырылган иде. Аннан соң күпме еллар үтсә дә, мин бүген дә ул китапларның саргайган битләрен дулкынланмыйча ача алмыйм. 469 биттән торган текстта каләм кагылмаган бер генә бит тә юк. Текст хәрефе-хәрефкә укылып, җөмлә кытыршылыкларыннан арындырылган; сүзләр, кайчакта тулы абзацлар, хәтта битләр үзгәртелгән. Төзәтүләр, зур бер кисәкме ул, яңадан өстәлгән фраза яки аерым сүзме, һәр очракта оста ювелир эшен хәтерләтәләр. Кызганычка каршы, миңа ул чакта романны тәрҗемә итәргә насыйп булмады. Беренче тоткарлык минем Казагыстанга күчүем аркасында килеп чыкты. Бу — Г. Ибраһимовка ошамады, ул үзенең килешмәвен ачыктан-ачык әйтте. Аннан озак та үтмәде, коточкыч вакыйгалар башланды.

Галимҗан Ибраһимов әдәби тәрҗемә эшенә гаять җитди карый иде. Рус теленә тәрҗемә итеп бастыруга ул бигрәк тә нык игътибар итте. Әдәби фронтның теләсә кайсы өлкәсендәге эшкә ул партия күзлегеннән карап хөкем йөртә иде.

Үзенең бер хатында Г. Ибраһимов минем эшне тикшерә һәм хатны миңа һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торуын аңлаткан сүзләр белән тәмамлый. Партияле фикер йөртүче әдип буларак, Г. Ибраһимов мораль ярдәмнең бәясен белеп, вакыт һәм көч белән исәпләшмичә, кешеләргә ярдәм итәргә әзер тора иде.

«Мин Сезгә, Сезнең эшегезгә тулысынча уңышлар телим. Мин Сезгә Ялтада яшәүче авыру автор, коммунист язучы көче җитәрлек булган һәр эштә иптәшләрчә ярдәм итәргә хәзер икәнлегемне әйтеп китүне кирәктер дип уйлыйм. Чөнки мин Сезнең эшегезне бик кирәкле, пролетарий революциясенең бер фронты өчен файдалы дип саныйм».

Үзенең 1932 елның 19 мартында язган хатын Г. Ибраһимов әнә шул сүзләр белән тәмамлый.

Безгә бу сүзләрне белергә һәм истә тотарга кирәк. Алар коммунист әдипнең никадәр ярдәмчел, кешелекле иптәш булуын ачык чагылдыралар.

Зәйнәп Кәримова

# УЛ БЕЗНЕҢ ЯКЫН ДУСТЫБЫЗ ИДЕ

Минем яшьлек дәверем, яшьтәшләремнең күбесенеке кебек, иске тормышны җимереп, яңа тормыш төзи башлаган чорга туры килде.

Яшьләр арасында демократик карашлар, халыкка хезмәт итү теләкләре, яңа фикерләр уянып килгән чор иде ул. Мондый карашлар, теләкләр үзләреннән-үзләре тумадылар, әлбәттә. 1905—07 еллар революциясе нәтиҗәсендә җанланып киткән әдәбиятыбызның, сәнгатебезнең, алдынгы фикерле җәмәгать эшлекләребезнең йогынтысы аркасында формалашты бездә ул карашлар.

Мин Астраханьда урта мәктәптә укыганда, безнең гаиләбез шагыйрь Сәгыйть Рәмиев белән бик якыннан таныш иде. Соңрак аның аркылы миңа укытучы, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Хөсни Кәрим белән танышырга туры килде. Бу соңгысы башта миңа мәгънәви ярдәм күрсәтүче якын дустым, соңыннан ярты гасыр буена бергә яшәгән тормыш иптәшем булды. Сәгыйть белән Хөсни аркылы 1916 елны Уфада шагыйрь Мәҗит Гафури һәм зур әдибебез Галимҗан Ибраһимов белән таныштым.

1916 елның май аенда мәктәптә укытулар беткәч, мин тулы хокуклы укытучы булыр өчен экстерн имтихан тоту нияте белән, ә Хөсни үзенең хезмәте буенча губерна земствосына Уфага килдек. Эшләре арасында Хөсни «Галия»дә бергә укыган иптәшләрен күрергә, мине алар белән таныштырырга уйлады. Миңа җәй торырга бүлмә табу нияте белән Уфа урамнарының берсеннән барганда, безгә урта буйлы, ачык йөзле бер кеше очрады. Ул Хөсни белән бик җылы мөгамәлә күрсәтеп исәнләште. Хөсни миңа:

— Зәйнәп, таныш бул, бу шагыйрь Мәҗит Гафури абзаң булыр, — диде.

Гадәттә сирәк очрашкан танышлар арасында сорашыла торган «кайдан киләсез, кая китеп барасыз?» кебек сүзләрдән соң, Хөсни Кәрим аңардан:

— Мәҗит, Галимҗанны күрәсе иде, кайда күреп булыр икән? — дип сорады. Мәҗит абзый:

— Галимҗан көндезге ашка Җиһанша Абдюшевка[1] йөри, хәзер шунда булуы мөмкин, — диде. Абдюшевның адресын өйрәтте.

Без Абдюшевларга барып кергәндә, зал якта, аш өстәле тирәсендә бер төркем ирләр утыра иде. Берсе аяк үрә торып калганнарга нәрсәдер сөйли. Ул кеше, Хөсни Кәримнең кергәнен күреп:

— Аба! Хөсни килде! — дип каршы алды Җиһанша Абдюшев булып чыкты ул.

Өстәл тирәсендә утыручыларның берсе, тиз генә урыныннан торып, Хөсни янына килде дә бер кулы белән аның аркасыннан кочаклап күреште. Аннары, миңа борылып:

— Бу Зәйнәп буладыр инде, — дип, минем белән күреште. Урта буйлы, иңенә төшеп торган, ыспайлап артка таба тараган озын чәчле, акыллы йөзле, үткер күзле, ябыграк чырайлы бу кеше — Галимҗан Ибраһимов иде. Барысы белән дә исәнләшеп, танышып чыккач, безгә табынга утырырга тәкъдим иттеләр. Хөсни моңа каршы:

— Рәхмәт, вакытыбыз бик аз, ашыгыч эшләребез бар, фәкать Галимҗанны күрергә дип кенә кергән идек, — диде.

Безнең китәргә ашыкканны күреп, Галимҗан Ибраһимов:

— Мин дә сезнең белән чыгыйм әле, — дип киенә башлады. Ул өстенә кара плащнакидка, башына йомшак салам эшләпә киде. Без калганнар белән саубуллашып чыгып киттек.

Урамга чыккач, Галимҗан абзый бездән:

— Юлыгыз кая таба? — дип сорады.

— Без синең белән бер-ике урам буе барабыз әле, — диде Хөсни. — Син, Галимҗан, мине мондагы яңалыклар белән таныштыр. Кемнәр бар, кемнәр юк?

— Яңалыклар шул, — диде Галимҗан абзый. — Уфага халык күп килә. Петроградтан ачлыктан килә, гаребтән сугыштан качып киләләр. Уфаның икътисади ягы авырая бара. Иптәшләр хәленә килсәк, Фатих Сәйфи-Казанлы белән Абруйны куштык, туй ясадык.

Аннары ул безнең нинди уңай белән Уфага килүебезне сорады. Хөсни аңа:

— Зәйнәп быел җәйне монда укырга уйлый, мин вакытлы эш белән губерна земствосына килдем, — диде. Ул көннәрдә безнең туебыз булачак һәм без аны Сәгыйть

[1] Җиһанша Абдюшев — ул елларда «Галия»дә укытучы.

Рәмиевләрдә үткәрергә уйлаган идек. Яңалык итеп, Галимҗан Ибраһимовка Хөсни шул турыда да әйтте һәм: «Туйның түреңдә буларсың», — диде.

Туйда Галимҗан абзыйның Хөснигә карата ярым шаяртып, җылы, якын иптәшлек мөгамәләсе күрсәтеп сөйләгән сүзләре хәтеремдә калган.

— Иптәшләр, минем гаиләм юклыгы барыгызга да мәгълүм. Шуңа карамастан, барыгыз да шаһит, мин бүген улымны өйләндерәм, — диде ул. (Туйның рәсми бүлегендә ул Хөснинең атасы вазифасын үтәде.) Аннары, җитди төс алып: «Хөсни белән бергә «Галия»дә укыдык, шәрикләр, дуслар идек. Хөснинең укыгандагы тырышлыгы, саф күңелле иптәш булуы һәм башка яхшы сыйфатлары гаилә тормышында да сакланыр дигән ышанычымны белдерәм», — диде.

Аз гына вакытка эш белән генә килгән Хөснинең Уфада тагы бер-ике көн генә торасын белеп, ул:

— Хөсни, син кайтырга ашыкма, бу — адәмнең гомеренә бер килә торган тантанасы. Һич булмаса, тагын бер атна чамасы тор, — диде. — Гомәр әле Уфада, хезмәтең буенча, ул синең начальнигың булырга тиеш. Аны ризалатып булыр, иртәгә аның янына бергә барырбыз.

Туйның икенче көнендә, без яңа күчкән бүлмәгә килеп, Галимҗан абзый Хөснине начальнигы янына алып китте. Гомәр ул вакытларда губерна земствосында мәктәптән тыш мәгариф эшләрен карый торган бүлек мөдире булып эшли иде.

Галимҗан абзыйның баруы тәэсир иткән булса кирәк: «Мондый очракларда исәпләшергә туры килә», — дип, Гомәр Хөснигә ун көнгә ял алырга рөхсәт биргән, һәм июнь ахырларында төбәк китапханә мөдирләре киңәшмәсе уздырылачагын белдереп җибәргән иде.

Хөсни ул елларны биш волостька караган, илледән артык авылга хезмәт күрсәтә торган төбәк китапханәсе мөдире булып эшли иде. Ул бу яңа оештырылып кына килә торган эшкә өзеклек керүенә дә борчыла, тик, үзенең тыйнак табигатьле булуы аркасында, моны белгертмәскә тырыша иде. Аның шундый уйлар белән яшәвен үзенең зирәклеге белән аңлап, Галимҗан абзый җылы сүзләре, киңәшләре белән ярдәм итәргә тырыша иде.

Галимҗан абзый белән без ул көннәрдә еш очраша торган булып киттек. Көн авышкач, вакытны бакчаларда уздыра, Агыйделдә, Димдә көймәдә йөри идек.

Сүз уңаенда, бер көнне Хөсни ана:

— Галимҗан, сиңа дә өйләндерергә вакыт түгелме? — диде.

— Син, Хөсни, минем әни кайгысын кайгырттың. Аның янына кайткач, бетмәстөкәнмәс күңел җылылыклары күрсәткән арада:

— Улым, инде өйләнгәндә дә ярар иде. Ялгыз яшәү ир кешегә авыр бит. Тормыш кирәкләренне кайгыртучы булсын иде, — дип мине өйләнергә вәгазьли. Гаилә тормышының үзенең фәлсәфәсе бардыр, ләкин мин ул хыялдан әлегә ерак торам. Ярый, син уйлаганча барып чыкса, тормыш булыр, ә чыкмаса — муенга әлмәк булыр. Син, Хөсни, үзеңә карата хөкем итмә, синең бөтенләй башка. Сез бер-берегезне озак аңлашкансыз. Мин аңа инде соңга калганмын. Аннан күңел утырырлык кешегә дә очраганым юк, — диде ул. — Яшьләр, сез иртәгә миңа килегез, — дип безне үзенә чакырды.

Ул елларда, ялгышмасам, Галимҗан абзый Вавиловский урамында, ике катлы агач йортның беренче катындагы ике бүлмәле квартирада тора иде. Бүлмәләре бик садә җиһазланган. Зал як бүлмәдә ашау-эчү өчен дә, эшләр өчен дә хезмәт итә торган әйбәт өстәл, берничә венский урындык, буфет-шкаф, тәрәзә янында таралып үскән зур фикус гөле. Эчке бүлмәдә пөхтә генә җыелган бер карават һәм комод күренә. Тәрәзәләр ачык, бүлмәдә һава яхшы.

Без барып кергәндә, Галимҗан абзый язып утырган булса кирәк. Без кергәнне күреп, ачык күңел белән каршы алды. Өстәлдә таралып яткан кәгазь табаклары аның күп яза, зур энергия белән эшли торган язучы икәнен аңлаталар иде. Безгә урын тәкъдим иткәч, ул шул язуларны тәртипләре белән җыеп, газетага төреп бер читкә алып куйды. Өстәлдә таралып яткан китапларны да бер өемгә җыеп, бик житез генә өстәлнең яртысын бушатты һәм шул ук житезлек белән түрдәге ишектән икенче бүлмәгә чыгып китте. Мин өстәл кырыенда ята торган бер китапны алып карарга тотындым. Бу китап мәшһүр революцион-демократ Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» дигән китабы иде. Мин аны Хөснигә күрсәттем.

— Әдәбият укырга да вакыт таба, житез кеше ул, — диде Хөсни. Шул арада Галимҗан абзый соры кәгазьләргә төргән төргәкләр тотып көлә-көлә бүлмәгә керде дә Хөснигә:

— Синең сүзең дөрес, миңа бу мәшәкатьләр белән чуалырга бер хатын-кыз кирәк иде шул, — диде.

Мин кулымдагы китапны куйдым да:

— Әйтегез, нәрсә эшләргә кирәк? — дидем. Ул:

— Ярый алай булса, — дип, миңа йокы бүлмәсендәге комодтан өстәл япмасы алып бирде дә:

— Миңа бу шкафта вак тарелкалар бар, шул төргәкләрдәге азыкларны тарелкаларга үзең белеп сал, — диде.

Түр ишектән бер хатын кайнап торган самовар күтәреп керде. Галимҗан абзый аңа: «Лена, рәхмәт сиңа», — диде.

Тарелкалар чәй ризыклары белән тулды. Чынаяклар куелды. Без өчәүләп чәй эчәргә генә утырган идек, Мәҗит абзый Гафури килеп керде.

— Әйдә, Мәҗит, мактап йөрисең икән, — дип, Галимҗан абзый аны табынга чакырды. Өстәл тирәсе кечерәк бер мәҗлескә әйләнде. Хәл-әхвәл сорашкач, Мәҗит абзый шәһәрдә азык мәсьәләсе авырая баруыннан зарланды. Галимҗан абзый аның зарлануын бик дикъкать белән тыңлап торды да: — Мәҗит, бу сугышның бер очы чыкмый торып, икътисади якның төзәлүен уйларга да ярамый. Аны хәл итә торган чаралар революциягә бәйләнгән. Сугыш революция якынаю факторларының көннән-көн көчәюен күрсәтә. Әнә, Хөснине тыңла, ул халык эчендә яши. Крестьян сугыштан туйган, җир кысырга әйләнеп бара. Эшләргә кеше юк. Эшче көчләр сугыш кырында. Завод-фабрика эшчеләре икмәккә интегә. Димәк, эшче сыйныфының да, крестьян катлавының да сугыштан ризасызлыгы зур. Без, Мәҗит, зур вакыйгалар алдында торабыз,— диде.

— Революцияне көтәбез көтүен, тик аның нәтиҗәсе 1905 елгы белән очланмасын, — диде Мәҗит абзый. Галимҗан абзый аны алай булмасына дәлилләр белән ышандырырга тырышты:

— Бүгенге әзерлек белән ул вакытны чагыштырырга ярамый, Мәҗит. Ул вакытта революция көчләренең оешу ягы хәзерге оешуга караганда бик йомшак иде. Хәзер революция көчләре бик үсте. Менә үзебезне генә алыйк, аң белән дә, каләм белән дә без күп көчле хәзер. Кирәк булса, кулга корал алып революциядә катнашырга һәм аны сакларга да көчебез җитәр. Шулай түгелме, Мәҗит? — диде. Мәҗит абзый, рухланып китеп: «Табигый, шулай!» — диде һәм алар тагын бераз гәпләшеп утыргач:

— Туганнар, сезнең янда очраклы туры килеп утыруым бик мәгънәле булды, китәсе дә килми, шулай да китәргә туры килә, редакциягә барасым бар, — дип, Мәҗит абзый ашыгып, исәнләшеп чыгып китте.

Галимҗан абзый, әле сөйләнгән сүзләрдән әсәрләнгән кебек, бүлмә буйлап, нидер әйтергә теләгәндәй уйланып йөри башлады. Аннары Хөсни алдында туктап:

— Мин, Хөсни, революция башында авылда булырга уйлыйм, ни дисең? — дип сорады.

— Куй, Галимҗан, анда син ничек түзеп ятырсың, синең хәрәкәт сөя торган табигатеңә хилаф нәрсә бит ул, — диде аңа Хөсни.

— Бәлки, шулай да булыр. Революциянең барышы, куәте зур булыр бу юлы. Анда үзеңнең юлыңны, тоткан урыныңны билгеләр өчен, аның юнәлешен белергә кирәк, — диде Галимҗан абзый.

— Авыл хәрәкәткә килгәнче шәһәрдә аның юнәлеше, сыйныфларның тоткан юлы билгеләнеп бетәчәк. Крестьян ничек революцияне каршы алыр гына димәсәң? Син анда бер көн дә тора алмассың, авылда булу, читтә тору авыр булачак синең өчен, — диде Хөсни.

— Бу — мин читтә калам, дигән сүз түгел, анда берәү дә читтә калырга тырышмас, берәүләр революция ялкынында кайнар, берәүләр ялкынны сүндерергә тырышыр. Үлмәсәк — күрербез, — диде Галимҗан абзый.

Ул бераз басып торды да, кинәт исенә нәрсәдер төшкән кебек, буфет янына барды һәм:

— Хөсни, минем монда бераз шәраб бар, без синең белән шуны уртаклашыйк әле, — дип, буфеттан кечкенә генә графин белән эчемлек чыгарып куйды.

— Зәйнәп, син ачуланма, без шәрик белән яшь заманнарны бераз искә төшерик әле. Сиңа күңелсез булмасын, менә, теләсәң, шул альбомны кара, — дип, миңа рәсемнәр альбомын бирде.

«Бераз утырулары» аларның кәефләрен күтәрде. «Галия»дә бергә укыган иптәшләрен искә төшереп, аларның тормышлары турында сөйләшеп утырдылар. Инде көн авышып барганын күреп, мин Хөснине кайтырга өндәдем. Ике көннән соң Дим буена чыгу турында вәгъдәләр куешып, без кайтырга кузгалдык. Галимҗан абзый безне озата чыкканда:

— Зәйнәп, син без бераз кәефләнгәнгә ачуланмыйсыңдыр бит? — диде.

— Юк, Галимҗан абзый, без бит бу көннәрне бәйрәм итеп йөрибез, сезнең эшегезне бүлдереп, вакытыгызны алырга бер хакыбыз да юк,— дип уңайсызлануымны белдердем.

— Анысы өчен борчылма, минем эш сәгатьләрем билгеләнгән, — диде ул.

Ялгышмасам, без Дим буена чыгарга дип билгеләнгән көн, җомга көнгә туры килде кебек. Көймәләр бирә торган станциягә унбишләп кеше җыелган. Алар арасында Фатих Сәйфи-Казанлы, хатыны Зөһрә апа белән Мәҗит абзый Гафури, Сәгыйть Рәмиев тә бар иде. Баштанаяк нәфис ак киемнәргә киенгән мөлаем чырайлы ханымны: «Хөсәен Ямашев сеңелесе Хәдичә», дип таныштырдылар. Тагын ике-өч пар яшьләр бар иде, әмма аларның исемнәре хәтеремдә калмаган.

Без, ике көймәгә утырып, Дим буена киттек. Көймә кузгалып китәргә торганда гына:

— Гафури! Мин бу көймәгә утырам! — дип, Зөһрә апа безнең көймәгә сикереп керде.

Галимҗан абзый:

— Зөһрә, хәзер үк үз көймәгезгә утыр. Югыйсә, барыбызны да батырасың, — дип куркытып, аны кире чыгарга мәҗбүр итте.

Бу кадәр кыю хатынның шул сүздән куркып кире чыгуы менә аптырашта калдырды. Хәдичә ханым белән мин: «Көймәдә урын бар бит, юкка кире кайтардыгыз»,— дип, Зөһрә апаны яклый башлаган идек. Хөсни, Галимҗан абзыйның сүзен куәтләп: «Капитан корабның күпме күтәрә алганын белә, тыныч кына утырыгыз», — дип безнең сүзне кисте.

Аның сере соңыннан ачылды. Мәҗит абзый җинел табигатьлелекне яратмый икән. Шул хәлне белгән Галимҗан абзый, Зөһрә апаның кәефен бозып булса да, Мәҗит абзый хәтерен саклауны артык күргән. Әмма үзара мөнәсәбәт бозылмады, бар да тыныч узды.

Без сокландыргыч матур, ялтырап ага торган Дим елгасына кердек. Ярлары куе агач, үсемлекләр белән капланган. Дим суында агачлар шәүләсе көзгедәге кебек чагыла. Дим буйлап беркадәр баргач, көймәләрне куеп, биек агачлар белән әйләндереп алган алан җиргә туктаттылар. Халык агач күләгәсенә урнаша башлады. Хәдичә ханым белән Зөһрә апа алып килгән азыкларны табынга куярга керештеләр.

Дим буена чыгуны оештыруда башлап йөргән Галимҗан абзый ялның зәвыклы узуы өчен дә зур сәләтлелек күрсәтте. Башлап ул һәркемгә бер эш бирде. Әйтик, Хөснигә уеннар, җырлар оештырырга кушты.

Сәгыйть абзый белән Мәҗит абзый:

— Сез, яшьләр, күңел ачыгыз. Менә без монда үлән өстендә ятып истирахәт кылыйк, — диделәр дә агач ышыгына киттеләр.

Без, яшьләр, бик дәртләнеп уйнадык. Саф һава, матур табигать эчендә узган бу күңел ачу чын бәйрәм төсен алды. Көнебез үзара дусларча, ягымлы мөгамәләләр белән узды. Көнг матур булган кебек, төне дә ай яктысы белән нурланган иде. Дим өсте ай нурында көмешләнеп ялтырый. Су өсте тып-тын. Хөснигә бу матур тынлык бик нык тәэсир итте булса кирәк, ул көйгә салып:

— Тып-тыныч ил, һич исми җил,
Серле, моңлы җәйге төн.
Нәкъ табигать җиргә иңдергән
Бу төнне бар хикмәтен, —

дип үзенең шигырен җырлап җибәрде. Көймәдәгеләр барысы да аның җырын дәвам итүне сорадылар.

Галимҗан абзый:

— Хөсни, я әле, озын көйләрнең берәрсен җырлап җибәр, — диде.

Хөсни көйләрне, бигрәк тә озын көйләрне, оста җырлый иде. Ул «Агыйдел», «Мәдинәкәй», «Ашказар» кебек озын көйләрне җырлап, иптәшләрнең күңелен ачты. Арада кушылып җырлаучылар да булды.

Без Агыйделдәге көймәләр станциясенә килеп җиткәндә, яктыра башлаган иде инде. Дим буенда узган көннең һәм төннең тәэсире барыбызны да бик рухландырган, халыкның таралбсы килми. Кайберәүләр, җәйнең яме беткәнче тагын шулай җыелып чыгарга кирәк, диделәр.

Фатих Сәйфи:

— Аның өчен кемгә булса да туй ясарга кирәк, — диде.

— Галимҗан, хәзер сиңа чират өйләнергә, — дию́челәр дә булды.

Шулай шаяра-көлешә барыбыз да өйләребезгә юнәлдек.

Галимҗан абзый безне икенче көнгә тагын үзенә чакырды.

Без килгәндә, ул язып утыра иде. Хөснинең:

— Галимҗан, без эшеңне бүлдерәбез бугай, — диюенә каршы: «Юк, бүген болай да күп эшләдем. Кичә яхшы ял итүнең тәэсире булса кирәк. Хәзер эшне туктатып торырга да була», — дип, язган язуларын җитез генә җыештырып куйды.

— Син, Галимҗан, укыту эшенә тирән чумгансың күренә. Язарга вакытың да күп калмыйдыр? — диде Хөсни.

— «Галия»дә укыту язуга комачауламый, киресенчә, уңай тәэсир итә. Менә мөгаллимәләр курсында укыту күп вакытны ала. Аны алырга да теләмәгән идем, курслар идарәсе бик сорагач, риза булырга туры килде,— диде Галимҗан абзый. Аннары: — Хөсни, язасыңмы, язсаң нәрсә язасың? — дип сорады.

— Мин, Галимҗан, яна эштә бит, укытканда язарга вакыт кала иде. Хәзер халык арасында эшләргә туры килә. Аның әле оештыру эшләре дә бетмәгән. Лекция, докладлар сөйләргә, аларны әзерләргә вакыт күп кирәк. Язудан ваз кичкәнем юк, тик вакытлыча өзелеп торам, — диде Хөсни.

Икенче көнне Хөсни китәргә җыенды. Ул, миңа киңәш итеп:

— Зәйнәп, укуыңның очына барып чыгарга тырыш. Биел максатыңа ирешмәсәң, соңыннан, теләсәң дә, сиңа мондый иркенлек тимәс, гаилә тормышы катлаулы нәрсә, аны да исеңдә тот, — диде.

Хөснине озатырга җыенып торганда урам як тәрәзәдән:

— Ниҗәл сез? — дигән тавышка әйләнеп карадык. Галимҗан абзыйның курслардан кайтып килешә икән. Хөсни чыгып ишек ачкан иде, Галимҗан абзый: «Мин хәзер киләм», дип, каядыр ашыгып китеп барган. Ул озак тормады, килеп тә җитте.

Якындагы кибеткә тәмәке алырга барган икән. Көлә-көлә тәмәке тартып керә, үзе сөйләнә:

— Икмәксез торып була, тәмәкесез тора алмыйм,— ди.

Без өчәүләп пристаньга киттек. Барып җиткәндә, пароход китәргә кырык минутлап вакыт калган иде. Билет та унай туры килде. Пароход кычкырткач, без чыгарга кузгалдык.

— Я, Хөсни, хәерле сәгать сиңа, изге юл. Хат яз. Хәбәр алышып торыйк, — диде Галимҗан абзый.

Хөсни миңа:

— Зәйнәп, сиңа әйтәсе сүзләремне әйттем, киңәшләремне бирдем, шаять онытмассың, — диде. Һәм без пристаньга чыктык.

Пароход соңгы тапкыр кычкыртып, парларын чәчә-чәчә, кузгалып та китте. Мин пароход күздән югалганчы Хөсни басып торган урынга карап тордым.

Галимҗан абзый:

— Пароход кире килмәс бит, кайтырга уйламыйсыңмы әллә? — дигәч кенә, без аның белән кайтырга кузгалдык.

— Я, Хөснине сагынырсыңмы? — диде Галимҗан абзый, шаяртып.

— Сагынырмын, мин аңа бик ияләшкән идем. Ул бик әйбәт күңелле кеше, кайгырырга бирми, күңелне шат, тыныч тотырга тырыша,— дидем.

Ул минем фикерем белән килешүен әйтте:

— Без 1911—12 елларда Казанда өчәү — Хөсни, Шәһит, мин — яшәдек. Хөсни анда русча укыды, укытучылыкка әзерләнде. Бик авыр көннәре булды, ачыга иде. Шунда аеруча түземлелек, тынычлык күрсәтте. Ач торып уку нәтиҗәсендә шактый вакытлар авырды. Мин аны ул авырлыкны күтәрә алмас дигән идем. Аның тыныч табигате ул авырлыкны да җиңеп чыкты, — диде.

Сөйләшеп кайта торгач, юл кыска күренде. Галимҗан абзый мине квартирама озатып куйды. Минем: «Безгә кермисеңме?» — дип соравыма, ул: «Ашыгыч эшем юк, кергәндә дә ярый», — диде.

Хуҗалар ягында өстәлдә кайнап торган самовар бар иде. Мин ике стаканга чәй ясап алып кердем. Мине укытырга алынган, Петроградтан килгән Софья Алексеевна Гучкова: «Менә шуларны укый торыгыз», — дип, ике китап калдырып киткән иде. Аларның берсе Ушинскийның «Человек как предмет воспитания», икенчесе, Песталоцциның «Воспитание умственное, нравственное, физическое» дигән китап иде.

Галимҗан абзый бу китапларны карап:

— Ул сине киң программа белән укытырга уйлый, күрәсең, — диде.

— Укытырга алынган кешем тирән белемле күренә. Биргәнен алырга тырышачакмын, — дидем мин.

Июнь ахырларында, губерна земствосының чакыруы буенча, Хөсни киңәшмәгә килде. Галимҗан абзый Хөсни килгәч күңелләнеп, җанланып китте. Алар көн дә диярлек күрешәләр, сөйләшәләр иде. Галимҗан абзый аңа язганнарын укый. Хөсни аның язган әйберләре турында үз фикерләрен әйтсә, Галимҗан абзый:

— Син дөрес фикер әйттең бит, — дип, аның белән килешә. Килешмәгән тәкъдирдә язган әйберенең дөреслеген, ышандырырлык дәлилләр китереп, аклый. Мондый фикер алышу моментлары еш була. Алар һәм мәгънәле, һәм күңелле үтә иде.

Галимҗан абзый — Хөсни тәгъбире белән әйткәндә, зур әдип, тирән психолог — кешенең рухи халәтен бөтен нечкәлекләре белән аңлый һәм гаҗәп осталык белән хөкем итә белә иде.

Хөсни озакка килмәгән иде. Киңәшмәләре өч-дүрт көн эчендә бетәргә тиеш. Бер көнне Галимҗан абзый:

— Әйдә, синең килүдән файдаланып, Дим буена чыгабыз. Барыбыз да беркадәр ял итәрлек арыганбыз. Көймәдә бер йөзеп кайту зарар итмәс, — диде. Ул су өстендә хәл җыюны бик ярата һәм файдалы дип таба:

— Табигатьнең матурлыгын суда күрәм, — дия иде.

Көн авышкач, көймә алып, Димгә киттек. Гадәттәгечә, Галимҗан абзый койрыкка утырды, Хөсни ишкәк иште. Димгә кереп беркадәр җир баргач, Галимҗан абзый алда күренгән бер алан җиргә бик төбәп карап торды да:

— Хөсни, син кибән куя беләсеңме? — дип сорады.

— Бәй, Галимҗан, мин авыл егете лә, белмәскә, — диде Хөсни.

— Алай булгач, иш сул якка! — дип әйтүе булды, көймәне зырылдатып борып китереп, ярга да терәде.

Ярга чыктык. Көймәне бәйләделәр.

— Әйдәгез, әнә теге печәнчеләргә булышабыз, — диде Галимҗан абзый.

Бер карт белән яшүсмер малай печән кибәне салалар иде. Яннарына килдек, исәнләштек. Галимҗан абзый:

— Кая, карт, арыгансыздыр, бераз булышыйк сезгә, — дип кулына сәнәк алды һәм:

— Син, Хөсни, печән бирерсең, мин өеп торырмын, — дип, яртылаш салынган кибән өстенә менеп тә китте.

Миңа да эш табылды. Кипкән печәнне тырма белән кибән төбенә җыеп китереп торам. Хөсни сәнәк белән кибән өстенә печән бирә. Галимҗан абзый бик житезлек белән кибән өеп тора. Шулай эшли торгач, зур гына кибән өчлап куелды. Картның

бик кәефе килде. Бигрәк тә аңа Галимҗан абзыйның печән кибәнен оста итеп, кырыйларын тигезләп очлавы ошады. Бу аларның соңгы кибәннәре икән. Яшүсмер малай бәрәңге пешерде, чәй кайнатты. Бабай безгә ихлас күңелennән рәхмәт әйтеп, бәрәңге ашап, чәй эчәргә тәкъдим итте. Хөрмәтне кире какмадык. Чәй эчкәндә бабай бу печәнлекне өч ел рәттән арендага алып, малларына кышка печән әзерләгәнен сөйләде.

Ике көннән Хөсни китте. Август урталарында имтихан комиссиясе эшли башлады. Мин имтиханнарны әйбәт тапшырдым. Бусы минем тормышымда яңа куаныч булды.

Мин кайтып китәргә йөргән көннәрдә Галимҗан абзый да, курсларда эшләрен бетереп, Казанга барып кайтасы барлыгы турында әйтте. Кызлар мәктәбендә укытучы якын танышым Гөлсем Еналиева да минем белән кайтмакчы иде.

Галимҗан абзый:

— Мин сезнең белән барырмын, ахры, — дигәч, без бик шатландык.

Минем юлым кыска, Гөлсемгә Казанга кадәр аның белән бергә барырга кирәк иде.

Без пароходка кереп урнашкач, Галимҗан абзый янына бер төркем яшьләр килеп керде. Берсе кулына мандолина тоткан. Галимҗан абзый:

— Шәехзадә, нишләп йөрисең, кая булса китеп барасыңмы? — дип сорагач, ул:

— Галимҗан абзый, сине Казанга китеп барасың дип ишеттем, менә музыка белән озатырга килдем, — диде.

Шаярып сөйләшергә ярата торган бу кешене Галимҗан абзый безгә: «Шагыйрь Шәехзадә Бабич», — дип таныштырды.

Без Шәехзадәнең мандолинада уйнавын үтендек. Ул бик оста итеп, төрле көйләр уйнап күрсәтте. Эч катырып көләрлек сүзләр сөйләп, безнең күңелне ачты. Без аңар:

— Әйдәгез, безнең белән бергә пароходта барыгыз, сезнең белән бару күңелле булыр, — дигәч, ул:

— Юк, анысы булмый, минем әти, хатын-кыздан ерак булырга кирәк, алар оҗмахтан да кудырта торган халык, ди иде. Менә хатын-кызлар арасында Галимҗан абзый гына курыкмый йөри. Бөтен курслары белән мөгаллимәләр пароходка төялсә дә, шулар арасында курыкмый барачак бит, — дип Галимҗан абзыйны да көлдерде. Аннары: — Әйдә, каютаңны күрсәт әле,— дип Галимҗан абзыйны каютага алып кереп китте. Пароход кычкырта башлагач, озатучылар ашыга-ашыга пристаньга чыктылар. Шәехзадә дә бергә килгән иптәшләре белән чыкты. Аннары безнең янга килеп мандолинада уйнарга тотынды...

Без төн уртасына кадәр палубада утырдык. Мин әле яңа гына үзем укып чыккан бер романны[1] кулымда тотып, шуның тәэсиренә чумып утыра идем, Галимҗан абзый ул китапны миннән алды да:

— Син бүген укый алмассыңдыр, Зәйнәп. Мин аны йокы алдыннан караштырыйм әле, — диде.

— Галимҗан абзый, бу китапны укый башласагыз, аңардан аерыла алмассыз. Ул роман һәм борынгы Мисырның тарихы да. Бер укый башлагач, бик кызыксынып укыйсың,— дидем.

— Син алай бик кызыксындыргач, укырмын да, — диде ул һәм: — Син, Зәйнәп, иртән Бирскида буласыңдыр инде. Әйтәсе сүзләреңне бүгеннән әйтеп куй, иртән өлгермәссең, — дип шаяртты.

— Әйтәсе сүзем шул: хәерле төн сезгә, — дидем мин.

Иртән сәгать ун тирәләрендә без Бирскига килеп җиттек. Безне анда Хөсни каршы алды.

Галимҗан абзый белән Гөлсем мине озата чыктылар. Пароход йөк бушатып, йөк алып Бирск пристанендә бер-ике сәгать торачак диделәр. Хөсни квартирага пристаньга якын гына туктаган икән. Без Галимҗан абзый белән Гөлсемне дә үзебез белән бергә алып киттек. Хуҗа хатын бик хөрмәтчән кеше икән, ул безне бик яхшылап сыйлап, кыстап-кыстап чәй эчерде. Аннары без кунакларны пароходка озатып куйдык. Галимҗан абзый киткәндә:

— Иптәшләр, хат языгыз, Казанга да, Уфага да хатларыгызны көтәм! — диде.

1917 елгы февраль революциясе чорында, май аенда, Хөсни делегат булып Мәскәүгә беренче мөселманнар съездына барды. Анда ул Шәһит Әхмәдиевне дә, Галимҗан абзыйны да очраткан. Ул аннан зур дәрт белән кайтты. Халык арасында эшләүнең планнарын үзгәртте.

Революция тудырган вакыйгалар бик тиз үзгәрә тордылар. Газеталарда сәяси платформалар турында хәбәрләр, бәхәсләр яза башладылар.

Учредительное собраниега сайлау вакыты якынлашу белән халык арасында аңлату эше нык көчәйде. Бөтен сәяси партияләр бу сайлауларга әзерләнәләр, үзләренең вәкилләрен җибәрергә тырышалар. 1917 елның җәй ахырларында Уфада җыелган бер җыелыш, берниди нәтиҗәгә ирешә алмыйча, җәнҗал белән тарала. Җыелыш Уфа губернасы мөселманнары исеменнән учредительное собраниега сайланачак вәкилләр-

---

[1] Немец язучысы Эберсның рус телендә басылган «Мисыр фиргавене кызы» дигән роман иде ул.

нең кандидатларын күрсәтеп, исемлеген төзү өчен чакырылган була. Ләкин анда нинди платформаны нигез итеп алу турында зур гауга чыга. Җыелышка ике платформа тәкъдим ителә: берсе Мәскәүдә булып үткән бөтенроссия мөселманнарының съездында, икенчесе Казан съездында чыгарылган карарлар. Уфада чыккан җәнҗал нәтиҗәсендә, җыелышның дәвамын Бирскига күчерделәр. Шул уңай белән Галимҗан абзый да Бирскига килгән иде.

Бик шау-шулы үткән ул җыелыш утырышларына мин дә баргаладым. Казан платформасын яклап сөйләүчеләр күбрәк муллалар, кулаклар, морзалар. Бу группаның башында Гомәр Терегулов һәм, аның кебек, үзен либеральный зыялы дип атаган кешеләр тора иде. Үз көче белән көн күрүчеләр файдасын яклаган группалар башында революция демократия теләкләренә ирешкәнче туктамаячак дигән социалистлар тора иде. Галимҗан абзыйның бер чыгышында сөйләгән сүзләреннән түбәндәгеләр хәтеремдә калган:

— Дөньяда социализм тугангача, бер сыйныф көн-төн эшләп тә ачлы-туклы тору, икенче бер груһ башкаларның маңгай тирләрен агызып, йөрәк канын суырып үзе рәхәттә яшәү кебек гаделәтсезлекләр беткәнгәчә, бу көрәшләр барачак һәм барырга мәҗбүр. Үз көче белән көн күрүчеләр өчен икътисади-сәяси мәсьәләләрдә ахыр теләк — социализм булырга тиешле. Шул теләк булмый торып, көрәш мәйданыннан чигенү мәсләккә каршылык, хыянәт булачак, — диде ул.

Бирскида җыелган җыелыш шул зур гаугалардан соң учредительное собраниега сайланырга тиеш булган вәкилләрнең исемлеген төзү белән бетте. Ул җыелыш буржуа вәкилләренең җиңелүен күрсәтте, чөнки, хәтеремдә калганча, алар үз тарафларыннан фәкать бер генә кандидат үткәрә алдылар.

1918 елны Хөснине Бөре (Бирск) мәгариф бүлегенә алдылар. Мәгариф эшләрен киң җәелдерү революциянең төп бурычы итеп куелган иде. Тик ул мәсьәлә вакытлы хөкүмәт заманында күбрәк сөйләнү белән уза. Практик чаралар бик йомшак, аз эшләнә иде.

1919 ел. Хөсни мәгариф эшендә дә крестьяннарның совет яклылары арасында политик эш алып бара иде. Ул шул чорларда бик авырлык белән генә кулына төшкән В. И. Ленинның «Ерактан хатлар»ын укый һәм аны аерым группаларда пропагандалый, «Апрель тезислары»нда куйган иң мөһим мәсьәләләрне аңлата иде. Ләкин аның большевиклар партиясе, Совет власте файдасына яшерен эш алып баруы куштаннар аркылы Колчак контрразведкасына (алар Бирскины алгач) ирештерелгән булып чыкты. Шулай итеп, Хөсни башында патша армиясенең ак офицеры Госман Фәезханов торган контрразведка кулына эләкте. Хөснине кулга алгач, Фәезханов ике агенты белән килеп, бездә тентү ясады. Тентү аларга киракле нәтиҗәне бирмәде. Тик ул рәсемнәр арасыннан Галимҗан абзыйның рәсемен табып алып, артына «Г. Ибраһимов лидер татарских большевиков» дип язып калдырды һәм:

— Ул кеше хәзер безнең кулда, аңар суровая расправа булачак! — дип, йөрәк яргыч сүз белән куркытып китте.

— Кәримовны нишләп тотасыз? Аның бер гаебе дә юк бит, — дип соравыма каршы:

— Сез ничек, аның хатыны була торып, белмисез? Ул большевиклар файдасына эшләп, советларны яклап, социализм идеясен таратып яткан кеше монда. Хәтерегезгә төшерегез әле, — диде.

Контрразведкага бу кадәр төгәл житештерерләр икән. Дөрес, Хөсни Бирск шәһәре управасы залында «Социализм — иң бөек принциплар нигезендәге җәмгыять төзелеше» дигән темага лекция сөйләгән иде.

Ике айдан артык төрмәдә ятып, анда тиф белән авырый башлагач, Фәезханов Хөснине чыгарды. Әмма Хөснигә хәзер Бирскида калу куркыныч иде. Төрмәдә үзе белән бергә яткан Миронов фамилияле бер рус иптәшенең үгетләве һәм ярдәме белән Хөснигә Бирскидан китеп торырга туры килде.

Июньнең (1919 ел) соңгы атналары иде бугай. Урамга караган тәрәзәләрне ачып, зал якны җыеп йөри идем, берәү таяк очы белән тәрәзәне шакылдатып, карлыккан тавыш белән:

— Хөснетдин өйдәме? — дип сорады.
— Ул өйдә юк, кем бар? — дидем.
— Җәмәгате дә юкмы?
— Җәмәгате өйдә.
— Булса, чыксын әле.

Мин, бу кем икән дип, тәрәзәдән карадым. Сәләмә генә киенгән бер авыл кешесе, йөзен күреп булмый, эшләпәсе каплый иде. Мин йөгереп урамга чыктым. Мине чакырган кеше, капка төбендәге эскәмиягә утырып, кулындагы чыбыркы сабы белән җиргә сызгалап утыра. Башын игән, йөзен күреп булмый.

— Сез кем буласыз, ни йомышыгыз бар? — дидем мин.

Ул әкрен генә башын күтәреп, йөзе белән миңа борылды. Мин гаҗәпләнеп, каушаган хәлдә:

— Галимҗан абзый?! Күземә күренәсезме, нишләп болай, каян килеп чыктыгыз? — дидем.

Ул төсен үзгәртми генә әзрәк карап торды да көлеп җибәрде.

— Менә сезгә килдем. Танымассың дип уйлаган идем, шөбһәсез таныдың бит, — диде. — Исәнме, Зәйнәп. Башта күрешик, — дип, миңа тузаннан каралып беткән кулын сузды.

Аның болай төсен, өс-башын үзгәртеп безгә килүе башка сыймаслык бер хәл иде. Бөтен кыяфәте качып йөргән кешегә охшый. Сакал-мыек үскән, бите юл тузаны белән капланган. Тик үткен күзләре генә ялтырап карыйлар. Өстенә сәләмәләнеп беткән кыска бишмәт, аягына кыйшаеп, җыерылып каткан иске күн итекләр кигән. Башында каралган киез эшләпә. Кулында чыбыркы.

— Әгәр күзләрегезне дә үзгәрткән булсагыз, һич танып булмас иде. Әйдәгез, Галимҗан абзый, өйгә керегез, үзебез генә өйдә, — дидем дә, үзем алдан юл күрсәтеп керергә дип, капкага борылдым. Ул, мине туктатып:

— Зәйнәп, өегезгә кермим, монда сөйләшеп утыру да минем өчен уңайсыз. Вакытың булса, әнә Агыйдел буена төшик, шунда бераз кирәкле сүзләрне сөйләшербез, — диде.

Күрәсең, керергә ярамый торган берәр хәл бардыр дип, мин аны артык кыстамадым.

— Ярый, алай булгач хәзер чыгармын, — дип, тиз генә өйгә кереп киттем. Мин дә, шәһәрдәге танышлардан яки шәкертләремнән берәрсе очрау ихтималын исәпкә алып, әниең зур кәшимир шәлеч бөркәнеп, капланыбрак чыктым. Ишек алдында уйнап йөри торган кечкенә энем Әхмәтне җитәкләп: «Әйдә, Идел буена төшеп менәбез», — дип алып киттем.

Без урамга чыкканда, Галимҗан абзый чыбыркысын иңенә салып, әкрен генә атлап, Агыйделгә таба китеп бара иде. Ул мине баштанаяк карап: «Абыстай булдыңмы? Тик чирбигең генә абыстайларныкы түгел», — дип, минем биек үкчәле аяк киемennән көлде. Мин ашыгуым белән аларны салып, алыштырырга онытканмын. Юлда без акрын гына сөйләшеп бардык. Ул Хөсни турында сорашты һәм тулырак сөйләвемне сорады. Кайчан кулга алынуы, нәрсәдә таепләүләре белән кызыксынды.

— Советлар файдасына эшләүче большевиклар калдырган кеше, дип карадылар. Кыш көне сезнең Әминев белән чигенеп китеп барган уңайда Бирски аркылы узуыгызны һәм бездә туктавыгызны кемдер күрсәткән, — дидем.

Хөсни тиф белән авырганда: «Галимҗанны коткарырга кирәк, аны атарга әйтәләр», — дип саташып ятканын сөйләдем.

Галимҗан абзый көлеп:

— Моңа чаклы андый хәлгә туры килгәнем юк. Аларның үзләрен тиздән каты җәзага тартырлар дип ышанам, — диде.

Хөснинең Уфага китеп күздән югалып торуын ул бик яхшы булган дип тапты. «Мотлак, тагын алган булырлар, артык дөнья күрсәтмәсләр иде», — диде.

Без Агыйдел буена төшкәч, кеше күзеннән еракkарак китеп, өелеп торган ташлар өстенә барып утырдык.

Җәй урталарында гына була торган тын, матур, җылы кояшлы көн иде. Агыйдел, күзгә кебек ялтырап, соклангыч күренеше белән күңелгә рәхәт биреп тора. Аның тынычлыгын әле күптән түгел генә булып үткән туп, мылтык тавышлары әйтерсең, бозмаган. Хәер, Бөре бу көннәрне инде Кызыл Армиянең ерак тылы булып калган иде. Галимҗан абзый бераз Иделгә карап торды да:

— Менә бу матурлыкны калдырып китүе дә бик җәл, ә вакытлыча китәргә туры килә, — диде.

Мин әле һаман аның төсен, өс-башын үзгәртеп нинди максат белән йөрүен белми идем.

— Галимҗан абзый, сез нишләп болай йөрергә уйладыгыз әле? — дип сорадым.

Ул нәрсәдер уйлап үз-үзенә көлде. Аннары:

— Колчак тылына китеп барам. Хәер-фатиха бирәсеңме? — диде.

— Шаярып сөйлисез бит. Анда нәрсә бар? Тотып алырлар үзегезне, Фәезханов кулына эләксәгез — котыла алмассыз, «сурово расправиться» итәр, — дидем.

Ул җитди төс белән:

— Юк, Зәйнәп, чыннан әйтәм, «сәфәрем» шул якка. Син беләсең, мин әдип кеше, шуның белән бергә революционер әдип. Ике сыйныфның каты, канлы көрәше бара. Бу зур тарихи көрәш. Мин аны дошманның тылына, контрреволюциянең эченә кереп үз күзем белән күрәсем килә. Колчак тылы контрреволюциянең иң дәһшәтле, кайнап торган учагы. Шуны күзәтеп, күреп кайтырга уйлыйм, — диде.

— Ярый ла кайта алсагыз, ә кайта алмасагыз? Фронт линиясендә үк тотсалар, харап итәрләр бит үзегезне, — дидем.

— Иншалла, андый нәрсәгә очрамам дип беләм. Гомерем бетеп, кайта алмасам, чикне чыгып китәр алдыннан мине күргәнеңне сөйләрсең иптәшләргә. Тик хәзергә беркемгә бернәрсә сөйләмә. Хәтта Хөснигә дә язма, хатыңның икенче кеше кулына төшүе мөмкин, — диде.

Мин кушлап ике бармакны күтәрдем. Бер француз язучысының язуына караганда, Франциядә «абсолютизм»га каршы көрәшүче яшерен оешма членнары, сер саклау, ышаныч билгесе итеп, уң кулларының ике бармагын күтәрә торган булганнар. 1916 елны ул китапны мин Галимҗан абзыйдан алып укыган идем. Шунлыктан Галимҗан абзый минем бу ишарәне бик тиз аңлап алды һәм, кәефе килеп көлде дә:

— Урынлы искә төшердең,— диде.— Шулай булгач,— диде аннары Галимҗан абзый, — мин сиңа ачыграк аңлатыйм: минем бу сәфәрем мәркәз белән рәсмиләштерелгән. Кызыл Армиянең политбүлекләренә фронтны кичеп чыкканда миңа ярдәм күрсәтергә әмер бар. Теге якка чыккач, анда инде үземә таянырга туры киләчәк.

Мин аңа:

— Галимҗан абзый, бәлки, бу ниятегездән кайтырсыз, бик куркыныч юлга чыккансыз бит, — дигән идем, ул:

— Тәвәккәлләп чыккан юлдан кире чигенү юк. Ул бик тирән уйланылган чара, — дип җавап бирде.

Ул үзенең болай үзгәреп авылдан чыгып китүенә инде байтак вакытлар узуын, моңарчы качып бара торган Колчак армиясе әзеннән аның халыкка карата эшләгән җинаятьләрен күзәтеп килгәнлеген сөйләде. Чыннан да аның бу кадәр каешланып каралган өс-башы, тузан баскан сакал-бите, йөзендәге арыганлык билгесе, газап чигеп байтак вакыт юлда булуын күрсәтеп торалар иде. Сөйләвенә караганда, башта ул үзе авылдан чыгып киткәндә күреп калган туганнары белән чикләнергә, башка кешегә күренмәскә уйлаган. Әмма юлда фикерен үзгәрткән, берәр сер сакларлык, югалып калсам иптәшләремә хәбәр итәрлек кешегә күренергә кирәк, дигән уйга төшкән. Шул ният белән, бара торган юлыннан зур борылыш ясап, Бирскига килгән икән.

— Хөснине очратсам, яхшы була иде, ярый, сине очратуыма да шатмын, — диде ул.

Ул безнең семьяда кемнәр бары белән кызыксынды [1].

— Семьягыз ул кадәр зур булгач, матди ягыгыз ничек соң? — дип сорады.

Мин тормышыбыз ярыйсы гына булуын, революцион комитет элекке эш урыныма кайтаруын, айлык эш хакымны түләвен сөйләп бирдем. Аннары уңлап шәкерткә хосуси дәресләр дә бирүемне әйттем.

Бу хәбәрем аны бик канәгатьләндерде булса кирәк.

— Бик яхшы, югалып калмагансың икән. Моның өчен сиңа дусларча рәхмәт, — диде ул.

— Моннан кайчан китәргә уйлыйсыз, Галимҗан абзый? — дидем мин, байтак сөйләшкәч.

— Кич, караңгы төшкәч китәргә ниятем.

Мин аны:

— Алай булгач, Галимҗан абзый, безгә килеп, кайнар аш ашап, чәй эчеп хәл җыеп китәргә дә өлгерерсез бит, — дип, безгә килергә өндәдем. — Шикләнмәгез, безнең өйдә үз семьябыз гына, — дип бик кыстагач, ул бераз уйланып торды да:

— Ярый, сез кечкенә егет белән кайта торыгыз, мин озакламам, килермен, — дип калды.

Озак та үтмәде, Галимҗан абзый ачык ишектән:

— Хөснетдин шушында торамы? — дип килеп тә керде.

Без аны зал якка кертеп җибәрдек. Ул азрак уңайсызланып торды да, бишмәтен салып, урындыкка куйды. Каралып беткән күлмәк өстеннән иске, җиңсез казаки кигән, эшләпәсен салгач ялтырап каткан түбәтәе күренде. Боларны күреп мин:

— Галимҗан абзый, артист булсагыз да бу кадәр килештереп киенә алмас идегез крестьянча, — дип көлдем. — Кулларыгызны юасызмы? — дип сорагач, ул:

— Юк, чайкыйм гына, — диде.

Өстәл янында зур диван тора иде, шуңар мин мендәр китереп салдым, ятып торыгыз, дидем.

Үзем шул арада аш урыны әзерләдем. Әни пешергән ашны да, башка ризыкларны да Галимҗан абзый бик яратып ашады. Аннары мин аны, хәзер хәл җыеп ятып торыгыз дип, үзен генә калдырып чыктым. Ул караңгы төшкәнче шунда хәл җыеп ятты. Аннары:

— Миңа китәргә рөхсәт ит инде? — диде.

— Туктагыз, чәй эчегез инде, — дип, мин тиз генә чәй әзерләдем. Чәй эчеп туйгач, ул миңа:

— Зәйнәп, бик рәхмәт хөрмәтегезгә, мин бүген чыннан да ару гына хәл җыйдым. Монда килеп, сине күреп, яхшы иттем. Хөсни дә өйдә булса, аны очратып китүем тагын да яхшы була иде, хәерле булсын. Үзен күргәч, Хөснигә сәлам әйт, аңа исәнлек телим. Сез Уфага күчәргә тырышыгыз, — диде. Һәм: — Зәйнәп, сиңа әйтә торган сүзем шул. Мин шушы китүдән фронт линиясен кичәргә юл тотачакмын. Бу якта соңгы күргән кешем булып син каласың, гомерем бетеп, үлгән хәбәрем ишетелсә, иптәшләргә мине күреп калганыңны сөйләрсең. Солтанморатка әнигә хат язарсың. Минем монда булып китүемне хәбәр итәрсең, — дип адресын өйрәтте.

— Үләргә җыенмагыз, исән-сау йөреп кайтыгыз. Әнкәгезгә минем кулым белән андый хатлар язарга насыйп булмасын, — дидем мин.

Ул минем белән исәнләшеп, тагын бер мәртәбә:

---

[1] 1918 елның җәендә Астраханьнан кунакка сеңелләрем, энеләрем белән әни килгән иде. Чехлар фетнәсе башланып, алар бүленеп калдылар. 1919 елны гына китә алдылар.

— Хөснигә сәлам әйтерсең, — дип чыгып китте.

Мин озата чыкмадым. Урам тыныч микән дип тәрәзәдән карадым. Тирә-якта кеше күренми, төн җылы, күктә йолдызлар җемелдәшә иде. Күнелемнән Галимҗан абзыйга хәерле юл, исән йөреп кайтуын теләп калдым.

* * *

Сентябрьнең соңгы атналары иде булса кирәк. Хөсни күтәренке рух белән эштән кайтып керде дә:

— Зәйнәп, Галимҗан кайткан, бүген кич безгә килә, — диде.

— Я, хода! Моны ишетер көн дә җитәр икән, — дидем. — Ул мина кайгылы бурычлар йөкләп киткән иде, бик яхшы булган кайтуы!

Сәгать сигезләрдә Галимҗан абзый килде. Мин аны куанып каршы алдым.

— Син, Зәйнәп, әллә чынлап та мине үләр дип уйлаган идеңме? — диде ул.

Яманны уйла, яхшыны көт, ди халык мәкале. Икесен дә уйлый идем. Колчак армиясе, аның контрразведкасы безгә бик таныш иде бит.

— Мин, Галимҗан абзый, сезгә гел изге теләктә булдым, әнә Хөсни әйтсен моның дөреслеген! — дидем.

— Дөрес әйтә ул, Галимҗан, — диде Хөсни.

— Рәхмәт сиңа, Зәйнәп, яхшы теләгең өчен, — диде Галимҗан абзый һәм Хөснигә Колчак армиясе тылында күргән хәлләр, вакыйгалар турында сөйли башлады.— Хәтерендәдер, Хөсни, 1918 елны мин Шәһит Ходайбирдин белән пароходта китеп барганда провокатор Вәгыйз Нәүрузовны Бирскида ЧИК ка биреп калдырган идек. Аны мин бер генә түгел, ике мәртәбә кулга алдырдым. Ә Петропавылда шул эткә очрап, харап була язганнан калдым. Сатучылык шаһадәтнамәсе алу нияте белән Петропавыл казначейтвосына кереп, кайсы тәрәзәгә барырга дип каранып торганда, шунда эшләүчеләрнең берсе: «Баш киемеңне сал!» — дип кычкырды миңа. Карасам, алдагы стенада Николай патша рамкасына Колчак портретын куйганнар. Эшләпәне салырга тотынган идем, үземнән бер җиде-сигез адым җирдә Вәгыйз Нәүрузовка күзем төште. Тиз генә борылып чыгып киттем, язмыш коткарды үч алудан, танымады ул мине.

— Галимҗан абзый, сезнең исән-сау кайтуыгыз мине Мөхәсәнә абыстайга күңелсез хат язудан коткарды бит, шуңа сөенәм әле! — дидем мин.

— Әни карчык янына кайтып килергә уйлап торам әле, аны тынычландырып килергә кирәк, — диде Галимҗан абзый. Аннары, Хөснигә борылып: — Шулкадәр күп материал җыелды, Хөсни, аларны тәртипкә салып чыгарга гына да бик озак вакытлар кирәк булачак. Ул бик күләмле хезмәт булырга тиеш, — диде.

Алар, үзара сөйләшеп, ярты төнгә кадәр утырдылар ул кичне.

—◆—

# *Әдипнең телеграммалары, яңа хатлары*

*14 апрель, 1919 ел, Казан.*

Милләтләр эше буенча Халык Комиссариатына, Үзәк Татар-Башкорт комиссариатына, Үзәк Бюрога

Безнең нәшрият каршында коммунистлар комитетының мөселман секциясе оештырылды. Комиссиягә миннән тыш Исхак Рәхмәтуллин, Шәһид Әхмәдиев, Вәли Шәфигуллин... кертелде. Безне раславыгызны үтенәм, эшкә керешәм. Кичекмәстән, схема буенча тиешле сумманы телеграфлавыгызны, шулай ук халык комиссариаты мәгарифе сметасын тизләтүегезне үтенәм. Гомумән, нәшрият эше коточкыч хәлдә. Әгәр озак тоткарласагыз, көзгә татар мәктәпләре дәреслекләрсез, укытучылар күрсәтмәләрсез, халык массалары китапсыз калачак. Барлык җирле совет оешмалары фәнни-популяр һәм агитацион китаплар һәм журналлар юклыктан зарлана. Бердәнбер татар журналы «Мәгариф»нең, кирәкле средстволар җитмәү аркасында, чыгудан туктавы тирән борчылу тудыра. Кичекмәстән журналны чыгара башларга кирәк. Гомумән, татарларның нәшрият эше бик авыр хәлдә.

*Адресым: Зур Мещан һәм Евангелистлар почмагы, 41.*
*Ибраһимов.*

---

**РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк Бюросы 1918 ел азагында Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының нәшрият бүлеге мөдирлегенә Галимҗан Ибраһимов кандидатурасын тәкъдим итә.**

**Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының нәшрият эшен яхшыртуга юнәлдерелгән һәм коммунистлар партиясе тарафыннан үзенә тапшырылган бу эшне Г. Ибраһимов зур җаваплылык тоеп, бик тырышып башкарырга керешә. Милләтләр эше Халык Комиссариатының 1919 елның 3 апрелендә үткәрелгән утырышында Г. Ибраһимов Үзәк Татар-Башкорт комиссариатының нәшрияты эше турында доклад ясый. Аның тәкъдиме буенча. Үзәк Татар-башкорт комиссариаты нәшриятын Казанга күчерергә карар кылына. Г. Ибраһимовның Казандагы татар-башкорт буржуазиясе кулындагы типографияләрне һәм китап басу средстволарын конфискацияләү һәм национализацияләү турындагы тәкъдиме дә утырышта яклау таба. (ЦГАОР, 1318 фонд, 1 опись, 1 эш, 113 бит.)**

**Милләтләр Халык Комиссариаты Г. Ибраһимовка мандат бирә. Ул мандатта җирле советлар депутатларына һәм башка оешмаларга Г. Ибраһимовка һәрьяклап булышлык күрсәтергә тәкъдим ителә. Г. Ибраһимовның РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары Коммунистик оешмаларының Үзәк Бюросы һәм Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты тарафыннан бирелгән мандатлары да була. Г. Ибраһимов, үзенә бу мандатлар бирелүгә озак та үтмәстән, нәшрият эшләренең торышын тикшерә һәм әлеге үзәк оешмаларга шушы телеграмманы җибәрә. Телеграмманы редакциягә Р. Хәйретдинов китерде, барлык аңлатмаларны ул язды.**

*20 август, 1918 ел, Мәскәү.*

Астрахань хәрби мөселман комиссариатына

Чын күңелдән тирән кайгыгызны уртаклашабыз. Ип. Туйбахтинны ерткычларча үтерүче контрреволюционерлардан һәм башка намуслы революционерлар тормышына кул сузучылардан каты рәвештә канлы үч алыныр. Революцион демократия акгвардиячеләр фетнәсенең тамырын кисеп ташлар. Делегат итеп вәкил җибәрәбез.

Комитетның председателе урынбасары: *(Ибраһимов)*

Секретарь: *(Гайнуллин)*

---

**1918 елның 15 августында Астраханьда контрреволюцион фетнә була. Шуннан файдаланып, Астрахань татар буржуазиясе җирле мөселман комиссариатын туздырып ташлый һәм комиссариатның председателе булып эшләгән татар революционеры Касыйм Туйбахтинны үтерә. Галимҗан Ибраһимовның шул уңай белән Астраханьга җибәргән бу телеграммасын редакциягә архивтан (ЦГАОР, 1333 фонд, 1 опись, 12 эш, 25 бит) Риф Хәйретдинов табып китерде.**

*2 октябрь, 1925 ел, Казан.*

Мөхтәрәм Василий Владимирович,

Сезгә Татарстан җөмһүриятен өйрәнү буенча кайбер материалларны һәм «Безнең көннәр» исемле үземнең бер китабымны җибәрәм.

Моннан ары Тат. җөмһүриятнең татар һәм рус телләрендәге барлык басмалары, шулай ук үземнең 1925 нче елга хәтле һәм аннан соң нәшер ителгән хезмәтләрем эзлекле рәвештә җибәрелеп торачак.

Сезнең алмашуны (әсәрләрегезне — М. Г.) бу адрес буенча җибәрүегезне үтенәм: Казан, Наркомпрос, Ибраһимовка (махсус).

Сәлам белән: *Г. Ибраһимов.*

---


**СССР Фәннәр Академиясе архивының Ленинград бүлегендә мәшһүр ориенталист академик В. В. Бартольдның шәхси фондында (68 фонд, 2 опись, № 104) Г. Ибраһимовның бер хаты саклана. Хат «Татарстан социал советлар җөмһүрияте Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге рәисе» диган татарча һәм шундый ук эчтәлекле русча грифлы бланкка әдипнең үз кулы белән русча язылган.**

**Документ, кечкенә күләмле булуга карамастан, Г. Ибраһимовның В. В. Бартольд белән эшлекле һәм дусларча мөнәсәбәттә булуын күрсәтә ала. Хатны журналга М. Госманов әзерләп тапшырды.**

*10 сентябрь, 1926 ел, Казан.*

Габдулла Гыйсмәти[1] иптәш!

Казанда чыга торган «Безнең юл» журналы партия Үзәк Комитетының матбугат бүлеге тарафыннан бөтен СССР татарлары өчен уртак бер әдәби-гыйльми журнал ителеп танылгандыр. Шулай булса да, Башкортстан эчендәге татарлар арасында мо-



Г. Ибраһимовның 1930 елның 5 июлендә Ялтадан Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмоваларга җибәргән хаты.

ңарчы бик аз таралды. Сездәге татар көтепханәләре, татар мәктәпләре боны ала алмыйлар. Яңа хуҗалык [елы] керү уңае белән Сез бу хакта чара күреп, журналның таралуы — ягъни Наркомпрос буенча үз учреждениеләрегезгә таралуы, абунә язылуы хакында берәр нәрсә эшләсәгез иде. Юкса, аңдагы татарлар мәхрүм калалар. Журнал да уңайсыз бара.

Казанда исәнлек. Бер көе эшләп ятабыз. Үзең ник бер дә Казанга килеп чыкмыйсың? Иптәшләргә сәлам.

Хөрмәт белән:
*Галимҗан Ибраһимов.*

---

Хатның оригиналы Башкортстан Үзәк дәүләт архивында (Р-798 фонд, 2 опись, архив № 1792) саклана. Хатны Татарстан Язучылар союзына филология фәннәре докторы Касыйм Әхмәр табып җибәргән, журнал редакциясенә Афзал Шамов тапшырды. Төшеп калган сүзләр квадрат җәяләр эченә алынды.

[1] Габдулла Гыйсмәти бу елларда Башкортстан Мәгариф халык комиссариатында, гомеренең соңгы елларында Башкортстан статистика идарәсенең начальнигы булып эшләгән. 1937 елда һәлак булган.


*11 апрель, 1929 ел, Ялта.*

Хөрмәтле Петр Семенович [1]!

Сезне бер мәсьәлә буенча борчырга мәҗбүрмен. Бүген шушы хат белән бер почтада минем хатыным Мөхәммәдова-Ибраһимова Өммегөлсем Даутовна әдәбият буенча читтән торып уку бүлегенә (әдәби формалар теориясе циклы) гариза һәм башка кирәкле кәгазьләр җибәрде.

Аның татар матбугатында эшләү буенча беркадәр тәҗрибәсе бар. Гимназия һәм Казан университеты медфагының 3 курсын тәмамлады. Ләкин Ялтада үзе белән булган документлардан Казан университеты медфагында тапшырган имтихан һәм зачет билгеләре теркәлгән предмет кенәгәсе генә бар.

Ул, шушы формаль әйберләр аркасында, кабул итү вакытында берәр кыенлык чыкмагае, дип борчыла.




Хатның адрес язылган ягы

Борчуым өчен, Сезнең алда гафу үтенәм, шулай да Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым: тиешле документлар житмәү сәбәпле, аңлашылмаучылык килеп чыккан очракта, мөмкин булганча ярдәм итсәгез иде. Җибәрелгәннәре җитәрлек булмаса, ул, озак тотмыйча, кирәкле бөтен документларын салыр.

Тирән хөрмәт белән,
*Галимҗан Ибраһимов.*

---

Галимҗан Ибраһимовның русча язылган бу хатын редакциягә филология фәннәре кандидаты Гөлчәчәк Әдһәмова тапшырды. Хатның оригиналы СССР әдәбияты һәм сәнгатенең Үзәк дәүләт архивында (237 фонд. Саклану бер. 53. 1 опись) саклана.

[1] Петр Семенович Коган — (1872—1932) күренекле әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Сәнгать фәннәре дәүләт академиясе президенты.

*17 февраль, 1931 ел, Ялта.*

Кави

Бу хатны сиңа хәл белдерү өчен генә язам.

Февраль башыннан алып бераз каефсезләнеп торам. Ангина булды, үзе үтсә дә хәзер шуның нәтиҗәсе бара: бик нык хәлсезлек, ватык, изелгеч бер настроение эчендәмен. «Атака»да басылган әдәби түгәрәкләр программасы турында сезгә җибәрергә дип кайбер төзәтмә-тәкъдимнәр язган идем. Бу каефсезлек аркасында бетерә алмадым. Иҗат методы белән «Корбан» [1] да шулай яталар. Бик күңелләнеп барганда бу җәфа бераз изде.

Сәрвәргә, Тансыкка күп сәлам. 8—9 нчы саннан бирле «Атака» килгәне юк. 6 нчы саннан бирле «Яңалиф» тә юк.

Хуш. *Галимҗан.*

---

**Галимҗан Ибраһимовның бу хатын редакциягә Сәрвәр апа Әдһәмова тапшырды.**
**[1] «Корбан» хикәясе матбугатка чыкмады.**

*21 апрель, 1932 ел, Ялта.*

Хөрмәтле Мусанныйф [1] иптәш!

Кырым АПП белән берлектә Кырым дәүләт нәшрияты тарафыннан чыгарылачак альманах өчен әдәби материал сорап язган хатыңны алдым. Бу көндә сиңа җибәрергә дип әзерләнгән бер парчам юк, кызганычка каршы, бу арада ашыгыч рәвештә бер парча да җибәрергә кулымнан килми. Тик киләчәктә чыгачак альманахларың өчен бер парча бирә алырмын дигән өметем бар. Беләсең, инде биш еллап Ялтада дәваланамын. Каты газаплы куркыныч авыруым миңа Кырым тормышына катнашырга һичбер төрле мөмкинлек бирмәде. Тик хәзер бик әкрен-әкрен сәламәтләнеп киләм. Шуның белән бергә, революциянең Кырым фронты өлкәсе белән аз-маз таныша барам. Мин моңа кадәр партиянең Казан татарларына каратылган фронтында эшләдем, ләкин бөтенләй аның белән генә канәгатьләнмәдем.

Мин башкорт массасы тормышыннан «Башкорт кызы Гөлбикә» һәм башка хикәяви типлар, шуның белән бергә Казагыстаннан «Казакъ кызы» кебек романнар бирдем.

Инде әгәр яхшы сәламәтләнә алсам, бәлки, Кырым массасының җирле көрәшеннән, иҗтимагый тормышыннан да билгеле бер әсәр бирә алырмын дип өмет итәм. Мин Кырымны бик яраттым. Кырым минем өчен дөньяның иң матур, иң мәгънәле, иң тирән хисләр уяткан яңа әдәби ватаным булып әверелде. Минем бу хисләрем каләмемне Кырым турында язарга мәҗбүр итәләр. Сәламәтлегем яхшыра барган саен мин үземнең бу өметемне гамәлгә ашыру өчен чаралар күрәчәкмен. Кырымның гыйльми-әдәби фронтында коммунистик бурычымны үтәргә тырышачакмын. Альманахларга материал җибәрү эше дә менә шул өметләр белән бер сафта тора.

Ком. сәлам белән,

*Галимҗан Ибраһимов.*

---

**1932 елда Кырым язучылары, үзләре чыгарачак альманах өчен, Галимҗан Ибраһимовтан нинди дә булса әдәби әсәр җибәрүен сораганнар. Бу — Ибраһимовның Кырым язучыларына җавап хаты. Хатны редакциягә А. Шамов тапшырды.**
**[1] Мусанныйф (1900—1937) «Большевик юлы» журналының редколлегия члены.**

# ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

## ҖЫРЛАП ҮТИК ЕЛЛАР АРКЫЛЫ

Моннан берничә ел элек, «Казан утлары» (ул вакытта «Совет әдәбияты») журналы редакциясенә исеме әле укучыга бөтенләй диярлек таныш булмаган яңа автордан шигъри кульъязмалар килә башлады. Редакциядә әлеге кульъязмалар белән танышкан иптәшләр бу яшь каләмнең поэзия иңшеген шактый кыю шакуын, шигырьләренең хискә һәм тойгыларга мул булуын әйттеләр. Ул шигырьләрнең күбесе журнал битләрендә басылып чыкты. Болар — нефтьчеләр шәһәре Әлмәттә яшәүче яшь шагыйрә Саҗидә Сөләйманова шигырьләре иде. Үзенең беренче иҗади уңышлары белән канатланган Саҗидә шигырь язу эшенә тагын да дәртләнебрәк кереште. Аның «Кыр казлары» дип аталган беренче җыентыгы поэзия сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителде. Күптән түгел Татарстан китап нәшриятында Саҗидә Сөләймановаңың «Бәхетне үзем табам»[1] исемле яңа җыентыгы басылып чыкты. Анда шагыйрәнең утызлап шигыре һәм «Язылмаган җырлар» поэмасы тупланган.

Күренекле рус шагыйре Михаил Светловның бер мәкаләсендә: «Начар кеше яхшы шагыйрь була алмый», дигән фикер әйтелә. «Бәхетне үзем табам» җыентыгындагы шигырьләрне укыганда, ул шигырьләрне иҗат иткән шагыйрәнең күңел сафлыгын, табигатьне һәм кешеләрне ихлас күңелдән яратуын, яшьлекнең аерылгысыз юлдашлары булган дуслык һәм мәхәббәткә изге бер хис итеп каравын тоясың. Әнә шушы күркәм сыйфатлар аңа лирик герой исеменнән тормышка түбәндәге юллар белән мөрәҗәгать итәргә тулы хокук бирә:

> Суга төшсәм, чылтырап аккан чишмә
> Сорый иде: «Сеңлем, ни йомыш?»
> Шул чишмәнең саф тамчысы булып,
> Агымыңа чыгыйм, әй, тормыш!

Җыентыкның беренче битенә урнаштырылган «Елга ага» шигырендәге бу юллар очраклы рәвештә генә, авторның матур сүз әйтергә теләвеннән генә килеп тумаган. Шагыйрә биредә тормышка карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Ул үзен чолгап алган вакыйгаларны читтән генә күзәтеп йөрүче булып калырга теләми, шул вакыйгалар эчендә кайнарга, шау-шулы агымга саф сулы чишмә тамчысы булып кушылырга омтыла. Кешедән тормыш белән бер адымга атлап бару таләп ителә — авторның әйтергә теләгән төп фикере әнә шуннан гыйбарәт. Бу фикер «Еллар аркылы» шигырендә тагын да көчлерәк яңгырый:

> Юк, ел түгел — без үзебез үттек,
> Җырлар җырлап еллар аркылы.
> Чор — оркестр гүя, кеше гомере —
> Әйтерсең лә, шуның бер кылы.

Саҗидә Сөләйманова нигездә лирик шигырьләр яза. Һәм, әйтергә кирәк, аның иҗади уңышының ачкычы да шунда. Хискә, кичерешләргә, табигать күренешләрен кешенең эчке халәтенә җавап бирерлек җанландырып бирүгә корылган шигырьләр йөрәккә тиз үтеп керә, дулкынландыра, уйландыра, моңарчы үзең дә күрмәгән, белмәгән

[1] С. Сөләйманова. Бәхетне үзем табам. Шигырьләр. Тиражы 7000. Бәясе 10 тиен.

нәрсәләрне күз алдына бик җинел китереп бастыра. Син, көнеләндә йөртеп тә, сүз белән аңлатып бирә алмаган уйларны шигъри юлларга салу өчен шагыйрьдән зур түземлелек, тәҗрибә һәм поэтик осталык таләп ителә. Шул осталыкка ирешү юлында яшь шагыйрәнең татар халык җырларын җентекләп өйрәнүен ике куллап хупларга кирәк: бу аның иҗатына унай йогынты ясый. Моның шулай икәнлеген «Юлларга чыксаң», «Болыннарда сихри бер ямь», «Киек казлар китә», «Әлмәт турында җыр» шигырьләрендә бигрәк тә ачык күрергә мөмкин. Саналып кителгән һәм башка кайбер шигырьләрендә, халык җырларына хас булганча, җыйнаклык, эчтәлекне ачып бирер өчен төгәл метафоралар, оста тотып алынган поэтик детальләр куллану күзгә ташлана.

Агым суга сал төшердем,
Тал бөгелә, кисмәдем.
Хисләреңне җилкән итеп,
Бармы дәрья кичкәнең? —

ди шагыйрә «Агым сулар» шигырендә. Әлеге юллар үзләреннән үзләре көй сорап торалар. Композиторларыбызга, яңа җырлар өчен текстлар эзләп, бер дә әллә кая барасы юк... Җыентыкка кергән зуррак күләмле әсәрләрдән «Дан турында баллада»сында Сажидә Сөләйманова нефтьче батырларның эшләренә мактау җырлый. Шигырьдә хезмәт героикасын чагылдырган юллар лирик геройның фәлсәфи уйлануларын, шатлык һәм борчылуларын эченә алган юллар белән аралаша. Ләкин аңа карап шигырь үзенең эзлеклелеген, динамикасын югалтмый. Киресенчә, анда тасвирланган вакыйгалар һәм күренешләр үзара үрелеп үсәләр, автор әйтергә теләгән фикерне калкурак итеп күрсәтү өчен бер-берсен тулыландыралар.

Ә менә «Язылмаган җырлар» поэмасы турында моны әйтеп булмый. Бу әсәр тигез бер сюжетка яки лирик геройның эчке кичерешләренә корылган тулы канлы поэма булудан бигрәк, мәхәббәт темасына язылган кыска-кыска шигырьләр җыелмасын хәтерләтә. Аерым-аерым алып караганда, ул шигырьләрнең һәркайсы әйбәт, һәркайсында хәтергә кереп калырлык уңышлы строфалар, афоризм булып китәрлек чагыштырулар бар:

Кайсыннан алыйм да, бирим соң кайсына,
Бирәүнең бәхете — бирәүнең кайгысы.
Кайгыны бүлешәм, шатлыкны өләшәм,
Ә бәхет бүленми, ник аның яртысы?

Укучыны уйландырырга мәҗбүр итә торган мона охшашлы юлларны «Язылмаган җырлар»да да, башка шигырьләрдә дә әледән-әле очратасың. Бу исә шагыйрәнең туктаусыз эзләнүе, иҗат мөмкинлекләренең киң булуы турында сөйли. Ләкин, турысын әйтергә кирәк, Сажидә ул мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланып бетерми әле. Кайбер очракларда ул үз-үзен кабатлый, укучы өчен әһәмияте аз булган вак темалар белән мавыга. Мисалга «Кыш үтмәгән әле», «Йөрәгемә язлар ярсу салды», «Кичке шәфәкъ», «Күзләрендә», «Куанасың сабый бала төсле» шигырьләрен алыйк. Аларда автор меңнарчы инде поэзиядә бик күп тапкырлар кабатланган бер үк фикерләр тирәсендә әйләнә. Бәлки, шуңа күрәдер, поэзия белән кызыксынучылар арасында: «Соңгы вакытта Сажидә Сөләйманова бер төслерәк яза башлады», дигән сүзләр ишетелгәли. Укучыларының борчу катыш әйткән бу сүзләренә Сажидә, әлбәттә, колак салыр дип ышанабыз.

Сажидә Сөләйманованың беренче шигырьләрендә ритмик яктан кытыршы урыннар, төзек булмаган рифмалар, дөрес кулланылмаган җөмләләр шактый еш очрый иде. Яңа җыентыгында аның бу кимчелекләрдән акрынлап арына баруын күрәсең. Тик ул әле алардан ахырынача арынып җитмәгән. Кайбер шигырьләрендәге «Шомырт-юмарт», «оча-эчә», «күнелле-күңелне», «йөзәрмен-төшәрмен», «бикләнмәгән-белмәгәннәрдәй» шикелле рифмалар, «бу житез каеннар кая гел йөгерә», «койрык кагып чапкан грузовойда...», «явар түгел, кояр янгыр», «эш эшләсәң элке-салкы» рәвешендәге ятышсыз сүз тезмәләре Сажидәнең үз каләменә тагын да таләпчәнрәк булуын сорыйлар.

Үзе әйтмешли, еллар аркылы җырлап узар өчен озын юлга чыккан Сажидә Сөләйманованан һәркайсыбыз яратып укырлык матур-матур яңа шигырьләр көтеп калабыз.

Рәшит ГӘРӘЙ.

# Җимерелгән бастион

Бөек Ватан сугышында фашистлар өерен тар-мар итүгә, туп тавышлары тынуга егерме бер ел тулды. Тыныч төзелеш шартларында узган бу вакыт эчендә совет халкы искиткеч матур шәһәрләр һәм яңа авыллар салды, зур-зур завод-фабрикалар корды. Сугыш елларында хәрабәләр хәленә китерелгән шәһәр-авыллар, элеккедән дә матуррак булып, яңадан аякка бастылар. Тик кешеләр күңелендәге яралар кипшермәгән, дәһшәтле сугыш көннәре хәтердә нык сакланалар әле. Юк, онытылмый ул көннәр, капитализм дөньясы онытырга мөмкинлек бирми. Америка империалистлары, сугыш уты белән уйнап, үткән канлы көннәрне һаман да искә төшереп тора. Котырынган сугыш чукмарлары, Вьетнам халкының тынычлыгын бозып, ил өстенә үлем һәм һәлакәт яңгыры яудыра, меңнәрчә ирләрне, хатын-кызларны һәм гөнаһсыз сабыйларны үлем кочагына ташлый. Җир өстендә канлы сугыш барган мондый көннәрдә фашизм калдыкларының ерткычлыкларын ничек онытасың?!

Бөек Ватан сугышы геройлары турында, бу сугышта совет халкы күрсәткән батырлыклар турында күп әсәрләр язылды, бик күп кинофильмнар иҗат ителде. Татар совет әдәбиятында да халкыбызның героик көрәшен күрсәткән романнар, повестьлар һәм поэмалар шактый: герой шагыйребез Муса Җәлилгә багышланган драмалар һәм романнар, Г. Әпсәләмовның «Газинур», «Алтын йолдыз», «Мәңгелек кеше» романнары, шагыйрьләребезнең бик күп шигырь, поэмалары...

«Яшәү белән үлем арасында» повесте белән укучылар арасында киң танылган язучыбыз Нәби Дәүли сугыш темасына багышланган тагын бер әсәрен — «Җимерелгән бастион»ын дөньяга чыгарды [1].

Әсәр фашизм тоткынлыгында газапланган совет кешеләренең героик тормышы турында сөйли. Моннан алдагы әсәрләрдәге кебек үк, автор әсирләрнең фашист концлагерьларында үткәргән авыр көннәрен, азатлык өчен көрәшләрен сурәтли. Романда укучының игътибарын җәлеп итәрлек вакыйгалар, фаҗигале хәлләр күп. Әсәрне укыганда, истә калырлык образлар, кеше язмышлары белән очрашасың. Шулар арасында күңелгә аеруча якын булганнары — татар кызы Нәҗия һәм хәрби әсир Талип.

Нәҗия, урта мәктәпне тәмамлагач, медицина институтына укырга керә. Шул елларда кызда саф, көчле мәхәббәт хисләре уяна, ул Талип исемле егетне ярата. Талип та авыл егете. Ул да Нәҗияне өзелеп сөя. Алар бергәләп матур тормыш корып җибәрү турында хыялланалар. Нәҗия укуларын тәмамлагач, Германия чигенә якын бер шәһәрдәге хәрби частька Талибы янына килә. Ләкин алар бер-берсе белән очраша алмыйлар, көтмәгәндә сугыш башлана. Талип фронтка китә. Ә кыз фашистлар тырнагына эләгә. Аны Эльзабет исемле бер тол хатында хезмәтче булып эшләргә мәҗбүр итәләр. Нәҗия өчен авыр, газаплы һәм мәсхәрәле көннәр башлана. Никадәр кыен булса да, түзәргә кирәк, җиңү көненә кадәр ничек тә чыдарга кирәк.

Бай хатында хезмәт итүчеләр арасында Конрад исемле бер карт та бар. Бер көнне Нәҗия картның, авыз эченнән генә шыңшып, татарча җыр җырлаганын ишетә.

— Конрад абый, әллә сез татармы? — дип сорый кыз.

— Әйе,— ди карт һәм авыр гына сулап куя.

Конрад карт беренче бөтендөнья сугышы елларында Германиядә әсир калган Әхмәт Гатин дигән татар кешесе булып чыга. Аның

[1] Нәби Дәүли. Җимерелгән бастион. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1965 ел.

бөтен тормышы әнә шулай ялчылыкта йөреп узган. Ул гомер буе үкенеп, туган туфрагын күрергә зар-интизар булып яшәгән кешеләрнең берсе.

Тора-бара комсыз немец хатынына Наҗия белән Конрад карт эшләп китергән табыш кына аз тоела башлый. Аның иген кырларын эшкәртү, зур хуҗалыгындагы башка күп эшләрен башкару өчен, Дорадагы лагерьдан хәрби рус әсирләре дә китерелә. Менә шунда Наҗия яшьлек мәхәббәте Талип белән очраша...

Рәхимсез сугыш мәйданында дошманның җиңелә баруы, безнең солдатларның Германия туфрагына аяк басулары турындагы җылы хәбәрләр хәрби әсирләр колагына да керә. Алар азатлык сәгатьләре көннән-көн якынлаша баруын сизенәләр. Әмма дошман, суга батканда саламга тотынгандай, әллә нинди яңа коралларга ышана, соңгы көнгә кадәр шуңа өмет баглый. Гитлерның менә шундый иң соңгы таянычы яңа корал «Фау—2» була, тау чокып яшерен завод эшләнә. Ләкин «Фау—2» не стартка чыгарырга җыенганда, фронт якынлаша, иненче яктан «фашистларга каршы көрәш комитеты» оештырган группа яшерен заводны шартлату аппаратын кулга төшерә. Ниһаять, безнең гаскәрләр килеп җитә, байтак кына корбаннар калдырып булса да, әсирләр азат ителә.

Гомумән алганда, романның сюжеты мавыктыргыч итеп корылган. Әсәрнең иненче, минемчә, тагын да әһәмиятлерәк ягы шунда: анда совет солдатларының тоткынлыкта азап чиккән патриотларның фашизмга каршы героик көрәше шактый тулы һәм матур чагылдырыла.

Тулаем алганда әйбәт язылган бу романда кайбер йомшак яклар да бар кебек. Әсәрнең соңгы, кульминацион бүлеге бик катлаулы язылган. Биредә пәрдә төшкәч, уенда катнашучыларның сәхнәгә чыгып басулары кебек, романда телгә алынган персонажларның барысы да диярлек тау тишеге алдына чыгып басалар. Бу минутта барысының да язмышы хәл ителә. Талип көрәштә үлә, Наҗия сөйгән егете өстенә ятып елый да... югала. Совет солдатлары килеп керә. Алар немец киеме йөртнән Талипны күреп, «Немец капут!» диләр. Иптәшләре Талипның кем икәнлеген аңлаталар, ә Наҗия юк. Сәхнәгә бер-бер артлы әсирләр җыела, шартлату аппаратын күтәреп Франц килеп чыга, рус әсирләре яклы булып эшләгән лейтенант Францны безнең офицерлар хуплап каршы алалар. Тау тишегеннән чыккан әсирләр кочаклашалар. Наҗияне күрүче һаман юк... Бу момент бик буталчык бирелгән, ул укучыларны канәгатьләндерә алмый, авторга карата ризасызлык уята.

Сәхнәдә Фрау Эльзабет та бар, ләкин аның бу моменттагы хисләре дөрес чагылмый кебек. Автор аның турында «Бу минутта карчыкның нәрсә дә булса әйтергә сәләте калмаган иде. (чөнки хәзер Клараның Әхмәт Гатин кызы икәне ачыклана — Г. Б.) ул курыккан да, оялган да кебек, шатланган да кебек иде», ди. Рус солдатларына карата искиткеч начар мөгамәләдә булган хатын турында дөрес бәя түгел бу!

Китапның рәсемнәре турында шуны гына әйтергә мөмкин: эчке битләрдәгеләре канәгатьләнерлек булса да, тышлыгын мактап булмый. Хәтта «Бу китапның исеме нигә икән?» дип, озак кына баш ватарга туры килә. Күрәсең, китапларны иллюстрацияләү эшенә җитдирәк игътибар бирергә кирәктер.

Г. БАКИРОВ.

—✦—

# Шагыйрьнең куен дәфтәреннән

Ә. Ерикәй

●

Син кайгырма, мин казыган җиргә
Кем дә булса килеп төшәр, дип;
Мин бит баз казымыйм, кое казыйм,
Чордашларым саф су эчәр, дип.

●

Сатып алып булмый намусны,
Тартып алып булмый намусны;
Саклый ала аны саф күңел
Һәм югалту аны бик җиңел.

●

Тормыш учагын
Һәркем үзенчә дөрләтә:
Белгән кеше үзе эшли,
Белмәгәне өйрәтә.

●

Хопкың начар булса, очынырга,
Кабынырга сәбәп табылыр;
Ә кайдадыр матур дуслык хисе
Кара кияр, кара ябыныр...

●

Әле дөнья тәгәл түгел һаман да.
Бар шундыйлар, гаделсез дип тормыйлар:
Берәүләрне токтомалга зурлыйлар,
Берәүләрне урынсызга хурлыйлар.

●

Торган җирең ямьле, сүз дә юк,
Туган җирең ямьлерәк.
Сатып алган икмәк — тәмле икмәк,
Үзең үстергәне тәмлерәк.

●

Асыл чәчәкне үрчетергә туры килә,
Билчән үзе ярала;
Хакыйкатьне таратырга туры килә,
Гайбәт үзе тарала.

●

Дошман сыена караганда,
Әрем татлырак;
Көнче күңеленә караганда,
Караңгы төн яктырак.

●

Ташкын су
Ташны шомарта,
Аракы
Башны чуалта.

●

Үзең утын булсаң,
Сүзең төтен булуы
Гаҗәп түгел.

●

Үзе тәзекнең юлы да тәзек,
Эше дә, ашы да;
Үзе бозыкның уе да бозык,
Кешегә карашы да.

●

Сәнгатьне сугара тормыш,
Талантны — эш.

●

Шундый юаш, шундый ягымлы,
Елмайгалап куя;
Иәрәгеннән, күзен акайтып,
Шайтан карап тора.

●

Акыллы кеше киңәш сораша,
Ахмак — акыл өләшә.

●

Дуслыгың бик озак бозылмас,
Үзең сак булсаң:
Туры сүз әйтмәсәң дустыңа,
Гел мактап торсаң.

●

Бюрократ ул чәчми үскән
Билчән кебек ләбаса.
Билчән дә бит иң кирәкле
Үсемлекләрне баса.

●

Кеше кашыгыннан
Каймак ашаганчы,
Үз кашыгыңнан катык аша.

●

Намусың саф булса,
Ялтырап яшәрсең.
Саф булмаса —
Калтырап яшәрсең.

*Шәүкәт Галиев*

# ШИГЪРИ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

## *Хисам Камалов.*

**«Әнкәй истәлеге»**

Шигырьләр.

**Сирәк кенә биреп төчесен,**
**Күп күрсәтте тормыш ачысын,**
**Йомшак табигатьле кеше син,**
**Кырыс хакыйкатьле кеше син,**
**Шул сыйфатлар белән көчле син!**

## *Шәриф Хөсәенов.*

**«Зөбәйдә — адәм баласы»**

Пьеса.

**Театрга барасы,**
**Рәхәтләнеп карасы.**
**Күп булмасын арасы,**
**Тизрәк тусын яңасы!**

## *Равил Фәйзуллин.*

**«Аҗаган»**

Шигырьләр.

**Бар иде кызыл шигырьләр...**
**Син язасың ак шигырь.**
**Әгәр булмаса сак шигырь,**
**Әгәр булмаса вак шигырь,**
**Әгәр булмаса чак шигырь,**
**Әгәр дә булса хак шигырь —**
**Ник язмаска ак шигырь!**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

1967 ел өчен газета-журналларга язылу башланган көннәрдә, «Союзпечать», әлемтә бүлекләре работникларына һәм җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларга мөрәҗәгать итеп, безнең редакция әлеге иптәшләрнең «Казан утлары»н таратуда актив катнашуларын үтенгән һәм журналга аеруча күп яздырган кешеләргә бүләкләр бирeләчәген хәбәр иткән иде. «Союзпечать» һәм әлемтә бүлекләре работниклары да, күп санлы җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар да редакциянең бу үтенечен гамәлгә ашыру өчен күңел биреп эшләгәннәр. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен ике санны чагыштырып карау да җитә: «Казан утлары»н 1966 елда барлыгы 37000 кеше алган булса, бу ел 57000 кеше алачак. Журналның бу ел 20000 язылучысы арткан дигән сүз бу! Шунысы да игътибарга лаек, журналны алучылар үз республикабызда гына түгел, илебезнең барлык районнарында, өлкәләрендә дә арткан. Мәсәлән, Башкортстанда журналны узган ел 9000 кеше алган булса, бу ел аңа 18000 кеше язылган.

Башка еллар белән чагыштырганда, Кыргызстанда (2556 данә), Үзбәкстанда (2441), Пермь (2045), Свердловск (1903), Оренбург (1330), Чиләбе (1052), Ульяновск (804), Кемерово (772), Куйбышев (687) һәм башка күп кенә өлкәләрдә дә журналга язылучылар саны бу ел ике-өч тапкырга арткан.

Үз республикабызда журналны узган ел 12000 кеше алган булса, бу ел 17530 кеше алачак. Татарстанның кайсы районында журналга күпме кеше язылган соң? «Казан утлары»на яздыру буенча кайсы район ничәнче урында тора? Бу сорауларга җавап алыр өчен, журналның республикабыз районнарында таралышын күрсәткән түбәндәге таблицага игътибар итик:

| Район исемнәре | 1966 елда күпме язылучы булган | 1967 елга язылучылар саны | Ничәнче урында тора | 1000 кешегә ничә данә журнал туры килә | 1000 кешегә яздыру буенча ничәнче урында тора. |
|---|---|---|---|---|---|
| Әлмәт | 619 | 1400 | 1 | 23 | 4 |
| Азнакай | 672 | 1250 | 2 | 34 | 1 |
| Актаныш | 500 | 904 | 3 | 22 | 5 |
| Сарман | 624 | 892 | 4 | 25 | 2 |
| Баулы | 495 | 829 | 5 | 22 | 6 |
| Чаллы | 345 | 712 | 6 | 14 | 11 |
| Мөслим | 573 | 661 | 7 | 24 | 3 |
| Лениногорск | 310 | 596 | 8 | 17 | 9 |
| Буа | 417 | 592 | 9 | 9 | 19 |
| Октябрь | 170 | 522 | 10 | 19 | 8 |
| Минзәлә | 289 | 521 | 11 | 13 | 14 |
| Арча | 378 | 477 | 12 | 7 | 29 |
| Мамадыш | 310 | 457 | 13 | 10 | 17 |
| Бөгелмә | 230 | 443 | 14 | 14 | 12 |
| Апас | 317 | 434 | 15 | 9 | 21 |
| Кукмара | 281 | 423 | 16 | 9 | 20 |
| Чирмешән | 205 | 406 | 17 | 20 | 7 |
| Чистай | 171 | 393 | 18 | 11 | 16 |
| Саба | 305 | 384 | 19 | 8 | 26 |
| Әгерже | 181 | 275 | 20 | 9 | 22 |

*Дәвамы*

| Район исемнәре | 1966 елда күпме язылучы булган | 1967 елга язылучылар саны | Ничәнче урында тора | 1000 кешегә ничә данә журнал туры килә | 1000 кешегә яздыру буенча ничәнче урында тора |
|---|---|---|---|---|---|
| Әлки | 150 | 252 | 21 | 14 | 13 |
| Балтач | 160 | 234 | 22 | 9 | 24 |
| Түбән Кама | 93 | 205 | 23 | 7 | 28 |
| Балык Бистәсе | 101 | 202 | 24 | 9 | 23 |
| Куйбышев | 74 | 193 | 25 | 17 | 10 |
| Алабуга | 110 | 192 | 26 | 5 | 32 |
| Зеленодольск | 135 | 182 | 27 | 5 | 33 |
| Аксубай | 93 | 172 | 28 | 9 | 18 |
| Кама Тамагы | 103 | 170 | 29 | 13 | 15 |
| Биектау | 100 | 168 | 30 | 6 | 30 |
| Тәтеш | 53 | 106 | 31 | 8 | 25 |
| Питрәч | 61 | 103 | 32 | 7 | 27 |
| Алексеевск | 84 | 103 | 33 | 6 | 31 |
| Лаеш | 46 | 72 | 34 | 5 | 34 |
| Югары Ослан | 23 | 38 | 35 | 3 | 35 |

Таблицадан күренгәнчә, без районнарның урыннарын барлыгы күпме һәм 1000 кешегә ничә данә журнал таратуларына карап билгеләдек. Нәтиҗәдә, «Казан утлары»н иң күп тарату буенча Әлмәт районы, ә 1000 кешегә иң күп тарату буенча Азнакай районы беренче урыннарны алган булып чыкты. Һәр ике күрсәткеч буенча караганда Актаныш, Сарман, Баулы, Мөслим районнары да мактаулы урыннарны яулап алдылар.

Әмма, шул ук вакытта, байтак кына районнарда әлеге ике күрсәткеч арасында зур гына аерма булуы да ачык күренә. Әдәби телебезнең нигезен тәшкил иткән Казан арты районнарының берсе булган һәм — монысы иң мөһиме! — 70000 гә якын татар халкы яшәгән Арча районы, мәсәлән, журнал алучылар саны буенча бары тик уникенче урында, 1000 кешегә ничә данә журнал туры килү буенча егерме тугызынчы, ягъни соңгы урыннарның берсендә тора. 477 данә журнал — Арча районы өчен бик аз ул. Азнакай, Сарман районнары белән чагыштырганда, анда, кимендә, 1600—2000 данә журнал таратырга мөмкинлек бар. 1000 кешегә ничә данә журнал туры килү җәһәтеннән караганда, Апас, Кукмара, Әгерҗе, Балык Бистәсе, Алабуга, Лаеш, Питрәч һәм Югары Ослан районнарының да арткарак калганлыкларын күрү читен түгел. Әлеге районнардагы «Союзпечать», элемтә работниклары һәм җәмәгать тәртибендә матбугат таратучы иптәшләр киләсе ел өчен журналга яздыру чорында бу хәлне искә алырлар һәм тырышыбрак эшләрләр дип ышанабыз.

Ә хәзер журналны тарату буенча үткәрелгән конкурс нәтиҗәләрен күздән кичереп үтик. Редакция игълан иткән бу конкурста «Союзпечать» һәм элемтә бүлекләре работниклары да, җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар да бик актив катнаштылар. **Аларның барысына да журнал редколлегиясе, Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары»нда үзләренең әсәрләре белән актив катнашып килүче язучыларыбыз чын күңелдән рәхмәт белдерәләр.**

Татарстан районнарындагы һәм Советлар Союзының башка республикаларындагы, өлкәләрендәге «Союзпечать» һәм элемтә бүлекләреннән алынган мәгълүматлардан чыгып, журнал редакциясе «Казан утлары»н аеруча күп тараткан кешеләрдән түбәндәге иптәшләрне бүләкләүгә лаек дип тапты һәм аларга бәяле (гармонь, скрипка, фотоаппаратлар, сәгатьләр) һәм истәлекле бүләкләр (автографлары белән, күренекле язучыларыбызның китаплары, Г. Тукай, М. Җәлил альбомнары) җибәрелде: **Вәлиев Р.** (Казан дәүләт университеты студенты), **Вәлиев Х.** (Казан, эшче), **Фәйзуллин Р.** (Казан, шагыйрь), **Зәйнуллин Э.** (Казан, эшче), **Вәлиев Ф.** (Казан, тарих фәннәре кандидаты), **Сәйфуллин Р.** (Ка-

зан, эшче), **Әйдильдинов Т.** (Казан, университет студенты); **Азнакай районы буенча: Сәетова** (Мәсәгут авылы), **Зиннәтова** (Сарлы авылы), **Хәмидуллина Д.** (Кәкре елга авылы), **Галиева** (Урманай авылы), **Нуриева** (Урсай авылы), **Мирзаһитова** (Сухаяш авылы), **Җәләева М.** (Азнакай), **Мөхитова (Чалпы авылы); Әлмәт районы буенча: Котлыбаева С.** (Габдрахман авылы), **Мөхетдинова** (Кәшир авылы), **Фәретдинова** (Кама-Исмәгыйль авылы), **Нуретдинова Р.** (Т. Мактама поселогы), **Гәрәева З.** (Сөләй авылы), **Дәүләтдина А.** (Мәмәт авылы), **Шәйхетдинова Н.** (Чупай авылы), **Шәмсиева З.** (Нәдер авылы), **Харрасова М.** (Бишмунча авылы); **Сарман районы буенча: Әхмәтгәрәева Ә.** (Тамак авылы), **Абдуллина Х.** (Әзәл авылы), **Сәетгалиев Ш.** (Янур авылы), **Мәҗитова Р.** (Минзәләбаш авылы), **Хәйбрахманова Х.** (Александр авылы), **Арасова А.** (Алкын авылы), **Исмәгыйлова Р.** (Нөркәй авылы); **Чирмешән районы буенча: Хәсәнова М.** (Үтәмеш станциясе), **Мөхәммәтшина Ә.** (Түбән Чегодай авылы), **Садыйкова Ф.** (Лашман авылы); **Баулы районы буенча: Морзакаев М., Шәрифуллина Р., Абдуллин Р., Шәфигуллина Ә.** (барысы да Баулы поселогыннан), **Хәлфетдинова Г.** (Кызыл яр авылы), **Хәсәнова Ф.** (Мортаза авылы); **Балтач районы буенча: Корбанова Н., Фәхриев И.** (икесе дә Балтач авылы), **Нәсихова С.** (Салауч авылы); **Әгерҗе районы буенча: Төхфәтуллин Ә., Мортазина Г.** (икесе дә Тирсә авылы), **Сәхәпова М.** (Варза авылы), **Әхмәтгалиева Ф.** (Әгерҗе шәһәре); **Апас районы буенча: Сәлимуллин Х.** (Бурнаш авылы), **Нуруллина З.** (Чирмешән авылы), **Галимҗанова Х.** (Апас авылы); **Татарстанның башка районнары буенча: Әминов Н.** (Кукмара районы, Чишмәбаш авылы), **Рябчиков Н.** (Кукмара поселогы), **Гильметдинова Н.** (Норлат районы, Бурмәт авылы), **Сойтеров К.** (Октябрь районы, Т. Игмай авылы), **Галләмова Х.** (Октябрь районы, Иске Әлмәт авылы), **Мәрдәнова Ф.** (Куйбышев районы, «Чапаев» исем. колхоз), **Әбуталипова Г., Хәбибуллина Х.** (Куйбышев районы, Тельман исем. колхоз), **Хөсәенов Г.** (Чистай районы, Каргалы авылы), **Шәвәлиев Б.** (Чаллы районы, Әскәр авылы), **Головин А.** (Чаллы районы, Бурда авылы), **Гимадиева Э.** (Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылы), **Муллин Р.** (Чаллы районы, Иштирәк авылы), **Әхмәтшина Ф.** (Лениногорск районы, Ю. Чыршылы авылы); **Башкортстанның Чакмагыш районы буенча** (матбугат таратучыларның авыллары күрсәтелмәгән): **Рахманова М., Газизова Ф., Галиева А., Бакирова М., Камалова Ф., Шәрифуллина Р., Шаяхмәтова З., Рязанова Р., Хабибуллин Ф., Вәлиева М., Юлдашев Л., Вәлиев Н., Камалова Ф., Гәрәев В., Галләмова Р., Хаҗиәхмәтова М., Гильвакова А., Мокулова Ф., Аппаев Л., Солтанов Р.; Башкортстанның башка районнары буенча: Ярмиева Р.** (Стәрлебаш районы, Бакый авылы), **Рамазанов Г.** (Илеш районы, Ново-Медведево авылы), **Низамов В.** (Бишбүләк районы, Меңсуз-Москва авылы), **Хәбетдинов С.** (Миякә районы, Баязит авылы), **Хәкимов С.** (Чишмә районы, Яныш авылы), **Шакиров Ә., Әхмәдиев Б., Ягъфәров М.** (барысы да Янаул районы үзәгеннән), **Фәйрузова Л.** (Салават районы, Гайлыс авылы), **Төхфәтуллина Р.** (Туймазы), **Мөхәммәтҗанов Х.** (Бүздәк районы, Якуп авылы), **Гайнуллина Ф.** (Янаул районы, Барабаш авылы). **Башка өлкәләр һәм республикалар буенча: Газиев М., Сәйфуллин Л.** (икесе дә Ленинград өлкәсе, Гатчина шәһәре), **Сарманова Р.** (Гюндук авылы), **Галәшева Г.** (Бичура авылы), **Гоминов К.** (Елпачиха авылы), **Нигъмәтуллин Г.** (Сараш авылы — дүртесе дә Пермь өлкәсеннән), **Әхмәтов Р.** (Чуваш автономияле республикасы, Бикшиқ авылы); **Курмаев И.** (Сөләй авылы), **Мостафина М.** (Т. Канадей авылы), **Әдикәева Ж.** (Б. Труев авылы — өчесе дә Пенза өлкәсеннән); **Бәхметов К.** (Мордва автономияле республикасы, Саранск шәһәре), **Вильданов Х., Бикмөхәммәтов И.** (икесе дә Куйбышев шәһәре); **Ротенберг И.** (Кемерово өлкәсе, Осинники шәһәре), **Непомнящий В.** (Кемерово өлкәсе, Киселевск шәһәре).

Җәмәгать тәртибендә журнал таратучы энтузиастлар арасында беренче бүләкне (гармонь) Казан шәһәрендә 100 данә «Казан утлары»н таратып, университет студенты Разил Вәлиев алды. Икенче бүләк (скрипка) 98 данә журнал тараткан эшче Хәмит Вәлиевкә (Казан) һәм өченче бүләк (фотоаппарат) 97 данә журнал тараткан Равил Фәйзуллинга (шагыйрь) тапшырылды.

Журналны иң күп тараткан республика, өлкә һәм район «Союзпечать» бүлекләре начальникларына да сигез бүләк билгеләнгән иде. Журналга язылу нәтиҗәләреннән чыгып, редакция Татарстан өлкә «Союзпечать» бүлеге начальнигы В. Иванов, Башкортстан өлкә «Союзпечать» бүлеге начальнигы Сергеев иптәшләрнең хезмәтләрен билгеләп үтте. Әлмәт районы «Союзпечать» бүлеге начальнигы Н. Гарифуллинага да фотоаппарат тапшырылды. Ә Чаллы, Октябрь, Актаныш, Сарман, Баулы, Бөгелмә районнары «Союзпечать» бүлекләре начальниклары Л. Камалова, Н. Смирнова, М. Гильфанова, М. Шәйдуллина, А. Кашапова һәм С. Садовойларга өстәл сәгатьләре җибәрелде.

**Конкурс бүләкләрен алган һәм, бүләкләнмәсәләр дә, «Казан утлары»н «кабызуда» актив катнашкан барлык матбугат таратучыларга редакция чын күңелдән рәхмәт белдерә һәм ул иптәшләр киләчәктә бу изге эшне тагын да нәтиҗәлерәк дәвам итәрләр дип ышана.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан язучылары союзы партия оешмасының 31 январенда үткәрелгән ачык җыелышында Бөек Октябрьның 50 еллыгына һәм В. И. Ленинның 100 еллык юбилеена әзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Җыелышта бу зур тарихи даталарны лаеклы каршылау буенча язучылар союзы оешмасы һәм һәр аерым язучы алдында торган мөһим бурычлар турында житди, эшлекле сөйләшү барды.

«Казан утлары» журналының җаваплы редакторы Р. Мостафин, «Азат хатын» журналының җаваплы редакторы А. Хәсәнова юбилей елында басылачак әсәрләр турында сөйләделәр, язучыларны журналларның эш планнары белән таныштырдылар.

Җыелышта чыгыш ясаган иптәшләрдән М. Горький исемендәге музей директоры М. Елизарова, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире С. Сабиров, Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе М. Әмир, идарәнең секретаре З. Нури, язучылардан Г. Латыйп, А. Талвир, Н. Дәүлиләр газета-журнал һәм нәшрият работникларын юбилей елына яңа, актуаль әсәрләр туплауда эшчәнлекләрен арттырырга чакырдылар.

## ТАТАР ТЕАТРЫНА 60 ЕЛ

Татар академия театры. Бу исем — халкыбызның горурлыгы һәм мактанычы. Театр сәнгатебезнең ярты гасырдан артык үсеш тарихы шушы исем белән бәйләнгән. Заманында Г. Камал исемендәге театр базасында уннарча театр коллективлары үсеп чыкты. Исемнәре бөтен илгә мәгълүм бик күп язучыларның, артистларның иҗаты шушы театрдан, аның бай һәм зур тарихыннан аерылгысыз.

Беренче мәртәбә театр ишекләре ачылган көннән соң 60 ел вакыт үтте. Һәм шушы елның февраль башында республикабыз җәмәгатьчелеге татар театрының 60 еллык бәйрәмен үткәрде.

Беренче февральдә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры бинасына сәхнә ветераннары, җәмәгать оешмалары һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләре, күп санлы сәнгать сөючеләр җыелды. Алар татар театрына 60 ел тулу тантанасында катнашу өчен килгәннәр иде. Кичәне, кыскача кереш сүз сөйләп, Татарстан АССР Культура министры Б. Гыйззәтуллин ачты. Театрның директоры, Татарстан АССРның халык артисткасы Р. Җиһаншина коллективның иҗат юлы турында доклад сөйләде.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев партия өлкә комитетының, ТАССР Верховный Советы Президиумының һәм Министрлар Советының театр коллективына котлавын укыды.

Бөтенроссия театр җәмгыяте идарәсенең председатель урынбасары И. Скачков, Башкорт дәүләт академия театры директоры Ф. Вахитов, Ижевск музыкаль драма театрының баш режиссеры И. Башмаков, Чувашия АССРның халык артисты И. Молодов юбиляр адресына кайнар котлау сүзләре әйттеләр. Республикабызның төрле оешмаларыннан, иҗат союзларыннан, учреждениеләрдән һәм киң илебезнең бөтен почмакларыннан килгән телеграммалар, котлау хатлары укылды.

Кичәнең икенче бүлегендә «Үткән юллар эзеннән» дигән күнелле тамаша булды. Тамашада театрның бөтен коллективы катнашты, һәм 60 ел эчендә куелган иң яхшы спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

Театрның 60 еллыгы уңае белән һәм татар совет театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры артистлары Ибраһим Насыйр улы Гафуровка, Мингали Ислам улы Надрюковка Татарстан АССРның халык артистлары, Асия Әмир кызы Галиева-Абдуллинага Татарстан АССРның атказанган артисты, театрның режиссеры Празат Нәкый улы Исәнбәткә һәм театрның художнигы Әнәс Ибраһим улы Тумашевка Татарстан АССР-

ның атказанган сәнгать эшлеклеләре диган мактаулы исемнәр бирде.

Күп еллык һәм нәтиҗәле эшләре өчен Г. Камал исемендәге театрның күп кенә эшчеләре Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамоталары белән бүләкләнделәр. Бүләкләнүчеләр арасында Татарстан АССРның атказанган артисты Г. Зыятдинов, артистка Г. Камалова, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, художник М. Сутюшев, сәхнә машинисты М. Шварцман иптәшләр бар.

КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, күп еллык һәм нәтиҗәле эшләре өчен, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының 60 еллыгы уңае белән, бик күп иптәшләрне КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамоталары белән бүләкләделәр.

Бүләкләнүчеләр арасында Ә. Гобәйдуллин, И. Маркитанов, П. Милованов, Г. Мөхәммәтҗанова, Г. Нигъмәтуллина, Р. Нурмөхәмәтова, В. Сподиков, Р. Солтанова, М. Халитова-Миңлебаева иптәшләр бар.

## ХӨСӘЕН ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 85 ЕЛ

Шушы елның январь аенда күренекле татар революционеры, ленинчы большевик Хөсәен Ямашевның тууына 85 ел тулды. Татарстан партия өлкә комитеты секретариатының махсус карары буенча, Хөсәен Ямашевның 85 еллыгы бөтен республикада киң күләмдә билгеләп үтелде. Предприятиеләрдә, колхозларда, совхозларда, уку йортларында, аның революцион эшчәнлегенә багышлап, лекция һәм докладлар укылды. Республика газета-журналларында Х. Ямашевның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган материаллар басылды. Татарстан радиосы һәм телевидениесе күренекле революционер турында махсус тапшырулар оештырды.

СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында Х. Ямашевның тууына 85 ел тулуга багышланган фәнни конференция уздырылды. Конференцияне, алдынгы иҗтимагый-политик карашлар үсешенә зур йогынты ясаган ялкынлы большевикның якты истәлеге турында кереш сүз сөйләп, тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов ачты.

«Хөсәен Ямашев һәм большевистик «Урал» газетасы», «Урал» газетасы — марксистик-ленинчыл экономик фикернең мөһим чыганагы», «Татар әдәби теленең иҗтимагый-публицистик стиле үсерүдә большевистик «Урал» газетасының роле» дигән темаларга докладлар укылды.

19 январьда КПСС өлкә комитетының конференц-залында күренекле революционер Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашевның тууына 85 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Х. Ямашевның тормышы һәм революцион эшчәнлеге турында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев доклад ясады.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Студентлар чакыруы буенча, Илдар Юзиев, Шәүкәт Галиев Казандагы кооперация техникумында булдылар. Алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, бүгенге татар поэзиясе турында сөйләделәр, күп санлы сорауларга җаваплар бирделәр.

19 январьда Зеленодольск шәһәренең «Родина» культура сараенда «Казан утлары» журналы бездә кунакта» дигән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәгә катнашу өчен Казаннан журналның җаваплы редакторы Р. Мостафин, шагыйрьләр И. Юзиев, Ш. Галиев, Р. Гатауллин килде.

## ТАТАРСТАН КИТАП ПАЛАТАСЫНА 40 ЕЛ

1926 елга кадәр Татарстанда чыккан матбугат продукциясен исәпкә алып баручы махсус бер үзәк юк иде. Нәкъ әнә шул елларда Китап палатасы ачу мәсьәләсе күтәрелә. Бу мәсьәләне Академик үзәк тә яклап чыга. 1926 елның 21 декабрендә Татарстан Совнаркомы Татарстан Китап палатасы турында «Положение» кабул итә. Татарстанда чыккан һәртөрле матбугат продукциясенең мәҗбүри экземплярларын туплау, аларның тегәл исәбен алып бару һәм саклау, библиографик белешмәлекләр чыгару һәм аларны китапханәләргә тарату — китап палатасына менә шул эшләр йөкләнә. 1927 елның 20 сентябреннән палата республикада басылган барлык төр матбугат продукциясенең мәҗбүри контроль экземплярларын ала башлый.

1929 елда аның фонды палата төзелгәнче (1917—1926 елларда) чыккан китаплар белән тулыландырыла. 1927 елның ахырыннан Китап палатасы, татар китаплары белән беррәттән, Татарстанда чыккан рус китапларының да мәҗбүри экземплярларын тупларга керешә. Хәзерге көндә (1966 елның 1 октябрена) Китап палатасының мәҗбүри экземплярлар фондында 16.501 исемдә татар китабы, 9.656 исемдә рус китабы бар.

Беренче чорда Китап палатасының нәшрият эше җәйга салынып китә алмый. Палата тарафыннан чыгарылган беренче белешмә 1929 елга карый. Гарәп шрифтында басылган бу белешмәлектә РСФСРның төрле шәһәрләрендә 1925 елда чыккан 414 татар китабы һәм татар телендә чыккан газета-журналларның исемлеге теркәлгән. Белешмәдә китаплар исемлеге белән бергә, ул китапларга карата язылган рецензияләр дә бирелгән. Аны Китап палатасының өлкән библиографы С. Ш. Тагирова төзегән. Тагын ике еллап вакыт узгач, 1930 елның 1, 2, 3 нче кварталлары өчен «Китап елъязмасы» чыгарыла (латин шрифтында). Ул «Елъязмалар»да 684 исемдә китап теркәлгән. Аларның 449 ы татар телендә, 197 се рус телендә, калган 38 е төрле телләрдә басылган әсәрләр. 1932 елга кадәр Китап палатасы Мәгариф комис-

сарияты каршындагы Академик үзәкка буйсына. Шул елда палата Казан университетының фәнни китапханәсе карамагына күчерелә. Фәнни китапханә карамагында вакытта, палатаның нәшрият эшчәнлеге бөтенләй диярлек туктала. Дөрес, 1919—1931 еллар арасында басылган китапларның «Елъязмасы» төзелә, ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, ул чыгарылмый кала.

Бары 1938 елда гына палата кабат Мәгариф комиссариаты карамагына кайтарыла. Шул чордан башлап палата регуляр рәвештә «Китап елъязмасы» һәм «Вакытлы матбугат елъязмасы» чыгара башлый. 1941 елга кадәр «Китап елъязмасы» кварталга бер мәртәбә чыгарылып килә.

Бөек Ватан сугышы елларында «Китап елъязмалары» чыгарылмый. Палатада алар төзелгәннәр, басарга да әзерләнгән булганнар, ләкин шул килеш калганнар. Сугыштан соң халкыбыз зур дәрт белән илебезне төзекләндерү эшенә тотынды. Шул ук вакытта халыкның культура дәрәҗәсен күтәрүдә зур урын тоткан китап басу эшенә дә игътибар арта һәм чыгарылган китапларның саны нык күбәя. 1945 елда барысы 212 китап басылган булса, 1946 елда 302, 1947 елда 457, 1950 елда 574, 1952 елда 603, 1953 елда 694, 1954 елда 785 китап чыгарылган. 10 елга барлыгы 5133 китап чыккан, аларның 3187 се татар телендә, 1942 се рус һәм 4 се таҗик телендә.

Соңгы 10—12 ел эчендә Китап палатасы үзенең нәшрият эшчәнлеген нык киңәйтте. 1953 елдан башлап, моңа кадәр чыгып килгән «Китап елъязмасы» һәм «Вакытлы матбугат елъязмасы»ннан тыш, «Рецензияләр елъязмасы», ә 1955 елдан журналларда һәм газеталарда басылган «Мәкаләләр елъязмасы» чыгарыла башлый. Бу еллар эчендә Китап палатасы тарафыннан 47 исемдәге төрле белешмәлекләр чыгарылды.

1938 елдан 1963 елга кадәр чыккан «Китап елъязмалары», 1953 елдан чыгарыла башлаган «Рецензияләр елъязмалары» палатаның өлкән библиографы М. З. Бурнашева тарафыннан төзелгәннәр.

Әйтеп кителгәнчә, 1955 елдан башлап Китап палатасы «Журналларда һәм газеталарда басылган мәкаләләр елъязмасы» чыгара башлады. Шуннан бирле бу елъязмага 69505 мәкалә теркәлгән, шуларның 53660 ы татар телендә. Нинди дә булса фәнни тема өстендә эшләүче галим, тикшеренүче «Елъязмалар»дан үзенә кирәкле материалны бик җиңел таба ала.

«Рецензияләр елъязмасы»на, безнең республикада басылган рецензияләрдән тыш, үзәк газета-журналларда һәм башка республикаларда басылган рецензияләр дә теркәлә. Соңгы 13 елда «Рецензияләр елъязмасы»на 2814 рецензия кергән. Шуларның 1516 сы татар телендә.

10 ел буена басылган китаплар саны белән рецензияләр санын чагыштырып карасак, бик күп китапларның тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калганлыгын күрәбез. Бу елларда татар телендә 1274 исемдә әдәби әсәр чыгарылган, ә рецензияләр саны 588 генә. Димәк, чыгарылган китапларның яртысыннан артыграгы рецензиясез калган.

1961 елдан Китап палатасы барлык елъязмаларны «Татарстан матбугат елъязмасы» дигән бер исем астында берләштереп чыгара башлады. Ул «Китап елъязмасы», «Рецензияләр елъязмасы», «Ноталар», «Журналларда һәм газеталарда басылган мәкаләләр елъязмасы», «Татарстан Советлар Союзы матбугатында» исемле биш бүлектән тора һәм кварталга бер мәртәбә чыга. «Татарстан матбугат елъязмасы» библколлектор аша барлык китапханәләргә таратыла.

«Татарстан Советлар Союзы матбугатында» дигән бүлек 1960 елдан кергән. Анда барлыгы 4511 китап һәм мәкалә теркәлгән. Бу бүлек язучылар, әдәбият галимнәре өчен аеруча кирәкле һәм кызыклы. Анда безнең язучыларыбызның илнең башка республикаларында һәм өлкәләрендә басылган әсәрләре, Татарстан турындагы мәкаләләр җыела. Бу бүлекне карап чыгып, кайсы язучының нинди әсәре нинди телләргә тәрҗемә ителеп, кайда басылып чыкканлыгын бик тиз әйтеп була. Бер 1965 елда гына да бу бүлектә 692 китап һәм мәкалә җыелган. Алар арасында безнең язучыларның төрле телләргә тәрҗемә ителеп, төрле республикаларда басылган 139 әдәби әсәре бар. Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуны илебезнең барлык почмакларында да билгеләп үттеләр. «Елъязма»ның 1966 елгы 2 санында М. Җәлилгә багышланган 200 гә якын мәкалә тупланган.

Соңгы 4—5 елда палата күп хезмәт куюны сорый торган зур эш алып бара. Палата 1917—1937 елларда Казанда һәм РСФСРның башка шәһәрләрендә татар телендә басылып чыккан китапларның тулы ретроспектив библиографиясен төзү эшенә керешге. Хәзер бу каталогта 11 мең чамасы китап исәпләнә. Каталогны төзү өчен нигездә Китап палатасының фонды алынган. Шулай ук Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә, В. И. Ленин исемендәге Республика китапханәсе, Бөтенсоюз Китап палатасы, В. И. Ленин исемендәге Кызыл Байраклы СССР китапханәсе, Салтыков-Щедрин исемендәге халык китапханәсе, СССР Фәннәр академиясенең Азия, Африка халыклары институты китапханәсе, Башкорт республика китапханәсе каталоглары каралган. Палатада җитмәгән китапларга библиографик карточкалар язылган. 1785—1916 елларда Казанда һәм Россиянең башка шәһәрләрендә татар, гарәп, фарси, төрки телләрендә чыккан китапларның каталогын төзү өстендә дә эш алып барыла. Бу каталогта хәзер 3856 карточка исәпләнә. 1917—1937 елларда Казанда рус телендә чыккан китапларның да каталогын төзү эше башланган.

Соңгы ике ел эчендә палата В. И. Ленинның Казанда һәм РСФСР шәһәрләрендә татар телендә басылган әсәрләренең библиографик күрсәткечен төзү буенча зур эш башкарды. Хәзер бу күрсәткеч Татарстан китап нәшриятына тапшырылган.

Ул В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлана.

«Положение» буенча Китап палатасы партия оешмаларына һәм дәүләт учреждениеләренә төрле библиографик характердагы белешмәләр бирергә тиеш. Китап палатасы бу өлкәдә дә шактый киң эш алып бара.

Китап палатасы Республика китапханәсе белән тыгыз элемтәдә эшли. Алар белән бергә «Татарстан Советлар Союзы матбугатында» дигән бүлекне төзи. Союздаш һәм автономияле республикаларның Китап палаталары белән дә элемтә кинәйгәннән киңәя бара.

1966 елның 21 декабрендә Татарстан Китап палатасы төзелүгә 40 ел тулды. Бу бәйрәмне палата коллективы зур күтәренкелек белән билгеләп үтте.

—◆—

# Зәйнәп ханым Хәсәния



7 мартта бөек шагыйребез Габдулла Тукайның дусты, күренекле язучыларыбыз Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовларны якыннан күреп белгән, алар белән дусларча аралашып яшәгән Зәйнәп ханым Хәсәния вафат булды. Зәйнәп Хәсәния әле Октябрь революциясенә кадәр үк бернинди гореф-гадәтләргә баш имичә, культурага омтылган, укымышлы, белемле булган татар хатын-кызларыбызның берсе иде. Шул заманда Казан шәһәрендә Фатиха Аитова ачкан кызлар гимназиясенең совет члены буларак, ул хатын-кызлар арасында җәмәгать эшләре алып бара. «Гасыр» нәшрияты ачып, рус классик әдәбиятын татар телендә бастырып тарату эшен башлап җибәргән, шулай ук күп кенә демократ язучыларыбызның әсәрләрен китап итеп бастырып дөньяга чыгаруга күп көч куйган укымышлы, мәгърифәт сөюче Гәрәй Хәсәнинең тормыш иптәше Зәйнәп Хәсәния дә нәшрият эшләренә бик якын була. Зәйнәп Хәсәния ире Гәрәй Хәсәни оештырган демократик юнәлештәге беренче әдәби-иҗтимагый «Аң» журналының җаваплы секретаре вазифасын үти. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов һ. б. күренекле язучылар үзләренең әсәрләре белән катнашып, «Аң» журналын чыгаруда якыннан торып булышканнар, аңа идея юнәлеше бирүче фикердәш булганнар. Г. Тукай бу журнал чыгуга шатланып «Аң» исемле шигырен яза һәм аны журналның беренче санында ук бастыра. Ә Г. Ибраһимов соңгарак журналның җаваплы секретаре булып эшли, гомумән журналның идея-эчтәлек ягына юнәлеш бирүче була.

Зәйнәп апа Хәсәния Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар турында исендә калганнарын матур хатирә итеп, сагынып сөйләргә ярата иде. Ул язучылар Зәйнәп ханымнарга килеп йөргәннәр, бер табында күңелле итеп чәй эчүләр, яңа әсәрләрен укып фикер алышулар Хәсәнияләр өендә бик еш булган.

Зәйнәп апа гомере буе бу дуслыкка тугры калып, аның якты хатирәсе белән рухланып яши иде. Г. Тукай һәм Г. Коләхметовларның беркайда басылмаган фоторәсемен, Г. Ибраһимовның хатларын саклап калган һәм аларны әдәбият тарихы өйрәнүчеләргә тапшырган кеше буларак та ихтирамга лаек иде ул.

Зәйнәп ханымны күреп белүче өлкән замандашлары һәм язучылар коллективы аның үлеме уңае белән тирән кайгы белдерәләр. Мәрхүмәнең бөек шагыйребез Г. Тукайга бәйләнышлы якты исеме ихтирам белән күңелебездә озак сакланыр.

———◆———

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,**

**Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,**

**Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 16/I-1967 ел. Басарга кул куелды 13/III-1967 ел. ПФ 09011. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 58246 экз. Заказ М-106. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# «СОҢГЫ ХАТ» ДРАМАСЫННАН

## ЗӨҺРӘ ҖЫРЫ

**ХӨСНУЛ ВӘЛИУЛЛИН** музыкасы

**ХӘЙ ВАХИТ** сүзләре

1

Чыгасың да Идел ярларына,
Сөяләсең бөдрә талларына.
Чал Иделнең таңкә дулкыннары
Тәгәрәп килә синең алларыңа. } Ике тапкыр
Трал-лял-лял...
Дулкын, дулкын йөрәк хисләремне
Сибәр идем синең алларыңа.







2

Чыгасың да урман аланына,
Сокланасың шомырт, баланына.
Кошлар моңына кумелеп шаулый урман } Ике тапкыр
Яфраклары коя алларыңа.
Трал-лял-лял...
Яфрак түгел, йөрәк хисләремне
Сибәр идем йөргән юлларыңа.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

(ОГНИ КАЗАНИ)

# КАЗАН УТЛАРЫ

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210